# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Ләбиб ЛЕРОН. Ятим сабый булып, мин ул елыйм... *Шигырьләр.* ....3
Шамил ИДИАТУЛЛИН. Тубагач. *Хикәя. (Л.Әбүдәрова тәрҗемәсе.)* ....8
Әлфия СИТДЫЙКОВА. Ялгызлык диңгезе упкындай... *Шигырьләр.* ....20
Рафис КОРБАН. Артык кешеләр. *Роман-эссе.* ....25
Лениза ВӘЛИЕВА. Мин инде мин түгел шикелле... *Шигырьләр.* ....93
Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Иблис коткысы. *Кыйсса.* ....98

ДӨНЬЯ ХАЛЫКЛАРЫ ӘДӘБИЯТЫ

Рәсүл ГАМЗАТОВ. Син йолдыз булып балкыйсың, Ватан! *Шигырьләр.*
*(Р.Корбан тәрҗемәләре).* ....138

«СЕЗ ИҢ ГҮЗӘЛ КЕШЕ ИКӘНСЕЗ!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Кәрим КАРА. ЧТД. *Хикәя.* ....142

ЯҢА ИСЕМНӘР

Гөлнур САФИУЛЛИНА. Ике бөртек. *Хикәя.* ....157

*Фотоархив*: Ләбибә Ихсанованың тууына – 100 ел,
Венера Ихсанованың тууына – 90 ел. ....164

2023 ЕЛ – ДАСТАННАР ЕЛЫ

Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА. Янә дә «Идегәй» хакында. ....166
«Идегәй» дастанының Александр ХОДЗЬКО тарафыннан язып алынган варианты. ....167

ЮБИЛЕЙЛАР

Әнвәр ШӘРИПОВ. Яшьнәп узган гомер. *(Рүзәл Юсуповка – 85 яшь).* ....173

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ләйлә ДӘҮЛӘТШИНА. «Шагыйрә күңел тәрәзәсен ача» *(Фәүзия Солтан иҗатына бер караш).* ....179

ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП

Аяз Гыйләҗевнең Марсель Галиевка язган хатлары. ....184

ГАЗИЗ ТАВЫШЛАР

Ул заманда опералар милли иде. *(Нияз Даутовның тууына – 110 ел).* ....188
Акчалардан тарих сөйләтте. *(Әзһәр Мөхәммәдиевнең тууына – 90 ел).*
*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире Нәсим АКМАЛ алып бара.* ....189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ

*№ 9 (1211) 2023*

*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**

*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**

*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**

*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**

*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**

*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*

Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---


Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.08.2023, график буенча 29.08.2023, басылып чыгу вакыты 05.09.2023
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-2296. Тираж 5595.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.

12+

© «Казан утлары», 2023 ел



Ләбиб
Лерон

# ЯТИМ САБЫЙ БУЛЫП, МИН УЛ ЕЛЫЙМ...

## Илаһи көн

Әйтерсең лә, төнлә нидер булып,
Бөтен нәрсә кинәт үзгәргән:
Кояш кебек балкый һәрбер  кеше –
Нур сибелә һәммә күзләрдән!

Шатлык белән тулган бөтен дөнья –
Кайгы-хәсрәт гүя юк сыман.
Шәфәкъ дөрли күңел офыгында –
Йөрәгемдә янган ут сыман!

Сөттәй ап-ак болыт ага ургып –
Әйтерсең лә, томан ертылган...
Төш вакыты. Серле, илаһи моң –
Кайтып барам иман йортыннан.

Йөзеп барам галәм диңгезендә –
Маяк булып яна ярымай...
...Күз тимәсен берүк – ай күк балкып,
Каршы алган сөйгән ярыма...

## Яз һәм Син

Яз миңа ашкынамы соң,
Мин сиңа ашыгаммы? –
Син – бу Вакыт дәрьясыннан
Җыр булып ташыган Моң!

Ләбиб ЛЕРОН (1961) – *шагыйрь, прозаик, драматург; Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Сине генә сөям», «Сөяксез тел», «Бәхеткә биш минут кала» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Кайчакта

Тиктомалдан шатланамын кайчак
Һәм юктан да күрәм матурлык...
Кодрәт тоям кайчак үземдә мин
Дөньяларны айкап кайтырлык...

## Рауда. Пәйгамбәр кабере янында

Җанда нидер сызган кебек,
Канда нидер йөзгән кебек, –
Һич аңлатып булмас бер хис
Үзәгемне өзгән кебек.

Бу – ни халәт: өнме, төшме,
Аягүрә йоклавыммы?! –
Тоям, сизәм үземнең мин
Күз яшьләрсез егълавымны.

## Иләт

Бүген дә – күгемдә, күңелдә – тынгысызлык.
Сызыла, сузыла, сөзелә таңгы сызык.

Мин яшим. Мең яшим: мең яшем – чарасызлык.
Буталма: бу таңга бу тамга – кара сызык.

Кара син: кара сын карашын – бөркет-мәче! –
Озакка йозакка – тозакка беркетмәкче.

Нишләргә – исәргә, исәнгә – хыял-аһы?!
Бары Син барысын барлыйсың, и Аллаһым!

Мин яшим. Мең яшим, мең яшем – таянычым!
Бүгенем – күңелем, түгелер аянычым...

...күренер Таянычым.

## Нур тавында

Кемнәргәдер – якын ара,
Кемгәдер – ерак нокта...
Нур тавы бу – Әл-Хәрамнан
Дүрт чакрым ераклыкта.

Рәсүлебез Мөхәммәднең,
Үзенә куыш табып,
Пәйгамбәрлек килгәнче үк
Гыйбадәт кылган тавы.

И мәгърур биеклекләрнең
Мәңгелек хәятләре!.. –
Шушында иңгән Коръәннең
Иң тәүге аятьләре.

Җәбәләннур дип тә атап
Йөртәләр аны монда.
Без дә булдык ошбу тауда –
Һира куышлыгында.

Менүе авыр булса да,
Ак ният-уйлар илә
Күтәрелдек тау башына
Юлдашым Илдар белән...

И Мәккаи Мөкаррәмә,
И бөек таулар иле! –
Иманы нык, юлы туры,
Калебе саулар иле!

Киңәя Мәккә, киңәя –
Тауларны кисә-кисә...
Кайнар җилләр искән мәлдә
Дәрдемәнд искә төшә:

«Шаулый диңгез... Җил өрәдер...
Җилкәнен киргән кораб...»
Догаңны укы, и инсан,
Кәгъбәгә туры карап!

Кысылып куя сулышың –
Тын җитмәс кебек була...
Һәм кинәт көч пәйда булып,
Йөрәккә кереп тула.

И Нур тавы – Җәбәләннур,
И сүнмәс Яктым минем:
И сөекле Пәйгамбәрем,
И бөек Раббым минем!

## Әл-Куба мәчете

Борын-борын заманнан ук
Төшәдер аның уты...
Ислам дөньясындагы бу –
Иң тәүге Аллаһ йорты!

Мәдинәгә күчеп килгәч,
Ташларны үзе тотып,
Рәсүлебез төзешкән һәм
Төзеткән Аллаһ йорты!

Изге Коръән аятендә
Әйтелгән бу турыда:
«Син намаз укырга лаек
Нәкъ менә шул урында –

Аның ризалыгы өчен
Һәм дә ки Аннан куркып».
Әҗерен алырсың – ике
Рәкәгать намаз укып.

Шөкер, димен, безләргә дә
Килергә язган монда...
...Рәсүлебезнең эзеннән
Йөртә күк азан-моңнар...

## Мәхәббәт турында шигырь

Һәр тарафтан шигырь карый көлеп,
Һәммә җирдән шигырь елмая! –
Яннан узып барган җил-сылуны
Шигырь диеп кочтым мин бая.

Һәммә җирдән шигырь исе килә,
Шигырь аңкый һәрбер тарафтан...
Муза булып, илһам булып килә,
Шигырь үзе килә пар атта!

Юк, кош түгел, шигырь оча күктә,
Чишмә түгел, шигырь ургыла...
Гөл-чәчәкле якты киләчәккә,
Шигырь булып, мин ул ыргылам!

Һәр тарафтан шигырь карый көлеп,
Һәр тарафтан шигырь елмая...
...Сөю тулы минем йөрәгемә
Шигырь булып уздың син бая...

## Кышкы көз

Кичәгедән юк бер аермасы:
Бүген дә шул яңгыр, шул ук кар...
«Көзме соң бу, кышмы?» – дигән сыман
Шомыраеп баскан шомыртлар.

Ничәмә көн карлы яңгыр ява...
Көз шәүләсе – Казан өстендә.
Кар яудырып, бер агартыйм, дисәң,
Җитмәс кебек хәтта өч көн дә.

Ничәмә көн шул ук бер күренеш.
Эңгер-меңгер. Суык. Җепшек кар.
Сыенышып, карт һәм малай килә.
Бозлы миләш чукый чыпчыклар...

## Мин – орлык

Бу дөнья гел тетрәнүдән тора –
Сынаулардан тора кешелек:
Бәндәләрне кырып китә бер чир,
Икенчесе килә ишелеп!

Бу дөнья гел тетрәнүдән тора –
Күпме сынау килә кешегә...
Чишмә корый, елга-сулар кибә,
Таулар булып таулар ишелә.

Аллаһ һәркөн сынауларын бирә:
Сугыш, зәхмәт, бәла-казалар...
Берәүләргә байлык биреп сыный,
Берәүләргә бирә – җәзалар.

Минем халкым күпме кайгы кичкән –
Тарих аны мәңге онытмый...
...Ишелергә торган тау – мин түгел,
Тишелергә торган орлык мин!

## Кояшсыз көз

Кояшсыз көз. Томан.
Пыскып-пыскып,
Әллә шәфәкъ, әллә көн яна...
Ак һәм кара тәмам буталышты –
Хәтәр заман килде дөньяга.

Кояшсыз көз. Болыт.
Күзне кисеп,
Әллә төтен, әллә көн ява...
Адәм балалары буталышты –
Хәтәр заман килде дөньяга.

Кояшсыз көз. Салкын.
Дертләп-дертләп,
Әллә гомер, әллә төн ага...
Хәсрәт белән шатлык буталышты –
Хәтәр заман килде дөньяга.

Кояшсыз көз. Курку.
Сүнеп-сүнеп,
Әллә өмет, әллә ил яна...
Ялган белән яман буталышты –
Хәтәр заман килде дөньяга.

Гел-гел болай булмас дөньякайлар,
Кояшлы яз килер бер вакыт...
И Аллаһым, кансыз бәндәләргә,
Мәнсез мәхлукларга бир акыл!

## Ничек кеше булып калырга?

Пыскып сүнгән мәлдә өметләрең,
Инде онытылгач – шат чагың,
Матур кәнфит кәгазенә төреп,
Ялган өләшкәндә чат саен,
Чарасызлыктан син сыгылганда,
Тыгылганда күзең яшьләргә...
Ничек алга таба барырга соң,
Ничек алданмыйча яшәргә?

Төрле яктан янау янаганда,
Төрле яктан әләк яуганда,
Төшләреңә өнең кергән чакта,
Өсләреңә афәт ауганда,
Ничек итеп исән калырга соң,
Каян көч-дәрт, куәт алырга?
Эткә әйләнүе җиңел дә бит,
Ничек кеше булып калырга?
Котырына исәрләнгән давыл,
Ничек каршы торыйм мин аңа?..
...Ятим сабый булып, мин ул елыйм
Һәм күз яше булып, мин агам.

## Көннәрнең үксегән чаклары...

Дөньяның күк йөзе чатнады –
Көннәрнең үксегән чаклары.
Ил күген сөремнәр каплады –
Беркайчан бетмәс күк таплары.
Кайдадыр очкычлар егылды,
Кайдадыр тимерләр сыгылды.
Кайдадыр йорт-җирләр ишелде,
Кайдадыр гомерләр киселде.
Ятимнәр, үксезләр ишәйде,
Афәтләр, кайгылар ешайды...

...Кайдадыр кемнәрдер шау итте,
Кемнәрдер тормышны яу итте!
Дөньяның күк йөзе чатнады –
Ил-көннең саташкан чаклары.
Кемнәрдер догалар ятлады,
Кемнәрдер сагаеп атлады.
Берәүләр барыр юл тапмады –
Туп-туры үлемгә атлады.
Берәүләр китте дә... кайтмады,
Аларның ал таңы атмады.
Йа Хода! Бирсәнә сабырлык!
Йөрәктә – тау кадәр авырлык!
Ил күген сөремнәр каплады –
Һичкайчан бетмәс күк таплары!
Көннәрнең саташкан чаклары...
Күпләрнең адашкан чаклары...
Кемнеңдер байлыгы ишәйде,
Кемнеңдер түбәсе кыйшайды...
Туктатчы бу мәхшәр-афәтне –
Тилертмә халыкны бу хәтле...

Барсын да Син күреп торасың –
Соңгы сүз Синеке, и Раббым!

## Үлгәннәр терелеп кайтсалар...

Никадәр агачлар янгыннан
Күмергә әйләнә, көл була...
Көн саен һәлакәт-яулардан
Кешеләр өзлексез кырыла!..

Йа Раббым! Бу мәхшәр-афәтләр
Бетәрме кайчан да булса бер?
Чәчәктәй гомерләр өзелә! –
Бәндәгә кайда да юк кадер...

...Күмергә әйләнгән агачлар
Беркөнне шау чәчәк атсалар...
Әгәр дә, могҗиза булып бер,
Үлгәннәр терелеп кайтсалар?!

Бу... соңгы орышта үлгәннәр...
Терелеп, әгәр дә... кайтсалар?!
– Әнием! Мин бит бу – улың! – дип,
Бикләнгән ишекне каксалар?!

Тәрәздән тәрәзгә йөрсәләр,
Ишекне ачтырып керсәләр...
Уллары терелеп кайтканын
Бичара аналар күрсәләр...

Мондый зур шатлыкка чыдармы,
Түзәрме аларның йөрәге? –
Йа Раббым! Бу – аның улымы?
Түгелме кемнеңдер өрәге?

Төшендә ничәмә мәртәбә
Бәйләде улының ярасын...
Төшендә ничәмә мәртәбә –
Йа Раббым! –
Коткарды үлемнән баласын!

Чынлап та, бу – аның улымы?
Бу аның кулымы – кочаклый?!
Йа Раббым! Әллә бу – саташу,
Әллә бу тилерү шулчаклы?!

Шатлыктан еларга иде дә...
Еларга... Тик чыкмый күз яше...
Каршында – сөекле баласы...
Тик нигә, нигә ул сүз дәшми?

Йа Раббым! Никләр дип анага
Бирдең Син бу сынау-кайгыны? –
Кояшы юк хәзер, җанын тик
Яктырта бары шул ай гына...

Йа Раббым! Бу җиргә нигә дип
Бирдең Син гарасат-давыллар? –
Һәркайда – хәрабә-шәһәрләр,
Хәрабә-агачлар, авыллар...

Һәркайда – өшәнгән кешеләр...
Учлардан саркыла аһ-ваһлар...
Кайдадыр җил булып уһылдый
Кабёрсез кадерсез әрвахлар...

...Күмергә әйләнгән агачлар
Әгәр дә шау чәчәк атсалар...
Йа Раббым! Ни дияр иде, дим,
Үлгәннәр терелеп кайтсалар?!



## Шамил Идиатуллин

# ТУБАГАЧ

хикәя

Төне буе яшенле яңгыр койды. Бөтен күк йөзен ямь-яшелгә буяп, телеп-телеп яуды да яуды. Ә иртәнгә тубагач үсеп чыккан иде. Башта аны өлкәннәр күреп алды, аннан соң бу турыдагы хәбәр Ситикала малайларына килеп иреште, иң соңыннан Булгакка мәгълүм булды. Ул иртәдән үк корабын төзәтеп маташкан иде.

Булгак тыны бетеп, аланга йөгереп килеп җиткәндә, ыгы-зыгылы чират икенче әйләнешен ясый иде инде. Буй-буй булып сорылы-яшелле төскә буялып беткән ыштаннары белән терсәкләренә караганда, малайлар чиратта икенче, кайберсе өченче тапкыр тора иде булса кирәк. Булгакка да тубагачны бер тапкыр күрер өчен егермеләп минут көтәргә туры килде.

Ул ботаника дәреслегенә төшерелгән рәсемдәге кебек иде: юан, тәбәнәк, уртачарак буйлы бер кешегә куеп санасаң, кеше ярым чамасы биеклектә. Кайрысы көмешсыман, кәкре-бөкре, сирәк ботакларында яфраклары вак һәм йомры, ә очы кырт киселгән кебек. Җирән Борхе агач башына «әһ» дигәнче менеп җитте: аягын ботакка куйды, бармаклары белән кайрысыннан эләктерде дә бер-ике генә сикерде һәм менә ул агач башында. Чират чинап җибәрде, ә Борхе дусларына сәлам бирде дә солдат рәвешендә агач эченә кереп чумды – әйтерсең лә коега сикереп юк булды. Тубагачның ботакларын сизелер-сизелмәс кенә итеп салындырып, шыгырдаганы бөтенесенә дә ишетелсен өчен шау-шу тынып калды. Аннан шакылдаган тавыш ишетелде – һәм Борхе батуттан сикергән кебек, аяк-кулларын тырпайтып, кәүсәдән очып чыкты да үлән өеменә килеп төште. Чират янә гөж килә башлады, Борхе, буялып беткән йодрыкларын төйнәп, сикереп торды да барысын да уздырып кычкырып җибәрде. Һәм шунда ук торып, янә чиратка барып басты.

---

Шамил ИДИАТУЛЛИН (1971) – *язучы, журналист; ике тапкыр «Большая книга» премиясе лауреаты. «Город Брежнев», «Бывшая Ленина», «До февраля» һ.б. китаплар авторы. Мәскәүдә яши.*

Тубагачка юан гәүдәсе белән Бо үрмәли башлады. Ә чиратның бу башындагы малайлар үлән өемен аяклары белән генә агачтан читкәрәк күчерергә тотындылар.

Булгакның чираты җиткәндә, тубагач ике тапкырга үсәргә өлгергән иде инде: астагы ботагы мәктәп турнигы биеклегенә җиткән. Аның алдында торган Андерс – мускуллары нык, сары чәчен рәвешен китереп тараган малай – җитез генә сикерде дә тартылып алды һәм ике дигәндә, агач эченә кереп тә чумды.

Булгак боларны коты алынып карап торды. Турникта тартылырга ул тәки өйрәнә алмады, ә физик әзерлеге буенча билгесен өстәмә рәвештә ике кросс биреп алды. Булгак йөгерергә ярата иде, йөгерә белә дә иде ул. Әмма монда алай гына булмый шул – агачка йөгереп түгел, сикереп менәргә кирәк.

Тубагач шыгырдап куйды һәм тонык кына бер тавыш чыгарды. Андерс йолдыз булып атылып чыкты да үлән эченә төшеп күмелде һәм, шатлыгыннан көлә-көлә, шунда бераз яткан булды. Булгак тәвәккәлләргә куркып, кәүсәгә таба атлады, өскә карады һәм сикереп кенә менеп җитә алмаячагын аңлагач, башмагы белән кайрының киң ярыкларыннан терәк эзләп, шуыша башлады.

– Менәмесең? Менмимесең? – дип сорадылар арттан.

Булгак каушап китте, шулай да аякларын тиз-тиз шудырып үрмәләргә тырышты. Әмма бу гына ярдәм итмәде. Хәзер куып җибәрәчәкләр, дип уйлады ул.

– Тотынып, – диделәр арттан.

Булгакны ян-якларыннан эләктерделәр дә ботакка аттылар. Ул ботакка теше-тырнагы белән ябышты да хәзер нишләргә инде дип уйлады. Шул ук көчле куллар Булгакның табаныннан этеп җибәрде һәм ул, үзе дә аңламастан, бөтен күкрәге белән ботакка ятты. Һәм авыртудан ыңгырашып куйды, аягын күтәреп алды да ботакка атланып утырды, куллары белән икенчесенә ябышты һәм саклык белән генә торып басты. Аяклары калтырый, башында нәрсәдер дөп-дөп тибә, эчен суык алды. Астан мыскыллап кына, үзеннән олырак Абэ белән Аксак карап тора.

– Рәхми, – дип пышылдады Булгак.

– Үрмәлән тизи, – диде Абэ.

Булгак эчендәге һавасын чыгарып бетерде дә, терсәкләрен сыдыра-сыдыра, эчен тырный-тырный, үрмәләп менеп китте. Ул өскә менеп җиткәч кенә, калтыраган аяклары белән кара тишек тирәли тигезсез бөҗра буйлап атлаганда гына тын алды. «Бәрелеп үләчәкмен бит, – дип уйлады ул, коты алынып, – йә аягымны сындырырмын, яки аңымны җуярмын да шул килеш очып чыгып, җиргә кадалырмын». Аста барысы да аңа карап тора. Булгак өметсезлеккә бирелеп, өйләре тарафына бер карап алды да, учларын ботларына куеп, тишеккә чумды.

Куркуы очышына караганда озаграк булды бугай. Тишек Булгакны бик йомшак кабул итеп алды, гүя калын мамык катламы өстенә килеп төште. Ул аның авырлыгыннан шыгырдап җыелып килде. Ул арада Булгак торып утырды, тотынырга җай эзләп, кулларын җәйде, бармакларын юеш мүккә батырды һәм, ялгыш кына шуннан учына лайла чумырып алып,

йодрыкларын корсагына җыйды да колак тондыргыч чатнаган тавышка очып чыгып китте.

Тубагач Булгакны почмактан аткан туп кебек итеп туп-туры күккә, күпереп торган болыттан сулгарак чыгарып бәрде. Йөрәге боз кебек каткан эченә егылып төште дә яңадан тамак төбенә сикерде, ачуы башына китереп бәрде: нишлисез сез, ахмаклар, хәзер бәрелеп үлсәм, җавап бирәсегез була бит!

Һәм шунда бәхет ишелеп төште.

Булгак секундның бер мизгеленә генә күкнең кыл уртасында рәхәт итеп катып калды һәм, көлүеннән тончыгып, чәчләрен йолыккалаган, күзеннән чыккан кайнар яшьләрен шундук бозга әйләндергән калын җилне ертып килеп төште. Үлән өеменең нәкъ уртасына.

Булгак еш-еш сулыш ала башлады, кулларын як-ягына ыргытты һәм әле генә үзе белән булган хәлләрне – очышын һәм, авырлыгын югалту халәтен исенә төшереп, көлеп җибәрде.

Төштәге кебек, тик куркынычрак һәм рәхәтрәк.

– Торың, юкса хәзер Аксак өстеңә төшеп сытачак, – диде Абэ.

Аксак инде тубагачның очына ук менеп җиткән.

Булгак сикереп торып, чират койрыгына чапты. Тик чиратның койрыгы юк иде. Аның урынына күңелләре төшкән малайлар гына тубагачка күз терәгәннәр дә зарланышалар:

– Ну Хасаныч, ну, әйди бер генә, без бит тизи генә.

Хасаныч дәшми, кулында пычкысын әйләндергәләп, мыек астыннан гына көлеп тора. Үзе Абэ артында торган берничә малайны күзәтә. Алар бәхетле – алар тагын бер сикерәчәк.

Булгак авыр сулап куйды. Хасанычны үгетләүнең мәгънәсе юк, моны барысы да белә.

Кеше гомеренә һәм сәламәтлегенә куркыныч яный торган агач буларак, тубагачның йөз ел элек үк тыелганлыгы турында да барысына да мәгълүм. Берничә көн эчендә ул элемтә мачтасыннан да биегрәк булып үсте дә орлыкларыннан оешкан төшләрен һавага төкерә башлады. Аның тирәсендәге берничә чакрым күк йөзе яшел төстәге лайлалы пәрәвезне хәтерләтә иде. Кораб оча алмый, кеше үтә алмый, тончыгып үләргә мөмкин. Аннан соң тубагач ничек тиз үссә, шундый ук тизлектә корый башлый, үз авырлыгын үзе күтәрә алмыйча ава да пычрак черек онына әйләнеп кала.

Шуңа да тубагачларны бетерергә кирәк – баш төртүгә яки бераз үсә төшкәч. Ситикала советы тубагачка өч метр биеклеккә кадәр үсәргә рөхсәт бирә. Менә бусы шушы биеклеккә кадәр үсеп җитте диярлек.

– Тизрәк, – диде Хасаныч, һәм бәхетлеләрнең соңгы икесе – Брюс һәм Бэнки, бер-берсенә булыша-булыша, аскы ботакка үрмәләделәр. Апулей менеп тә җитмәгән иде әле. Калганнар, өметсезлеккә бирелеп, тагын да катырак зарланышырга керештеләр.

Хасаныч Бэнкиның кәүсә эченнән очып чыкканын көтте дә, тантаналы кычкырып, пычкысын жуылдатырга тотынды. Тубагач шыгырдап алды һәм тамак кыргандай тавыш чыгарды да тынып калды.

Кичкә таба ул ботаклары корып, эче куыш, алтынсу төстәге яңгыравык

бер бүрәнәгә әйләнәчәк. Шуннан киләчәкләр дә тураклап, такта яру заводына алып китәчәкләр.

Малайлар таралыша башлады. Мыгырданган тавышларны «Ә мин бөтенегезгә караганда да шәбрәк очтымай, күрдеңмәй?» дип, бер-берсен бүлдергән кычкырышулар күмеп китте.

Булгак тубагачка якын ук килеп, аның тәмам көмешләнгән кайрысын сыйпамакчы булды. Күр син аны, әле һаман йодрыкларын төйнәгән килеш йөри икән. Йодрык эчендәге лайла кипшергән, яшелләнеп, ярмаланып тора. Булгак башта кулын селкеп кенә киптермәкче иде, әмма ни өчендер сак кына итеп, ярмаларны җыеп алды да электермәле кесәсенә салып куйды.

Һәм мәктәпкә чапты. Соңга кала язган лабаса.

– Аңлавымча, чирекне тагын алып килмәгәнсең, – диде Галина Джоновна. – Бу юлы нәрсә: оныттыңмы, өлгермәдеңме, заряд җыя алмадыңмы?

Сыйныф шаркылдап көлеп җибәрде.

– Кораб ватылдый, – дип пышылдады Булгак.

– Чөнки теманы башкалар кебек Кайту өчен хезмәт әзерлеге буенча алырга кирәк иде. Синең шул булыр инде: мәңге шул фантазияләрең, мәңге шул гал... – дип башлаган иде Галина Джоновна, туктап калды. – Ярар. Димәк, башка уенчыклар калмады, барыбызга да тынычрак булыр. Теоретик эшен эшләрсең. Бүген Михалычка бар, интервью ал да Кайту турында доклад әзерлә. Ике минутлык гомуми телдә сөйләгәндә. Авыр сулама, пүчтәк кенә бу. Без иншаның кереш өлешен дә озынрак яза идек. Күргәзмәгә куярбыз. Ике көн сиңа, югыйсә төп табельгә «икеле», аңладыңмы? Нәрсә булды?

Булгак, эчтән сулкылдап:

– Михалыч куркыта, – диде.

– Курыкма, мин аңа әйтеп куярмын, – дип тынычландырды Галина Джоновна. – Ул сиңа бөтенесен дә сөйләп бирер. Дәресләрдән туп-туры шунда барырсың, аннан соң миңа күрсәтерсең. Соңгы «өчле»ңне «бишле»гә төзәтермен.

– Рәхми, – дип мыгырдады Булгак.

– Рәх-мәт! Күпме әйтергә була инде? Мәктәптә булса да, кешечә сөйләшегез әле, үзегезчә пупаламыйча гына.

– Без түгелмени кешечә? – дип аптырады Бо.

Галина Джоновна авыр сулап куйды.

– Менә Йортка кайткач, сез үзегезнең «Сәмс, рәхми, әйдәк»ләрегез белән килеп тә чыгарсыз – бөтенесе кычкырып көлә дә башлар. Үтенеп сорыйм – китап укыгыз. Аңлыйм, кыендыр, тик шулай да...

– Ә кайчан кайтаз? – дип сорады Булгак, тәвәккәлләп.

Бөтен сыйныф, аңа карап, телсез калды. Галина Джоновна да аңа текәлгән. Шулай күпмедер торгач, ул, ниһаять, елмаеп җибәрде һәм:

– Ну Булгак! Оныттыңмыни? Безне орбитада «Мәңгелек» көтә. Мәгълүматлар туплап, хезмәт әзерлеген төгәлләүгә – кузгалачакбыз. Ни өчен кузгалачакбыз?

– Йортны Бәхетле итәр өчен! – дип, ятлаганны кабатлады бөтен сыйныф.

Булгак та баш какты, шулай да кабатлап сорарга булды:

– Ә... кайчан?

– Тәк. Дәрес күптән башланды инде. Өй эше буенча җавабың бармы? Шулай дип уйлаган идем инде аны. Бар алайса, урыныңа утыр. Дәресләрдән соң Михалыч янына, ике минут. Дүртенче бүлекне ачабыз, төп битне: «Урмандала полосасында исән калу юллары һәм аяк астында булганнардан азык табу».

Михалычны мәктәп укучылары яратмый иде. Ә Булгак бөтенләй курка аннан. Былтыр малайлар белән корабны якыннанрак күрергә дип төшкәч, Михалыч аларны кычкыра-кычкыра, артларыннан чүбек ыргыта-ыргыта куды. Булгакның арт чүмеченә эләкте ул вакытта. Авыртмады, әмма күңелгә тиеп калды. Михалыч аны хәтерләп калган булса? Мәктәпкә җиткерер. Яки үзе тотып, колагын бора башласа? Һәм моның өчен аңа берни дә булмаячак. Бердәнбер кораб белән идарә итә белүче бердәнбер очучыга кем каршы әйтә алсын?

Булгак тәвәккәлләде. Ул киртә аша шуып кына үтте дә кыюсыз гына Михалыч янына килеп басты:

– Сәмс.

Михалыч җавап биреп тормады, хәтта кымшанмады да. Ул ишегалды уртасында очучы кәнәфиендә утырып тора иде. Кәнәфи астында атыныр өчен таганнары да бар. Ләкин Михалыч атынмый. Ул күккә баккан.

Булгак кырый күз белән генә Михалыч артындагы озын сарайга карады. Сарай тубагачның урталай ярдырылган алтынсу бүрәнәләреннән төзелгән иде. Ангар иде ул. Ангарда кораб тора. Булгакның аны ике тапкыр Ачылу Көненә тәгәрәтеп алып чыкканнарын күргәне булды. Бәлки, Михалыч кабинага кереп утырып карарга да рөхсәт итәр әле.

Михалыч һаман күккә караган килеш утыруын белә. Күз дә йоммый диярлек. Булгакка да әһәмият бирми. Булгак урынында таптанып алды да Кайту планы турында беләсе килүен әйтте, Галина Джоновна кушты, диде. Галина Джоновна турында өченче тапкыр кабатлагач, Михалыч түбәннән генә йөзгән болытлар арасыннан күренеп калган яшькелт яктылыктан күзен алмыйча гына сүз башлады:

– Кайту – бик гади ул. Төп план: «Мәңгелек»кә төяләбез дә Җиргә, ну, сезнеңчә әйтсәк, Йортка очабыз. Монда очып килгән кебек үк: хәтта очучыларның да кирәге юк, «Мәңгелек» үзе алып барачак, хәзер көткән кебек. Ике сикереш, егерме тәүлек. Очып килүгә болай дибез: Йорт, бүләк итеп Бәхетлене ал, дөресен генә әйткәндә, бөтен Галәмдәге иң яхшы планетаны. Анда җылы, су, һава бар, хәтта черкиләр дә юк. Черкинең ни икәнен беләсеңме?

– Ю-ю, – диде Булгак. – Ә кайчан?

– Нәрсә кайчан? Җәй көне алар очалар, тешлиләр, кан эчәләр. Соңыннан кычытып интектерә.

– Ю-ю, – дип кабатлады Булгак. – Кайчан соң ул Кайту?

– Ну, кораб очып киткәч. Ничек уйлыйсың, кайчан очар икән?

Булгак җилкәсен генә сикертте. Михалыч:

– Ну, бар, кара инде, алай акыллы булгач. Бар-бар, ачык анда. Ябып куюдан ни мәгънә...

Булгак ышанырга да, ышанмаска да белмичә, артына борылып карыйкарый, шырпылы икәнлекләре ерактан ук күренеп торган капкаларга таба атлады. Ни гаҗәп, алар җиңел һәм тавышсыз гына ачылып китте.

Капка артында кораб тора – зур, ак төстә. Ул гүя чүгәләгән дә күккә сикерер алдыннан кулларын җәйгән кебек. Булгак аның салкынча каты һәм шома борыныннан кулын шудырып, канатына таба китте һәм Михалычка ялварулы караш ташлады. Бәлки аңлар да кабинага ук үтәргә рөхсәт итәр? Бәлки рульгә утырып карап булыр? Хәтта очып карарга да ярар – биек түгел, ишегалды өстеннән генә.

Михалыч:

– Кабинага ук менәсең дә киләдер әле? – дип сорады.

Булгак, «әйе» дигәнне белдереп, баш какты.

– Мен алайса, – диде Михалыч.

Булгакның йөрәге сикерергә кереште, бая тубагачтагы кебек итеп. Ул, ашыга-ашыга, кораб ишеген эзләргә тотынды – дәреслектә люк икенчерәк урында иде. Озынча түгәрәк ишек кырыйгарак күчкән. Булгак сискәнеп китте, Михалычка кырын күз белән генә карап алды да кораб эченә кереп югалды. Бусагада абынып, аягын авырттырды. Корабның эче зур икән, сыйныф бүлмәсе кадәр, караңгы бүлмәдә сәер генә урнаштырылган кәнәфиләр... Михалычныкына охшаган, бераз кечерәк кенә. Булгак аларның берсенә утырып карады, аннан – икенчесенә, әмма, мөһим эше исенә төшкән кебек, сикереп торды да очучы кабинасына кереп китте. Ни өчендер ул ачык иде.

Кабинада капитан кәнәфие юк иде, аның урынында үткәргечләр тырпаеп тора. Үткәргечләр панельләрдән дә асылынган, дәреслектә анда утлар янарга тиеш дип сурәтләнгән, ә монда тонык һәм тузанлы. Булгак үтә күренмәле пыяла белән капланган зур кызыл төймәдән күзен алмыйча гына  икенче очучы кәнәфиенә утырды. Ул, колакларын торгызып, сак кына башка төймәләргә дә баскалады, идарә итү тоткычын боргалады, ниндидер тәрәзәләргә, экраннарга төрткәләп чыкты. Төчкерде һәм кәнәфигә аркасын терәп утырды, аны бәхет һәм горурлык хисе биләгән иде.

Ул чын корабның очучы кәнәфиендә утыра. Малайлардан берсенең дә анда утырганы юк әле, ә менә ул – утыра! Һәм, әгәр теләсә, реакторны кабызыр иде дә шушы корабта «Мәңгелек»кә таба очар иде.

Булгак кулын кызыл төймәдән алды, тирән итеп бер сулады да Михалыч янына чыкты. Кораб яныннан киткәндә, аның шома яныннан тагын бер сыйпап үтте.

Михалыч аны күрде бугай, гәрчә элеккечә кебек күккә төбәлеп утырса да.

– Сыйпарга гына калды инде хәзер. Тишекне күрдеңме? Үткәргечләр тырпаеп торамы? Анда реактор иде. Хәзер юк ул анда. Шуңа да күпме телисең, шуның кадәр сыйпа.

Булгакка бу сүзләр ошады.

Ул елмайды да:

– Кайчан Кайту була? – дип сорады.

– Беркайчан да, – дип җавап бирде Михалыч.

Булгак уйга калды. Аннан соң:

– Галина Джоновна миңа доклад...

– Галина Джоновнаның ничек итеп ул һәм башкалар, сез йомыркалардан чыксын дип, корабтан реакторны салдырып алганнарын исенә төшер әле. Чөнки, имештер, балаларсыз булмый, үзләре дә таба алмый, ә балаларсыз

бәхетле – яшәү түгел, имеш. Бу дөньяны тагын кемгә... Исенә төшер әле аның, ничек итеп ул минем лачынның йөрәген йолып алды да инкубаторга тыгып куйды, йомыркалардан сез чыксын дип. Лачын урынына чебешләр. Аннан соң сезгә соядан – яки нәрсәдән анда тагын – кәтлитләр булсын дип... Сез булмасагыз, күптән очар идек инде – юк шул, аларга тамырлары белән ябышырга кирәк иде! Аннан соң реактор ватылды, инкубатор ватылды. Шуңа да сезнең малайлар гына, бер генә кыз да юк. Һәм сезнең Бәхетлегездә берәү дә бер генә кеше дә тумаячак, хәер, моңа кадәр дә туmаган, ә аннан соң без бөтенебез дә үлеп беткәч, һәм сезнең Бәхетлегез дә...

– Мин кеше, – диде Булгак. Ул барысын да аңлап бетермәде, шуңа да төгәллек кертергә теләде, юкса Михалыч күп сөйләп ташлады. Иң мөһиме, колакны гына бормасын.

– Кеше син, – диде Михалыч, беренче тапкыр Булгакка карап. – Ну алай кеше булгач, кешечә булсын: укы, эшлә, йолдызларга мен. Йолдызларга кадәр үк кирәк тә түгел, стратосферага кадәр дә җитә. Скафандрда эвакуация режимын кабызасың да, «Мәңгелек», югары орбитадан түбән орбитага төшеп, сине үзенә тартып ала. Скафандрны хәзер үк алсаң да була, мәктәбегездә тулы бер склад алар, бөтен үлчәм дә бар. Кызганыч, сиңа болар кызык түгел. Кирәк тә түгел.

«Кирәк», – дип уйлады Булгак, хәтта уйлаганын әйтмәкче дә булды. Михалыч кулын гына селтәде:

– Кызганыч, самолёт юк. Самолёт та кирәкми стратосферага җитәр өчен. Монда тәбәнәк ул. Һава шары да җитәр иде, стратостата берәр төрле. Әмма алары да юк бит. Гелий да юк. Водород та. Лабораторияләр дә. Аның каравы балалар бар. Шуннан...

Михалыч, ниһаять, Булгакка таба борылды, һәм болытлар арасындагы яктылыкка бармагы белән төртеп күрсәтеп:

– «Мәңгелек»не күрәсеңме? Әнә тегендә эленеп тора, күрәсеңме? Күрмисең, билгеле.

– Күрәм, – диде Булгак.

– Нәрсә күрәсең? – дип, түбәнчелекле итеп сорады Михалыч.

– Ут яна. Зәңгәрсу.

Михалыч башын күтәрде дә күккә төбәлде. Аның күзләре кысылган иде, хәтта сул күзеннән яссы гына яшь агып чыгып, җыерчыклары буйлап агып китте. Аннан соң Булгакка карады да:

– Нинди кеше буласың соң син, орбитаны күргәч? – дип мыгырданды.

– Мин – кеше, – дип кабатлады Булгак, еламаска тырышып.

– Кеше, имеш... Җиргә, ну – Йортка кайтасың килә, димәкче буласыңмы?

Булгак иреннәрен тешләде, шулай да «әйе» дигәндәй баш селекте.

– Нәрсәгә инде сиңа ул – Җир? – дип сорады Михалыч йомшак кына итеп диярлек. – Анда салкын, вулканнар, туфан, кешеләре дә күп. Чагыштырып карасаң, монда оҗмах. Ну, дөрес, кызлар юк инде. Тапалган кәтлитләр юк. Тик сиңа аларның кирәге дә юк бит.

Булгак кызлар белән тапалган кәтлитләрнең нәрсәләр икәнен ничек кенә хәтерләргә тырышмасын, һич тә исенә төшерә алмады. Ул «мин – кеше» дип тагын бер кабатламакчы иде, әмма үкереп елап җибәрүдән куркып тыелып калды. Ә Михалыч Булгакның ни әйтергә теләвен аңлады булса кирәк:

– Кеше икәнсең – бар, – диде.

– Кая?

– «Мәңгелеккә». Скафандр өченче складта, кайда икәнен беләсеңме? Менә. Әгәр кеше икәнсең, скафандр сиңа ярарга тиеш. Моннан ничек тә очып китү юлын табарсың. Укы, сораштыр, үзең берәр нәрсә уйла. Кеше – акыллы зат ул, алар уйлап чыгарырга маһир. Стратосферага кадәр, аннан соң үзеннән-үзе, аңлашылдымы? Бар, кеше!

Булгак киртәгә таба китте.

Михалыч аның артыннан:

– Ишетәсеңме, кеше? Мине дә «Мәңгелек»кә  аласыңмы соң?

Булгак уйлап торды да «Әйе», – дип, баш какты.

Өйгә кайтасы килми иде. Булгак мәктәпкә юл алды, барышлый тубагач янына кагылып үтте.

Тубагачның кайрысы саргайган, яфраклары алан уртасында нәрсәдер турында фикер алышып торган олылар өстенә коела. Булгак алар яныннан табан ялтыратмакчы иде – олы малайлар бала-чаганың аяк астында буталганын яратмый – әмма Абэның ничек итеп ярты көн буена казыгычын ремонтлаганы турында сөйләгәнен ишетеп алды.

Булгак кыюсыз гына алар янына килде дә:

– Егиләр, реакторны төзәтергә өйрәнеләбезме? – дип сорады.

– Ычкынып монна, – диде Аксак ялкау гына, әмма Абэ сәер тавыш белән сорап куйды:

– Нәрсәме?

Булгак ашыга-ашыга, нәрсәдән башларга белмичә бутала-бутала, корабның реакторы ватылуы, реактордан башка корабның очмаячагы, ә корабтан башка берәүнең дә «Мәңгелек»кә оча алмаячагы, ә «Мәңгелек»тән башка Йортка кайтып та, хәтта элемтәгә дә чыгып булмавы турында сөйләде. Булгакның беркайчан да болай озак сөйләгәне юк иде, киеренкелектән аның хәтта тамагы авырта, башы әйләнә башлады, әмма Абэ барыбер аны тыңлап бетермәде. Ул:

– Без гел монда. Килешергә кирәк, – диде.

– Төзәтергә өйрәнелик... – дип кабатлады Булгак, еларга җитешеп.

– Нәрсәне, нәрсә белән, – диде Абэ. – Реактор тузан түгел, принтер тузан түгел, полимерлар юк, металлар юк, уран юк. Һава бар, алмалар бар, су бар, соя, үлән. Тубагач бар әнә. Килеш тә яшә.

– Ә Йорт?.. –  дип пышылдады Булгак.

– Ә Йорт – бездән башка гына. Без – синнән башка. Ычкынып монна.

Абэның ачуы чыккан иде, шуңа да Булгак тизрәк мәктәпкә йөгерде.

Галина Джоновна урынында иде әле. Булгак хәзер үк эшен эшләп тапшырырга теләвен әйткәч, зарланмады. Булгак китапханәгә кереп утырды, редакторын кушты һәм бер дә ялгышмыйча диярлек Кайту турындагы докладын сөйләп яздырды. Укытучылар ачуланмасын өчен сөйләмен дөресләп чыкты. Укытучылар Кайтырга комачаулый торган проблемалар турында әйткәнне яратмыйлар, шулай да Булгак докладының ватык реактор турындагы өлешен калдырырга булды. Бары тик аңа Михалыч әйткәннәрне генә өстәп уйды: кеше ничек итеп очып китәргә икәнлеген уйлап чыгарырга тиеш, шуңа да без һичшиксез юлын табачакбыз.

Ахыры әйбәт килеп чыкты, Булгак хәтта сөенеп куйды.

Ул эшен Галина Джоновнага илтеп бирде, тегесе мактады һәм кичке ашка соңламаска кушты. Булгак исә туп-туры өченче складка китте.

Склад өченче дип атала, гәрчә азык-төлек белән машиналар саклана торган ике склад күптән юк инде: машиналар ватылып бетте, ә азык-төлекне Ситикалада үзләре үстереп, үзләре әзерлиләр иде. Өченче склад белән берәү дә кызыксынмый, аның кыяфәте үк кызыксынырлык түгел иде – тәбәнәк, соры һәм ямаудан гына тора. Аның каравы ишеге яңа: ак һәм шома. Тоткасыз.

Булгак кыюсыз гына ишеккә кагылды, этеп карады – әмма ишек селкенмәде. Булгак анда сизелер-сизелмәс рәсем күреп алды – әйтерсең кемдер анда бармакларын тырпайтып, кул рәсемен төшергән. Булгак сак кына учын рәсемнең уртасына куйды. Рәсем зәңгәр төскә кереп алды. Ишек кырыйга күчте. Караңгылыктан Булгакка тузан һәм салкынча һава исе бөркелде.

Ул, тәвәккәлләп, эчкә үтте. Ут кабынды. Тирә-якта әллә нинди аңлашылмый торган тартмалар һәм төргәкләр белән киштәләр тезелгән. Скафандрларны ул бүлмәнең түреннән табып алды. Алар бик күп иде, Ситикалада яшәүчеләр санныннан да күбрәк.

Һәрбер скафандр эчендә ике зур ташы булган капчыкка охшаган. Булгак стенадагы плакат булмаса, кайсын алырга белмәс иде. Анда кирәкле үлчәмдәге скафандрны ничек табарга, сүтәргә һәм ничек кияргә икәнлеге күрсәтелгән иде.

Булгак аңа тиз ияләште, шулай да ыштаннарында буталып, егыла язды һәм берничә секунд башын шлемга түгел, ә түгәрәк букчага тыгарга азапланды. Ул скафандрны эләктереп бетерергә дип, күкрәген сыпырды. Һәм скафандр ысылдап алды, бераз кабарды һәм җиңеләеп калды. Аны кигән килеш атлавы җиңел түгел иде, өстәвенә Булгакка шлемның кырыйлары күренеп тора, никтер алары да куркыта.

Хәзер малайлар янына чыгып мактансаң да булыр иде, әмма алар тагын, мөгаен, Булгакны төрле сүзләр белән мыскыллар, гел аяк астында буталасың дип кычкырырлар кебек тоелды. Җитмәсә, «Кем беренче булып шлемны вата?» дип, ярыш та оештырулары ихтимал. Булгак скафандрын салып, пөхтә итеп төрде дә, бераз уйлаганнан соң, тагын берне алды. Ул ике капчыгын да мәктәп артындагы имәнчыршы астындагы яшерен урынга тыгып куйды һәм тирә-ягына карангалап алды. Берәү дә юк иде, бары тик мәктәптә генә кемдер хәлсез тавыш белән ямьсез итеп җыр суза. Булгакның музыкага колагы каты иде, әмма хәтта ул да җырның дөрес түгеллеген аңлап, елмаеп куйды.

Җыр укытучылар бүлмәсеннән ишетелә икән. Тәрәзә янында Галина Джоновна утыра. Бер кулына ул Булгакның эшен тоткан, икенчесе белән иягенә таянган. Ул җырламый, ә әрнеп елый иде. Һәм күккә карый. Бөтен малайлар ниндидер ут күргән якка карый, ә үзе ул утны күрми – никтер олылар күрми иде аны.

Минем аркада елый дип уйлады Булгак, һәм аңа оят булып китте. Ул Галина Джоновнаны өнәп бетерми иде, әмма хәзер аны юатасы килеп китте. Өметләндерәсе. «Мәңгелек»кә аласы.

Ничек аласың инде, кораб ватык бит, ә аннан башка очып китеп булмый. Әллә очып буламы?

Булгак эләктермәле кесәсен сыйпап алды һәм тубагачка таба йөгерде.

Такта яра торган завод платформасы килгән, Хасаныч һәм Ет Кам эшлекле кыяфәттә тубагачның алтын кәүсәсен чылбырлар, каешлар белән урап яталар. Булгак аларның күзенә күренмәскә тырышып, геометрия дәресендә өйрәнгәннәрен исенә төшерде дә тубагачның озынлыгын, биеклеген һәм проекциясен язып алып, китапханәгә чапты.

Ул китапханәдә бер атна утырды. Укыды, укыды, башы сызлый, куллары калтырый башлаганчы укыды. Ә кичерәкләрнең вакытында кичке ашны ашаулары өчен җаваплы булган олы малайлар Булгакны китапханәдән куып та чыгара алмадылар. Бервакыт Галина Джоновна аны агарып калган йөзе өчен ачуланып алды да башкаларга сөйләм теле өчен үрнәк итеп куйды. Брюс белән Бэнки Булгакка моның өчен йодрыкларын күрсәтте. Ә Булгакка барыбер иде.

Ул иң мөһим әйберне белде.

Үсеп җиткән тубагач орлыкларын стратосферага кадәр ата икән.

Тубагач өченче көнгә үсеп җитә, дүртенче көнгә таркала башлый.

Скафандрның коткару режимы стратосферада автомат рәвештә кабына.

«Мәңгелек» коткару режимындагы скафандр кигән космонавтны ун секунд эчендә мәҗбүри рәвештә эвакуацияли башлый.

Ранецлы двигатель стратосферада тулы куәтенә ярты минут эшли.

Кораб координаталары белән «Мин – Мәңгелек», ярдәм кирәк» дигән сигнал төп пульттагы сул рычагка күчергәч, Йортка «Барлык каналлар – СОС» төймәләре белән китә.

Булгак Капитал калкулыгы артына тубагач утыртты – бу урын Ситикаладан күренеп тормый, ә тимер җиләк җыючылар анда ылыслы мур кырылышыннан соң йөрми башладылар.

Тубагач тиз үсте, әйтерсең лә аны Булгак утыртмаган, ә яшенле яшел яңгырдан соң үсеп чыккан.

Булгак шунда ук аңа үрмәләп менде дә берничә тапкыр рәхәтләнеп сикерде. Тавыш-тын чыгармады, эчтән генә сөенде. Аннан соң аягы сыдырылгач, бөтен планнары җимерелер дип курыкты.

Икенче көнне ул сикермәде, ә ике скафандрын да алып килеп куйды, баудан баскыч үрде.

Төнлә Булгак тубагач янына мәктәптән урлаган янгын балтасын алып килде һәм таңга кадәр диярлек, арудан һәм эше бармавыннан елый-елый, каты тамырларны чапты. Чөнки калкулык битенә утыртылган тубагач өскә түгел, ә ян-якка карап үскән иде. Шуңа да өченче көнне ул Булгакны зенитка түгел, ә Юләр урман чытырманлыгына атар иде, ә аннан җиңел генә котылырмын, димә. Бигрәк тә скафандр кигән көе.

Булгак балтаны урынына кайтарып куйды, мәктәпкә барды, йокысын туйдырды һәм икенче көнне мәктәптән соң озакка дип, калкулыкка китте. Ул тубагач утыртасы мәйданны тигезләде, орлык бөртеген кадерләп кенә алды да йомшартылган җиргә утыртты һәм бер сәгатькә якын шул урынны сыйпаштырып утырды, әйтерсең лә үсентегә, соңыннан сабакка, соңыннан кәүсәгә бары тик өскә генә үсәргә дип юнәлеш бирә иде. Бары тик өскә таба.

Ниһаять, Булгак тыелып кына көлеп җибәрде, агачка аягы белән ялгыш тиеп китмәс өчен ераккарак тәгәрәде һәм чалкан карап, бик озак ятты. Бөтен дөнья асты өскә килгән кебек болай. Дөнья аша ашыкмый гына күккә көмеш үрмәли – әллә геройлар кылычы, әллә йолдызларны тоташтыра торган торба шунда.

Булгак берничә өем үлән әзерләп куйды, әмма, өскә – яшькелт төсле күктәге зәңгәр ноктага туры сикерәчәгенә инаныр өчен бер генә тапкыр сикереп карады.

Өченче көнне Булгак тубагач янына иртән иртүк килде.

Тубагач тагын да биегәйгән, Ситикаладагы теләсә кайсы бинадан биегрәк, элемтә мачтасыннан аз гына тәбәнәгрәк булган. Булгакның баскычны беренче көнне үк аскы ботакка бәйләргә башы эшләмәгән, хәзер менә ыргытып та буй җитәрлек түгел. Кайрының калын ярыкларына тотынып үрмәләргә туры килә. Алай авыр да, куркыта да, өстәвенә, аркага аскан скафандрлы капчык йә билгә бәреп авырттыра, йә Булгакны да йолкып алырдай булып болгана. Шактый биек үрмәләгәндер инде. Тикшереп карыйсы килми иде.

Өскә дә карыйсы килми. Арды Булгак, муены да авырта.

Ул каршындагы көмешсу ярыкларга карап үрмәли дә үрмәли. Менә дә менә. Баш түбәсе аскы ботакка килеп терәлгәнче шулай менде ул.

Булгак еш-еш сулап, корсагы белән ботакка ятты, ял иткәч, торып утырды. Тагын бераз ял итте дә алга таба китте.

Алга таба җиңелрәк иде инде.

Бик үк юан булмаган ботакка басып, агачның шома түбәсенә тотынган килеш скафандр кию җиңел эш түгел. Шулай да Булгак бирешмәде.

Ул курсны дөресләр өчен кулларны ничек җыярга һәм гәүдәне кайсы якка авыштырырга икәнлеген тагын бер хәтереннән үткәреп, һава сулап торды да тубагачның түбәсенә сикерде. Таеп китте, чактан гына мәтәлеп төшмәде, шулай да тигезлеген кайтара алды һәм ашыгып, тубагачның кара авызына чумды.

Тубагачның ябышкак эче аны шундук эләктереп алды, колакларны тондырырлык итеп кыштырдатып, шыгырдатып һәм шапылдатып, төпкә өстерәде, ул да булмады, тавыш эче сызгыруга күчте, бу сызгыру, аның эченә боз тулгандай, куырып алды. Һәм аякларына китереп сукты.

Булгак очып китте.

Ул курстан тайпылудан куркып, өскә карады: анда зәңгәр йолдыз яна. Аска карады: анда – калкулык артында Ситикала. Бигрәк бәләкәй икән ул, ә икенче яклап, офыкка кадәр Юләр урманның инәле яшел күбеге җәйрәп ята. Урман зурая бара, Ситикала – бәләкәйләнә. Ә өстәге күк йөзе караңгылана һәм салкыная бара, хәтта кыяфәте белән үк.

Менә атмосфераның өске катламнары. Биредә һава алай ук тыгыз түгел, хәзер очарга җиңелрәк булачак, дип уйлады Булгак һәм әкренәюен сизеп алды. Стратосферамы икән әле бу, юкмы?

Ул кычкырып, унга кадәр санады, ләкин скафандр һаман да коткару режимын кабызмый, «Мәңгелек»тән җавап юк, ә тизлек кимегәннән-кими иде.

Булгак үзенең очамы, әллә эленеп торамы икәнлеген дә аңламый иде.

Булгак, йодрыкларын төйнәп, янә «Бер! Ике!» дип башлады һәм күкрәгендә бушлык тоеп алды. Менә ул авырлык югалу халәте, күрәсең, ул космоска җитмәгән әле. Һәм ул кычкырып җибәрде, бармаклары белән ракета букчасын тизләтелгән режимга күчерде. Бу космостагы авырлык югалу халәте түгел, ә физика дәреслегендә өскә чөелгән ташның иң югары ноктасындагы халәтен тасвирлаганга охшаш бер халәт иде. Таш туктап кала да аска төшә башлый. Булгак та егылырга тиеш иде, тик ни гаҗәп: ул өскә таба оча.

Хәзер ул, зәңгәр йолдызга ялварып карап, утызга кадәр санады. Ну, «Мәңгелек» дип пышылдады ул, унике, ну, үтенеп сорыйм, унөч.

«Егерме бер»гә җиткәч, күз алдында «Коткару режимы» дип язылган кызыл ут янды һәм ул тизрәк очкан кебек була башлады. Өлгерәм, дип уйлады Булгак, «Мәңгелек» белән очрашырга әзерләнеп. Егерме өч! Егерме дүрт! Ну, менә хәзер, хәзер! Егерме алты! Әйдә инде!

Мөгаен, Булгак артыгы белән әкрен саныйдыр. Букчадагы ягулык «егерме сигез»не санаганда бетте – нәкъ шул вакытта күз алдында «Мәңгелек» мәҗбүри эвакуация элемтәсе» дигән зәңгәр ут кабынды.

Булгак янә авырлык югалу халәтендә туктап калды, ул хәтта күзен йомарга да курка иде. Шуңа да зәңгәр утның ниндидер саннар баганасын һәм таныш түгел символларны чыгарып, юкка чыгуын күрми калмады.

Һәм Булгак егылды.

Дөресрәге, яңадан түбәнгә оча башлады.

Бәхетлегә кадәр озак очасы иде әле, коткару режимына куелган скафандр парашют системаларын кушу һәм төшеп утыру ноктасын табу өчен вакыт сайлый-сайлый, аска таба очышны тоткарлый. Ә Булгак кычкыра, ачулана һәм елый иде. Ул инде башка беркайчан да бу әкрен кыймылдаучы каһәр суккан «Мәңгелек»кә очмаска, үзе белән Михалычны да, Галина Джоновнаны да алмаска ант итә иде. Беркайчан да, беркемне дә.

Булгак Юләр урманның кырыендагы имәнчыршының куе ябалдашына төшеп кунды да вак ботаклар һәм корыган яфраклар өстенә шуып төште. Күпмедер вакыт ул тузан болытына һәм ерактагы зәңгәр йолдызга таба күтәрелеп очкан коры яфракларга карап ятты.

Шуннан авырлык белән генә торып утырды, скафандрыннан чыкты, исәнлеген тикшереп, үзен чеметкәләп алды да офыкта тырпаеп утырган тубагачка таба китеп барды. Башта әкрен генә атлады, аннан соң адымнарын тизләткәннән тизләтә барды. Кичке ашка кадәр, агач башына менеп, «Мәңгелек»кә кадәр очып барып җитәргә кирәк иде.

*Русчадан* **Ландыш ӘБҮДӘРОВА** *тәрҗемәсе.*



Әлфия
Ситдыйкова

# ЯЛГЫЗЛЫК ДИҢГЕЗЕ УПКЫНДАЙ...

## Җилләр исә

*Уйный-уйный таң алдыннан әкрен генә*
*Җилләр килеп, тәрәзәмне кагалар да:*
*«Син уйлыйсың, шашкан кеше?» –*
*Диләр дә алар*
*Тагын бик тиз югалалар далаларга.*
Һ.Такташ

**I**

Күз дә йоммый яткан чагым мендәремдә,
Җилләр тынгы бирми ярсу йөрәгемә.
«Акылыңнан язгансың син, җүләр хатын!»
Байгышмы соң, хәбәр сала тирә-юньгә.
Кап-караңгы төн пәрдәсе тәрәзәмдә,
Тулган ай да качкан болыт арасына.
Ялгызлыкның кочагында ятам арып,
Күзләремне манып төннең карасына.

**II**

Керфекләрдә тамчы-тамчы яңгыр мәллә,
Аңлый алмыйм, әллә инде таң чыгымы?
Уем белән актарам мин серләр тулы
Хәтер дигән гаҗәеп зур янчыгымны.
Әнә минем күкрәгемә башын салып,
Таң калдырган ярты җаным йоклап ята.
Яңа гына җәйгән идем урын-җирне,
Кай арада алсуланып таңнар ата.

**III**

Уйнама, җил, тәрәз чиртеп, чү, уятма,
Йокласын ул, ә мин менә черем итмим.
Багам йөзен, сыйпыйм кара чәчләреннән,
Кояш нуры кызартканчы күкнең читен.

---

Әлфия СИТДЫЙКОВА (1957) – *шагыйрә; С.Сөләйманова, И.Юзеев исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Утлы җимеш», «Тансык бәхет», «Яктылык сулышы» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

Танымасын таң тугачтын мине дөнья:
«Күр, яшәргән!» – дип соклансын әле күреп.
Хатын-кыз ул терек суы эчкән төсле,
Мәхәббәте назлар белән алса төреп.
Төн тынлыгын сискәндереп бала елый,
Күкрәгемә сөт төшкәнен сизә бугай.
Сөеп алам аны кайнар кочагыма,
Күңелемдә сайрый былбыл, әллә тургай.
Бишек җырын минем белән бергә көйли.
Сабый туеп, изрәп кабат йоклап китә.
Кошлар җырын тыңлап ятам тын да алмый,
Сәгать теле минут саный, вакыт үтә.

**IV**

Таң да атты. Ай да батты. Кояш чыкты.
Һәм күмелде бөтен җиһан якты нурга.
Тик ятакта мин ялгызым, ярым кайда,
Төн пәрие алып киткән кайсы чорга?!
Төштә генә булган мәллә сихри мизгел,
Әллә бу соң саташумы акыл җуеп?!
Шашкан кеше ялгызлыкның куенында
Төш күрәме өндә килеш, төннән туеп.

**V**

Күктә кояш балкыса да, җанда, томан,
Уйный-дулый җилләр исә, тапмый тынгы.
Үткәннәргә әллә язмыш, әллә ялгыш
Бикләп куйган инде күптән кайтыр юлны...

## Шакыма...

*Эч пошыргыч китапны ябып куя,*
*күңелсез киноны ташлап чыга, кадереңне*
*белмәгән кешеләрдән китә белергә кирәк.*
Александр Грин

Шакыдың йөрәкне, шакыдың...
Ишеттем ялгызлык тавышын.
Шашыныр чикләргә җиткерде
Тәкъдирдән язылган сагышым.

Ялгызлык диңгезе упкындай
Гел тартты, һай, тартты үзенә.
Күзләргә кергәндә куркыта
Күз салу парлылык йөзенә.

Беркем дә яңадан табалмый
Тормышта югалткан бәхетен.
Патша да меналмый кабаттан,
Җуйса тик бер тапкыр тәхетен.

Бер агып киткән су дулкыны
Кабаттан тибрәтми беркемне.
Гомерлек яр итеп язмышың
Таклыкка бәйләсә иркеңне.

Парлашып типми шул йөрәкләр,
Яралар гел тоташ кан гына.
Тиң ярын сагынып күкрәктә
Сыкрана талчыккан җан гына.

Күзләрдә бөрегә күмелми
Алмасын бер койган алмагач.
Тиз генә тонмый ул елга да,
Шашынып ташудан болгангач.

Күңелнең кыллары нечкәргәч,
Хәлсезлек басканда йөрәкне,
Гомернең кышына кергәндә
Ашкыну, ярсулар кирәкме?!

Тын гына аккан бер елгадай
Тынлыкка көйләнгән дөньяма
Кагылма, берүкләр кагылма...
Моң тулы сагышка буяма.

Рәнҗемә, берүкләр каргама,
Юксынма, мин сиңа тиң түгел.
Беркемгә берекмәс хыялый,
Ирексез иректе уй, күңел.

Мин көткән хис түгел синдә дә,
Яңадан язылмый язмышлар.
Минем дә, синең дә йөрәктә
Югалту яздырган сагыш бар.

Буйсынмас җан миндә, шакыма,
Шакыма йөрәгем ишеген.
Сөюең түгел лә, бары тик
Ялгызлык тавышын ишеттем.

## Көтеп яшим

Сөенәсе килә, сөеләсе,
Бердәнбере булып берәүнең.
...Кулың суздың, гомер буе эзләп,
Арып типкән чакта йөрәгем.
Мин сөюнең төсен җуйган идем,
Онытылган хәтта тавышы.
Ничә еллар ялгыз гына үткән
Гомеремнең моңлы агышы.
Таштан түгел минем җан да юкса...
Сыңар канат арып талчыккан.
Ачыкканнар белә икмәк тәмен
Татып тары кебек валчыктан.
Мыскал белән үлчәнгәнме әллә
Язмышыма сөю өлеше?!
Җәйге челләдә дә җаным боздай
Ничә туңды, ничә өшеде.
Ничек итеп ышандыра алыйм
Алдау-йолдау күргән күңелне.
Йөрәгеңне ачып көткән ярга
Түгелмичә яшәү җиңелме?!

Син – даланың горур бер бөркете,
Кыятаудан сикереп төшәрлек.
Синең белән бәйләп куйсам әгәр
Өнем белән бергә төшләрне
Үкенмәмме, үкенмәссең микән,
Ялгыш булмас микән язмышлар?!
Икебезгә уртак булалырмы
Аерым-аерым язган сагышлар.
Шикләнүләр теләдә бәгыремне,
Рәнҗетүдән куркам үзеңне.
Шуңа күрә синнән көтеп яшим
Ныклап әйткән төпле сүзеңне.
Яраланган ике йөрәк бергә
Тибә алырмы соң бер булып?!
Агар микән калган гомерләрдә
Бәхет-чишмә суы ургылып?
Бал кортлары кебек шушы уйлар
Гүләп тора минем башымда.
Шуңа куркам, яшерен хыялларым
Бу тормышта чынга ашудан.

## Бәхетле була күр!

Ялгызлык яздырган көйләрне
Тыңлавы авыр ул, беләмен.
Төн озын. Кыскартыр өчен мин
Хыялда яныңа киләмен.

Йокысыз төнеңне бизәргә
Сөйлимме башымнан кичкәнне?!

Онытырсың сагышлы чишмәдән
Кушучлап тозлы су эчкәнне.

Чаларган чәчеңнән сыйпармын,
Үбәрмен иркәләп битеңнән
Елмайгач, сөенеп ал кояш
Күз сирпер офыклар читеннән.

Бәхетле була күр, үтенәм!

## Дәшә алмадым

Көтмәгәндә юллар кушылды да,
Син хуш күрдең мине үзеңә.
Мин дә сине бик тиз якын иттем,
Сагыш яши иде күзеңдә.
Ни әйтсәң дә, йөрәгемә язып
Куя бардым һәрбер сүзеңне.

Өметкә юл ачкан өчен сиңа
Көнбагыштай бордым йөземне.
Мәтрүшкәләр эзләп, нәфис кулым
Әремнәргә һәрчак юлыкты.
Бөтен килеш сиңа җанны шуңа
Бәйләп куяр өчен курыктым.

Мең мәртәбә алданды саф күңел,
Җиләк диеп, балан капканмын.
Төн йокымнан калып, ничә еллар
Көттем сөю ишек какканын.
Арып беткәч ишегемне түгел,
Йөрәгемне килеп шакыдың.
Япа-ялгыз яшәвемнең җирдә
Баса алырсыңмы шаукымын.
«Түрдән үт!» – дип дәшәр өчен сиңа,
Әйләнмәде телем нигәдер.
Гомер көзләренә кергән чакта,
Төшенсәм дә, син ул – бердәнбер.
Тупас кулы белән ныклап тоткан
Итәгемнән шыксыз ялгызлык.

Котсыз авызы сөйли: «Без яшьлектән
Салкын утны бергә кабыздык!»
Ялкын түгел, суык теле белән
Чагып җанны гомер буена
Озата бармак була, каһәр суккан,
Мине соңгы гомер туена.
Иң зур теләгедер мәхрүм итү
Якты, кайнар, тансык сөюдән.
Ләззәтләнә җылы таба алмый,
Тәкать бетеп, канат көюдән.
Миһербансыз, кансыз ялгызлыктан
Йолып алчы, зинһар, җанымны!
Гомер кышын бергә каршыларбыз
Һәм корырбыз сөю табыны.

## Кичердем...

Син – табыш! Син – ялгыш! Син – сагыш!
Туганчы тәкъдиргә язылган.
Син мине аердың кыш булып,
Хыяллар иленнән, язымнан.
Җәйләрне күрмәдем. Күземне
Күк томан каплады, адаштым.
Яралы күңелдә яшәде
Әрнүле моң тулы карашың.
Озынмы, кыскамы гомернең
Юллары берьялгыз үтелгән.
Синең дә, минем дә очасы
Канатлар ялкында өтелгән.
Нәрсәдер исбатлау идеме
Исрафка үткәргән гомерләр.
Без икәү тергезгән учактан
Өелеп калды тик күмерләр.
Кабынмас яңадан бер сүнгәч,
Кузлары әйләнгән көлләргә.
Кайтыплар булмый ул әйләнеп
Бер узган елларга, көннәргә.
Кая соң күпләрнең күзләрен
Кыздырган шәп егет, мин белгән?
Яшиме дастанга күчеп ул,
Өзелеп халыкның теленнән?
Әллә соң онытылган көй булып
Төшәме исенә кемнеңдер?
Бәлки ул җаннарга көч биргән
Шиңмәслек мәхәббәт гөледер?!
Яисә сыздыргыч[1] шикелле
Күңелнең кылларын чиртәме?
Әллә соң таңнарда былбылдай
Уята кояшлы иртәне?!
Яисә йолдызлы төннәрдә
Балкыймы күктә ул ай булып?

[1] Сыздыргыч – скрипка смычогы.

Керәме тәрәздән өйләргә,
Өр-яңа җыр сыман ургылып?
Мең төрле уй телә бәгырьне,
Белмимен, кем булып яшисең.
Җил генә искәндә китерә
Яныма яшь исен, яшь исен.
Ул синең күзләрдән тамганмы,
Әллә соң йөрәгең түреннән.
Бәлки син тилереп, тилмереп
Өзелгән ялгызлык чиреннән.
Юктыр ла, ышанмыйм, китмәссең,
Мине бер күрмичә яңадан.
Давыллап, тузаннар туздырып
Кырык ел үтсә дә арадан.
Төннәрне йокысыз үткәрәм,
Моң шакый бикләнгән ишекне.
Минутлар, секундлар санаган
Тавышны йөрәгем ишетте.
Бәлки ул нәкъ синең яралы
Йөрәгең тибеше булгандыр.
Хәбәрдер бәлки син кайтуга,
Син инде күптәннән юлдадыр.
Адашкан сукмаклар буйлатып,
Әйт әле, ни уйлап атлыйсың?!
Юл сорап дәшәсең микән соң
Күргәндә җәяүле, атлысын?
Чакрымнар үткәндә, кулыңда
Бар микән таяныр таягың?
Утырып хәл җыю җаен бер
Таптыңмы арганда аягың?!
Юлларың озындыр, ураудыр,
Гомерең буена сузылган.
Теләгем, очрасын Хозыр карт,
Җитәкләп алырга кулыңнан.
Гомернең ахыры җиткәнче,
Очрашу көтәм мин язмыштан.
Без генә түгел бу дөньяда
Бер-берен танымый ялгышкан.
Ялгышны була ул төзәтеп,
Исән-сау булганда икең дә.
Каргыштан пәрдәләр кормасаң
Һәм корым сөртмәсәң битеңә.
Син миңа гомерем буена
Җитәрлек сагышны эчердең.
Бәхиллек бир миңа киткәнче,
Мин сине күптәннән кичердем.

Рафис
Корбан

# АРТЫК КЕШЕЛӘР

РОМАН-ЭССЕ

5

Шамил Усмановтан үзләре теләгән мәгълүматларны ала алмагач, аның троцкийчы-зиновьевчы оппозиционерлар төркемен оештыручы булуын фаш итүгә ирешмәгәч, аның урынына яңа лидер эзләп табарга һәм сындырырга кирәк иде. Ул кеше, әлбәттә инде, Усманов кебек үк партиянең фидакарь көрәшчесе, массаларны әйдәп бару сәләтенә ия булган чын ленинчы булырга тиеш. Һәм андый кеше бар. Ул – Галимҗан Ибраһимов!

Салих Галимҗан абыйсын шулай ук Шиһап җизнәсенең алар гаиләсенә кушылган көненнән башлап белә. Әле малай чагыннан ук күп мәртәбәләр аның белән очрашканы, хәтта җизнәсе алып биргән рояльдә уйнап, аның мактау сүзләрен ишеткәне булды.

Ибраһимов белән очрашуларның иң күбе Кызыл Байракта үтте. Ул Идел аръягындагы буш яткан җирләрдә татар авыллары оештыру идеясен хуплап чыккан кешеләрнең берсе иде. Кызыл Байракка ял итәргә еш йөрде. Аның ял дигәне иҗат итү иде. Язучылар өчен махсус салынган йортларның берсендә ул үзенең «Казакъ кызы» романын язды, «Безнең көннәр» романының яңа вариантын эшләде. Соңыннан Кырымга киткәч язган әсәрләрендә, бигрәк тә «Тирән тамырлар» романында, шушы тирәләрнең табигатен, кешеләрен сурәтләде.

Галимҗан Ибраһимов, Октябрь инкыйлабы җиңсен, совет власте ныгысын өчен бөтен тырышлыгын куйган, белемен һәм сәламәтлеген биргән кеше. Аны совет хөкүмәтенә каршы троцкийчы-зиновьевчы оппозиционерлар оешмасының Казандагы бүлеген төзүче дип гаепләр өчен НКВД җәлладларына бөтен сәбәпләр бар. Ул үзенең революцион эшчәнлеген Мәскәүдәге Мөселман Комиссариатында Мулланур Вахитовның урынбасары буларак башлаган иде. Вахитов ак чехлар тарафыннан үтерелгәч, аның урынына Мирсәет Солтангалиев билгеләнә. Милли мәсьәләләрдә Сталин белән уртак тел тапмаган Солтангалиев 1923 елда инде большевиклар партиясенең милли мәсьәләләргә багышланган киңәшмәсендә кискен тәнкыйть утына тотыла. Ул үзе һәм аның

*Ахыры. Башы 7, 8 нче саннарда.*

тарафдарлары «солтангалиевче»лектә гаепләнеп эзәрлекләнә башлый. Заманында Солтангалиевнең урынбасары булып эшләгән Галимҗан Ибраһимовны шушы чылбырның бер буыны итеп күрсәтү бер дигән табыш иде. Җитмәсә, инкыйлабка кадәр эсэрлар партиясендә булган кеше.

Казаннан НКВД солдатлары Ибраһимовны кулга алырга 1937 елның 29 августында килделәр. Яңгырлы, салкынча көн иде. Ялтадан Симферопольгә алып барып, шуннан ул этап белән Казанга озатылырга тиеш иде. Вокзалда аны дүрт сәгать буе яңгыр астында басып торырга мәҗбүр иттеләр. Хатыны Гөлсем аерылып киткәч, соңгы елларда аны өйдәш хатын Хәдичә карап, тәрбияләп торган иде. Хәдичә комитетчылардан Галимҗанны Казанга хәтле озата барырга рөхсәт итүләрен сорады.

– Мин бит авыру, үпкә чиреннән интегәм. Нигә мине, операция кичергән кешене, болай яңгыр астында тотасыз? – диде Галимҗан.

– Зонтигыгыз юкмыни? – дип, мыскыл белән җавап бирде конвоирларның башлыгы.

– Оятсызлар. Җир йотсын үзегезне.

– Башта – сезне, аннары гына – безне, – дип көлде начальник.

Дүрт сәгать үткәннән соң алар янына бер сержант килеп:

– Иптәш начальник, троцкийчы Ибраһимовның барлык милкен капчыкларга тутырып, товар вагонына китереп тапшырдык, – диде.

Аның өендәге бөтен китапларын, язмаларын, үзләре өчен кирәкле дип тапкан бар мөлкәтен Казанга алып кайтырга кушылган булган икән.

Аларның үзләрен дә товар вагонына, үз әйберләре янына утырттылар. Ике көннән соң поезд аларның вагонын Казанның Пләтән төрмәсе ишегалдына китереп калдырды.

Килгәндә, аның хәле начарланды, юл буе буылып йөткерде, температурасы күтәрелде. Аны шунда ук төрмә хастаханәсенә салдылар. Хәдичәне хастаханәгә кертмәделәр. Ул бернәрсәсез, көзге киемнәрдән урамда торып калды. Ибраһимов Кырымга киткән вакытта үзенең Казандагы дүрт бүлмәле фатирын, савыгып кире кайткач, яңасын бирерләр әле дип, хөкүмәткә тапшырып калдырган була. Урта Азия якларыннан килгән мескен Хәдичә Казанда яшәүче ерак туганнарын эзләп китеп барды. Икенче көнне дә, өченчесендә дә, аннан соң да аңа Ибраһимовның ни хәлдә булуы хакында берни дә әйтмәделәр. Шулай итеп, аларның юллары мәңгегә аерылды.

Берәр ай дәваланып, беркадәр аякка баса алган Ибраһимовтан сорау алулар башланды. Аның эше өлкән тикшерүче Селиванскийга тапшырылды. Аны хастаханә бинасында ук урнашкан сорау алу бүлмәсенә алып керделәр.

– Гаепләнүче Ибраһимов, үзеңнең Кырымда яшәп, троцкийчы-зиновьевчы корткычлар оешмасының Казан бүлеген оештырып ятучы булуыңны таныйсыңмы?

– Мин шуның өчен кулга алындыммыни?

– Әйтмәделәрмени кулга алган вакытта?

– Әйттеләр. Ләкин мин андый оешма барлыгын белмим һәм беркем тарафыннан да андый күрсәтмә алганым юк. Мин 1927 елдан бирле Кырымда дәваланып ятам.

– Син бу эш белән әле 1923 елдан бирле шөгыльләнгәнсең. Ул чагында сау-сәламәт булгансың.

– Мин ул чакта әле Татнаркомпросның Академик Үзәгенә җитәкчелек итә идем. Татарстанда нәшрият эшен җайга салу белән шөгыльләндем.

– Нәкъ менә шул вакытта троцкийчы пантюркист Мирсәет Солтангалиевкә үзенең кара эшләрен башкарырга ярдәм итеп йөргәнсең.

– Мирсәет Солтангалиевне, 1934 елда акланып, бүгенге көндә Саратов шәһәрендә яшәп ята дип беләм.

– Барысын да беләсең, барысыннан да хәбәрдар. Ә үзең юлбашчыңның март аеннан бирле Казанда Пләтән төрмәсендә кабат тикшерүгә ябылганын белмисең.

– Анысын беренче тапкыр ишетәм.

– Аның белән бергә синең ярдәмчеләрең Кави Нәҗми, Гомәр Галиләр НКВД изоляторында тикшерү үтәләр бу көннәрдә. Аларын да белмисеңме?!

– Аларын да белмим.

– Белмәсәң, бел: Кави Нәҗми сине үзләренең троцкийчы-зиновьевчы оешмаларының башлыгы дип язып бирде.

– Аның белән очраштыруыгызны телим. Нинди йөз белән карар икән ул минем күземә.

– Очраштырырбыз. Бездән калмас. Ә менә син үзеңнең гаебеңне танырга тиеш.

Шунда кинәт Ибраһимовның хәле начарланып китте. Ул йөткерә башлады. Үпкәсеннән авызына кан килде. Аны яңадан палатасына озаттылар.

Галимҗан Ибраһимов палатада тикшерүченең Кави Нәҗми турында әйткән сүзләрен уйлап ятты. «Чынлап та язды микән Кави мине троцкийчылар оешмасының җитәкчесе дип? Язган булса, үзе артыннан башкаларны да сөйрәргә мөмкин бит ул. Минем хәлне белергә дип күпме генә кеше килмәде бу елларда. Әле күптән түгел генә яшь язучылар исеменнән делегат булып Ибраһим Салахов дигән егет килгән иде. Ул алып килгән хатта ничәмә яшь язучының исеме бар. Тинчурин килгәләп торды. Егерме тугызынчы елның җәендә бер көтү артистлар, язучылар килеп, хәлен белешеп китте. Аларның барысын да шушы оешмага ябыштырып куйсалар?..

Хәле бераз җиңеләйгәч, Ибраһимовны камерага чыгардылар. Ләкин ул иң кырыс шартлардагы камера булып чыкты. Башка камералар тоткыннар белән дыңгычлап тутырылган булса, Галимҗанны кешеләр белән аралашмасын өчен ялгызын гына бикләделәр. Ашарга да онытканда бер китерәләр. Ачтан интектереп үтерергә телиләр иде булса кирәк. Тора-бара ул тәмам ябыкты, шыр сөяккә торып калды. Аптырагач, ул төрмә башлыгына гариза язарга булды. Аның Ялта саклык банкында егерме мең сумлап акчасы калган иде. Шул акча хисабына үзенә аерым ашату бирүләрен сорады. Ләкин гаризасына җавап бирүче булмады.

Октябрь инкыйлабының егерме еллыгын ул төрмә хастаханәсендә каршылады. Бу юлы аны үзе шикелле үк нык чирле һәм ярым сукыр, буржуаз милләтчелектә гаепләнеп, инде икенче тапкыр төрмәгә ябылган Садри Җәләл белән бер палатага салдылар. Садри беренчесендә 1931 елның 6 маенда ук кулга алынган иде. Шул ук көнне аның туганнан туган абыйсы Җамал Вәлидине дә милләтчелектә һәм совет хөкүмәтенә каршы

эшчәнлек алып баруда гаепләп кулга алып, Пләтән төрмәсенә утырталар. Җамал кыйнауларга түзә алмыйча, төрмә тәрәзәсеннән сикереп гарипләнә һәм озак та үтми вафат була. Ә Җәләлне биш елга ирегеннән мәхрүм итү хакында хөкем чыгарып, Беломор-канал төзелешенә җибәрәләр. Анда хөкем срогын тутырып кайткач, ике елдан соң тагын кулга алып, Пләтән төрмәсенә ябып куялар.

Галимҗан заманында Садрины да, Җамалны да буржуаз милләтчелектә гаепләп, мәкалә язган кеше. Ә хәзер алар икесе дә бер үк хәлдә, коммунист Ибраһимов та, ул тәнкыйтьләгән милләтче Җәләл дә – халык дошманнары.

Киеменнән хушбуй исе аңкып торган сержант кереп, Галимҗанга ниндидер төргәк биреп чыкты:

– Бүген бәйрәм. Подследственныйларга да бәйрәм паёгы бирелә, – диде.

– Хәлем бер дә юк, ачып кара әле, ниләр бар икән? – дип, Галимҗан төргәкне ачарга Садрига бирде.

Анысы, төргәкне чишеп, андагы әйберләрне күргәч:

– Төрмә паёгына охшамаган бу, – диде. Төргәктән чыккан тәм-томнарны ачып, Галимҗан алдына китерде. – Монда ниндидер язу да бар. Менә, үзең укы, минем күзем күрми, – дип, кулына дүрткә бөкләнгән кәгазь кисәген тоттырды.

Галимҗан хатны эчтән генә укып чыкты. Аны Галимҗанның яшьлек мәхәббәте Хәнифә язган иде.

– Хәнифәдән, – диде Галимҗан һәм авыр көрсенеп куйды. – Яшьлек мәхәббәтем иде. Яшьлек хатам. Үз гаебем белән бергә була алмый калдык. Хәзер үкенәм. Миннән авырга калган иде. Хатамны төзәтим, әйдә өйләнешик, дип сөйләшергә барсам, үпкәләп, Казанны ташлап, читкә киткән булып чыкты. Шуннан соң өйләнгән хатыным Гөлсем, авыруым көчәйгәч, унике ел бергә торган ирен, мине, ташлап, башка иргә чыкты. Рөстәм исемле улыбыз бар иде. Бәләкәй чагында ук үлде. Менә шул Хәнифә килгән хәлемне белергә, минем төрмәдә ятканымны белеп. Кертмәгәннәрдер инде үзен.

Ничек булгандыр, бәлки бәйрәм уңаеннан рөхсәт иткәннәрдер, Хәнифәнең үзен кертмәсәләр дә, китергән күчтәнәчләрен алып калганнар иде. Күренеп тора, төргәк чишелгән, әйберләрнең барысын да бирмәгәннәрдер, күрәсең. Шулай да ул Галимҗан белән Садри өчен бик зур бүләк булды бу бәйрәм көнендә.

1938 елның 21 гыйнварында Галимҗан Ибраһимов хастаханә койкасында дөнья белән бәхилләште. Үзенең шул көнне үләсен сизде бугай, өстендәге күлмәгенең түш кесәсеннән карандаш чыгарып, палатадагы өстәлнең тартмасы астына яза башлады: «Мин – татар язучысы Галимҗан Ибраһимов, халкым каршында минем бернинди дә гаебем юк. Моның шулай икәнен тарих күрсәтер. 21 гыйнвар, 1938 ел».

**6**

Мәскәүдән кайткач, Салихның иң юксынган кешесе Кәрим Тинчурин булды. Аның юклыгына һич ияләшәсе килми иде. Театрга керсә, «Килдеңме, Салих?» – дип, колачын җәеп, ул каршы алыр шикелле. Урамнан барганда да, каяндыр чаттан ул килеп чыгар кебек; йә артыннан

килүче кеше ул булып, гадәттәгечә шаяртып, иңенә кулын куеп: «Нәрсә борыныңны салындырдың, балтасы суга төшкән кеше кебек барасың?» – дип әйтер күк. Валясы үлгәч тә, бу кадәр боекмаган иде. Ике канатын кисеп аткан кош шикелле тилмереп йөри ул хәзер. Бер эшкә дә кулы бармый. Репертуардан икесе бергә эшләгән бөтен спектакльләрне дә алып атканнар. Радиодан җырлары яңгырамый. Дөньяның яме, яшәүнең кызыгы калмады. Тинчуринның халык дошманы булуы һич аңына барып җитә алмады. Ә бит үз араларындагы кешеләр, хезмәттәшләре, каләмдәшләре таккан шундый ярлыкны. Иң кызыгы, аны тәнкыйтьләгән кешеләрнең үзләрен дә ябып куйганнар. Фатыйх Сәйфи-Казанлы да, Кави Нәҗми дә халык дошманнары икән.

1937 елның сентябре. Тинчуринның әле бер дустын, әле икенчесен халык дошманы дип, Черек күлгә алып китеп торалар. Гомәр Гали, Кави Нәҗми, Шамил Усманов, Галимҗан Ибраһимов... Бу ни хәл бу? Һич акылга, башка сыя торган нәрсә түгел. Октябрь инкыйлабының егерме еллыгы якынлашканда, һәр тармакта эшне әйдәп баручы белгечләрне «халык дошманы» дип алып китәләр. Язучылар, артистлар арасында гына түгел, партия, совет оешмаларында да шул ук хәл. Инде кичә Галимҗан Нигъмәтине дә алганнар. Тинчурин үзенең утлы таба өстендә йөргәнен аңлый иде инде. «Миңа да чират җиткәндер, мине генә тынычта калдырмаслар. Туфан йөри дә, Бурнаш йөри, мин йөрим».

Кәрим шуларны уйлап утырган мәлдә ишеккә шакыдылар.

– Кем булыр икән бу вакытта, төнгә каршы? Тукай әйтмешли, «и пычагым кергере...» – дип сукрана-сукрана, Заһидә ишекне барып ачты.

Ишек төбендә биш егет басып тора иде.

– Кәрим Тинчурин биредә яшиме?

– Биредә, – диде дә, Заһидә бүлмә ягына карап: – Кәрим, сине чакыралар, – дип кычкырды.

Кәримнең миен: «Килделәр...» дигән уй көйдереп узды.

Ул арада «кунаклар», Заһидәнең рөхсәтен көтеп тормастан эчкә үттеләр дә Кәрим бүлмәсенә үк килеп керделәр.

– Кәрим Тинчуринмы?

– Әйе, мин.

– Җыеныгыз, сез кулга алынасыз.

– Ни өчен?

– Анысын тикшерү комитетында әйтерләр. Менә сезне кулга алу турында карар. Өегездә тентү үткәрелә. Шикле әйберләрегез конфискацияләнә.

Кәрим ишек төбендә нишләргә белмичә аптырап басып торган Заһидәсе янына килеп:

– Миңа да җитте чират, – диде.

Заһидә исенә килеп:

– Сез нишлисез? Нинди халык дошманы булсын ул?! Гомере буе театрга хезмәт иткән кеше, – диде, НКВД кешеләренең өлкәнрәге булып күренгән капитан каршына басып.

– Без кушканны үтәүчеләр генә. Анда тикшерерләр. Гаебе булмаса, җибәрерләр.

– Ярар, Заһидә, дәшмә. Сине-мине тыңламыйлар инде алар.

Ул арада егетләр шкафларны, комодларны, өстәл тартмаларын актара башладылар. Урын-җирне туздырып ташладылар.

– Нишлисез? Нигә туздырасыз өйне? – дип, Заһидә алар алып ташлаган әйберләрне җыештырырга тотынды.

– Апа, тик кенә утырыгыз. Югыйсә икегезне дә алып китәбез. Каршылык күрсәткән очракта шулай эшләргә кушылды, – диде егетләрнең өлкәне.

– Заһидә, тынычлан. Актарсыннар. Бездә алар күрергә теләгән берни дә юк.

– Бу йортта тагын кемнәр яши?

– Кем яшәсен? Әнием Хәдичә дә, без икәү. Хезмәтче тотмыйбыз. Ашсуны үзем әзерлим, – дип, җавапны Заһидә бирергә ашыкты.

– Ике катында да сезме? Биш бүлмәсендә дә?

– Икесендә дә үзебез. Фатирга кеше керткәнебез юк.

– Да, сез буржуйлар икән бит! Иреңне утыртып куйган очракта сине бу йорттан сөреп чыгарачак совет хөкүмәте. Җыена тор.

Тинчуриннар Заһидәнең атасы, дворян, статский советник булган кеше, педагог Шаһбазгәрәй Әхмәровтан калган зур фатирда яшәп яталар иде.

Кулга алырга килүчеләрнең башлыгы егетләренә китап-кәгазьләрне капчыкларга тутырып, алып китәргә әзерләргә боерды. Бераздан барысын да урамда торган машиналарына ташыдылар, күтәрә алган хәтле затлы әйберләрне дә тутырдылар капчыкларына. Кәримне алып чыгып киттеләр. Кая алып китәләр, ул хакта берни дә әйтмәделәр.

Черек күл ерак түгел, тау менәсе дә тау төшәсе – алар Профсоюзный белән Банк урамнары кисешкән чатта яшиләр иде. Аны Черек күл изоляторына илтеп яптылар.

Тинчуринның кире кайтмаячагы икенче көнне үк аңлашылды. Иртәгесен кичәге капитан домуправны да ияртеп, ат җигеп, ике солдат белән килеп җиткән. Кичтән тими калдырган бөтен нәрсәне ат арбасына ташып, йорттагы бөтен зиннәтле әйберләрне алып киттеләр. Бернинди опись ясап та тормадылар, күрәсең, капитан үзенә ташыйдыр, дип уйлады Заһидә. Алар әнисе Хәдичә белән аның сеңлесе Суфиянең кызы Гөлнараларга барырга булдылар. Гөлнараның ире Хлопушин атлы бер коммунист иде, партия өлкә комитетында эшли. Гөлнара бер дә Кәримне яратмый. Аның кулга алынуы турында ишеткәч: «Бүген генә кунасыз да, шуның белән шул! Үзегезгә фатир табыгыз!» – дип кырт кисте.

Гөлнараның әнисе Суфия дә алар белән бергә яши иде. Ул апасын урамда калдырырга уңайсызланды бугай:

– Хәдичә апа бездә яшәп торыр, – диде.

Гөлнара, явыз, шунда ук ире янына обкомга йөгерде. Аңа Кәрим Тинчуринның кулга алынуын, хатынының урамга куып чыгарылуын әйтте һәм тиз генә аларның фатирын сеңлесе Динарага алып калу артыннан йөрергә кирәк дип, команда бирде. Хлопушинның моның ише нәрсәләрне генә эшләргә хәленнән килә иде.

Кәримне Черек күл изоляторында озак тотмадылар. Октябрь керүгә үк Пләтән төрмәсенә озаттылар. Аңа беренче сорау алганда ук тикшерүче Бикчәнтәев япон шпионы дигән ярлык такты.

– Син, Тинчурин, Төркиядә качып ятучы япон шпионы Гаяз Исхакый белән хат алышасың икән.

– Беренче тапкыр ишетәм. Каян килеп аның белән хат алышыйм, ди?

– Хатыныңа да Исхакыйның кызы хат язып ята.

– Анысы тагын ни дигән сүз инде?

– Икегез дә совет властена каршы корткычлык эше алып барасыз дигән сүз. Аңлашылмыймыни?!

– Заһидә дә, мин дә берникнди хат та язганыбыз юк Исхакыйга.

Бикчәнтәев шулай дигәч, өстәлдә яткан папкадан берничә хат чыгарып, Кәрим алдына салды.

– Боларны нәрсә дип беләсең?!

Кәримнең йөзе агарып китте. Бу чынлап та ун ел чамасы элек Исхакыйдан килгән хат иде.

– Бу бит инде күптәнге хатлар, – диде Кәрим, тынычланырга теләп.

– Димәк, күптәннән бирле хат алышасыз. Исеңдәме, ниләр яза анда дустың? Укып күрсәтергәме?

– Кирәк түгел.

– Димәк, хәтерлисең. Бик әшәке сүзләр яза бит. Нецензурный сүзләр. Атабыз бөек Сталин турында! Әгәр дә аның сүзләре белән килешмәсәң, шул вакытта ук китереп тапшырырга тиеш идең бу хатны тиешле органнарга. Ә безгә ул чит кешеләр аркылы керде.

– Илтеп тапшырырга уйлаган идем... Югалттым мин ул вакытта бу хатны.

– Югалтмагансың, алдама. Икенче бер дустыңа биргәнсең. Ә ул аны яшереп саклаган. Кирәкле моментны көткән.

– Сволочь, – дип куйды Кәрим.

Бикчәнтәев шул вакыт сикереп торы да, Кәримнең ияк астына сугып җибәрде.

– Кем сволочь?!

Кинәттән сугудан Кәримнең башы артка каерылып, муеныннан ычкынып киткәндәй булды. Теле тешләнеп, авызыннан кан чәчрәп чыкты. Ул ачудан:

– Син! – дип әйткәнен дә сизми калды.

– Ах! Әле шулаймы?!

Бикчәнтәев кеше кыйнап остарган иде инде, ул баягыдан да катырак итеп айканып, һушына килергә дә өлгермәгән Кәримнең касыгына китереп сукты. Ул, «ык» иткән тавыш чыгарып, идәнгә бөгелеп төште. Палач кызганнан кыза барып, идәнгә мүкәләгән тоткынны типкәли үк башлады. Тыныч кына башланган сорау алу кыйнауга әйләнде. Бикчәнтәев хәлсезләнгән Кәримне типкәләде-типкәләде дә бүлмәдән чыгып китте. Бераздан ике сержант кереп, аны камерага чыгарып ташладылар.

Камерада бераз хәл кергәч, аңа кемнәндер бушаган аскы сәндерәдән урын бирделәр. Мондагылар барысы да аны таный, белә торган булып чыкты. Аны кертеп ташлагач ук, Ибраһим Кули танып алган икән. Кули заманында театрда суфлёр булып эшләп йөргән иде. Бик укымышлы, зыялы кеше. Соңыннан ул китап нәшриятына мөхәррир булып күчте.

– Карарлыгыгызны калдырмаган, хайван, – диде ул Кәримгә. – Бикчәнтәев идеме әллә?

– Шул. Аңламастан кыйный башлады. Югыйсә берне бирсәм, үтерәм инде үзен. Телне тешләтте, кабахәт.

Камерадагылар көлешеп куйдылар. Тинчурин дөрестән дә атлетларча төз гәүдәле, таза, нык ир-егет иде.

– Сезне генә кыйныйлар инде монда. Мохтар Мутинның да карарлыгын калдырмаган иде ул кабахәт, – диде Кули. – Әзмәвердәй адәмнең.

– Ул да мондамыни? Кайсы камерада?

– Күршедә генә.

– Тагын кемнәр бар?

– Әдәбият-сәнгать тирәсендә чуалган бөтен халык монда диярсең. Гали Ильясов та монда әле.

– Чынмы? Хөсәенне дә алмаганнармы?

– Юк. Ул иректә. Ә нәрсә, аны да алырга тиешләрмени?

– Кем белә. Бәлки... Алган булсалар, үзем кыйнап үтерәм, бәдбәхетне, – диде Кәрим.

– Нәрсә, шуның доносы белән алганнармы әллә үзеңне?

– Шуныкымы, юкмы, белмим. Ләкин шуңа укыткан бер хатны үземә күрсәттеләр. Чыксам, иманын өшкерәм үзенең.

– Исән чыксаң, кочаклап үбәр идең әле. Чыгулар булыр микән, – дип куйды кемдер.

– Анысы шулай, – диде тагын берсе.

Сорау алулар гел кыйнау белән барды. Икенче көнне дә, өченчесендә, дүртенчесендә дә имгәткәнче типкәләделәр.

– Исхакыйның туганы Хәсән белән очрашканда, ниләр турында сөйләшә идегез?

Кәрим аның белән очрашканым юк дип әйтә алмый иде. Чөнки Хәсән белән аның чынлап та берничә мәртәбә очрашканы булды. Кайчан, кая икәнен дә искә төшереп торырга вакыт юк. Берәрсен әйтсәң, болар башкасын күз алдында тоткан булсалар, әле анда да очраша идегезмени дип бәйләнүләре мөмкин. Шуңа күрә Кәрим: «Эш буенча гына очрашкаларга туры килде», – дип котылмакчы булды.

– Җитди генә кеше инде үзең, оятың да юк, алдашып утырасың, – диде Бикчәнтәев.

– Нишләп алдашыйм. Булганын сөйлим.

– Сөйләмисең шул. 1921 елдан бер ел буе Ташкентта бергә эшләгәнсез шул контра белән. Япон шпионы!

Кәрим әллә кайчан булган хәлләрне искә төшерә дип һич уйламаган иде. Чынлап та, егерме бер – егерме икенче елларда, бер ел буе, алар Ташкентта театрда эшләделәр. Хәсән суфлёр иде. Бер үк вакытта администратор булып та йөрде. Алып-сату эшендә – маклер! Аңа гына бир. Гаяз Исхакыйның энесе үзе. Аптыратып бетерде ул чакта Төркиягә китик абый янына дип. Гаязның кызы Сәгадәт тә шунда. Аны Заһидә рус теленә өйрәтте. Бик талантлы, акыллы, зиһенле кыз иде. Төркиягә чыгып китте. Үзе белән китәргә Заһидә белән Кәримне дә бик үгетләде. Боларын да беләләр инде болай булгач, дип уйлады Кәрим. Белмим дип утырсаң, тагын кыйнаячаклар. Шулай да беләм дип әйтмәскә булды.

– Шул еллардан бирле күргәнем юк ул Хәсәнне, – диде.

– Хатыныңны алып килеп әйттерсәк, ни диярсең?

Хатыныңны дигәч, Кәрим коелып төште. Ышан бу хәшәрәтләргә. Заһидәсен дә алсалар, бетте баш.

– Ул да шулай дип әйтәчәк. Без егерме икенче елны Казанга кайтып киттек. Ә Хәсән калды, кайтмады. Шуннан кая киткәндер, бер дә белмим.

– Ярар, белмисең дә, ди. Ә менә Исхакый ни өчен сине Төркиягә чакырып ята? Анысы турында ни диярсең?

– Үзеннән сорагыз. Мин каян белим.

– Ах, әле шулаймы?!

Кәрим тагын үзенең кызып китүен аңлады. Болай җавап бирергә һич тә ярамый иде. Болай да уңай җавап ала алмавына каны кайный башлаган Бикчәнтәев чынлап та йодрыкларын эшкә җикте. Ләкин үзе бер-ике мәртәбә генә кизәнергә өлгерде. Ишектә ике әзмәвер күренде. Алар керүгә Кәримне дөмбәсли башладылар. Бу юлы да карарлыгын калдырмыйча, камерага чыгарып ыргыттылар.

Икенче көнне сорау алу бүлмәсендә башка палач утыра иде.

– Подследственный Тинчурин, таныш булыйк – Исхак Гатин. Моннан ары синең белән миңа эшләргә туры киләчәк.

– Бик әйбәт. Югыйсә Бикчәнтәев сугышудан башканы белми иде. Сугыш чукмары, томана.

Кәримнең шушы сүзеннән Гатин көлеп куйды.

– Ярар. Кайсы яклардан буласың инде син?

Ул шулай диде дә, тышына «Кәрим Тинчурин» дип язылган папканы ачып, тоткынның эше белән таныша башлады.

– Әһе, якташлар түгел икән. Пенза губернасы, Демьян Бедный районы Таракан авылы... тараканы икәнсең.

– Ә сине кайсы авыл тараканы дип белик? – диде Кәрим юри Гатинның ачуын чыгару өчен. Шулай итсә, сорау алып маташмас, сугыша башлар да тизрәк эшен бетерер, дип уйлады. Шулай булып чыкты да. Гатин эшне йодрык уйнатудан башлады.

– Әле бер ай элек кенә илле яшен тутырган абзаңны кыйнамакчы буласыңмы, молокосос! – дип, Кәрим үзенә йодрык күтәргән утыз яше дә тулмаган, чыраеннан малайлыгы та чыгып бетмәгән Гатинга әйләндереп берне сылады. Теге мескен тәгәрәп, ишек төбенә барып төште, дөпелдәп, башы белән ишеккә килеп бәрелде. Ишек артында басып торганнардыр, күрәсең, Гатинның бәрелгән тавышына ике әзмәвер килеп керделәр.

Ул көнне сорау алу булмады. Гатин ишектән керүче надзирательләргә:

– Нәрсә карап торасыз, күрмисезмени нишләгәнен?! – дип кычкыруга, Кәримне кыйнарга тотындылар. Таза, махсус шөгыльләнгән сугыш чукмарлары икәне әллә каян күренеп тора. Шактый яньчеделәр Кәримне. Инде тәмам кешелектән чыгарып, Кәрим тын да ала алмыйча идәндә ята башлагач, кыйнаганнарын читтән карап кына торган Гатин, тегеләргә туктарга кушты да йөгереп килеп, тагын бер тапкыр эченә типте. Карарлыгы калмаган Тинчуринны өстерәп, камерасына чыгарып салдылар.

Ул төне буе ыңгырашып чыкты. Авыртмаган, сызламаган җире юк. Тәне генә түгел, йөзе-бите кара янып чыккан иде. Ул икенче көнне ачлык игълан итәргә булды. Иртән китергән паёктан баш тартты.

– Алай эшләмә. Болай да песи ашы гына бирәләр. Бөтенләй бетәчәксең, – диде күрше сәндерәдә ятучы Алкин.

– Ә болай кыйнап үтерәчәкләр.

– Гатинмы әллә синең тикшерүчең? Ул бик кабахәтләрчә кылана.

– Шул үзе. Маңка гына малай, мине кыйнарга дип килә башлаган иде, әйләндереп берне сыладым. Ишеккә башы белән барып бәрелде. Шуннан тотындылар кыйнарга.

– Шәп иткәнсең. Минем дә сытып ташлыйсы килә ул мәхлукларны. Көч җитми.

– Аның Бикчәнтәеве дә шундый иде. Яңа тикшерүче билгеләгәннәр. Илле яшьлек абзасына йодрык күтәрмәкче була. Акыл булыр моннан соң, – диде Кәрим.

Шул минутта ишек эшермәсен этәрә башладылар.

– Кемнедер алырга килделәр, – дип куйды Алкин.

– Тинчурин, чыгарга! – дип кычкырды надзиратель, ишекне ачып.

– Карап анда. Бүген ашамадың, көчең тиз бетәр. Тагын сугыш башлый күрмә.

– Мин ачлык игълан итәм. Сез мине тынычлыкта калдырырга тиешсез! – диде Кәрим.

– Тикшерүче алып килергә кушты. Торыгыз, киттек.

– Бар, бар. Тагын кыйный башларлар. Үзеңне кулда тот.

Кәрим ыңгырашып кына торып, ишеккә юнәлде. Бу юлы тикшерүче бүлмәсе ишеге төбендә ике әзмәвер басып тора иде.

– Мин ачлык игълан иттем. Начальствога җиткерегез, – диде Кәрим, камерага кергәч тә.

– Җиткерербез. Йә, ничек, таракан, башың авыртмыймы? – дип башлады сүзен Гатин.

– Сезгә катырак төште бугай. Миегез селкенмәгәнме?

Гатин тоткыннар арасында сорау алучыларга кул күтәрергә батырчылык иткән кешене әле беренче тапкыр очратты. Ул Кәримгә беркадәр куркып та, ләкин нәфрәт белән карый башлаган иде. Моңа кадәр утыртып сорау алган булсалар, бүген аңа утырыр өчен бүлмәдә урындык куймаганнар иде. Сорау алуны да көндез генә түгел, тәүлек буе, бервзлексез, чиратлап алып бара башладылар.

– Кави Нәҗми дигән язучы синең троцкийчы-зиновьевчы антисоветчиклар оешмасының Казандагы лидеры Галимҗан Ибраһимов белән элемтәдә торуың турында күрсәтмә язып бирде. Оешмагызда тагын кемнәр бар?

– Нинди-нинди оешма? – дип, сорауга сорау белән җавап кайтарды Тинчурин.

– Башыңны җүләргә салма! Галимҗан Ибраһимов төзегән троцкийчы татарлар оешмасы.

– Кайда оештырылган соң ул? Ибраһимов бит ун ел инде Кырымда яшәп ята. Дәвалана. Чирле кеше нинди оешма төзи алсын?

– Анысын Кави Нәҗмидән сорарсың. Үзеңнең нинди эшчәнлек алып баруың турында сөйлә.

– Кави Нәҗми язып бирде, дисең бит. Тагын ни кирәк? Мин бернинди оешма турында да белмим.

– Белерсең. Моңа кадәр бернинди дә махсус чаралар кулланмаган идек. Куллана башласак, әйтмәгән җирдән әйтерсең.

Гатин шулай диде дә, әзмәверләргә Тинчуринны ниндидер бассейнга алып барырга кушты. Аны алып чыгып киттеләр. Коридор буенча барып, подвалга төштеләр һәм бер бүлмәгә алып керделәр. Ул бүлмәдә бер якка өстәл һәм урындык куелган, икенче яртысында метр ярымга метр ярым итеп, чама белән бер метр тирәнлегендәге бассейн ясалган иде.

– Чишен, кер суга! – диде артларыннан кергән Гатин.

Кәрим чишенеп, баскычтан бассейн эченә төшеп басты. Су шактый ук салкын, дүрт-биш градус булгандыр.

– Йә, менә хәзер сөйлә инде. Оешмагызда кемнәр бар?

– Мин бернинди оешманы да белмим.

– Ярар, тор шулай берәр сәгать. Аннары исеңә төшерерсең.

Гатин шулай диде дә, әзмәверләргә сакларга кушып, камерадан чыгып китте.

Бераздан Кәримнең тәне кызышып, кып-кызыл булып чыкты. Ул туңудан дер-дер калтырый башлады. Судан чыкмакчы булып баскычка килгән иде, теге әзмәверләр башыннан этеп, эчкә кертеп җибәрделәр. Аптырагач, ул кулы белән тегермән әйләндергән хәрәкәтләр ясарга кереште. Тәнен, кызышкан аякларын уды. Ләкин бераздан үзендә хәл бетә башлавын тойды. Аякларын көзән җыера башлады. Әйтерсең лә аның хәле беткәнен каяндыр күзәтеп торган шикелле, камерага Гатин килеп керде.

– Йә, ничек? Исеңә төштеме? – диде ул көлемсерәп.

– Юк. Булмаган нәрсәне бар дип әйтә алмыйм. Бернинди дә оешма белмим, – диде Кәрим, һәм аңын җуеп, суга егылды.

Аңына килгәндә аны камерасына алып кайтып салганнар иде инде. Камерадагылар аны киендереп, шунда булган чүпрәк-чапрак белән төргәннәр. Алкин тырышып-тырышып тәнен уа иде.

– Уяндыңмы? Озак йокладың, – диде ул, шаярткан булып.

– Суга батырып үтерәләрме дип торам.

– Үтерерләр дә болар. Нәрсә әйттермәкче булалар соң?

– Ниндидер оешма турында сорыйлар. Галимҗан Ибраһимов оештырган.

– Бөтенебездән дә шул бер нәрсәне сорап аптыраталар инде. Кемнәрдер түзми, сөйли. Булмаганны да булды, ди. Күрәм, сез нык торасыз, Кәрим абый. Сез йоклаганда ашарга китерделәр. Үз паегыгызны капкалап алыгыз. Сәндерәгездә.

– Юк, дускай, мин ачлык игълан иттем. Ир сүзе бер була.

– Болай ачтан үләчәксез бит.

– Үләм, ләкин кешегә яла якмыйм. Булмаган оешманың нинди әгъзалары булсын?

Кәрим икенче көнне дә, өченче көнне дә ашамады. Көн саен яңа төрле җәза чарасы уйлап таптылар аңа карата. Салкын суда тотудан суык тиеп, ул нык кына авырый башлады. Температурасы күтәрелде. Бөтен тәне кызышты. Бизгәк тотты. Аны төрмә хастаханәсенә илтеп салдылар. Анда да әллә ни дәваламадылар. Айдан артык аунады хастаханә ятагында. Октябрь инкыйлабының егерме еллыгын ул хастаханәдә каршылады.

Шулай сорау алулар, кыйналулар белән көннәр, атналар, айлар үтте.

Хөкем карары чыгарып, кемнәрнедер лагерьларга озаттылар, кемнәрнедер атып үтерделәр. Өрлек кебек ирнең сәламәтлеге тәмам какшады. Үзләре теләгән җавапны ала алмагач, каядыр хезмәт белән төзәтү лагерена җибәрүдән бу кешедән файда булмас диптер, ахры, Кәрим Тинчурин өч кешелек махсус киңәшмә карары белән 1938 елның 15 ноябренә каршы төндә атып үтерелде.

**7**

Мәскәүгә китәр алдыннан театр икегә бүленеп, Салих музыкаль театр составына кертелгән булса да, Казанга әйләнеп кайткач, ул яңадан элекке беренче драма театры составына күчерелде. Казанда опера театры ачуга хәзерлек бара иде. Драма театрына академия театры дигән исем бирелде. Музыкаль спектакльләр кую чикләнде. Тинчурин драмалары репертуардан бөтенләй алып ташланды. Театрда артистлар арасында мөнәсәбәт киеренкеләнгән иде. Барысы да бер-берсеннән шикләнеп, артык сүз сөйләшмичә, куркып яши башлаганнар. Салихка карата да мөнәсәбәт үзгәргән. Ул үзе дә артистлар белән бик аралашмаска тырышты. Чөнки Кәрим Тинчурин белән дуслыгы аны да «халык дошманы» дип аталуга бер сәбәп булып тора һәм ул артистларның мондый шикләнүләреннән курыкты. Аларга да, Салих белән аралашу шундый ярлык тагылу куркынычы тудырырга мөмкин дип уйлады.

Шундый катлаулы бер вакытта Салихка карата дустанә мөнәсәбәт саклап калган кеше Таҗи Гыйззәт булды. Ул баш режиссёрны үзенең 1932 елда ук иҗат иткән «Бишбүләк» драмасын куйдыруга күндергән икән. Салихның Мәскәүдән кайтып, эшкә чыккан беренче көннәрендә үк Таҗи Гыйззәт аңа:

– Салих дускай, син Мәскәүгә киткәнче үк язылган «Бишбүләг»ем кире әйләнеп кайтуыңны көткән икән, баш режиссёр Габдулла Уральский быелгы репертуарга шул спектакльне кертте бит. Режиссёры итеп Вәлиев-Сульва билгеләнде, – диде.

– Бик әйбәт! Мин инде миңа эш булмас, ахры, театрда дип куркып йөри идем.

– Син ул драма белән таныш бугай. Язган елны ук укыган идек.

– Таныш, таныш. Казанны ак чехлар басып алган көннәр турында.

– Нәкъ үзе.

– Кайчан башлыйбыз эшне?

– Башта Сульва, син, мин – өчәү – авыллардан әйләнеп кайтсак дигән идем. Шул драмада барган вакыйгаларда катнашучы кешеләр белән очрашу, музыкасын язганда, әсәрне тулырак күз алдына китерү өчен җиңелрәк булмасмы, дип уйладым. Режиссёр өчен дә зыяны булмас. Син ничек карыйсың? Кәрим абый белән «Кандыр буе»н язганда шундый сәяхәттә йөреп кайтуыгызның файдасы булды бугай.

– Мин каршы түгел. Тик берүк велисәпиткә атландыра күрмә. Кәрим абый белән велисәпиттә йөреп кайткач та, өч ай ботларым авыртып йөрдем.

– Юк, бу юлы безне ат арбасында кунак итеп кенә йөртерләр. Мин бит атаклы драматург хәзер Татарстанда! Син Мәскәүдә укып йөргән арада «Мактаулы заман» дигән драма язып куйдырып, халык арасында абруй

казандым. Бөтен районнардан алдынгы колхозчыларны машиналарга төяп, массовый рәвештә шул спектакльне карарга йөрттеләр.

– Кит аннан.

– Менә күрерсең, өрмәгән урындыкка да утыртмаслар әле үзебезне, – дип мактанып алды Таҗи.

Шулай булып чыкты да. Әтнә райкомына телефоннан шалтыратып, театрдан яңа пьеса язарга материал туплау өчен өч кешелек делегация килә. Аларны алырга Казанга машина җибәрегез, дигәч, райком секретаре үзе йөри торган машинаны җибәргән иде.

«Мактаулы заман»ны гына түгел, Салих Сәйдәшев белән Кәрим Тинчуринның «Кандыр буе»н язар алдыннан килеп китүләрен дә яхшы хәтерләүче кешеләр бар икән әле бу якларда.

Бәрәскә авылында алар, тарихны яхшы беләләрдер дип, мәктәпкә керергә булдылар.

– Бу юлы нинди җилләр ташлады? – дип каршылады аларны мәктәп директоры Гарәпша Хәсәнов. Ул Сәйдәшев белән Тинчуринның берничә ел элек үзләрендә кунак булып китүен хәтерли булып чыкты.

– Менә тагын бер спектакль чыгарырга йөрибез, – диде Таҗи. – Бу юлы Салих белән минем спектакль булачак. Ул көен яза, ә менә бу дустыбыз Сөләйман Вәлиев-Сульва – режиссёры. Унсигезенче елларда ак чехларга каршы сугышларда катнашкан берәр кеше юкмы авылыгызда?

– Ак чехларга каршы? Уйлап карарга кирәк. Булгандыр инде ул. Шактый вакыт узды бит инде ул еллардан соң.

– Бар бит, Гарәпша абый, бар бит андый кеше, – диде райком вәкиле алып килгән кунакларны күрергә дип җыелган укучыларның берсе – Гаптери Исмәгыйлев дигән малай.

– Кем? – диде Гарәпша.

– Зиннәт абый, Зыятдинов. Ул гражданнар сугышында катнашкан кеше бит.

– Зиннәт? Аның турында сөйләргә ярамый, – диде директор.

– Нишләп алай? – дип куйды Сульва.

– Халык дошманы дип гаепләнеп утырып чыкты ул.

– Чыккан дисең бит инде.

– Чыгуын чыкты. Ләкин мәктәптә укытырга рөхсәт итмәделәр.

– Ни өчен?

– Халык дошманы булган өчен.

– Нинди дошманлык эшләгән иде соң? Аклангандыр бит? Югыйсә чыгармаган булырлар иде. Әйдә, безне шуның янына алып бар әле, – диде Таҗи Гарәпшага.

Алар бишәүләп, райком вәкиле машинасында Зиннәт Зыятдиновларга киттеләр. Юлда Гарәпша Зиннәт белән булган хәлне сөйләп алды.

– Озак та утырмады. Тарих укытучысы иде ул. Узган уку елында класс диварында эленеп торган Галимҗан Ибраһимов портретын коридорга чыгарып ыргытканы өчен утыртып куйганнар иде. Ялгышлык белән. «Нишләп алай иттегез?» – дигәч, укучыларга: «Ибраһимов халык дошманы икән!» – дигән. Шуның өчен алып китеп, өч ай утырып чыкты. Дөрес әйткән булган икән. Безне район НКВДчылары үзләре дә Галимҗан Ибраһимовның

халык дошманы икәнен белмичә алып киткән булганнар. Аклап чыгардылар үзен өч айдан соң. Тик мәктәптә укытырга рөхсәт бирмәделәр. Хәзер йөри гади колхозчы булып.

– Гаҗәп хәлләр бар бу илдә, – дип куйды Салих. – Күпме кеше утыра бүген шулай ялгышлык белән.

– Күп сөйләшмә, Салих, – дип куйды Таҗи Гыйззәт. – Ялгыш булгач, чыгарганнар бит әнә.

Кызыклы гына кеше булып чыкты Зиннәт Зыятдинов. Салих белән бер яшьтә икән. Шактый укымышлы. Күпне күргән, күпне белә. Таҗи Гыйззәтнең «Бишбүләк» драмасын куярга йөрибез, дигәч:

– Укыдым, укыдым. Бик кызыклы драма, – дип, шунда ук бәясен дә бирде. – Өченче ел китап булып басылып чыкты бит ул. Мин чыккан бер китапны укып барам. Бик дөрес һәм мавыктыргыч итеп язгансыз ул еллар турында.

«Бишбүләк»не Таҗи Гыйззәт 1932 елда ук язып, утыз өченче елда ул куелырга да планлаштырылган иде. Театр кинәт кенә Баку, Ташкент шәһәрләренә гастрольләргә чыгып китеп, куелмыйча калды. Ә 1936 елда ул нәшриятта аерым китап булып басылып чыкты. Зиннәт шул китапны укыган икән.

– Менә шул драмада тасвирланган вакыйгаларга өстәп, үзегезнең баштан кичкәннәрне дә сөйләсәгез, минем өчен бер дигән ярдәм булачак, – диде Сульва. – Мин спектакльнең режиссёры. Материалны драмада язылганнан да яхшырак беләсе килә. Аннары авылларда үтә торган тула басу өмәләре, аларда җырлана торган җырлар турында да ишетәсе, беләсе иде. Анысы Салих абыегыз өчен музыка язганда, бер дигән ярдәм булыр иде.

– Алайса ул елларда актив эшләгән ярлылар комитеты рәисе Гыймади абый белән очраштырырга кирәк сезне, – диде Гарәпша.

– Менә-менә. Һәвәскәр артистларыгыз белән дә очрашсак, начар булмас иде.

– Бездә профессионал артистлар да бар, – дип куйды райком вәкиле. – Әтнәдә бер дигән театрыбыз эшли. Артистлар белән очрашырсыз.

Зиннәт Зыятдинов белән сөйләшеп утырганнан соң райком вәкиле колхоз ашханәсенә алып барып, чәй эчүне оештырды да, председательгә кунакларны авыллар буйлап йөртер өчен җигүле транспорт бирергә кушып, үзе Әтнәгә кайтып китте. Кунаклар кич клубта алар өчен махсус оештырылачак концертны карыйсы дигәч, Бәрәскәдә генә кунып калырга булдылар. Кунакларны авыл яшьләре белән концерт-театрлар уйнап йөрүне оештыручы Госман Әхмәтҗанов исемле комсомол егеткә тапшырып, Гарәпша да үз эшләре белән китеп барды.

– Безнең тагын бер нәрсә турында тәфсилләбрәк беләсебез килә бит әле, Госман туган, – диде Таҗи алар белән йөрергә калдырылган егеткә.

– Нәрсә турында?

– Тула басу турында.

– Аны белүчеләр күп бездә. Элегрәк елларда һәр ике йортның берсендә тула тукый торганнар иде. Безне тула тукырга малай чактан ук өйрәтеп үстерделәр. Үзем дә бик әйбәтләп сөйләп бирә алам.

– Әйбәт булыр иде. Кемнедер эзләп йөрергә дә калмас.

– Тула – постау дигән сүз бит инде ул. Сукно, русча әйткәндә. Менә шул туланы киндер һәм сарык йоныннан эрләгән җепләрдән махсус ясалган туку станогында тукыйлар. Станок бөтен кешедә дә булмый. Үз өйләрендә тула тукыган яшьләр, станогы булган кешегә җыйналып, тула басалар. Шуны тула басу өмәсе дип атыйлар инде. Тула басу шактый кыен нәрсә. Станоктан чыгарганнан соң туланы кайнар суда манчып, сәкегә җәеп салалар да тал чыбыгыннан үргән читән белән ышкыйлар. Егетләр өчәү-дүртәү булып, бер төркем арыгач, икенчесе алышынып, чиратлап эшлиләр. Калын, мамыклы тула барлыкка килгәнче эшләргә кирәк. Егетләр артыннан кызлар туланы яхшылап юалар. Яшьләр җыелган җирдә уен-көлке, җыр-бию була бит инде. Эш беткәч, кич белән яшьләр чәйләр эчеп, җырлап-биеп күңел ачалар.

Җитен сүсеннән тукылган киндерне йомшарту һәм агарту өчен бүрәнә өстенә җәеп салып тукмаклыйлар. Тукмаклауның үзенә күрә бер көе дә була. Ул тирә-якка ишетелеп, авылга матур бер моң тарата. Ерактан ишетелеп торган бу көй авылда бүген кайсыдыр өйдә тула басу өмәсе булганын сөйләп тора. Менә бүген кич клубта буласы концертта бу көйне үзегез дә ишетерсез әле.

– Бигрәк оста итеп сөйләдең, артистлардан бер дә ким түгел, – дип куйды Таҗи Госман атлы бу егеткә.

– Минем үземнең дә артист булырга теләк зур. Армиядән әйләнеп кайткач, Казанга артистлыкка укырга барырга дип исәпләп торам.

– Бик әйбәт булыр. Үземнең янга кил, училище директоры белән үзем сөйләшермен, – диде Таҗи.

Алар кич белән авыл яшьләре куйган концертны карадылар. Салих бигрәк тә тула басучы кызларның җырларын, туланы тукмаклау вакытында чыккан көйләрне отып калырга тырышты.

Бәрәскәдән соң алар икенче көнне – Әтнәгә, аннары Мәңгәргә барып, авыл активистлары белән очраштылар. «Бишбүләк»не баетыр өчен шактый гына материал тупладылар. Спектакльдәге Исламгәрәй бай йортының декорацияләрен ясар өчен рәссам Мортаза Абдуллинга өч авылда да элекке авыл байларының йортларын фотога төшереп алып кайттылар. Салих авыл һәвәскәрләре концертларында күрсәтелгән тула басу өмәләреннән көйләрне нотага язып алды.

Таҗи Гыйззәтне Әтнә якларында йөреп кайту гына канәгатьләндермәде. Берничә көннән алар театр директоры Мингали Дәүләтшин һәм Салих Сәйдәшев белән бергә туган якларына, Красный Бор районына кайтып килделәр. Шуннан соң театрда спектакльнең репетицияләре башланды.

Ул арада Салихның тормышында тагын бер истәлекле вакыйга булып алды. Сафия өченче баласын тапты. Аңа Эмиль дип исем куштылар. Якын дусларын югалтудан, спектакльләре репертуардан төшерелүдән кәефе кырылып, төшенкелеккә бирелеп йөргән Салих өчен бу аның күңелен күтәреп, тормышка дәртен арттырып җибәргән зур вакыйга иде. Ә 1939 елның 3 гыйнварында «Бишбүләк» сәхнәгә чыкты. Сәйдәшев музыкасын сирәк ишетә башлаган тамашачылар өчен дә бу көтеп алынган зур шатлык иде. Ул зур уңыш казанды. Сезон ябылыр алдыннан аның сәхнәдә илле тапкыр уйналуын зурлап билгеләп үттеләр. Гәзитләрдә зур-зур мәкаләләр чыкты.

Ул елны Салих җәйне Кызыл Байракта үткәрде. Театр сезонны тәмамлауга алар гаиләләре белән җыелып, Идел буена ял итәргә китеп бардылар. Кызыл Байрак Сәйдәш өчен Габдулла Тукайның Кырлае кебек үк изге урын иде. Биредә ул ял итте, балык тотты. Җәйге айлы кичләрдә учакягып, дуслары, күршеләре, туганнары, гаиләсе белән җыелышып утырулар аның күңелендәге тирән кичерешләрне үткәреп җибәрү өчен иң уңайлы вакытлар иде. Аның инде бүтән беркайчан да күрешмәскә дип аерылган кешеләре – Шиһап Әхмәров, Шамил Усманов, Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчуриннар белән аралашып яшәгән еллары Кызыл Байракта узды. Биредә алар яңа тормыш төзү турында сөйләштеләр, киләчәккә планнар кордылар, бер-берсенең әсәрләрен укыдылар, Сәйдәшнең музыкасын, җырларын тыңладылар. Сәйдәш шушында үзенең күпме әсәрен иҗат итте. Менә ул янә Кызыл Байракта.

Килгән көннәрне үк аларны Тажи Гыйззәт кунакка алды. «Бишбүләк»нең уңышы аны канатландырган иде. Ул Салих белән икесенең хезмәте нәтиҗәсендә яуланган бу уңышны дуслары, театр артистлары белән билгеләп үтәргә уйлаган иде. Хөсәен Уразиков, Шакир Шамильский, Фатыйма Ильская, Зифа Басыйрова; әлбәттә инде, барысы да парлары: ирләр – хатыннары, хатыннар ирләре белән. Мәҗлестә Фәтхи Бурнашның да булуы Салихка аеруча тәэсир итте. Ул аның кебек үк якын дусты Кәрим Тинчуринны искә төшерде һәм ничектер күңелсезләнеп утырды.

– Ни булды, Салих? Кәефең кырылган кебек, – диде Бурнаш, дустының күңелсез генә утыруына игътибар итеп. – Әйдә, уйнап җибәр әле фортепиано дустыңда. Балтасы суга төшкән кеше кебек утырма моңаеп.

Шулай дигәч, Салих фортепиано алдына барып утырды да бармакларын клавишалар өстеннән йөгертеп узды. Ниндидер моңсу, тирән хәсрәт хисләре уята торган көй башлап җибәрде.

– Нәрсә инде матәм көе башлап җибәрдең? – диде Фатыйма, иренең соравына каршы сагышлы музыка уйный башлаган Салихны кисәтеп. – Әйдә, уйнап җибәр әле Фәридә җырын. Зифа әнә баядан бирле инде шуны көтеп утыра.

– Уйнасын, нигә бүлдерәсең аны? Күңеленең тулган чагыдыр. Уйна, Салих абый, уйна шул Сакай маршын. Кем белә, бүген без монда күңел ачарга җыйналдык та, якын дусларыбыз Тинчурин, Ильясов, Исмәгыйлев, Мутиннар кайларда йөриләрдер анда? Исәннәрдерме әле? – диде Басыйрова.

– Шиһап абзый анда төрмәдә интегеп ята. «Эштә чыныккан батырлар килә, бирегез мәйдан!» дип мактанып ята торган көнме? – дип, Шамильский Әхмәровны искә төшерде.

Салих, Шакирның сүзләреннән соң бераз тукталып торды да, яңа гына иҗат иткән, әле беркемгә дә уйнап күрсәтмәгән җыр көен уйный башлады. Шундый да моңлы, сагышлы көй агылды. Әйтерсең лә ул бу көйгә үзенең йөрәген ярып салган, диярсең, аннан йөрәк түрендәге иң мөкатдәс моңнар агыла иде. Салих җырның беренче строфасының көен уйнап чыкты да үзенең йомшак, мамыктай тавышы белән акрын гына җырлап җибәрде.

– Туган җирем, сөйгән авылым,
Бигрәк якын күңелгә.

Кай илләрдә яшәсәм дә,
Оныта алмам гомергә.

Хуш, авылым, сау бул,
Сәламнәр көт
Таң җилләре искәндә.
Мин җырлармын сине сагынып,
Өзелеп искә төшкәндә.

Матур була, ямьле була
Яз көннәрең, җәйләрең.
Исән булсам, бер кайтырмын
Язлар кебек әйләнеп.

Хуш, авылым, сау бул,
Сәламнәр көт
Таң җилләре искәндә.
Мин җырлармын сине сагынып,
Өзелеп искә төшкәндә.

– Нинди җыр бу, Салих абый? Үзәкне өзә торган моң, – диде Зифа Басыйрова.

– Бүген безнең арадан киткән дусларның җыры бу. Аларның Кызыл Байрак белән хушлашу җыры, – диде Салих.

– Искиткеч! Мондый җырларны бары син генә яза аласың, Салих туган, – диде Шамильский. – Бугазга яшь төере утырды. Тагын елатасың икән инде халыкны.

– Бу бит Хәбиб Фәтхуллинның «Күзләр» пьесасындагы сүзләр. Сукыр кыз җырлый торган җыр булырга тиеш. Инде көен дә язарга өлгердеңмени? – диде Хөсәен Уразиков.

Хөсәен режиссёр буларак, бу әсәрне укып чыккан булган. Театр медицина институты студенты Хәбиб Фәтхуллин китергән бу пьесаны яңа сезонда куярга булган икән. Ә Хәбиб ул арада Сәйдәшев белән дуслашырга да өлгергән. Салих пьесадагы шәһәргә күзләренә операция ясатырга китәргә тиешле сукыр кызның җырын, Кызыл Байрак белән мәңгегә хушлашып китеп барган дусларының җыры итеп, үзәк өзгеч көен дә тапкан.

Табындашлар Салихны кат-кат җырлаттылар.

– «Хуш, авылым» дип куярга кирәк бу җырның исемен, – диде Басыйрова. – Сукыр кыз ролен үземә бирерсең, Хөсәен абый. Сәхнәдән үзем башкарасым килә.

– Белмим бит әле, режиссёры кем булыр? Мине билгеләсәләр, һичшиксез, – диде Уразиков.

– Кайларда йөрисез икән сез? – дип уфтанып куйды Салих.

– Ярар, алар турында күп сөйләшмик әле. Алда үзебез белән дә ниләр буласын бер Алла гына белә, – дип куйды Таҗи. – Әйдә ишегалдына, бакчага чыгыйк. Нәрсә шундый матур җәйге кичтә өйдә пыскып утырабыз. Җитмәсә елашып. Мәликә, кызлар, нәрсә анда, самавырыгыз куелганмы? Чәй әзерме? – дип, ул хатынына һәм башка кыз-хатыннарга эндәште.

– Самавыр да куйган, малайлар тотып кайткан балыктан уха да пешкән.

Кайчан чыгып ашарлар икән дип борчылып ята балыклар, – дип шаярткан булды Мәликә.

Алар кич буе сөйләшеп, җырлашып, «Бишбүләк»не чыгарган вакытта булган төрле хәлләрне искә алып, төн уртасы җиткәнче күңелле итеп утырдылар. Казаннан кунаклар килгәнен белеп, учак янына күрше-күлән җыйналды.

«Күзләр»нең премьерасы яңа сезон ачылышына, 17 сентябрьгә билгеләнгән иде. Бу драманы да халык яратып кабул итте. Спектакльнең Сәйдәшев музыкасы белән баруы, анда яңгыраган «Хуш, авылым» һәм «Тургай» дигән җырлар тамашаның популярлыгын бермә-бер күтәрделәр. Спектакльдән соң ТАССР Верховный Советы Президиумының Салих Сәйдәшевкә «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирүе турында Указы игълан ителде. Шул уңайдан соңыннан композиторны котлап, махсус кичә оештырылды. Бу мактаулы исемне Салих кырык яше якынлашып килгәндә, аның хезмәтләренә югары бәя дип кабул итте...

**8**

Якын дусларын югалту хәсрәтләрен оныттырып, яңа премьералар шатлыгы белән яши генә башлады дигәндә, 1940 ел Салих өчен яңа борчулар алып килде. Әллә соң «артык кеше» дигән мөһер аңа өстән, Аллаһы Тәгаләнең үзе тарафыннан сугылганмы? Республиканың музыкаль тормышына яңалык булып, Татарстан Композиторлар союзы төзелеп, композиторлар үзара аралашып, яңа тормыш белән яши башладылар дигәндә генә, шул союз Салих Сәйдәшевне һәртөрле тәнкыйть утына тота башлады.

Июль аенда Казанда автономияле республикалар композиторларының конференциясе булды. Анда Сәйдәшев әсәрләренә карата тискәре фикерләр әйтелде. Бигрәк тә Мәскәүдән килгән музыка белгечләре кискен чыгышлар ясады. Имеш, ул иҗатында халык көйләре традициясеннән китәргә теләми, дөнья һәм рус композиторлары классикасы үрнәгендә иҗат итәргә сәләтсез. Пролетар татар музыкасы тудырасы урында пентатоникадан күтәрелә алмаган вак буржуаз татар музыкасы тудыру белән генә шөгыльләнә.

Шуның өстенә Салихны яңадан опера дигән нәрсә белән аптыратырга тотындылар. Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрү дигән нәрсә уйлап чыгардылар. Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсын, Галиәсгар Камал, Таҗи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәт әсәрләрен декадага алып барырга хәзерли башладылар. Ә Салих Сәйдәшевнең музыкаль драмаларын татар театры казанышы итеп күрсәтүне кирәк дип тапмадылар. Ул гына да түгел, аны эшеннән үк чыгарып аттылар. Аның урынына театрга музыкаль җитәкче итеп, Җәүдәт Фәйзи билгеләнде. «Наёмщик» музыкаль драмасын опера итеп үзгәртеп эшләргә кирәк дигән сылтау белән аңа Ливадия иҗат йортына путёвка тәкъдим иттеләр. Сәйдәшевнең опера жанрын ят күрүе Мәскәүдә чагында ук беленгән иде югыйсә. Хәзер яңадан шул нәрсәне көчләп такмакчылар. Юк, ул беркайчан да опера язмаячак. Ул тудырган музыкаль драма татар театры сәхнәсендә үз урынын тапты һәм аны алга таба үстерергә, яңа әсәрләр иҗат итәргә кирәк. Хәтта опера театры урынына

музыкаль драма театры ачканда, ул татар халкы өчен кызыклырак, якынрак сәнгать үзәге булыр иде. Ә өстәге абзыйларга аның кирәге юк. Халык ул турыда нәрсә уйлый, бу хакта кызыксынырга берсенең дә теләге юк.

Шулар өстенә, бәла өстенә каза дигәндәй, 24 августта Кызыл Байрактагы дачасында язып утырган җиреннән иң якын дусларының тагын берсен, бергәләп унике спектакль чыгарган драматург Фәтхи Бурнашны халык дошманы дип кулга алдылар. Дошман эзләүләр инде бетте, инде тынычландык бугай дигәндә, 1930 елда буржуаз милләтчелектә, солтангалиевчелектә гаепләнеп, партиядән чыгарылганнан соң, партия Үзәк Комитетына апелляция язып, яңадан партиягә алынып, ун ел узгач та тынычлап яшәргә ирек бирмәделәр Бурнашка. Фатыйх Сәйфи-Казанлының 1929 елда «Яңалиф» журналында Фәтхи Бурнаш иҗатын тәмам бетереп ташлаган «Сарайлар, ханнар, кенәзләр, мәчетләр шагыйре» дигән мәкаләсе аны башкалар тарафыннан да төрлечә тәнкыйтьләүләргә, буржуаз милләтчелектә, солтангалиевчелектә гаепләп язарга юл ачты. Менә, ниһаять, ун ел үткәннән соң аның эшен яңадан карап, үзен Җир йөзеннән себереп түгәргә карар кылдылар булса кирәк. Бу бит халык яратып кабул иткән «Яшь йөрәкләр», «Таһир-Зөһрә», «Камали карт», «Адашкан кыз», «Авыл яшьләре», «Хатирә апа», «Лачыннар», «Ялгыз Ярулла» спектакльләре театр репертуарыннан алып ташланачак, алардагы никадәрле җыр яңгырамаячак дигән сүз. Шундый әсәрләр язган драматург, шагыйрь халык дошманы була ала микәнни? Болай булгач, Салихның үзен дә иректә озак йөртмәүләре ихтимал. Декадага катнаштырмаулары шуның турында сөйләмиме икән? Фәтхи Бурнаш кебек кешене дә артыкка чыгаргач, аны гына тынычлыкта калдырмаслар инде болай булгач.

Ул әнә шулар турында уйлап, яңадан төшенкелеккә бирелеп яши башлады.

Эшсез торып калган Салих иҗат йортына путёвкадан баш тартмады. Операны язса-язмаса да, ичмасам кеше күзеннән бераз читтә яшәп алырмын, дип уйлады.

Иҗат йортына китәр алдыннан декадада катнашучыларга таныклык һәм Бауман урамында кафеда бушлай туклану өчен талоннар өләштеләр. Салих шулай бер көнне урамда бушлай ашап кайтырга дип, кафега баручылар төркеменә тап булды.

– О-о, Салих абый! Әйдәгез безнең белән, кафега барып, тамак ялгап кайтабыз, – диделәр егетләр.

– Мин бит декадада катнашмыйм. Сезнең кебек бушлай ашап йөрергә талоным юк, – диде Салих.

– Борчылмагыз, Салих абый, үзебезнең аштан өлеш чыгарырбыз, – диде егетләрнең берсе, аның оркестрында уйнап, бер үк вакытта музыка училищесында укып йөрүче Афзал Хәйретдинов.

– Ярый алайса, мин каршы түгел, – диде Салих.

Яраткан композиторлары белән ашханәгә кереп, тамак ялгап чыгу студент егетләр өчен мәртәбә иде. Җитмәсә, күбесе Афзал кебек театр оркестрында уйнаучы егетләр икән. Әле кайчан шулай үз җитәкчеләре белән бер өстәл артында ашап утырырга җай чыгар? Егетләр ашханәгә кереп, үзләренә өстәл сайлап утырышырга да өлгермәделәр, алар янына башка

музыкантлар да җыйналыша башлады. Ашханә хезмәткәрләреннән рөхсәт сорап, алар үз өстәлләрен Салих абыйлары утырган өстәлгә куштылар да, озын гына табын барлыкка килде. Барысының да Сәйдәшев белән бер табында утырасылары килә икән.

– Эх, кызганыч, Салих абый, безнең белән декадага бармыйсыз икән, – диде кайсыдыр.

– Дүрт ел яшәп, тәмам туеп кайткан идем мин ул Мәскәүдән. Бик әйбәт булды әле, – диде Салих, исе китмәгән кыяфәт чыгарып.

– Нишләп опера язмыйсыз, Салих абый? «Наёмщик»ны опера итеп үзгәртсәгез, сезне дә алып барырга тиешләр икән бит.

– Шулай эшләп була микән ул? Бер туган баланы яңадан тудыру белән бер бит инде бу. Шулай дип уйламыйсызмы?

Егетләр Салих абыйларының бу аргументыннан көлешеп алдылар.

– Алайса яңа опера языгыз.

– Юк, егетләр, булмый ул миннән. Операга күңел ятмый минем. Безнең халык өчен ят нәрсә ул опера. Нindидер бака туе.

Егетләр тагын хихылдашып алдылар.

– Ә балет? Балет язарга теләгегез юкмы? Анда бит музыка да бию генә. Бернинди дә бака туе да, мөгрәү дә, үкерү дә юк.

– Балет башка нәрсә. Дөрес әйтәсез. Балетны кабул итәм. Минем барлык музыкаль драмаларымда да балет фрагментлары бар, «Наёмщик»та да, «Кандыр буе»нда да. Башкаларында да. Балет язарга уемда бар.

– Салих абый, сезне опера язу өчен Ливадия иҗат йортына китә икән, диделәр бит. Шул дөресме? Болай булгач, опера язарга ризалашкансыз булып чыга түгелме соң?

– Дөрес, китәм. Ләкин опера язарга җыенмыйм. Менә сез, Мәскәүгә барабыз дип, бушка ашап йөрисез бит әле. Мин дә опера язам дигән булып, бушка иҗат йортында яшәп алырга булдым.

– Дөрес эшлисез, Салих абый. Сезне дә декадада катнаштырмагач, шул кирәк аларга.

Егетләр сөйләшә-сөйләшә, талонга бирелгән бер кисәк ит йөзеп йөргән шулпа белән бәрәңге боламыкларын ашап бетергәннәрен сизми дә калдылар.

Салих икенче көнне Ливадия иҗат йортына китеп барды. Аннан ул сугыш башланыр алдыннан гына кайтты. Ә егетләрнең күбесе сугышка алынды. Бик тырышып әзерләнгән декада булмыйча калды.

**9**

1941 елның май урталары иде. Ливадия иҗат йортыннан кайтып төшкән Салих Галактионов урамы буйлап, апаларына хәлен белешергә бара иде. Ленин бакчасы ягыннан каршына менеп килүче Фәрит Яруллинны күреп алды. Ул каядыр ашыга, очраган кешеләрне дә абайламый. Янына ук килеп җиткәч, күрмичә үтеп китә бугай дип, Салих аңа үзе дәште:

– Ут капкандай кая чабасың болай, бәгырь? – диде.

– Уф, котны алдың, Салих абый, син икәнсең, – диде ул, кинәт эндәшүдән йөзенә курку кыяфәте чыгып.

– Нишләп йөрисең бу урамда?

– Мин бу урамда торам бит хәзер.

– Шулаймыни? Кайчаннан бирле? Дүрт-биш ай Казаннан китеп торган идем, әллә ниләр булып беткән монда.

– Өйләндем бит, Салих абый. Шушы урамда яшәүче бер матурга.

– Кем инде, сер булмаса?

– Сер түгел. Опера-балет театрының иң матур балеринасына. Галина исемле бер чибәргә.

– Марҗамыни? Гафу ит, рус кызымыни, диюем.

– Марҗа түгел.

– Исеме... Марҗаның да бар җаны дип, мин дә марҗага өйләнгән идем яшь чакта. Бәлки ишеткән булгансыңдыр. Үлеп китте, мине ялгыз калдырып.

– Беләм, Салих абый. Улыгыз Альфредны тапкач үлгән дип ишеткән идем.

– Шулай булды шул.

– Минеке дә бәби табарга йөри. Шуңа ашыгып кайта идем. Бераз булышырга дип үзенә. Марҗа түгел, хохлушка минеке. Украинадан опера-балет театрына килгән кыз. Минем «Шүрәле»дә кошлар биюендә бии. Тик менә декадага бара алмас инде. Бәбиебез булырга тиеш. Биетмәсләр.

Сөйләшүләре озаккарак китте шикелле, Фәрит ашыга иде:

– Мин кайтып җиттем, Салих абый. Ашыгам, башка вакытта озаклап сөйләшербез әле. Сөйләшер сүзләр дә бар.

– Бу йортта торасызмыни? Коммуналка. Күршеләр икәнбез бит.

– Әллә сез дә монда күчтегезме? Сез бит театр ишегалдында тора идегез.

– Монда минем апам тора. Менә Ливадиядән кайттым да бүген, хәлләрен белешим дип килүем иде.

– Алай булгач, вакытыгыз булса, кергәләп йөрегез, Салих абый.

– Минем вакыт булыр да ул, синеке менә.

– Минем вакыт бик тыгыз шул хәзер. «Совет» кунакханәсе – Мехчылар клубы – Галактионов урамы. Шушы өч бина арасында йөгереп үтә көннәрем.

– Йә, ярый алайса, бар, йөгер. Яшь бичәң көтәдер.

– Вакытыгыз булса, иртәгә «Совет» кунакханәсенә килеп чыгыгыз әле, Салих абый. Балетның ноталарын карап чыгарсыз, бәлки.

Фәрит саубуллашты да ашыгып, Салихның апалары тора торган йортның күршесендәге ишегалдына кереп китте.

Мәскәүгә декадага баручыларга әзерләнер өчен «Совет» кунакханәсеннән махсус номерлар биргәннәр иде. Фәрит тә, күрәсең, шунда балетын әзерләү белән мәшгульдер. Ә Мехчылар клубында репетицияләр үткәреләдер. Галактионовта яши, димәк.

Декадага әзерлек башлангач, опералларда җырларга, балетта биергә артистлар җитешмәве ачыкланды. Казанда гына түгел, Мәскәүдә дә баш вата башладылар. Казанга төрле театрлардан опера һәм балет артистларын, музыкантларын җибәрергә булдылар. Галина Сачек та Украинаның Днепропетровск музыкаль драма театрыннан килгән балерина иде. Вакытлы командировкага гына җибәрелгән кыз белән Фәрит Яруллин арасында мәхәббәт уты кабынып, аңа шулай итеп мәңгегә Казанда торып

калырга насыйп булды. Тик Фәрит белән аларга ярты ел да бергә яшәргә язмаган булып чыкты.

Салих иҗат йортыннан кайтып төште. Ләкин театрда аны көтеп торучы юк иде. Барысы да декада мәшәкатьләре белән мәшгуль: репетицияләр бара; язучылар, композиторлар алып барасы әсәрләрен камилләштерү белән шөгыльләнәләр. Бар да кызу эштә. Салих театрга кереп чыкты да, Фәритнең кичәге чакыруын искә төшереп, Бауман урамына төшеп китте. «Совет» кунакханәсенең икенче катында кайсыныңдыр кызып-кызып, рояльдә уйнаганы ишетелә иде. Нигезендә пентатоника яткан ниндидер халыкчан да, көнбатыш аһәңнәре дә яңгырап-яңгырап киткән музыка ишетелә. Салих музыка ишетелгән икенче катка күтәрелде. Бу клавишаларга бөтен гәүдәсе белән ятып, дәртләнеп-дәртләнеп уйнаучы пианист Фәрит Яруллин булып чыкты. Ул клавишаларда бармаклары белән түгел, бөтен уч төбе белән йөгергән сыман иде. Янында дүрт-биш кеше. Алар дөньяларын онытып, композиторның әсәрләнеп уйнавын күзәтәләр. Яннарына Сәйдәш килеп басканга да игътибар итмәделәр. Фәрит либреттога кертелгән үзгәреш өчен яңа музыка язган да шуны авторларга уйнап күрсәтүе икән.

– Булган бу, – дип куйды тыңлаучыларның берсе. – Килешәсеңме, Әхмәт?

Ул либретто авторы Әхмәт Фәйзигә мөрәҗәгать итте. Әхмәт килешәм дип баш какты да, шунда яннарында басып, үзләре белән бергә музыка тыңлаган Сәйдәшне күреп алды.

– Бәй, Салих абый, син дә мондамыни?!

Салихтан өч кенә яшькә кече булса да, ул аңа абый дип дәшә иде.

– Бауман урамында нинди матур музыка ишетелә икән дип кергән идем менә, – дип шаяртып алды Салих. – Шүрәле килгән икән Кырлаеннан.

– Ә-ә, Салих абый, килдегезме? Әйбәт булган. Сез дә тыңладыгызмы? Менә Былтырны туйга киендерү моментын тасвирлый торган сюитаны яңарткан идем. Шуны тыңладык, – дип Фәрит Салихка бакты.

– Әйбәт музыка, – диде Салих.

– Әйдәгез, бүлмәгә керик. Фикерләрен тыңлыйк иптәшләрнең, – диде дә, Фәрит пианино яныннан торып, бүлмәсенә таба атлады. Ул озын коридорның башында ук урнашкан тугызынчы бүлмәдә шөгыльләнә икән. Бүлмәгә Әхмәт Фәйзидән кала тагын дүрт кеше керделәр. Аларның берсе заманында Салих белән бергә театрда эшләп алган биюче Барый Әхтәмов иде. Салих шулай ук Ленинградтан килгән балетмейстер Якобсонны да белә, Ливадиягә китәр алдыннан күреп калган иде. Ә менә, күрәсең, бер ир белән хатынны беренче тапкыр күрүе иде.

– Таныш булыгыз, композитор Салих Сәйдәшев, – дип таныштырды аларны Фәрит Салих белән. – Ә болар – Ленинград операсы һәм балет тетры биючеләре Нәгыймә һәм Габдрахман Кумысниковлар.

– Балтачеева, – дип төзәтте үзенең фамилиясен Нәгыймә дигәне, Салихка кулын сузып.

– Бик яхшы, – диде Салих.

– Балетмейстер Якобсон, – дип, Фәрит, Салихка инде таныш булган, атлет кыяфәтле утыз яшьләр тирәсендәге егеткә күрсәтте.

– Ничек фикерегез, Салих абый? Сез дә тыңладыгыз шикелле.

Салих музыканы башыннан ук ишетмәгән иде. Ләкин тыңлаган

кадәресе анда матур тәэсирләр калдырды. Хәтта аның оркестр яңгырашы да колагында тора иде. Бию өчен бик матур көй.

– Мин бераз соңрак килдем. Башыннан ук ишетмәдем. Ләкин матур музыка дип әйтер идем. Сыгылмалы, бию өчен ятышып торган, әлегә күренмәсә дә, бию күренешен күз алдына китереп бастыра торган музыка, – диде ул.

– Булган бу! – диде Якобсон. – Либреттога туры килеп тора.

Либретто авторы белән Якобсонның теләге буенча үзгәртеп язылган сюита иде бу. Шуңа күрә калган тыңлаучыларның фикерләре инде әһәмиятле түгел иде. Шуның белән фикер алышуны тәмамлап та куйдылар.

– Хәзер моның тиз генә оркестр өчен партитурасын язарга да, клубка илтеп бирергә кирәк, – диде Якобсон. – Яхшы, Фәрит эшләсен, таралышыйк.

Барысы да үз бүлмәләренә таралыштылар. Бүлмәдә Фәрит белән Салих кына торып калды.

– Салих абый, безнең монда чәй кайнатып эчәргә дә ярамый. Әйдәгез, ресторанга төшәбезме әллә? Бераз сөйләшеп утырырбыз.

– Соңыннанрак, бәгырь. Син бит балетның ноталары белән таныштырам дигән идең.

– Ә, әйе шул. – Ул өстәл тартмасыннан бер өем кәгазь чыгарды. – Менә алар. Бу – клавир. Партитуралары клубта, оркестрга шөгыльләнергә алып киттеләр.

– Ярый, клавирын күреп тә аңларга була, – дип, Салих ноталарны карарга кереште. Ә Фәрит балетны язган вакытта булган хәлләр турында сөйли башлады.

– Мин моны, дөресен генә әйткәндә, сез Ливадиядә булган вакытта язып чыктым. Сез дә берәр опера язып кайткансыздыр инде.

– Юк, бәгырь. Яза башлаган эшем бар иде. Фәтхи абый белән башлаган идек. Аны төрмәгә утырткач ташладым. Кул бармый. Язып чыккан булсам да, халык дошманы либреттосына язгансың дип куймаслар иде.

– Шулай шул. Минем дә бит катлаулы ситуация килеп туды элекке варианты белән. Монысын өр-яңадан эшләдем, арты елда дияргә була. Гыйнвар белән май арасында.

– Ник алай?

– Мин бит «Шүрәле»не Мәскәүдә чакта ук язган идем. Литинский белән бергәләп, аның киңәшләрен тыңлый-тыңлый. Казанга кайткач, Гай Таһировның да «Шүрәле» поэмасына нигезләнеп, балалар өчен бер пәрдәле балетка либретто язганын ишеттем. Сәнгать эшләре идарәсе хуплаган, опера театры белән килешү дә төзегән булып чыкты. Шуннан соң Литинский хат язып, минем балетның инде язылган булуын, кызыклырак килеп чыгачагын дәлилләгәч, Гай абый үзенең либреттосын өстәл тартмасына салып куярга мәҗбүр булды. Ә миңа мондагы иптәшләр, дуслар белән карап чыккач, күп кенә урыннарга төзәтмәләр кертергә туры килде. Өр-яңадан язган кебек булды инде. Абдулла Алиш тырышлыгы белән балет музыкасының берничә кисәген радиодан эфирга та чыгардык. Халык яратып кабул итте. Ишеткәнсездер, бәлки.

– Ишеттем. Алар фортепиано башкаруында гына иде бит. Оркестр белән яңгыраса, эффекты тагын да зур булачак әле. Котлыйм, бәгырь,

булдыргансың! Беренче татар балетын язган композитор булып тарихка керәчәксең, болай булгач! Инде исән-сау булып, Мәскәүдә башкарылуын күрергә язсын! – Салих шулай диде дә, ноталарны җыйнап, Фәриткә кире бирде. – Мә, җыеп куй.

Алар шуннан соң кунакханәнең рестораныла төшеп, чәйләп алдылар да, Салих саубуллашып кайтып китте. Шуннан соң алар тиз генә күрешмәделәр. Июньнең егерме икесендә балетның клавирын Фәрит үзе Мәскәүдән килгән комиссиягә уйнап күрсәтергә тиеш иде. Ләкин бу көнне ил фортепиано клавишалары чыгарган моңнар урынына бомбалар гөрселдәгән авазларга күмелде.

Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрү мәсьәләсе көн тәртибеннән төшеп калды. Мәскәүнең үзен саклау мәсьәләсе көн үзәгенә килеп басты.

Сугышның беренче көннәрендә үк хәрби комиссариатлар тирәсе үз теләкләре белән фронтка китүчеләр, аларны озатырга килүчеләр белән тулды. Һәркайда: завод-фабрикаларда, предприятиеләрдә, оешмаларда, сугышка каршы митинглар үткәрелә башлады. Партия өлкә комитетында завод-фабрикаларның, оешмаларның, уку йортларының, иҗат берлекләренең җитәкчеләрен җыеп, сугышка җибәрмәс өчен бронь бирелергә тиешле кешеләрнең исемлекләрен төзеделәр. Язучылар һәм Композиторлар союзларында да төзеделәр андый исемлекне.

Язучылар союзы идарәсенең чираттагы утырышы оешманың эшчәнлеген хәрби шартларга яраклаштырып үзгәртү мәсьәләсенә багышланды. Каләм ияләре алдында чыгыш ясарга килгән хәрби комиссариат вәкиле сүз алып: «Совет халкы бердәм булып, фашистларга каршы көрәшкә күтәрелде, Язучыларның урыны да бүген фронтта, армияләр каршында чыга торган гәзит редакцияләрендә. Сез совет солдатларының тиңдәшсез батырлыгын чагылдырган әсәрләрегез белән җиңүгә үз өлешегезне кертергә тиешсез!» – диде. Аның чыгышын хуплап, күп кенә язучылар үзләренең фронтка китәргә, фронт газеталары редакцияләрендә эшләргә теләкләре булуын белдерделәр. Озак та үтмәде, Язучылар союзында исәптә булган 54 әгъзаның егерме сигезе өсләренә шинель киде.

Композиторлар союзы идарәсендә дә булды шундый утырыш. Ләкин ул сугышка җибәрмәү өчен композиторларга бронь сорау мәсьәләсенә багышланды. Партия өлкә комитеты өчен шундыйларның исемлеген төзеделәр. Композиторлар берлеге әле зур түгел, анда нибары унике әгъза иде. Һәр композиторны берәмтекләп санадылар. «Кемне генә сугышка җибәрергә соң?» дигән сорау алдында торып калды Җиһанов. Бик катлаулы һәм җитди сорау иде бу. Әлбәттә инде, яшьрәкләрне һәм каядыр эш урыны булмаганракларны. Шундыйлардан ике кеше табылды: Мәсгут Латыйпов һәм Фәрит Яруллин.

Көннәрнең берендә Галактионов урамында Салих белән Фәрит кабат очраштылар.

– Мин фронтка китәм, Салих абый, – диде Фәрит.

– Ничек инде? Әдәбият-сәнгать әһелләрен фронтка җибәрмәү турында сүз бара бит. Алар җиңүне якынайту өчен үзләренең әсәрләре белән көрәшергә тиеш, дип яздылар. Мәскәүдән, Ленинградтан бер көтү язучы,

композитор, артист, музыкант килеп тулды Казанга. Язучылар союзы, гәзит-журналлар, китап нәшриятлары шулар белән шыплап тулган. Сөйләштеңме соң Җиһанов белән? Бронь белән ул шөгыльләнә бит.

– Юк шул. Минем хатын да бала табарга тиеш тиздән. Фронтка китүне кичектереп торганда, начар булмас иде.

– Шулайдыр шул. Син бит әле беренче татар балетын язган композитор да. Бу ничек була инде? Шундый талантлы егетне сугышка җибәрәбезмени инде? Беренче татар балеты дип, Мәскәүгә хәтле алып барып күрсәтергә җыенып йөргәндә, шуның авторын үлемгә җибәрәбезмени?! Юк, бәгырь, үзем барып сөйләшәм Нәҗип белән. Ул моңа юл куймаска тиеш.

Салих шул сөйләшүдән соң туп-туры Мәдәният йортына юнәлде. Килсә, мондагы оешмаларның кайсын кая күчереп бетергән булып чыктылар. Мәдәният йорты хәрби комиссариатның солдатка чакырылучыларны фронтка озату үзәгенә әверелгән икән. Композиторлар союзы да каядыр чыгып киткән. Инде каян табарга бу Җиһановны?

Фәрит Яруллинның сугышка җибәрелүенә үзе гаепле сыман тойгы калды Салихның күңелендә. Шулкадәр әрнеде, шулкадәр гарьләнде. Ничек инде шундый талантны сугышка җибәрергә була? Мәскәү сәнгатькарләре җыйналышып Казанга кайткан анда. Ә Казан үзенең бердәнбер баласын яклап кала алмый. Ул кабат үзенең халык дошманы дип, төрмәләргә озатылган дусларын искә төшерде. Бу да шундый ук нәрсә түгелме соң инде?

Һәм менә бүген, кирәкмәгән хезмәткәр буларак, эштән куып чыгарылганнан соң, үзенең җәмгыять өчен артык кешегә әйләнгән күпме дустын искә төшергәндә, ул Фәрит Яруллин турында да уйлап куйды. Ул да бит артык, кирәксез кешегә әверелгән кырык беренче елда. Синең талантың да, беренче татар балетын иҗат итүең дә беркемгә дә кирәк түгел икән бит! Ничек гарьләнмисең дә, ничек шул әрнү белән яшәргә кирәк шушы җәмгыятьтә?!

24 июльдә Фәрит Яруллин сугышка чыгып китте.

Алдагы көнне Сәйдәш аның белән саубуллашырга керде. Фәрит нечкә күңелле булса да, үзен горур тота иде.

– Күптән түгел Җәлил белән очрашкан идем. Үзенең бер шигырен бирде. Шул шигырьгә көй яздым. Матур гына җыр туды – «Соңгы көрәшкә». «Кызыл Татарстан»ның унөченче июль санында басылып чыкты.

– Күрдем, бәгырь. Бик вакытлы, кирәкле җыр. Безгә хәзер менә шундый җырлар иҗат итәргә кирәк. Сине генә сугышка җибәреп әрәм итәләр.

– Муса да сугышка китәргә йөри икән. Алиш, Кутуй, Баян, Фәтхи, Саттарлар – барысы да тиздән өсләренә шинель киячәкләр. Алар киткәндә без генә калыйкмыни читтә посып? Үкенмим, Салих абый. Үз теләгем белән китәм. Тик менә язучылар берсен-берсе җыйналышып озаталар. Безнең белән генә хушлашырга уйлаган кеше юк Союзда. Шулмы инде дуслык? Шунысы үкендерә.

– Исең китмәсен, бәгырь. Чын дусларны фронтта табарсың. Окопта ятканда, дошманга каршы мылтык тотып һөҗүмгә барганда. Исән-имин йөреп, дошманның муенын сындырып, илгә әйләнеп кайтырга язсын.

– Шулай анысы. Тагын бер үкенеч кала. «Шүрәле»нең сәхнәгә менгәнен күрәсе иде.

– Күрерсең. Дошманны дөмектереп, җиңү белән әйләнеп кайткач, һичшиксез күрерсең, бәгырь.

Сәйдәш калтыранган тавыш белән әйтте бу сүзләрне. Шулай диде дә, күзендә ялтырап яше күренде. Ул, кесәсеннән кульяулык чыгарып, күз төпләрен сөртте.

Фәритне зурлап озатучы булмады. Ул хәтта Галясына да барырга рөхсәт бирмәде Мәдәният йортына. Бары тик кочагына алып, озак кына басып торды, иреннәреннән суырып үпте һәм аның юл кирәк-яраклары дип тутырган капчыгын иңенә салды да саубуллашып, өйдән чыгып китте. Аны Ульяновск шәһәренә пехота училищесына кыска сроклы курсларга укырга җибәрделәр. Ә берничә айдан хатыны кыз бала тапты. Аңа ул Фәритенең сүзен истә тотып, Наилә дип исем кушты.

**10**

Сугыш башлануга, Татар дәүләт академия театрын да, опера театрын да Зур рус театры бинасына күчерделәр. Академия театры бинасында сугышта яраланган солдатларны дәвалау өчен госпиталь ачылды. Театр директоры Мингали Дәүләтшин аның комиссары итеп билгеләнде. Спектакльләр тукталды. Яшь артистлар фронтка китте. Салих солдатка каралу яшеннән узган иде инде. Аның кебекләргә дә эш табылды. Артистлар төркем-төркем булып госпитальләргә, фронтларга солдатларның сугышчан рухын күтәрү өчен концертлар белән йөри башладылар. Көннәрнең берендә Мингали Дәүләтшин Сәйдәшевне һәм Фәйзулла Туишевны дәваланучы яралылар алдында чыгыш ясар өчен госпитальгә чакырды.

Иң кадерле, якын дусларының халык дошманы дип юкка чыгарылуы, инде дөньялар тынычланды бугай дигәннән соң да Фәтхи Бурнаш дустының кулга алынуы, спектакльләренең репертуардан төшерелүе, җырларының җырланмый башлавы хәсрәтеннән әле һаман да айный алмыйча йөргән Сәйдәшкә үзенә күрә бер юаныч, тынычлану өчен күпмедер мөмкинлек иде бу. Ул госпитальгә барырга бик теләп риза булды. Җитмәсә, аның театр бинасында урнашкан булуы җанга ниндидер җылылык бирә. Зал тутырып яткан яралы солдатлар аңа әле кайчан гына аның спектакльләрен карарга килгән тамашачыларны хәтерләттеләр. Җитмәсә, алар барысы да Татарстан егетләре иде. Госпиталь комиссары Дәүләтшинга ияреп, Сәйдәш белән Туишев килеп кергәч, солдатлар да спектакль караучы шул тамашачылар кебек ничектер дәртләнеп, гөрләшеп алдылар. Күрәсең, араларында татар егетләре шактый иде, алар музыкантларны шундук таныдылар.

– Исәнмесез, кадерле дуслар! – дип башлады яралылар белән очрашуны Мингали Дәүләтшин. – Бүген сезнең белән очрашуга халкыбызның күренекле музыкантларын, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклеләре Фәйзулла ага Туишев белән Салих Сәйдәшевне чакырдык.

Ул шулай дигәч, солдатлар тагын бер гөрләшеп алдылар.

– Таныйбыз, таныйбыз!

– Зур рәхмәт! Яраткан кешеләребез.

– Яраланмаган булсак, кайчан күргән булыр идек үзләрен?!

– Бәхетебез бар икән.

Солдатларның бу сүзләреннән күңеле күтәрелеп киткән Салих:

– Их егетләр! Бәхет шунда гына булса икән! Менә сезнең, яралы булсагыз да, исән калуыгыз – үзе зур бәхет, – дип куйды.

– Кадерле дуслар, Сәйдәшев белән Туишев абыйларыгыз бүген сезне үзләренең иҗатлары белән таныштырыр. Гармунда да уйнап күрсәтерләр, сорауларыгызга да җавап бирерләр. Тартынып тормагыз, мөмкинлектән файдаланып, кызыксындырган сорауларыгызны биреп калыгыз. Мондый кешеләр белән гел очрашып тормассыз, – диде дә Дәүләтшин, – тагын бер кунак килергә тиеш иде, нишләптер соңара, – дип, өлкән шәфкать туташын үз урынына калдырып, залдан чыгып китте.

Фәйзулла Туишев очрашуга берсеннән-берсе бәләкәй дүрт-биш гармун күтәреп килгән иде. Сәйдәшнең: «Мин нишләрмен икән?» – дигән соравына ул: «Шушы гармуннар икебезгә дә җитә инде», – дигәч, Салих та гармун уйнарга җыенды.

– Без сүз осталары түгел. Бөтен белгән һөнәребез – гармун. Шуңа күрә сез сорагыз, нинди көй ишетәсегез килә, без шуны уйнарбыз, – диде Туишев.

– Башта бер-ике көйне искә төшереп үтик инде, Фәйзулла абый, – диде Салих.

– Була ул, – дип, Туишев гармуннарының иң зурысын кулына алды да «Иске кара урман» көен уйный башлады.

Ул уйный гына башлаган иде, залга Мингали Дәүләтшин һәм Фәттах Маннапов атлы җырчы килеп керделәр. Фәйзулла аларны күреп туктап калды.

– Уйнагыз, уйнагыз, Фәйзулла ага, – дип, Мингали, Салих янындагы икенче урындык янына килеп, Фәттахка утырырга кушты. Туишев уйнавын дәвам итте.

Фәттах Салих белән кул биреп күреште дә:

– Соңардым бераз. Башлап җибәргәнсез икән, – дип пышылдады.

– Зыян юк. Бу әле беренче номер гына, – диде Салих.

«Иске кара урман»нан соң Туишев «Су буйлап»ны уйнарга кереште. Шунда Фәттах торып басты да:

– Фәйзулла агай, мин кушылып җырлыйм булмаса, – диде.

– Җырласын, җырласын, – диде яралылар арасыннан берәү. Фәттах Фәйзулланың җавап биргәнен дә көтмичә, өзелгән музыканы ялгап җырлый да башлады.

Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул.
Караңгы төн, болытлы көн –
Без аерылган көн бит ул.

Җырга яралылар арасыннан да берничә егет кушылды. Җыр беткәч, җырлаучы егетләрнең берсе Туишевка: «Фәйзулла абый, сезгә сорау бирергә мөмкинме?» – дип сорады.

– Мөмкин, әлбәттә, – диде гармунчы.

– Фәйзулла абый, мин – сезнең авылдашыгыз, – диде егет.

– Шулаймыни? Түгел Багаданмыни син? – диде Туишев.

– Әйе, Түгел Багадан, Мәләкәс якларыннан.

– Түгел Багада беркемем дә калмады шул инде, туганкай, – диде Туишев.

– Шулай да безнең авылда сезне бик яхшы беләләр һәм безнең авылдан чыккан дип горурланалар.

– Нинди сорау бирергә теләгән идең соң, туганкай? – диде Туишев.

– Минем фамилиям дә Туишев бит. Туишев Баһман.

– Шулаймыни?

– Шулай шул. Без бер нәселдән түгел микән дип сорамакчы идем.

– Кем белсен инде аны? Без бит миңа ун яшь тулганда ук, гаиләбез белән Мәләкәскә күченгәнбез. Ундүрт бала булып, җидебез генә исән-сау үскәнбез. Бәлки авылда әти белән әнинең туганнары калган булгандыр. Анысын мин белмим шул. Бәлки калмагандыр да. Әтинең дә, әнинең дә бер дә әйткәннәре булмады.

– Безнең ярты авыл Туишевлар бит. Димәк, бер тамырдан таралганнар.

– Анысы шулайдыр, килешәм. Син гармунда уйный беләсеңме соң?

– Белмим шул.

– Алай дисәң, безнең гаиләдә дә миннән башка берсе дә уйнамый.

– Ярый, Фәйзи агай, туганнар да булмадыгыз. Уйнавыгызны дәвам итсәгез иде. Очрашудан соң сөйләшерсез, бәлки, – дип, яралы солдатлар арасыннан башкалардан өлкәнрәк булуы күренеп торган бер карт солдат аларны бүлдерде.

– Гафу, егетләр. Чит-ят җирдә авылдашыңны, якташыңны очрату күңелле бит ул. Бу адаш егетнең дә Казан госпиталендә якташымны очраттым дип куануыдыр. Гаепләмәгез инде. Хәзер мин сезгә шырпы тартмасы хәтле гармунда уйнап күрсәтәм.

Ул шулай диде дә костюм кесәсеннән шырпы кабыннан чак кына зуррак гармун чыгарып, «Күн авылы» көен уйный башлады.

– Вәт булдыра! – дип куйды солдатлар арасыннан берсе.

– Өздерә генә!

Туишев «Күн авылы»ннан «Җәмилә»гә, аннан соң «Баламишкин» һәм шулар ише җитез уйнала торган башка халык көйләренә күчеп, тезмә башкарды. Солдатларның күңеле булып, гөрләтеп кул чаптылар. Туишевтан соң Фәттах Маннапов тагын берничә җыр башкарды. Соңгы җырым дип, «Каз канаты» көен игълан итте:

– Ә хәзер композитор Салих Сәйдәшев эшкәртүендә халкыбызның «Каз канаты» көе, – диде. – Аккомпаниатор – Салих Сәйдәшев үзе!

Сәйдәшев исемен ишетүгә, яралылар, инде җырны тыңлап бетергәннәр диярсең, шаулашып кул чабарга керештеләр.

– Ашыкмагыз, җырламадым бит әле, – диде Фәттах.

– Җырлагач тагын чабарбыз, – диде кайсыдыр.

Маннаповтан соң чират аерым чыгыш ясау өчен Салих Сәйдәшевкә бирелде.

– Без сезнең «Кызыл Армия маршы»н тыңлап, фронтка киттек, Салих абый. Җырларыгызны да бик яратабыз. «Наёмщик»тан Батырҗан җырын җырлагыз әле, – дип сорады шунда Туишевка кисәтү ясаган карт солдат.

– Мин җырлый белмим шул, уйнап кына күрсәтә алам. Әйдәгез, хәзер

мин дә сезгә үз җырларымның көйләренә тезмә уйнап күрсәтим башта. Аннары Фәттах дус сез сораган җырларны башкарыр. Килештекме? – диде Салих. Ул шулай диде дә, Фәйзулланың иң олы гармунын алып, үзенең берничә әсәренә попурри башкарды. Шулардан соң аерым игълан итеп, «Наёмщик»тан вальс уйный башлады да яралыларга мөрәҗәгать итеп:

– Ә хәзер бии алганнарны рәхим итеп вальс әйләнергә чакырам! – диде.

Аягына баса алганнар чынлап та, торып басып, койка араларындагы буш мәйданчыкка чыгып, вальс әйләнергә тотындылар. Карт солдат та яшьлеген искә төшереп, иң беренче булып кунакларны озатып йөрүче шәфкать туташы янына килеп, аны биергә чакырды. Солдатларны дәвалаучы башка шәфкать туташларына да кавалерлар табылды. Вальс тәмамлангач, уртага тагын Фәттах Маннапов чыкты.

– Ә хәзер «Наёмщик» музыкаль драмасыннан Батырҗан җыры, – дип игълан итте һәм җырлый да башлады:

– Сау бул, минем туып үскән ямьле илем,
Сау булсыннар урман, басу, кырларым,
Сау булсыннар печән чапкан болыннарым,
Сау булсыннар даннар тоткан Сабан туйларым...

Батырҗаннан соң «Хуш авылым»ны сорап җырлаттылар.

– ...Матур була, ямьле була
Яз көннәрең, җәйләрең.
Исән булсам, бер кайтырмын
Язлар кебек әйләнеп.

Хуш, авылым, сау бул,
Сәламнәр көт,
Таң җилләре искәндә.
Мин җырлармын сине сагынып,
Өзелеп искә төшкәндә.

Болар икесе дә яралы егетләрнең сугышка җырлап чыгып киткән җырлары иде.

Очрашу уйламаганда музыкаль кичә рәвешен алды. Барысының да күңеле булды. Салих Сәйдәшев җырларын тыңлаганда, күбесенең күзләре яшьләнгән иде. Алар үзләренең туган авылларын, анда калган сөйгәннәрен, әти-әниләрен, балаларын күз алларына китергәннәр иде.

Очрашуны Сәйдәш «Кызыл Армия маршы» белән тәмамлады.

**11**

Илдә сугыш бара. Язучыларның күбесе фронтта, берәүләр – кулларына корал тотып, фашистларга каршы турыдан-туры көрәштә катнаша; икенчеләре – фронт гәзитәләре чыгаруда, ялкынлы сүзләре белән солдатларны фашистларга каршы аяусыз сугышка рухландырган язмалар, әдәби әсәрләр иҗат итү хәстәрендә; өченчеләре – тылда чыга торган матбугат битләрендә, радиотапшыруларда халыкның дошманга каршы алып барган көрәшен чагылдырган әсәрләр иҗат итәләр, радиотапшырулар

әзерлиләр, госпитальләрдә яралы совет солдатлары алдында чыгышлар ясыйлар; фронт концерт бригадалары төзеп, сугыш кырындагы солдатлар өчен концертлар куюны оештыралар. Музыкантлар, артистлар, шул исәптән композитор Салих Сәйдәшев тә өченчеләр сафында – әледән-әле госпитальләрдә, фронт концерт бригадаларында сугышчылар белән очраша. Сәйдәшев инде берничә мәртәбә театрда үзенең иҗат кичәсен оештырып, билет сатудан кергән акчаны сугышчыларга җылы киемнәр тегү өчен Кызыл Армия фондына тапшыртты. Сугышчылар алдында куела торган концертларда җырлар өчен берничә әсәр иҗат итте. Кави Нәҗми белән бергәләп, алар «Поход маршы» дигән җыр иҗат иттеләр. Тынлы оркестр өчен «Ватан маршы» дигән әсәр язды.

1942 елда опера һәм драма театрлары яңадан элекке бинага күчтеләр. Чиратлашып әле драма, әле опера спектакльләре күрсәтелә башлады. Нәҗип Җиһановның «Качкын», «Алтынчәч» опералары, драма театрының төрле елларда чыккан спектакльләре уйналды. Хәбибулла Ибраһимов белән Салих Сәйдәшнең әле 1922 елда ук татар театры сәхнәсендә уйналган «Башмагым» әсәре нигезендә Таҗи Гыйззәт иҗат иткән либретто буенча Җәүдәт Фәйзи музыкаль комедия язып, опера театрында шуның премьерасы булып узды. Опера театры яшь композитор Фәрит Яруллин иҗат иткән «Шүрәле» балетын куярга әзерләнә башлады. Урамнарда хәтта булачак балетның афишалары да эленде. Фәрит үзе сугышка киткәндә, балетының клавирын опера театрының директоры Ильяс Әүхәдиевка биреп калдырган иде.

Салихлар гаиләсе театр ишегалдындагы янкормада артистлар Шакир Мәҗитов һәм Фатыйма Камалова белән күршеләр булып яши иде. Шакир ул елларда үпкә чире белән изаланды. Шуның аркасында сугышка да бармый калды. Салих бик еш кына кечке якта күршеләренә кереп, хәлләрен белешә торган иде. Шакир үзе дә гади артист кына түгел, пьесалар язгалый, көйләр дә иҗат итә. Соңгы керүендә ул Салихка яңа язган җырын гармунда уйнап күрсәтте.

– Бер җыр яздым бит әле, – диде ул, тумбочка өстендә торган гармунын кулына ала-ала.

– Йәле, йәле, уйнап күрсәт.

– Фатыйма җырлап ук күрсәтер дип торам, – диде Шакир һәм күрше бүлмәдә табын әзерләп йөрүче хатынына дәште: – Фатыйма, бире кер әле.

– Хәзер, биш минут, – дип җавап бирде Фатыйма. – Чәйнегем кайнап чыгып килә.

Кухня ягыннан чәйнек кенә түгел, керосинкада утырган табада нәрсәдер пешә дә иде бугай, май чыжылдаган тавыш та ишетелә иде.

– Сибгат дустан хат алдым. Хәрәкәттәге армиядә, Ржёв тирәсендә сугыша икән. Взвод командиры итеп билгеләгәннәр.

– Ниләр яза Сибгат? Һаман чигенәләрме?

– Чигенәбез дигән шул. Фашист Сталинград юнәлешендә алга ыргыла, ди. Мәскәү астындагы уңышсызлыгын Сталинградны буйсындырып капламакчы була, каһәр, – диде дә Шакир кырых-кырых йөткерергә тотынды. – Ичмасам бу чир аяктан екты. Кеше сугышканда, өйдә ят инде, караватта аунап.

– Алай димә син. Менә бит, җыр яздым, дисең. Җырларың белән сугышчыларның, тылдагы халыкның рухын күтәрәсең. Ул да бит җиңүгә керткән бер өлеш. Мәскәү астында кирәген алды бит, мәлгунь, Сталинградка да үз башына ыргыла.

Шакир гармунын бер-ике шыгырдатып алды да, моңа кадәр таныш булмаган моңлы, салмак көй уйный башлады. Бер куплетын уйнап чыккач, үзенең карлыккан тавышы белән җырлап җибәрде:

– Күз карашым нинди уйчанланды,
Син беләсең микән, юк микән?
Син киләсе юлдан күзем алмый,
Сине көтәм, иркәм, кич-иртән.

Ул арада бүлмәгә Фатыйма кереп, ишек яңагына сөялеп, җырны тыңлый башлады. Шакир аның керүен күреп, җырлаудан туктады.

– Әйдә, дәвам ит әле, – диде. Үзе уйнавын яңадан башлады. Фатыйма гармунга кушылып җырлап җибәрде.

Күз карашым нинди уйчанланды,
Син беләсең микән, юк микән?
Син киләсе юлдан күзем алмый,
Сине көтәм, иркәм, кич-иртән.

Яратам мин, әйтмим генә аны,
Син йөрәкне күреп белмисең.
Кошлар кайта безгә, син һаман юк,
Син һаман юк, никтер килмисең.

Бакчабызда шомырт агачлары
Җәй буена сине көттеләр.
Син килмәдең, көзге җилләр инде
Яфракларын җиргә сиптеләр.

Бу вакытлы гына юксынуым,
Дусларымның исе китмәсен;
Тик ярата белгән кеше генә
Сагына шулай үзенең иркәсен.

Фатыйма җырлап бетергәч, өчесе дә беркавым сүзсез тынып тордылар.

– Шәп җыр! – дип куйды Салих, тынлыкны бозып. – Сагыну җыры. Заһидулла белән Мусаның «Сагыну»ы кебек.

– Шигырьнең исемен «Юксыну» дип куйган Сибгат.

– «Юксыну» дисәң дә ярый. Шәп. Сугышта йөргән сөйгәнен юксынып җырлаучы кыз җыры. Менә бит, туры килеп тора, сугыш чоры өчен бер дигән җыр! Сугыштан соң да җырланачак. Мәңгелек җыр бу!

– Мин дә шулай дим, – дип, Салихны куәтләде Фатыйма.

Салих шунда Шакирдан гармунын сорап алды.

– Каяле, үзем уйнап карыйм. Иртәгә бер төркем артистлар белән госпитальгә барабыз, Кабан арты мәчетендә урнашкан госпитальгә. Шунда Зифага биреп җырлатырмын. Сүзләрен дә күчереп алырмын әле.

Салихның ишеткәнне хәтерләү сәләте бик көчле иде. Ул җырны бер

ишетүгә күңеленә сеңдергән. Шунда ук үзе уйнап, үзе үк җырлый да башлады.

Күз карашым нинди уйчанланды,
Син беләсең микән, юк микән?
Син киләсе юлдан күзем алмый,
Сине көтәм, иркәм, кич-иртән...

– Гениальный җыр! Бөтен халык яратып җырлаячак һәм тыңлаячак. Елый-елый тыңлаячак! – дип куйды ул, җырлап бетергәч.

– Бар, Салих абый, Сафия белән малайларны чакырып кер, коймак пешергән идем. Бергәләп чәй эчеп алырбыз, – диде Фатыйма.

– Кирәкмәс иде. Ашадык-эчтек. Тамак тук, – дип каршы килде Салих.

– Тамак туктыр. Сөйләшеп утырырбыз. Югыйсә эштә дә гел шул сугыш кайгысы, өйдә дә шуны уйлыйбыз, – дип, Шакир хатынына кушылып, күршеләрен чәйгә чакырды.

– Кая, үзем чакырып чыгыйм әле йөгертеп кенә, – дип, Фатыйма үзе керергә әзерләнде.

– Булгач-булгач, ишле булсын, Хәким белән Галияне дә дәш инде булмаса. Балаларсыз гына утырыйк. Аларга коймакны әниләренә тоттырып чыгарырсың, – диде Шакир хатынына. – Күршеләр булып яшибез, күрешкән дә юк, бу сугыш дип, тәмам кәзәңкәләргә кереп постык, тараканнар кебек.

Күршедә үк Хәким Сәлимҗанов белән Галия Нигъмәтуллиналарның ишле гаиләсе дә яши иде.

– Ярар-ярар. Табында булганы белән. Күңелең киң булсын, җитәр, – диде Фатыйма һәм күршеләрне дәшәргә чыгып китте.

Күршеләр ялындырып тормадылар. Бераздан Хәким белән Галия дә, Сафия дә бер-бер артлы кереп җиттеләр.

– Нинди мәҗлес бу монда? Илдә сугыш барганда? – диде Хәким керә-керешкә.

– Мәҗлес түгел, худсовет, бәгырь, – диде Салих. – Шакир дустыбыз җыр язган. Шуны тикшерәбез. Минем фикер генә канәгатьләндермәде авторны. Сезгә дә тыңлатып карарга булдык.

– Шулаймыни?! Шундый зур ышаныч күрсәткәнегез өчен рәхмәт инде, күршекәйләр. Кая, тыңлап карыйк булмаса.

– Утырышыгыз. Кемгә – карават, кемгә – урындык, – диде дә Шакир кулына гармунын алды.

Барысы да кайсы кая җайлашып утырыштылар.

– Фатыйма, син җырла инде, бәгырь, – диде Сәйдәш. – Шакир аккомпанировать итәр. – «Юксыну». Шакир Мәҗитов музыкасы, Сибгат Хәким сүзләре. Җырлый – Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасының отказ алган артисткасы Фатыйма Камалова.

– Шаяртма инде, Салих абый. Кеше әллә ни уйлар.

– Әйдә, бәгырь, җырла. Гел елап йөреп булмый инде, шаяртып алсаң да ярый ул бераз. Бигрәк тә яңа җыр тыңлар алдыннан.

Фатыйманың җырлавын тын да алмый тыңладылар.

– Әйбәт җыр булган бит бу! – диде Хәким. – Халык үз итәчәк. Басыйрова репертуарына тагын бер шәп җыр өстәлә икән, бахыр.

– Мин дә шуның тавышын ишетәм бу җырда, – дип куйды Галия, иренең сүзләрен хуплап.

– Тач өстенә бастыгыз. Иртәгә госпитальгә барабыз. Шунда Зифага җырлатырга алып барырмын дигән идем, – диде Салих.

– Тик ятмый икән анда Сибгат дус та. Фронтта, диюем. Бер дигән шигырь язган. Заман кадагына суккан.

– Әйе, яза да безнең егетләр, сугыша да. Корал белән дә тукмый дошманны, каләм белән дә бирә кирәген. Тик менә, чигенәбез, дигән Сибгат. Ржёв тирәсендә сугышалар икән. Взвод белән командалык итәм, дип язган.

– Безнекеләр сугыша. Ә менә рус язучылары җыйнаулашып, Чистайда ята.

– Син, Хәким, сөйләмә андый сүзне. Харап булып куюың бар, – диде Шакир, саксыз сүз ычкындырган күршесен кисәтеп.

– Дөресен әйтәм бит. Әле теге Марина Цветаева дигәне асылынган, ди, бахыр. Рәхәт тормыш эзләп килгәндерме монда? Мәскәвендә генә ятса шунда, ярамаган. Нинди йөз белән килгәндер татарлар арасына, ояты да юк икән?.. Татарны мыскыл итеп, нинди әшәке шигырь язган үзе. Гитлер белән тиңләгән.

– Алай ук түгелдер инде, арттырасыңдыр, – дип куйды Фатыйма.

– Шулай шул менә. Хәзер, сөйлим, искә төшсә тулысы белән.

Хәким шулай диде дә эчтән генә пышылдап, хәтер дәфтәрен актарырга тотынды.

– Әһә, менә искә төште. Тыңлагыз. Исемен «Бишек җыры» дип куйган бит әле. Баласын йоклата, имеш. Бәләкәйдән татарга нәфрәт белән тәрбияләп үстерә сабыен. Хәерсез.

В оны дни певала дрёма
По всем сёлам-деревням:
– Спи, младенец! Не то злому
Псу-татарину отдам!

Днесь – во всей стране богемской,
Да по всем её углам:
– Спи, богемец! Не то немцу:
Пану Гитлеру отдам!

Татарны эт дигән, ә Гитлерны – пан. Шул паннан качып, татарлар янына килеп сыенган үзе.

– Ә безнекеләр сугышта кырыла! – дип хуплап куйды Шакир күршесен.

– Дөрес әйтәсең, бәгырь, – диде Салих һәм бераз сүзсез торганнан соң көрсенеп: – Кайда йөриләрдер безнең Кәрим, Фәтхи абзыйлар? – дип куйды.

– Алай да, сугышка җибәрмичә калырга була иде инде ул Сибгатләрне, Мусаларны, – диде Шакир.

Иренең сүзен дәвам итеп, Фатыйма:

– Җәлилне инде бигрәк тә, – дип куйды. – Союз председателе булып эшләп торган җиреннән. Җитмәсә, өч хатын зар елап калды. Кечә Рауза Хасиятуллинаны күргән идем. Мусадан малай үстереп ята. Быел көзгә

укырга бара икән инде Альберты. Зәкия Садыйкованың да Люциясе койган да куйган Муса инде менә.

– Алар хат алалардырмы Мусадан, белмим. Әминә, җәй башында хат килүдән туктады, бернинди хәбәре юк дип елап алды кичә. Кекин кибетендә күргән идем. Талонга ипи алып ятканда, – диде Галия. – Плингә-мазар төшсә, өчесен дә сатлыкҗан хатыны дип, талонсыз калдырачаклар бичараларны.

– Әйтмә инде. Шушы көннәрдә генә Кутуй да сугышка киткән. Өч баласын Галимәсенә калдырып. Галимә, мескен, көне-төне эштә. Госпитальдә, яралы солдатларны дәвалый.

– Әйтәм аны, радиодан тавышы ишетелми башлады Кутуйның дип йөри идем, – дип куйды Фатыйма, Хәкимнең Кутуй турында әйткән сүзләренең дөреслеген раслагандай.

– Әле ел башында ук Язучылар һәм Композиторлар союзлары бергәләп оештырган митингта ясаган чыгышында Кутуйның фронтка китәргә ашкынуы сизелә иде, – диде Салих. – «Минем вөҗданым шул ерткычлар белән көрәшергә куша. Мин һич булмаса бер немецны теге дөньяга җибәрү турында хыялланам. Ерткычларны юк итмичә торып, мин үземне бәхетле дип саный алмыйм», – дип чыгыш ясаган иде. Минем Кутуйның чыгышларын күп ишеткәнем булды. Бу чыгышы шикелле ялкынланып, ярсып сөйләгәнен беренче тапкыр күрдем шул митингта.

– Алайса, тәки китәргә карар кылган инде. Сталинград өчен сугышка киткәндер инде. Рядовой солдат булып. – Хәким шулай диде дә: – Җәмәгать, без монда нәрсәгә дип җыелганыбызны онытып җибәрдек бугай, – дип, хатынына мөрәҗәгать итте: – Фатыйма, чәең суынган бит. Без монда сүз куертып, коймакларың турында онытып та җибәргәнбез ләбаса!

Фатыйма урыныннан сикереп торды да:

– Коймаклардан авыз итә торыгыз әле. Мин хәзер, чәйне яңартып алыйм, – дип, чәйнеген күтәреп икенче якка чыгып китте.

Башыннан бирле дәшми-тынмый гына тыңлап утырган Сафия дә торып:

– Булышырга кирәк түгелме? – дип, Фатыйма артыннан иярде.

– Ашагыз әле, ашагыз. Бик тәмле була Фатыйма җиңгәгезнең коймаклары, – дип, Хәким күршеләрен кыстарга кереште. – Сугыштагылар сагынадыр майлы коймак ашап, чәй эчеп яшәп яткан матур чакларны.

– Сөйләмә инде, бәгырь, – дип куйды Салих. – Безнең Фәрит Яруллин да китеп барды бит ул каһәр төшкән сугышка.

– Аны да алып калып булгандыр инде ул. Нинди талантлы композитор бит. Ул җырлары, дисеңме, ул «Шүрәле»се. Операга хәтле яза башлаган булган.

– Үзе теләп киткән, диделәр шул.

– Теләсә соң. Шундый композиторны үзе теләгәндә дә җибәрмичә калырга мөмкин булгандыр, – диде Галия, ире белән килешмичә. – Җиһанов ник китми әнә?! Опера язган бердәнбер композитор түгел бит. Ә Фәрит – балет язган бердәнбер композиторыбыз.

– Нишләп бердәнбер булсын? Салих язмадымыни?

– Юк, Хәким, бәгырь, язмадым. Балет язарга талпынып карау гына ул нәрсәләр. Фәрит шикелле төгәлләнгән, оригиналь әсәрне әлегә берсенең дә

язганы юк арабызда. Кызганыч, әгәр дә һәлак булып калса, бик талантлы, киләчәккә зур өметләр баглаган егетебез әрәм булачак. Тажи абыйның Үзбәгеннән әнә әле август аенда гына училище тәмамлап, танк командиры булып сугышка керүе турында хаты килгән булган. Шуннан соң тагын ике генә хаты килгән дә, тугызынчы сентябрьдә Ржёв өчен барган сугышта һәлак булуы хакында командирларыннан хәбәр алганнар. Тирән кайгыда Тажи абый белән Мәликә апа.

Сәйдәш әйткән хәбәрне шәрехләп, Шакир:

– Әйтмә инде. Уналты яшеннән үз теләге белән фин сугышына китәм дип йөргән малай иде. Сугыш башланганда, Сызраньда танк училищесында укый торган булган. Сугыш сайлап тормый, барысын да рәттән кыра да сала. Берүк исән генә йөри күрсеннәр инде, Фәрит тә, Сибгат тә, – дип куйды. Аның шушы сүзләреннән соң барысы да тынып калдылар.

Ул арада тынлыкны бозып, яңадан кайнатып чыгарган чәйнеген тоткан Фатыйма белән бер табак коймак күтәргән Сафия килеп керделәр.

– Менә, чәен дә яңарттык, коймакларын да. Авыз итегез әле, бисмиллагызны әйтеп, – дип, Фатыйма чынаякларга чәй ясый башлады. – Кара көнгә дип саклап торкан бер чүмеч оным бар иде. Шуны суда гына изеп, төче камырдан коймак ясарга булган идем. Сезнең бәхеттән икән. Әйдәгез, ашагыз әле, ашагыз, мае суынып катып киткәнче.

Барысы да өреп каба-каба, туң майда пешкән кайнар коймакларны ашарга тотындылар.

**12**

Икенче көнне Басыйрованың «Юксыну»ны җырлавын бөтен госпиталь халкы «аһ» итеп тыңлады. Кат-кат сорап җырлаттылар хәтта. Икенче тапкыр җырлавын сораган кеше Якуб Чанышев булып чыкты. Салихның күптәнге танышы. Беренче Татар укчы полкының командиры. Сәйдәштән «Кызыл Армия маршы»н яздырткан кеше.

Чанышев сугышта яраланган да, дәваланырга Казанга кайтарганнар икән. Шушы госпитальдә аны очратырмын дип, Сәйдәшнең уена да килмәгән иде. Җырның премьерасы дип игълан итеп, Зифа җырлап бетерүгә, аксый-туксый килеп җитте Чанышев артистлар янына.

Беренче Казан укчы дивизиясеннән Якуб Чанышевны 1932 елда Мәскәүгә, Фрунзе исемендәге Хәрби академиягә укырга җибәрделәр. Шуннан бирле Салих аның кайларда, ни эшләп йөрүе хакында берни дә белми иде.

– Бик матур җыр! Шакир үзе кайларда йөри соң? Театрдамы, сугышка җибәрмәделәрме? – диде Чанышев.

– Юк, Казанда ул. Үпкә чире белән өйдә ята. Менә шулай җырлар языштыра. Пьесалар язгалый, – диде Салих. – Күршеләр без. Бер өйдә яшәп ятабыз.

– Шул театр ишегалдындагы йорттамы?

– Шул инде безнең ышык.

– Сәлам әйтегез үзенә. Менә дәваланып, аякка бассам, килеп чыгармын әле бер яныгызга. Бик күрәсе, сөйләшеп утырасы, үткәннәрне искә төшереп аласы килә. Искә төшерерлек нәрсәләр күп булды бит сезнең белән.

– Килегез, кил, Якуб абый. Безнең ишек һәрчак ачык.

– Ничек үзеңнең хәлләр? Гаилә? Малайлар үсәме? Ничәү булдылар инде?

– Дүртәү булганнар иде. Берсе үлеп китте, өчәү калдылар.

– Кызганыч.

Чанышевның артистларны бүлдереп, алар белән сөйләшә башлавы очрашуны тоткарлый иде. Төркем җитәкчесе булып йөрүче Рәшидә Җиһаншина Чанышевны бүлдереп:

– Якуб абый, безнең артистларның чыгышлары бетмәгән иде әле. Сүзне кабат аларга бирсәк? – дип куйды.

– Рәшидә сеңлем, минем дә бер-ике сүзем бар сугышчы егетләргә. Рөхсәт итсәң, мин дә сөйләп алыр идем, – диде Чанышев.

– Әйдәгез, әйдәгез, Якуб абый. Сезне игълан итеп торырга кирәкмидер инде, барысы да таныйдыр.

– Юктыр, Рәшидә, матурым. Игълан ит инде. Минем дә солдатлар алдында популярлык яулыйсым килә.

Бу сүзләрдән артистлар көлешеп куйдылар.

– Ярый алайса, рәхәтләнеп, – диде Рәшидә. – Хөрмәтле солдат иптәшләр! Сезнең алда күренекле хәрби начальник... – диде дә ул Чанышевның хәрби званиесе нинди икәнен әйтә алмыйча тукталып калды.

Ярдәмгә госпиталь начальнигы килде:

– Сезнең алда, хөрмәтле солдатлар, хәрби начальник, якташыбыз, 333нче укчы дивизия командиры, шушы көннәрдә генә генерал-майор дәрәҗәсенә лаек булган Якуб Җангир улы Чанышев! Якуб Җангировичны бу олы дәрәҗәсе белән кайнар котларга рөхсәт итегез.

Солдатлар һәм артистлар кул чабып, гөрләшеп алдылар.

– Рәхмәт, кадерле дуслар! – дип башлады сүзен Чанышев. – Монда мине түгел, сезне котларга, сезгә рәхмәт белдерергә кирәк! Солдатларга – Ватанны саклап, каннарын да кызганмыйча, җиңүне якынайтабыз дип, аяусыз сугышканнары өчен! Артистларга – яралы солдатларның рухларын күтәреп ясаган чыгышлары өчен. Беләсезме, дусларым, кемнәр чыгыш ясый бүген сезнең алда?! Халкыбызның күренекле уллары һәм кызлары! Бөек композитор, бөек «Кызыл Армия маршы»н язган Салих Сәйдәшев! Рәхмәт сезгә, Салих Җамалетдинович! Сезнең маршыгыз безнең солдатларны фашистларга каршы көрәшкә рухландыра! Дөньяда иң көчле маршларның берсе ул сезнең әсәрегез! – Чанышев шунда беразга тукталып, читтәрәк басып торучы Зифа Басыйрова янына барып, аның иңеннән кочып алды: – Менә бу яшь артисткабыз, әле генә сезнең алда бик матур, моңлы, сагышлы, ләкин патриотик җыр башкарган кызыбыз – Зифа Басыйрова. Нинди моңлы тавыш! Кара ипигә каймак ягып ашаган кебек тәэсир калды күңелдә! Җырын гына әйт әле син аның! «Юксыну»! Дошманга каршы сугышта йөрүче егетен сагыну, юксыну җыры! Бәлки ул инде исән дә түгелдер, фашистны чәнчелдерер өчен һәлак та булгандыр. Ә сөйгәне аны көтә, сагына, юксына. Бу җыр сугышчыларга да туган ягында сагынып көтүче сөйгәннәре барлыгын искә төшереп тора, дошманга каршы аяусыз сугышка рухландыра. Кем сүзләре, дидегез әле? Сибгат Хәким дидегезме? Сибгат үзе дә сугышта бугай. Афәрин аңа! Әйбәт сүзләр язган. Ватан өчен хәлиткеч сугышлар барганда, солдатларыбызның шулай рухларын күтәргән әсәрләр иҗат иткән әдәбият,

сәнгать әһелләребезгә мәрхәбә! Яшәгез, егетләр, кызлар! Зур рәхмәт сезгә! Биредәге барлык солдатлар исеменнән. Фронтларда кан коючы Кызыл Армия солдатлары исеменнән! Бу җырларыгыз аларга да барып җитә! Без аларны ишетәбез. Сезгә рәхмәтләр укыйбыз.

Чанышев чыгышын тәмамлады да аксаклый-титаклый, кире үз койкасына барып утырды.

Чыгышларны башка артистлар дәвам иттерде.

Салих бу очрашудан канәгать булып кайтты. Аны Якуб Чанышевның ялкынлы чыгышы аеруча рухландырды. Шакир Мәҗитовның җыры да күңелен җилкендереп җибәргән иде. Ул театрда музыкаль спектакльләр куелмаса куелмас, җырлар язарга кирәк икән дигән уйга килде. Сугышка киткәндә, җыр яз әле боларга дип, Гадел Кутуй биреп калдырган шигырьләрне карап чыкты. Арадан «Алга» дигәнен сайлап, җыр язарга булды. Салихның, юкса, заказ буенча җыр язганы юк диярлек. Аның күп җырлары спектакльләр өчен иҗат ителгән. Ә монда театрлар яңа спектакль куярга дип тормыйлар. Солдатларның, халыкның рухын күтәрү өчен шигырьләргә көй язып карарга да буладыр, дип уйлады ул. Өстәл тартмасындагы кәгазьләрне актара торгач, «Совет әдәбияты» журналыннан Мәхмүд Максутның «Җиңү белән кайт» дигән шигыренә игътибар итте. Мәхмүд үзе 1941 елда ук Кызыл Армиягә алынып, «Совет сугышчысы» дигән фронт газетасында мөхәррир урынбасары булып хезмәт итә иде. Аның язмалары, шигырьләре әледән-әле Казанда чыга торган газета-журналларда да басылып килә.

Сәйдәш шулай итеп, үзенә эш тапты.

Көннәрнең берсендә кечке якта аларның ишеген шакыдылар. Салих барып ачса, ишек артында Якуб Чанышев басып тора иде.

– Мөмкинме? – диде ул һәм җавап сүзен ишеткәнче үк эчкә атлады. – Исәнме, Салих туганкай!

– Исәнмесез, Якуб абый. Исәнмесез, бәгырь. Чыгардылармыни госпитальдән?

– Туйдырган иде инде. Тизрәк фронтка китәргә кирәк. Фашист Сталинградка ыргыла анда. Минем урын бүген шунда булырга тиеш.

Чанышев шинелен салып, ишек янындагы дивар элгеченә урнаштыргач, алар Салихның пианиносы торган эш бүлмәсенә үттеләр. Сафия кунак белән кереп исәнләшкәннән соң, чәй әзерләргә чыгып китте.

– Кая, егетләр белән дә күрешик инде.

Салих күрше бүлмәгә чыгып, Нәүфәл белән Эмильне ияртеп керде.

– Йәле, егетләр, абый белән күрешкәндә нәрсә диләр?

– Исәнмесез, – диде Нәүфәл.

Эмиль дә аңа ияреп: «Исәнмесез», – дип куйды.

– Оһ! Менә ичмасам егетләр! – диде Якуб. – Йәле, тот бишне, – дип кулын Эмильгә сузды. Аннары Нәүфәлгә бирде.

– Олысы кая?

– Олысы олы инде. Заводка эшкә йөри. Мәктәптә дәресләрдән соң кичке сменага эшкә бара. Унынчыда укый инде.

–У-у, солдатка да алып куюлары бар икән. Киләсе елга көтегез повестканы, болай булгач.

– Шулай дип уйлап йөрим инде.

– Ә син ничә яшьтә? – диде Якуб Эмильгә.

– Дүрт яшьтә, – диде малай, уң кулының дүрт бармагын күрсәтеп.

– Саный да беләсеңмени?

– Унга кадәр! – диде малай.

– Син дә зур икән инде, егет булып киләсең, – диде Якуб, Нәүфәлгә карап.

– Җиденчедә укыйм.

– Йә, ярый, егетләр. Барыгыз бүлмәгезгә. Дәресләрегезне карагыз.

– Минем дәрес юк, – диде Эмиль.

– Ах сине, шаян! – дип куйды Якуб һәм аның башыннан сыйпады.

Малайлар бүлмәләренә чыгып киттеләр. Якуб рөхсәт сорамыйчанитмичә генә фортепиано алдына килеп утырды да капкачын ачып, клавишаларга кагылды. Аның хәтере яхшы икән, бер-ике тапкыр тыңлагач ук отып калган, «Юксыну» җырының көен уйный башлады.

– Сез музыкант икән бит, Якуб абый! – дип, соклануын белдерде Салих.

– Малай чакта уйнаштыргалый идем бераз. Яхшы җырлар тиз истә кала. «Юксыну» шундый җыр бит. Кая, Шакир дусның хәлен белеп чыксак, начар булмас иде.

– Сафия табын әзерләсен инде. Үзләрен чакырырбыз. Госпитальдә сезнең белән очрашу турында сөйләгән идем, бик кызыксынды. Үзенең дә сезне күрәсе килә.

– Яле, Салих, уйнап җибәр әле үзеңнең берәр көеңне, – дип, Якуб торып, кәнәфигә барып утырды.

– Була ул.

Салих фортепино алдына килеп утырды да, клавишаларны тикшереп чыккандай, бармаклары белән аларга берәмләп баскалый башлады.

– «Кызыл Армия маршы»н уйна әле, Салих.

Салих беренче аккордларны алды да, тантаналы быргы яңгыраган тавышлар чыгарып, уйный да башлады. Марштан соң ул үзенең аеруча яраткан җырларыннан «Батырҗан ариясе»н уйнарга керешә. Беренче кат уйнап чыкканнан соң, салмак кына бәрхет тавышы белән үзе үк җырлый да башлады:

Сау бул, минем туып үскән ямьле илем,
Сау булсыннар урман, басу, кырларым,
Сау булсыннар печән чапкан болыннарым,
Сау булсыннар даннар тоткан Сабан туйларым.

Чанышев аның җырлаганын ахырынача тыңлап бетерә алмады, ихтыярсыз, үзе дә җырга кушылды. Җыр беткәннән соң:

– Тетрәндергеч! – дип куйды. – Нинди моң! Нинди сагыш! «Наёмщик»тан бит?

– Әйе, Таҗи абыйның «Наёмщиг»ыннан Батырҗан ариясе.

– Ничек анда Таҗиның хәлләре? Эшләп йөриме?

– Кәефе бер дә юк. Быел улы Үзбәк һәлак булды бит. Ржёв янында. Үзе Язучылар союзында эшли. Союзда бит илле дүрт язучының егерме сигезе фронтта.

– Яртысыннан артык икән.

– Рус язучылары Чистайда ята, безнекеләр сугышта, кан коя. Күпме язучыны утыз җиденче елда юк иттеләр.

– Мин дә бит ике ел утырып чыктым.

– Шулаймыни?

– Шулай. Тик бу хакта күп сөйләргә ярамый.

– Сез булып, сезне дә халык дошманы, дигәч инде... Кемне генә дошман күрмиләрдер бу илдә? Минем җизни Шиһап Әхмәров та утырып кайтты төрмәдә. Егерме тугызынчы елда ук хөкем иткәннәр иде солтангалиевче дип. Тәмам мөһерен сындырып кайтарганнар.

– Салих туганкай, Солтангалиев мәсьәләсе бик катлаулы һәм буталчык. Әйдә, без бу теманы читтә калдырыйк әле. Мин үзем Солтангалиевне бик күптән беләм. Аны милләтләр мәсьәләсендә Сталин белән бәхәскә кереп, ялгыш юлдан киткән кеше дип исәплим. Мин үзем 1921 елның мартында партиянең унынчы съездында катнашкан кеше. Съезд партиянең милли мәсьәләләр буенча чираттагы бурычларына багышланган иде. Шунда бу мәсьәлә буенча Ленинның докладын тыңладым һәм Сталин милләтләр эше буенча Ленин күрсәткән юлны тайпылмыйча алып барды дип исәплим. Утыз җиденче елда кулга алынгач, мин Солтангалиевкә карата партия позициясендә торуым нәтиҗәсендә генә, үземнең партия һәм совет власте каршында гаепсез булуымны исбатлый алдым. Мине гомумән, солтангалиевчелектә түгел, троцкийчылыкта гаепләп кулга алдылар. Утыз дүртенче елда хәрби академияне тәмамлап, Төркестан укчы дивизиясенә командалык итә башлагач, ниндидер бер Примаков атлы бәндә мине троцкийчы оешмага вербовать итте дип, күрсәтмә язып биргән иде. Эшемне тикшерү өчен Казанга Черек күлгә кайтарылдым. Бу вакытта Казан гарнизонында «фашистик оешма заговоры» буенча эш карала торган булган. Миңа да шул заговорга катнашы булган кеше дигән гаеп такмакчылар иде. Имеш, Германия белән сугыш башланган очракта, без Казан халкын химик матдәләр белән агулап үтерергә тиеш булганбыз.

Ярар, бу хакта бетерик сөйләшүне. Сәнгать дөньясына әйләнеп кайтыйк әле. Сәнгать дөньясында нинди яңалыклар бар?

Чанышевның Солтангалиевне яратмыйча, чынлап торып дошман күреп сөйләвен бигүк аңлап бетермәгән Салих, сәнгать дөньясында да күп кенә якын дусларының солтангалиевчелектә гаепләнеп кулга алынулары турында Чанышев белән нәрсә сөйләшергә мөмкин икән дип уйлап куйды.

– Сәнгать дөньясында да шул ук нәрсәләр бугай инде. Күпме кешене солтангалиевчелектә, вак буржуаз милләтчелектә гаепләп, халык дошманы дип кулга алдылар һәм юк иттеләр. Инде мин үземне дә кулга алырлар, ахры, дип куркып яши башлаган идем. Сугыш башланганнан соң гына тындылар сәнгать кешеләрен милләтчелектә гаепләүдән. Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш кебек дусларымның халык дошманы дип хөкем ителүләре аркасында театрда алар белән бергәләп иҗат иткән музыкаль драмаларым уйналмый башлады. Радиодан җырларым яңгырамый. Дусларым төрмәләрдә утырса, мин иректә килеш тоткын хәлендә яшим. Театрлар музыкаль спектакльләрне, гомумән, куймый башладылар. Сәяси тоткын итеп сизәм хәзер мин дә үземне. Бары тик төрмәгә генә ябып куймадылар.

Композиторлар союзы да якламый. Киресенчә, юк-бар гаепләр табып, тәнкыйть итү белән генә шөгыльләнәләр. Опера яз дип таләп итәргә тотындылар. Мәскәүдә булырга тиешле әдәбият һәм сәнгать декадасында да катнаштырмаска иде исәпләре.

Әйдә, чынлап та туктатыйк әле болар турында сөйләшүне.

Салих урыныннан торып, чәй куярга, табын әзерләргә дип юкка чыккан хатынын чакырып керергә бүлмәдән чыгып китте. Аның сүзләреннән уйга калган Чанышев кәнәфиеннән торып, фортепиано янына барып утырды да ниндидер көй уйнарга тотынды. Бераздан бүлмәгә чәйнек һәм савыт-саба, чынаяклар күтәреп, Салих белән Сафия килеп керделәр.

– Бик кызып сөйләшә идегез. Сүзегезне бүлергә теләмичә, кухня якта көтеп утырдым. Гафу итегез, – дип, Сафия табын әзерләргә кереште.

– Мин күршеләрне дәштем әле. Хәзер керәбез дип калдылар, – диде Салих.

Ул Шакир Мәҗитов белән Фатыйма Камалованы чакырган иде.

Алар өстәл янына килеп утырдылар.

– Әйдә, чәйләп алыйк. Табында әллә ни юк инде.

– Кыенсынма, Салих туган. Булганы белән диген. Чәй эчсәк, шул җиткән. Аның бит чәеннән бигрәк, бер очрашып, сөйләшеп утыруы кадерле. Ничек дигәннәр әле, бер утыру – бер гомер. Искә алырлык нәрсәләр күп бит безнең. Син дә шул Төркестан далаларында чыныккан егет бит.

– Күрде инде башлар. Яшь чак бит. Яшь чак – җүләр чак, дигәннәр бит. Яшьлек белән чыгып кителде инде. Аны-моны уйлап торылмаган.

Шулчак ишектә Шакир белән Фатыйма күренде.

– У-у, кунак бар икән! – диде Шакир керә-керешкә. – Исәнмесез, Якуб абый. Госпитальдә ятасыз дип ишеткән идек. Савыктыгызмы? Кәефләр ничек?

– Саумы, Шакир туганкай! Менә, күргәнегезчә, бастык аякка. Безгә озак авырып ятарга ярамый. Фронт көтә. Фашистлар Сталинградка барып җиткән, ди анда. Минем дивизия кырылып бетмәгән булса ярый инде.

– Бетмәс, Ходай кушса. Сталинград өчен татар егетләре сугыша икән бит анда. Татар егетләре сынатмас, – диде дә Шакир Чанышев белән ике куллап күреште.

– Әйдәгез, утырышыгыз әле, табын артында сөйләшербез, – дип, Салих Шакир белән Фатыйманы табынга дәште.

– Бик шәп җыр язгансыз, Шакир туган. Сез инде миңа шулай гади генә туган дип дәшкәнгә үпкәләмәгез. Үз итеп, якын күреп дәшүем. Мин бөтен кеше белән дә шулай сөйләшәм. Бездә бит отчество белән сөйләшү юк. Иптәш дип тә әйтәсе килми. Туган – иң якын сүз!

– Нишләп үпкәлик, үзем дә олы кешегә абый дияргә өйрәнгән. Яшьрәк кешегә туган дисең инде.

– Менә шул. Бик шәп җыр. Госпитальдә Зифа Басыйрова башкаруында тыңладым. Түзмәдем, кабат сорап җырлаттым. Искиткеч җыр. Әле бүген монда килгәч, үзем дә фортепианода уйнап алдым шул җырның көен.

– Ярый инде, әллә ни искитәрлеге юк.

– Алай димәгез. Менә шундый җырлар кирәк халыкка. Йөрәкне айкап чыгара торган. Мин үзем шундый моңлы җырларны яратам. Үзебезнең

пентатоникада язылган җырларны. Көнбатышның ул дыңгыр-даңгыры йөрәккә ятып бетми. Дөрес, көнбатышта да бар әйбәт әсәрләр. Ләкин пентатониканың аның үз моңы бар. Безнең халык пентатоника белән әвәләнгән. Татар җырлары моңлы да, хәсрәтле, дип гаепли кайберәүләр. Имеш, татар гомере буе изелеп яшәгән дә, гел моңланган, сагышланган. Алай түгел ул. Моң ул изелү билгесе түгел. Ул безнең рухыбыз билгесе. Пентатоникада яңгыраган халык музыкасы, ул имеш, безнең артталыкны күрсәтә дигән сафсата куерталар кайбер белгечләр. Имеш, шуннан китәргә теләмәгән композиторлар искелек яклы, вак буржуаз музыка тарафдарлары дип акыл саталар. Әкият. Сәйдәшевне мин шуның өчен хөрмәт итәм. Ул, татар классик музыкасы иҗат итәм дип, пентатоникадан китәргә теләмәде. Пентатоникага ярымтоннар өстәде дә үзенең музыкасын тудырды. Саф милли музыкабызны!

– Сез, Якуб абый, музыка белгечләреннән дә уздырасыз музыка теориясе буенча, – диде шунда Фатыйма.

– Мин музыка белгече түгел. Ләкин музыка белгечләренең белем дәрәҗәсе аксый дип саныйм. Ярар, операсын да тудырсыннар. Ләкин Салих Сәйдәшев тудырган музыкаль драма – ул татарның рухына туры килеп торган жанр. Аны югалтмаска иде. Аны үстерергә, көчәйтергә иде. Менә шуны аңламый ул сезнең белгечләрегез. Шул моңнарны саклап язган әсәрләрне үзешчәнлек дип ялгышалар. Ләкин халык бар. Халык нәрсәнең нәрсә икәнен яхшы күрә, аера. Менә сезнең «Юксыну»ыгыз да шундый җыр булып чыккан. Халык бәгыреннән чыккан җыр булып. Әйдәгез, шуны җырлыйк әле. Менә күрерсез, фронтта татар егетләренең яраткан җырына әвереләчәк ул. Моңа кадәр Заһид Хәбибуллин белән Муса Җәлил язган «Сагыну» җыры шундый иде. Аны да ярата татар егетләре. Кызлар җыры дип тормыйлар, яратып җырлыйлар. Күптән түгел фронтка концерт белән филармония артистлары килде. Җәвәһирә Сәлахова, Рәшит Ваһаповлар. Менә шул җырларны башкарып, халык көйләрен җырлап, на «ура» концерт куеп киттеләр. Татар егетләренең сугышчан рухын күтәреп.

Шунда Шакир фортепиано алдына барып утырды да уйнарга тотынды. Беренче аккордларны алуга, Фатыйма җырлый башлады. Җырга Чанышев кушылды.

Күз карашым нинди уйчанланды,
Син беләсең микән, юк микән?
Син киләсе юлдан күзем алмый,
Сине көтәм, иркәм, кич-иртән.

Алар шактый озак утырдылар ул кичне. Шакир белән Фатыйма чыгып киткәч тә, Чанышев китәргә ашыкмады. Сафия дә табыннарны җыештырып, үз бүлмәсенә йокларга китте. Ә Якубның Сәйдәш белән сөйләшер сүзләре тиз генә бетмәде. Сәгать дүртләр җиткәндә ул:

– Мин сездә генә кунып китим инде булмаса. Бу вакытта кая барасың. Миңа иртәнге унда вокзалга, – диде.

Сафия кунып каласын белгән кебек аның өчен малайлар ягында урын җәеп куйган иде.

## 13

Көннәр бер-бер артлы үтә тора. Театрда, госпитальләрдә, радиостудиядә төрле чараларда катнашып, кеше арасында булырга тырышса да, Салих тормышның кызыгын, ямен җуйды. Күңелсез иде. Үткәннәр искә төшә, мәңгегә югалган кешеләр күз алдына килә. Салих өчен күңелен бушатырлык бер генә кеше калды бугай тормышта. Ул да булса, сугыш алдыннан гына ун еллык хөкем срогын тутырып, Соловкидан исән-сау әйләнеп кайткан җизнәсе Шиһап Әхмәров. Ләкин аның да мөһерен сындырып, дөньяга карашын үзгәртеп, кешеләр белән аралашудан кача торган итеп кайтарганнар иде. Элеккеге ачык, шат күңелле кеше түгел иде инде ул. Кызыл Байрак та кызыксындырмый аны хәзер. Бармы – бар, яшиме – яши. Аның проблемалары, борчулары, мәшәкатьләре аңа мөһим түгел. Салих шулай да буш вакыты чыкса, еш кына аның янына барып, сөйләшеп утырырга, үзеннән бигрәк, аның күңелен күрергә, кәефен күтәрергә тырыша. Андый аралашу җизнәсе өчен бик мөһим иде хәзер. Чөнки ул гына кешеләрдән түгел, кешеләр дә аннан читләште, аның белән аралашмаска, очраганда, күрмәмешкә салышып үтеп китәргә тырышалар.

Кырык өченче ел Салих тормышында гыйбрәтле, күңелсез вакыйгаларга аеруча бай булды. Ул менә хәзер, эштән куып чыгарылгач, кайта-кайта үткәннәрне искә төшергәндә, кырык өченче елны уйлап куя да, күңеле имәнеп, әллә ничек куркыныч булып китә. Утыз җиденче ел вакыйгаларыннан соң кешеләргә карата болай да күңеле каткан Салих өчен бу ел тагын да әшәкерәк, мәкерлерәк вакыйгалар алып килде.

Шушы елның егерме алтынчы октябрендә улы Альфредка унҗиде яшь тулды. Күрәсең, шушы көнне көтеп кенә йөргән, кич белән ул әтисен шаккатырып, аның кәефен җибәрә торган хәбәр әйтте:

– Әти, мин бүген хәрби комиссариатта булдым. Үзем теләп, сугышка китәм, – диде.

Бу елларда унҗиде яше тулуга егетләрне солдатка ала башлаганнар иде. Бу хәбәрдән югалып калган Салих нәрсә дип әйтергә дә белмәде.

– Яхшылап уйладыңмы соң, улым? – диде дә, аякларының хәле китеп, урындыкка барып утырды.

– Нигә алай авыр кабул иттең, әти? – диде Альфред. – Кулына корал алырдай бөтен кеше бүген сугышта бит. Минем яшьтәшләр, без барыбыз да, хәтта кызлар да класс белән фронтка китәргә булдык.

– Нәрсә дип әйтим инде мин сиңа, бәгырь? Барма, дип әйтә алмыйм. Моңа минем хакым да юк. Синең кебек яшь чагымда мин үзем дә үз теләгем белән гражданнар сугышына киттем. Дөрес, кулга мылтык тотып сугышып йөрергә туры килмәде. Сугыш сугыш инде. Анысында да үтерәләр иде. Монысы аеруча хәтәр сугыш. Фашистларны бигрәк тә явыз, диләр. Берүк сак булырга тырыш. Алла саклангганны саклармын, дигән. Тагын бер теләгем бар, улым: плингә төшә күрмә, берүк. Плин михнәтләрен күрү бер газап булса, «сатлыкҗан» дигән яманат тагарлар. Анысы, плиннән соң исән кайтсаң да, халык дошманы дип атарга сәбәп булачак. Минем сиңа теләкләрем шул.

– Рәхмәт, әти, борчылма, илне сатмам. Сугышка үз теләгем белән барам. Һәлак булсам, бәхил булыгыз.

Ата белән ул арасында әнә шундый сөйләшү булды ул кичне. Икенче көнне алар иртәдән Вахитов районы хәрби комиссариатына киттеләр. Альфред шикелле үз теләкләре белән фронтка китүчеләр шактый иде. Барысын да озатырга әти-әниләре, сөйгән кызлары килгән. Барысы да елаша, күз-яшь түгә. Альфредның сөйгәне булгандырмы, юктырмы, Салих аның тирәсендә елап торган бер кыз да күрмәде.

Салих эшендә дә кызык тапмый башлады. «Күзләр»дән соң театр бер генә музыкаль спектакль дә куймады. Ул театрның музыка бүлеге җитәкчесе булып саналса да, асылда, аның бер эше дә юк иде. Ул бары тик театр исеменнән госпитальләргә яралылар алдында чыгыш ясарга, ул елларда фронтка ярдәм итү фонды тарафыннан оештырыла торган химая концертларына йөрде.

Ноябрьнең салкын, ни яңгыр, ни кар яумаган шыксыз бер кичендә Салих соңлап кына өйгә кайтып килә иде. Бу кичне ул госпитальдәге очрашудан соң апасы белән җизнәсенең хәлләрен белешергә дип, аларга кереп чыккан иде. Җизнәсе белән озак кына сөйләшеп утыргач, соңлап кына кайтырга чыкты. Театр ишеге янында, Салихлар ишегалдына карап моңаеп, салкыннан өшегән чебеш кебек кукрайган, башын пәлтә якасы эченә кертеп бетергән бер кеше басып тора. Яныннан узып китим дигәндә, генә ул өн катты:

– Салих абый...

Салих әйбәтләп караса, бәй, артист дусты Ибраһим Гафуров түгелме соң?!

– Ибраһим, бәгырь, нишләп торасың монда? Туңып беткәнсең бит.

Сәйдәшнең сүзләре аны уятып җибәргәндәй булды, ул башын яка астыннан чыгарып:

– Барырга урын булмаганга торам менә, – диде.

– Нишләп? Өеңә кайтырга акчаң юкмыни? Миндә тиеннәр булырга тиеш, – дип, Сәйдәш пәлтә кесәсен кармаларга кереште.

– Кирәкми, Салих абый. Акчам бар. Барырга урыным юк.

– Нишләп? Өең бар бит.

– Өй бар да... Хатын...

– Нәрсә хатын?..

– Ачуланыштык.

– Соң. Аны ачуланышасың да, татуланышасың да.

– Юк шул. Куып чыгарды хатын. Менә кунар урын юк.

Салих беркавым уйлап торды да:

– Соң, бәгырь, әйдә алайсам, безгә. Кунып чыгарсың да, иртәгә кайтып татуланышырсыз, – диде.

– Әйбәт булыр иде, – диде дә Ибраһим Салих артыннан иярде.

Өйгә кергәч, Салих хатынына:

– Мин кунак белән кайттым әле, әнисе, чәй куй, – диде.

Ибраһимны күргәч, кечкенә Эмиль Салихны аптырашта калдырып:

– Ибрай абый! Ибрай абый! – дип, күптәнге танышын күргән кебек сикергәләп алды.

– Кара син аны, Эмиль дә белә икән бит үзеңне, – диде Салих Ибраһимга. – Сал пәлтәңне. Әнә элгечкә урнаштырып куй.

– Театр ишегалдында күргәләгәне бар бит. Беркөнне прәннек биргән идем үзләренә, шуннан таныйдыр, – дигән булды Гафуров.

Улының чит кешене үз итеп шулай исеме белән дәшүенә эче пошкан Сафия кулындагы тастымал белән Эмильнең артына сыпырып:

– Бар, кер бүлмәңә, йөрмә монда аяк астында буталып, – дип, аны бүлмәсенә куып кертеп җибәрде.

Салих икенче көнне эше булмаса да, театрга кереп чыгарга булды. Иртән торып чәйләр эчкәч, ул Ибраһимның бүгенге эшләре турында сорашты. Кичен буласы спектакльдә музыка юк иде. Шуңа күрә репетициядә утырып тормаска булды. Гафуровның спектакльдә роле бар икән, шуңа күрә репетициядән соң өенә кайтып килергә вакыты калачак. Салихларның өе театр ишегалдында ук булгач, аңа өенә кайтып тормаска да була иде.

– Салих абый, репетициядән соң да сезгә генә кереп торсам, ярар микән? – диде ул.

– Хатының янына кайтып аңлашырга, татуланырга теләмисеңмени?

– Татуланудан, аңлашудан узган шул инде безнең хәлләр. Әйберләремне чемоданга тутырасы да чыгып китәсе генә калган, – диде Ибраһим.

Аларның сөйләшүен тыңлап торган Сафия әйтә куйды:

– Соң, яшәсен бездә генә. Урын җитәрлек бит. Малайлар икесе бер бүлмәдә яшәр. Дүртебезгә дүрт бүлмә. Синең эш бүлмәң болай да буш тора.

– Белмим тагы. Син каршы булмасаң, яшәсен шунда. Мин риза. Урамга куып чыгарып булмый бит инде кешене.

Шулай итеп, хатыны урамга куып чыгарган Ибраһим Гафуров Сәйдәшләр өендә яши башлады. Аңа Салихның эш бүлмәсеннән урын бирделәр. Зал ягында торган караватны шунда кертеп куйдылар. Кичләрен утырып, фортепиано уйнарга гына мөмкинлек калмады. Болай артык кысрыкламый иде квартирант. Салихның музыкантлыгына, композиторлыгына театрда ихтыяҗ беткәнлектән, пианино алдында утырырга да әллә ни теләге юк иде. Галиәсгар Камал пьесасы буенча куелырга тиешле «Хафизәләм-иркәм» спектакле өчен музыка язасы бар-барын. Ләкин аны да Салихның үзенә генә түгел, Казанга эвакуацияләнеп килгән Ленинград консерваториясе профессоры Юдин белән берлектә, аңа ярдәм итү формасында гына эшләргә кушылды. Шуңа күрә бу эшкә Салих әллә ни ашкынып та тормый иде.

Көннәр шулай үтә торды. Салих ике көннең берендә госпитальләргә яралы солдатлар белән очрашуларга йөрде. Концертларда чыгышлар ясады. Театрга кергәләп чыга иде. Ибраһимга өйдә тәмам ияләштеләр. Бигрәк тә Эмиль яратты чит абыйны. Кайчан кайтып керсә дә, Эмиль белән өстәл артында нидер эшләп маташкан чаклары була иде: йә китап укыйлар, йә нидер язалар, йә рәсем ясап утыралар. Ләкин Ибраһим Эмильне генә түгел, аның әнисен дә яраткан булып чыкты. Шулай беркөнне госпитальгә барам дип чыгып киткән Салих вакытыннан алда өйгә кайтып керсә, Сафия белән Ибраһим караватта аунашалар иде. Көпә-көндез, ишекне дә бикләмичә, дөньяларын онытып әүмәкләшеп ятучы ике бәндәне күргәч, Салихка әллә ничек уңайсыз булып китте. Ул: «Гафу итегез», – дип, ачкан ишекне кире япты да ишек артында тегеләрнең эшләрен бетергәнен көтеп тора башлады. Бераздан исенә килеп, үзенең нинди хәлдә калганын аңлады. Болай басып тору мәгънәсезлек иде. Ул өйдән чыгып китте. Аңа

бу өйгә кире керергә ишек ябылган иде инде. Ул шуны аңлады. Ләкин бит ике малай бар. Икесенең дә атасы – ул. Дөрес, аерылышкан очракта балаларны әниләре белән калдырачаклар. Ә бит фатир аныкы. Театр аны аңа бирде. Хыянәтче хатынын куып чыгарса, балаларын да куып чыгару булачак. Нишләргә? Балаларын ярата бит ул. Алардан башка ничек яшәр? Кая барыр? Кемгә барып сыеныр? Салих бу көнне тагын бер мәртәбә үзен беркемгә дә кирәк булмаган артык кеше итеп хис итте. Ул театрга да кирәк түгел, Композиторлар союзына да кирәге юк. Хатыны булып, аңа да кирәге калмаган. Менә бит дөнья нишләтә. Исән-сау килеш артык кешегә әйләндерә. Моннан да зуррак, моннан да рәхимсезрәк этлек эшләргә мөмкинме икән дөньяда кешегә?! Хыянәттән дә әшәкерәк эш булуы мөмкинме икән?!

Салих аптыраганнан нишләргә белмичә озак йөрде ул кичне урамда. Инде нишләргә? Кая барырга? Ул кайта-кайта, үзенә шундый сорауны бирде. Барып сыеныр урыны бер генә – апасы белән җизнәсе яшәгән йорт. Алар Салихлардан ерак та түгел Галактионов урамында гына яшиләр. Шунда бармый, кая барсын? Югыйсә үзләре дә шактый ишле: балалары да үсеп җиткән. Үзбәк тә өйләнеп, өйгә килен алып кайтты былтыр. Гөлнар белән Җанбәк тә зурлар. Шулар өстенә ул да барып керсә. Ләкин берни эшләр хәл дә юк. Урамда йоклап булмый. Салих төн уртасы җитеп килүгә карамастан, барып, аларның ишеген шакыды. Әле берничә сәгать элек кенә, госпитальдән кайтканда кереп хәлләрен белешкәннән соң, үземә кайтам дип, өйләреннән чыгып киткән иде ул алардан.

Төнге ишек шакулардан куркып яшәгән ул елларда кешене тагын бер куркуга салу иде бу. Бераздан эчтән җизнәсенең: «Кем бар анда?» – дигән тавышы ишетелде.

– Мин бу, җизни, ач әле, – диде Салих ишетелер-ишетелмәс тавыш белән, читенсенеп кенә.

Шиһап абзый ишекне ачты да аптырап:

– Нәрсә булды? – дип сорады.

– Җизни... мин... ни... сездә генә кунып китим әле...

– Кер, кер. Ни булды соң?

– Их, җизни... – диде дә Салих өйгә керде һәм ишек төбендә торган урындыкка килеп утырды.

– Нәрсә, өйдә тавыш чыктымы әллә, соңга калып кайттың дип?

Ул арада йокы бүлмәсеннән апасы чыкты. Ул да энесен күреп, аптыраушта калган иде.

– Ни булды?

– Бар, Җанбәк янына урын җәеп бир Салихка, – диде Шиһап җизнәсе.

Салих чишенеп, Җанбәк йоклаган бүлмәгә кереп, аның янына барып ятты. Ләкин аның йокысы качкан иде. Ул төне буе борсаланып, тугланып ятты. Апасы белән җизнәсен дә йокы алмады. Бераздан Шиһап абзый Салих янына кереп, аның да йокламыйча ятуын күрде дә, кухня якка чакырды.

– Ни булды соң, кайниш? – диде ул, артыннан ияреп чыккан Салихка кухня өстәле артындагы урынга күрсәтеп. – Утыр әле.

– Их, җизни, бәгырь, – диде Салих, тагы да шул баягы сүзне кабатлап. – Яшәп булмас инде бу Сафия белән.

– Ник алай?

– Шулай, китәргә булдым мин аннан. Характерлар туры килми безнең.

– Шулай ук җитдимени мәсьәлә?

– Бик җитди, җизни. Чыгып киттем дә менә, кая барып бәрелергә дә белмичә йөргәч, сезгә килдем.

– Аңлашылды... – диде Шиһап. Аннары көрсенеп: – Менә ит син кешегә яхшылык... Ниемә дип керткән идең син ул мөртәтне өеңә? – Ул нәрсә әйтергә дә белмичә сүзсез калды. Аннары: – Ярар, бездә торып торырсың башта. Аннан күз күрер тагын. Берәр җае чыгар, – диде.

– Электән үк кергәләп йөргән булгандыр, ахры. Эмиль аның белән кайтып кергәч, «Ибрай абый! Ибрай абый!» дип сөенгән иде.

– Алайса, чыгып китүең хәерле, кайниш. Андый хатын белән торганнан тормавың хәерлерәк. Дөрес эшлисең.

– Балалар бар менә. Малайлар. Алар кызганыч.

Унөч яше тулган Нәүфәл нәрсәнең нәрсә икәнен аңлый башлаган иде инде. Әнисенең кунарга дип кенә кергән чит кеше белән яши башлавын, әтисенең аларны калдырып чыгып китүен ул бик авыр кичерде.

Берничә көннән Салих эшкә килгәндә, театр ишеге төбендә басып торучы Сафияне күрде. Ул аны күрсә дә, сөйләшмичә генә театрга кереп китмәкче иде, хатын аңа үзе дәште:

– Салих, туктале, сүзем бар, – диде.

– Минем синең белән бернәрсә турында да сөйләшәсем килми, – диде Салих.

– Салих, мин Нәүфәл турында...

– Нәрсә булган Нәүфәлгә?

– Ике көн инде өйдә кунмый.

– Нишләп?

– Әти кайтмаса, мин дә кайтмыйм өйгә, ди. Сөйләш әле шуның белән.

– Мин нәрсә дип әйтим аңа? Үзең сайладың бит балаларыңа әтине, үзең сөйләш.

– Ул бит аларның әтисе түгел.

– Шулаймыни?

– Шулай.

– Үзең аңлат алайсам үзеңнең ни кылганыңны.

Салих шулай диде дә театрга кереп китте.

Салихның өйдән чыгып китүе турында театрда да белеп алганнар иде. Китте чышын-пышын сөйләнүләр. Китте акыл өйрәтүләр, киңәш бирүләр. Ул андыйларга ни дияргә дә белмәде. Шул хакта сүз чыкса, тизрәк алар яныннан китәргә ашыкты. Ә Нәүфәл үзсүзле, нык егет булып чыкты. Ул да мәктәптән соң Әминә апаларына кайтып йөри башлады.

– Болай булмый, бер-бер хәл кылырга кирәк, – диде Шиһап Салихка, дәресләрдән соң үзләренә Нәүфәл килеп кергәч.

– Юк, мин алар белән яшәргә теләмим! – диде Нәүфәл, Шиһап җизнәсенең нәрсә әйтергә теләгәнен аңлап.

– Нишләп, улым? Ул бит синең әнкәң.

– Мин әтинең дә шунда кайтуын телим. Әти кайтса гына кайтам!

– Әтисе, ә син ни дисең?

– Аптыраган. Баш каткан, җизни. Нишләргә дә белгән юк.

– Балаларның монда бер гаебе дә юк. Кайт та үз бүлмәңдә яши башла.

– Ие, Салих нәнәм. Җизнәң дөрес әйтә, – дип, сүзгә Әминә апасы кушылды.

Аптыраган Салих бу көнне улы белән үз өйләренә кайтып китәргә мәҗбүр булды. Алар кайтып, «Без монда кунарга кайттык» дигәч, пианино торган зур бүлмәгә карават кертеп куйдылар. Тик аның белән сөйләшергә, аңлашырга теләгән кеше булмады. Хәер, аның үзенең дә аларны күрәсе, сөйләшәсе килеп тормый иде. Ул бу өйгә бары тик шул улын тыңлап, аны ничектер юатырга теләп кенә кайтты. Салих бу йортта яши алмый иде инде. Шул төнне генә кунды да ул тагын чыгып китте. Бу юлы улына үзенең ни хәлдә икәнен, ни өчен алар белән яши алмавын аңлатып китте. Нәүфәл аңламаслык яшьтә түгел иде инде. Шулай да аңа бик кыен иде.

– Мин килгәләп йөрермен, улым, – диде Салих.

Аның кечкенә улы Эмильне бик тә пианинода уйнарга өйрәтәсе килә иде. Малайда ул музыкага сәләт күрде. Әле биш кенә яшь булса да, Эмиль әтисе уйнаганда, аның янына килеп, озаклап карап утыра, үзе дә клавишаларга баскалый һәм ниндидер көйләр чыгарырга маташа иде. Бераз үскәч, ул аның белән чынлап торып шөгыльләнергә дип ниятләп йөрде. Болайга калгач, булмый икән инде дип, бик борчылды, кәефсезләнде.

Озакламый Салих гаиләсендә килеп чыккан хәл турында бөтен Казан сөйли башлады. Кая барып чыкса да, аны күрсәләр, шул хакта сорашырга тотыналар. Эчтән гарьләнсә дә, тыштан сиздермәскә тырышты ул үз хәлен. Еш кына юморга борып җибәрә торган булды.

– Хатынымны кияүгә бирдем шул, – дип җавап кайтарды.

– Кияүне үзеңә йортка керттеңмени? – диделәр ачы теллеләр.

Болай яшәп булмый иде. Ниһаять, ул аерылышырга кирәк дигән карарга килде. Шулай бер көнне эштән соң үзендә көч җыеп, Сафия белән Ибраһим янына барып керде.

– Исәнмесез! – диде дә түргә барып утырды.

Тегеләр: «Нишләп йөри икән бу?» – дигәндәй, бер-берсенә карашып куйдылар.

– Исәнме, Салих, – диде Сафия.

– Болай булмый, җәмәгать. Ике ирнең хатыны булып яшәгән хатынны беренче тапкыр күрәм. Килешә торган эш түгел бу. Шәригатькә сыя торган эш түгел, сизәсезме?

– Шулай да бит. Нишлик соң? – дип куйды Ибраһим.

– Бәгырь, мин бит сине урамда күшегеп, кәкрәеп катмасын дип кенә керткән идем өйгә. Үз өең бар иде түгелме соң?

– Бар иде дә.

– Булгач, бар, кайт үз өеңә, хатының көтәдер анда.

– Мин чыгып киттем бит аннан. Аерылыштык.

– Синең хатын белән торам, димәкче буласыңмы?

– Шулай.

– Алай булмый ул, бәгырь. Башта хатының белән законный аерылыш. Аннары минем хатын белән законный кушыл. Шуннан соң икегезгә йорт эзләгез. Югыйсә әкияттәге шикелле була бу. Салкыннан туңган

төлкене кунарга кертеп, өйсез торып калган куян шикелле. Беләсездер шул әкиятне.

Тегеләр ни әйтергә дә белмичә, аптыраšта калдылар.

– Ни бит...

– Нәрсә ни бит? Ап-ачык һәм аңлаешлы итеп әйттем бит.

– Балалар бар бит, – диде Ибраһим.

– Синең балалар түгел бит алар. Үзегез белән аласыгыз килмәсә, калсыннар. Мин аларны кумыйм. Үзләренең дә сезнең белән китәселәре бик килеп тормый. Нәүфәл әнә ике көннең берендә минем белән куна.

Шушы сөйләшү кирәк булган икән. Икенче көнне Ибраһим каяндыр белешеп, фатир табып кайтты. Берничә көннән алар үзләренә тиешле әйберләрен җыештырып, өйдән чыгып киттеләр.

Нәүфәл уку елы беткәнче әтисе белән яшәп калды.

**14**

Сугыш елларында Сәйдәшнең иң аралашкан, якын дустына, фикердәшенә әверелгән кеше Таҗи Гыйззәт булды. Менә хәзер, икесе бергә штат кыскартылу сәбәпле дип эштән чыгарылгач, Салих аның белән язмышларының да уртаклыгына игътибар итте. Һади Такташ, Шамил Усманов, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнашлардан соң Сәйдәшнең җанын аңлаган, йөрәгендә кайнаган хисләрне бүлешкән, серләрен уртаклашкан кеше дә ул иде бит. Тинчуриннар, Бурнашлар киткәннән соң театр өчен шул чор проблемаларын күтәргән тормышчан әсәрләр иҗат иткән бердәнбер драматург булып та ул калгандыр, мөгаен. Бөек Ватан сугышы китергән афәтләр турында киң масштаблы, халыкчан пьесаларны тудыручы Таҗи Гыйззәт иде. «Наёмщик», «Чаткылар», «Ташкыннар», «Ялкын», «Кыю кызлар», «Мактаулы заман» кебек сугышка кадәрге чорда халык ихтирамын казанган әсәрләренә өстәп, Ватан темасына багышланган «Бишбүләк», «Таймасовлар», «Төнге сигнал», «Изге әманәт», «Чын мәхәббәт» пьесаларын эченә алган драматик эпопея иҗат итте ул. Аларның күбесенә сәхнә бизәлеше өчен музыканы Салих Сәйдәшев язды.

Олы улы Үзбәкнең һәлак булуы турындагы хәбәрдән йөрәгенең әрнүе басылырга да өлгермәде, кече энесе Хаҗиәхмәт сугыш кырында батырларча башын салды. Шуның артыннан ук икенче улы Казбек фронтка китте. Түзсә дә түзә икән кеше йөрәге. Шул килеш тә эш дип, театр дип йөри. Әле шуның өстенә язган бер әсәрен тәнкыйтьләп, куйдырмас өчен нинди генә сәбәпләр табып бетермиләр. Ә куелса, халык яратып карый торган, аншлаг белән үтә торган спектакль килеп чыга.

Таҗи Гыйззәтнең «Изге әманәт» драмасының да язмышы шундый хәлләргә дучар булды. Сугыш вакытында Донбасс татарларының героик көрәшен күрсәткән әсәр тудыру уе белән Донбасска барып, андагы тормышны өйрәнеп язган әсәрен башта Язучылар союзында мактап чыктылар. Аннары фикерләр үзгәреп, төрлечә хурлаулар башланды. Ахыр чиктә партия өлкә комитеты куярга дигән карар чыгарып, әсәр сәхнәгә менеп, халык арасында зур популярлык казанды. Ләкин драма куелганнан соң да матбугатта аңа каршы язмалар күп чыкты.

Салих шундый авырлыклар каршында да каушап калмаган Таҗи

абыйсына карап соклана, аның кебек түзем һәм үҗәт булырга кирәк бу тормышта дип уйлый иде. Әйе шул, Салихның тормышы да бал да май түгел. Төрлесен күрсәтте язмыш. Менә тагын хатынсыз торып калды. Хатынсыз тормыш алып бару кыен. Дөрес, Сафия белән аерылышу әллә ни зур югалту түгел иде аның өчен. Күптән инде ул аның белән серләрен уртаклашмый, уйлары белән бүлешми. Шатлык-кайгысын аңа сөйләми. Бармы – бар, хатынмы – хатын. Шулай яшәделәр ничә еллар. Валя түгел иде шул Сафия. Кәрим абыйсы да өйләнгәндә, тиккә генә ялгышасың дип әйтмәгән булгандыр, ахры. Нишлисең инде, ялгыштым дип, кешегә сөйләп йөреп булмый. Менә шулай үзеннән-үзе хәл ителде мәсьәлә.

1945 елда тагын бер тапкыр шаяртып алды аның белән язмыш. Ул өйләнде.

Сугыш азагына якынлаша, дошман чигенә, совет гаскәрләре фашистларны үз өннәрендә кыйный башлаган көннәр иде. Әминә апасы белән кызы Гөлнар Сталино шәһәренә барып кайтырга булдылар. Казан госпитальләренең берсендә хәрби табиб булып эшләүче Гөлнарның ире Донбасс якларындагы шушы шәһәрнең коменданты итеп билгеләнгән иде. Сталиноның ярты халкы татарлар икән. Гөлнарның ире яши торган йортта да үзебезнең Казаннан күчеп килгән татар гаиләсе күршеләр булып чыкты. Җитмәсә, Әминәнең танышлары – Казаковлар икән. Казаковлар – Казанда атаклы нәсел. Бер туганнары Исхак Казаков дигән кешене Әминәнең әле Шиһапка кияүгә чыгып йөргән көннәрдә Шәрык клубында күп мәртәбәләр күргәне бар. Шиһап аны драматург дип әйтә торган иде. «Сәйяр» труппасы аның «Казанга сәяхәт» дигән комедиясен уйнап йөрде. Соңыннан бу кеше Татарстан хөкүмәте башлыгының урынбасары булып та торды. Шиһап халык дошманы дип хөкем ителгән елларда аны да кулга алганнар иде бугай. Шиһап белән дуслар иделәр. Шиһап әле аның сеңлесе Өммегөлсемне Мулланур Вахитовның әнисе дип тә әйтә торган иде. Казандагы мәшһүр бай Габдулла Апанаев хатыны Зөләйха да шул Казаковлар кызы. Аларның Битаманда тегермәннәре бар дип тә сөйли торган иде Әминәнең Миңлебай бабасы. Менә шул Апанаевларның бер кызлары Асия Казакова Сталинода яшәп ята икән. Мескенкәйнең ире сугышта үлгән. Улы Фәрхәд тә сугышта икән. Гөлнарның шәһәр комендантының хатыны булуын белгәч, танышырга дип кергән иде, күптәнге танышлары булып чыкты. Гөлнарның ире Шиһап Әхмәровның кияве булуын гына белмәгән булган икән.

Әминә белән алар күптәнге танышлар булып, ачылып сөйләштеләр.

– Салих нишләп йөри соң анда? – дип сорады Асия. Әле Шәрык клубында оркестрда уйнап йөргән чакларыннан ук белә иде Асия Салихны. Аннан берничә яшькә олырак иде бугай ул, Әминә яшендә булмады микән?

– Буйдак булып йөри Салих, – диде Әминә. – Беләсең микән, беренче хатыны Валентина бала тапкан чакта ук үлгән иде бит.

– Шулаймыни? Белми идем. Мин бит гражданнар сугышы елларында ук киткән идем инде.

– Икенче хатыныннан уңмады. Ундүрт ел яшәгәч аерылыштылар. Өч малае бар Салихның. Беренчесе Валядан иде. Икенче хатыныннан өч малай иде. Берсе үлде.

– Хәзер ялгызмы?

– Олы улы Альфред сугышта. Сафия үз балаларын үзе белән алып китте.

– Ялгыз башына кыендыр инде. Өйләнергә уйламыймы соң?

– Аның яшендә каян табасың инде ул холкыңа туры килгән хатынны? Бик өйләнер иде дә...

– Шулай шул.

– Синең чыгарга теләгең юкмы соң? Ялгызың калгансың бит.

– Минем дә улым бар. Сугышта.

– Без әле тиз генә кайтмыйбыз Казанга. Берәр ай торырга дип уйлап торам. Гөлнар ире янында калмакчы була. Уйласаң, кара, бергә кайтып китәрбез, – диде Әминә. Ул Асияне ничектер ошатты. Тыныч, сабыр хатын кебек күренде. Аңа да немецлар басып алган шәһәрдә яшәве җиңел булмагандыр ялгыз башына.

Берничә көннән Асия яңадан кереп, үзенең риза булуын әйтте.

– Мин уйладым, Әминә. Мин риза, – диде.

– Яхшылап уйладыңмы соң, Асия? Салих бит гади генә кеше түгел. Холкы белән сабыр, тыныч булса да, гел балалар кебек. Карарга кирәк үзен.

– Минем ирем дә шундый кеше иде. Сабый да сабый, ул да сабый. Яшәдек, Аллага шөкер. Егерме биш ел. Сугышка китеп кенә харап булды, бәгырькәем. Юксынам үзен.

– Шулайдыр инде. Ир бирмәк – җан бирмәк, дигәннәр бит. Сагындырадыр. Ярый алайса, китәр алдыннан хәбәрләшербез. Кергәләп йөр.

Шушы сөйләшүдән соң бу темага кире кайту булмады. Асия көн саен булмаса да, Гөлнарларга кергәләп торды. Февраль башларында алар Әминә белән Казанга кайттылар.

Салих Асияне хәтерли булып чыкты. Шәрык клубы кичәләрендә алар беркадәр аралашкан да булганнар. Ләкин унҗиденче елда Салих Буага китеп баргач, аннары – Кызыл Армиягә, Төркестан якларына, аларның юллары аерылды. Шуннан бирле ул дөньяда Асия исемле кеше барлыгын белмичә дә яшәде бугай инде. Һәм менә егерме сигез елдан соң язмыш аларны бергә кавыштырды. Алар икесе бергә Салихның театр ишегалдындагы квартирасында көн күрә башладылар.

Салих уллары белән дә очрашты. Бик еш кына аларны мәктәптән өенә алып кайта торган булды. Ул Эмильне аеруча ярата иде. Аны үзенең дәвамчысы итеп күрде. Аны әле биш яшендә чагында ук фортепианода уйнарга өйрәтә башлаган иде. Малай үзе дә сәләтле, тиз отып кала һәм үзлегеннән уйнарга яратты. Ләкин көтмәгәндә, Салихка тагын бер зур кайгы килде. Ходай үзенең үксез баласын шулай сыный иде булса кирәк: матур гына укып йөргән җиреннән икенче класста укучы Эмиль үлеп китте. Тәнәфес вакытында шаярып-шукланып уйнап йөрүче малайларның кайсыдыр ишекне аягы белән тибеп ача да ишек төбендә торган Эмильнең башына китереп бәрә. Малай башына каты җәрәхәт ала. Берничә көннән ул хастаханәдә вафат булды.

Аның үлеме Салих өчен гаять зур җан ярасы булды. Ул моны бик авыр кичерде. Валясы вафатындагы шикелле иләсләнеп, дөньясын онытып, тормыштан гаме китеп йөри башлады. Ул үз эченә бикләнде. Кеше белән сөйләшмәде. Ашы – аш, эше – эш, йокысы йокы булмады.

Җиңүдән соң икенче елда фронттан Альфред кайтты. Аның артыннан ук

диярлек Асиянең улы Фәрхәд тә кайтып төште. Икәү генә яшәгәндә иркен булып күренгән өйдә ничектер кысан булып китте.

Салихны карап, тәрбияләп торырга дип ышандырып кайткан хатын беренче елларны сүзенә тугры булды. Ләкин уллары кайткач, алар үз кайгылары, үз мәшәкатьләре белән яши башлагач, Асия дә үзгәрде. Улы турында күбрәк кайгырта башлады...

Шулай бер кичне театрда спектакльнең беренче пәрдәсе тәмамлангач, вестибюльдә тамашачылар белән сөйләшеп торганда, Салих янына ниндидер бер кыз белән Альфред килеп басты.

– Әти, таныш бул, бу – Вера, – диде улы.

– Нинди Вера?

Сорау ничектер дорфа килеп чыккан шикелле булды.

– Гафу итегез, дөрес сорамадым. Улым, син мине уңайсыз хәлгә куясың.

– Гафу ит, әти, – диде Альфред. – Сине үземнең сөйгән кызым белән таныштырырга теләгән идем.

– Ә-ә, шулай диген аны. Бик шат, – дип, Салих Верага кулын бирде. – Салих, Альфредның әтисе.

– Беләм, – диде Вера. – Гафу итегез инде Альфредны. Юристлар шундый була инде ул. Ничего, без аны өйрәтербез әдәпкә.

Альфред бу вакытта университетның юридик факультетына укырга кергән иде. Шуңадыр, күрәсең, Вера аны юрист дип атады.

– Юрист булганчы юриспруденцияне өйрәнәсе бар әле биш ел буе, – диде Салих.

– Кайгырма, әти, өйрәнермен. Аның яртысын сугышта өйрәнеп кайттым инде мин.

Шулвакыт тәнәфес бетүен искәртеп, кыңгырау чылтырады. Салих оркестр чокырына ашыга иде.

– Гафу итегез, ашыгам, – диде дә вестибюльдән залга кереп китте.

Шуннан соң озак та йөрмәделәр, Альфред белән Вера өйләнешеп тә куйдылар. Альфред хатыны квартирасына яшәргә күчте.

Шулай беркөнне Салих Галактионов урамында сыртына күтүмкә салган Заһидулла Яруллинны очратты. Аны бик күптәннән күргәне юк иде инде. Шактый картайган Заһидулла абыйсы. Утыз биш ел белә бит инде ул аны. Беренче тапкыр үзен рояльдә уйнарга өйрәтә башлаган чакларда ук олы кеше шикелле иде инде ул. Шиһап җизнәсеннән биш яшькә кечерәк иде бугай. Җизнәсе хәзер алтмыш биштә. Димәк, алтмышлар тулып киләдер инде остазына да. Салих аның беренче хатыныннан аерылганын белә. Фәрит утыз сигезенче елда әтисенең яшь хатынының малай алып кайтуы, энекәше тууы турында әйткән иде. Ул малайга да тугыз яшь тулган булырга тиеш икән инде. Ничек әле исеме? Мирсәет. Әйе шул, Мирсәет.

– Исәнме, Заһидулла абый? – дигәнгә, остазы сискәнеп китте.

– Бәй, Салих, син түгелме соң?!

– Мин шул. Нәрсә, Фәритнең кызын, оныгыңны күрергә килдеңме әллә?

– Каян беләсең? Әүлияме әллә син?

– Беләм. Ник белмәсен. Фәрит шушы йортта яши иде бит, – дип, Салих Фәритнең хатыны Галина торган коммуналкага төртеп күрсәтте.

– Ә син нишләп йөрисең бу тирәдә?

– Җизниләргә килешем. Җизниләр менә бу йортта тора бит. Фәритләрнең күршесендә.

– Шиһап җизнәңме?

– Әйе.

– Шулаймыни? Исән-саумы ул?

– Әйбәт кенә йөри. Әле килүең генәме, Заһидулла абый? Кереп күренмәдеңме әле Галяга?

– Килүем генә шул.

– Әйдә, икәү бергә кереп күренеп чыгабыз да җизниләргә керербез. Бер сюрприз ясыйк әле җизнигә. Кайтканнан бирле беркем белән дә аралашмый. Беркемнең дә килеп, аның хәлен белгәне юк. Тәмам кыргыйланып бетте тормыштан. Бер бәйрәм яса әле үзенә.

– Үземнең дә бик күрәсем килеп китте. Әйдә, шулай итик әле. Киленнең дә сине күреп, күңеле булыр. Фәрит синең белән бик дуслаштым дип сөйли иде. Дуслар идегез бит. Һәлак булды Фәритем. Җиһанов алып кала ала иде... Шуның чакыруы буенча килдем менә. Мәскәүдән килгән нindидер кешеләр, Власов диме шунда, «Шүрәле»не яңадан карап чыкканнар. Репетицияләре бара икән. Бу көннәрдә шуны күрсәтмәкчеләр, ди, халыкка.

– Шулай дип ишеткән идем шул. Власов белән Фере редакцияләп, балетмейстер Якобсон куярга әзерли икән, диделәр. Бик әйбәт булыр. Фәрит үзе күрми калды, бәгырь. Бөтен хыялы шул иде.

Шаулап-гөрләп каенатасы белән Салих килеп кергәч, Галина югалып калгандай булды. Салих аны ике көннең берендә күргәләп, хәлләрен белешеп тора иде. Икесе ике театрда булса да, бер бинада эшләп йөриләр бит. Атнаның бер көнендә драма театры спектакле барса, икенчесендә опера театры тамаша күрсәтә. Галина да репетицияләргә йөри.

– Исәнмесез, бәгырькәйләр, – дип, беренче булып Салих күреште. – Менә кунак алып килдем.

– О-о әткәй! Ничек киләсе иттең?! Юл ерак бит.

– Килеп җиттем инде, машиналарга утырып, җәяү килдем ат белән.

– Ничек, ничек?

– Ат белән дә, җәяүләп тә, машинага да утырып, ди бит. Ничек килсә дә килгән инде.

– Менә, килен, авыл күчтәнәчләре, – дип, Заһидулла абзый күтүмкәсендәге күчтәнәчләрен бушата башлады. – Әллә ни юк. Булганы бар да шунда. Хәнифә апаң күп сәламнәр әйтеп җибәрде дә юл капчыгыма менә шул нәрсәләрне тутырды. – Ул капчыктан берәм-берәм сөт, атланмай, эремчек, тавык йомыркасы кебек нәрсәләрне бушатты.

Килен тиз генә табын әзерли башлады, примуска чәй кайнатырга куйды.

– Килен, чәйләр эчеп тормыйм, без Салих белән Шиһап абыйларыңа кереп чыгыйк әле. Шиһап минем яшьлек дустым ул. Күршеләр булып яшисез икән бит. Кереп хәлен белешмәсәм, гөнаһ булыр. Чәйләрне соңыннан. Сез Наилә матурым белән чәй эчегез анда, – диде дә Заһидулла абзый, кемнәр килде икән безгә дип аптырап та, куркып та өстәл артында тын гына утыручы бәләкәй кызчыгын кулына алып сөйде. – Нинди дәү үскән минем кызым!

Наиләгә бу вакытта инде алты яшь тулган иде.

– Нинди дәү кызы булган бит улымның. Үзе генә күрмәде. Әтисез үсә бала. Ятим үсә.

Алар кергәндәге шикелле үк гөрләшеп кире чыгып киттеләр.

Салих белән Заһидулла Яруллинның килеп керүе Шиһап өчен көтелмәгән хәл булды. Ул аларны күргән сөенеченнән телсез калды. Аларның күрешмәгәннәренә төп-төгәл егерме дүрт ел икән бит инде. 1923 елда Заһидулла Казанны ташлап, Уфага чыгып киткәннән бирле. 1930 елда кире әйләнеп кайттылар алар Казанга. Ләкин ул вакытта Шиһап төрмәдә җан тирен агыза иде шул инде. Аннан ул сугыш башланыр алдыннан гына котылып кайтты. Кайтты да беркем белән дә аралашмыйча, беркемне дә күрмичә, шыпырт кына йөреп ятты Казан белән Кызыл Байрак арасында.

– Заһидулла! Син түгелме соң! Син дә исән икән бит!

– Мин шул, мин, Шиһап туганкай! Исәнме, саумы? Ни хәлләрдә?

– Исәнме, Заһидулла! Менә, ятабыз инде шушында әкрен генә. Яшәп дисәң, яшәү түгел, яшәү түгел дисәң, хәтере калыр. Тереклек итәбез. Ярый инде, Соловки түгел. Түзәрлек. Әйдә, уз әле. Салих, чишендер кунакны.

– Әй, Шиһап, Шиһап. Сине дә күрер көннәр бар икән. Ничә ел бит инде! Ничә ел! Салих әле армиядән кайтып, эшли генә башлаган иде. Инде ир уртасы булган. Мирхәйдәрнең «Галиябану»ындагы кырык биш яшьләрдәге авыл карты. Аны да узган бугай инде.

Алар чишенеп, пәлтәләрен ишек төбендәге чөйләргә элделәр дә түр якка уздылар.

– Әйдә, утырышыгыз әле, – дип, Шиһап кунакларга урыннар тәкъдим итте дә алгы бүлмәгә карап: – Дилбәр, синме анда, чык әле бире, – дип кайсындыр чакырды.

Дилбәр дигәне кереп исәнләште.

– Бу безнең килен була. Дилбәр. Беләсең бит Мәдәният йортында баш администратор булып эшләп йөргән Пороховой Җамалыйны? Җамалетдин Саинов.

– Беләм, белми ни.

– Менә шуның кызы Дилбәр, безнең килен хәзер. Үзбәкнең хатыны.

– Шулаймыни?

– Ничек соң Җамалетдин, исән-саумы? – дип, Заһидулла Дилбәргә сорау бирде.

– Исән-саулар, Аллага шөкер. Бер килеш яшәп аталар әни белән шул үзләренең Пороховой бистәләрендә.

– Дилбәр, Заһидулла абзаңны таныйсыңдыр. Чәй табыны әзерлә әле. Әминә кибеткә чыгып керәм дип киткән иде. Кайтыр инде, – диде Шиһап.

Дилбәр хәзер дип, кухня ягына чыгып китте.

– Йә, сөйләп җибәр, Заһидулла. Ни хәлләрең бар? Ни эшләр бетереп йөрисең?

– Йөрим инде шунда юкны бушка авыштырып. Үзең ни хәлләрдә? Син сөйлә әле. Күп михнәтләр күреп кайттың? Кемнәр белән булдың?

– Әй, Заһидулла. Әйтмә инде. Күрде инде башлар. Бер гаепсезгә бит.

Бер гаепсезгә. Япон шпиуны дип тинтерәттеләр бит. Каян килеп япон шпиуны булыйм инде мин?! Анда бер көтү идек без япон шпиуннары. Шулкадәр күп шпиун җибәргәннәр икән японнар. Искитмәле. Аннары булмагач, солтангалиевче милләтче, вак буржуаз элемент дигән гаеп тактылар. Солтангалиев үзе дә яңадан сөрелгән Соловкига. Аңа һәм безгә Троцкий-Каменев-Зиновьев оештырган оппозицион платформаның «милләтче төркеме» дигән гаеп тактылар. Мирсәетне егерме сигезенче елда кулга алган булганнар икенче тапкырында. Аны утыз дүртенче елда азат иттеләр. Без калдык. Утыз тугызынчы елда атып үтергәннәр, ди, мескенне. Мин кайттым менә биш ел срогымны тутырып. Аннары биш ел хокуксыз булып яшәп яттым. Хәзер дә гел тикшереп, кая йөргәнемне күзәтеп кенә торалар.

Шунда кибетләрдә йөреп, Салихның Әминә апасы кайтып керде.

– Кунак бар бездә, Әминә, – дип каршы алды аны Шиһап.

Әминә бүлмәгә кереп, кунакның кем икәнен күрде дә:

– Заһидулла абый, син түгелме соң? – дип, аның белән килеп күреште.

– Мин, Әминә. Менә килен янына, Фәритемнең кызын да күреп кайтыйм дип килгән идем, сезнең күршеләр булып чыктылар. Күршеләр булгансыз икән бит Фәритем белән.

– Әйе шул. Фәрит кенә әрәм булды, Заһидулла абый. Әрәм булды.

– Әйтмә инде.

– Бар, Әминә, килен белән табын хәстәрләгез әле анда, – дип, Шиһап хатынына чәйне ашыктырырга кушты да сүзен дәвам иттерде: – Без кайттык әйләнеп. Бездән бушаган нарларга яңа халык дошманнарын җыеп китерделәр: Тинчуриннарны, Бурнашларны. Аларның срогы бетмәс борын сугышта плиндә булганнар белән тутыра башладылар. Алар да халык дошманы икән бит. Плингә төшмичә, атылып үләргә тиеш булганнар, мескеннәр. Плиннән котылып, дошманга каршы сугышта йөрсәләр дә, Берлинның үзенә хәтле барып җитсәләр дә, тикшереп, гаепле дип табалар күбесен. Менә шуларны күрәм дә, җан әрни. Шундый ил төзер өчен дип ясадыкмыни соң без ул ривәлүтсияне?! Ул сугышта кырылды мескен адәм баласы. Командирларның наданлыгы аркасында. Чын командирларны сугыш алдыннан халык дошманы дип аттырып бетерделәр дә, сугыш рәтен белмәгән уналты-унҗиде яшьлек малай-шалайларны өч-дүрт айлык курсларда укытып, командалык итәргә җибәрделәр. Нәрсә белсен ул молокосослар?! Сугыш тактикасын беләләрме алар? Нимесләр алар өйрәнгән, әзерлекле. Һөҗүмгә бөтен төр гаскәрләр белән килә. Башта разведка өйрәнә обстановканы, аннан һавадан самолётлар килеп бомба ташлап китә, артиллерия утка тота. Шуннан танклар килә өскә ябырылып. Алар артыннан – пехота. Ә безнең нәрсә? Ята мескен кичә армиягә алынган малай-шалайлар окоп төбендә качып. Иң соңыннан, шул пехотасына каршы чыккан булып карый. Анда инде исән калганы булды микән ул һөҗүмгә каршы барырга? Менә шулай кырылды сәвит солдатлары. Шулай бетте синең Фәритең кебек талантлы егетләребез. Фатих Кәрим, Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Гадел Кутуй, Рәхим Саттар, Нур Баян кебек язучыларыбыз. Ул Мусалар, Алишлар, Саттарлар бөтенләй хәбәрсез югалдылар. Халык дошманнары булып

йөриләр хәзер. Хатыннары иза чигә. Сугышның самый кайнап торган җиренә китереп тыктылар да... Ул Бөтенсоюз старостасы Калинин, гражданнар сугышында атка атланып кылыч айкап йөргән маршал Будённыйларның хатыннары да ятты безнең белән халык дошманы булып. Үзләре ил белән идарә итте, янәсе. Сугыш каһарманнарына медаль тагып йөрделәр. Адәм көлкесе...

– Син үзең сугышта булган шикелле сөйлисең, Шиһап абзый. Каян белеп сөйлисең боларны?

– Сугыштан кайтканнарның сөйләгәннәрен тыңлыйм мин. Үзем бармадым сугышка. Ләкин сугыштан исән кайткан солдатларның кайсыннан гына сорасаң да, нәкъ шуны сөйли. Мәсгут Латыйпов сөйләде боларны миңа. Ул исән-сау кайтты әйләнеп. Йә, ярар. Бетте сугыш, Аллага шөкер, җиңдек. Инде бүтән сугышлар булмасын. Әйдә, чәй әзердер анда, чыгыйк әле кухня ягына.

Шиһапның әйткәнен ишеткән кебек кухнядан Әминәнең тавышы ишетелде:

– Шиһап, алып чык кунакларны, табын әзер.

Алар сөйләшә-сөйләшә, үткән гомерләрне искә ала-ала, чәй эчтеләр. Аннары Салих Заһидулла абыйсын килененә озатып куйды. Заһидулла абзый иртәгесен башта Композиторлар союзына барып, Җиһанов белән күреште. Аннары кичен Салихлар белән дә бергәләп, театрга «Шүрәле» балетын карарга бардылар.

**15**

Сәйдәшевнең Ленинград консерваториясе профессоры Юдин белән эшләгән «Хафизаләм-иркәм» спектаклен опера театрында куярга дигән карар чыгарылды. Аннан соң эшләнгән «Изге әманәт» зур каршылыклар белән драма театрында берничә мәртәбә уйналды да тукталып калды. Ниһаять, Сәйдәшкә күңелен салып башкарырдай яңа эш бирделәр. Таҗи абыйсы «Чын мәхәббәт» дигән пьеса язган иде.

Таҗи драманың идеясе, анда бара торган вакыйгалар турында уйларын башта ук Салих белән уртаклашты.

– Салих, мин безнең сугышта җиңүебездә Европа халыкларының да зур өлеш кертүен күрсәткән әсәр язарга телим, – диде ул.

– Шәп идея бу. Кайсы ил сугышчылары мисалында язмакчы буласың?

– Беләсеңме, күп илләр немецлар ягыннан торып сугышты. Чехлар, венгрлар... Ә менә югославлар, партизан отрядлары төзеп, балканда фашистларга каршы көчле сугышлар алып бардылар. Менә шундый отрядларның берсендә барырга тиеш вакыйга.

– Алай булгач, югослав җырларын да кертеп җибәргәндә, начар булмас иде.

– Идея бу. Спектакльнең абруен күтәреп җибәрәчәк.

– Син, бәгырь, Казан университетында укып йөрүче югослав студентларын табып китерсәң иде миңа. Аларны җырлатып карап, көйләрен отып калырга иде.

Шуннан соң Таҗи университетта укучы ике студент егет белән сөйләшеп, аларны Салих белән очраштырды. Югославлар бик җыр сөючән

халык икән. Көйләре дә, үзләре славян булсалар да, төрек җырларына охшап тора. Салих берничә җырны нотага салып, үзе өчен җыр калыпларын әзерләп куйды. Таҗи абыйсының текстлар язып бирүен генә көтәсе калды. Инде пьеса язылып бетте, җыр сүзләрен генә язасы калды, дип йөргән көннәрнең берендә көтелмәгән хәл килеп чыкты. Югославия белән СССР арасында ниндидер конфликт барлыкка килгән. Газеталарда югославларны тәнкыйтьләгән мәкаләләр басылды. Инде нишләргә? Пьеса хәтле пьесаны үзгәртергә, анда барган вакыйгаларны башка ил белән бәйләргә кирәк булачак бит.

– Нишлибез инде, Салих, югославлар безнең эшкә таяк тыкты бит? – диде Таҗи.

– Югославия булмаса, башка бер ил белән алмаштырып куярга да бетте-китте, вәссәлам, – диде Салих. – Югослав дигән сүзне башка бер исем белән алмаштырасың, әллә ни күп зыяны юктыр бит. Шул ук сугыш бит инде ул.

– Шулай шул, әйбәт идея әйттең. Карале, Югославия белән күршедә нинди ил бар соң әле ул?

– Соң, бәгырь, күршеләрендә генә албаннар яши бит. Албания партизаннары да сугышкандыр бит фашистлар белән?

– Ну баш та инде үзеңдә! Юкка гына композитор булып әрәм булып йөрисең.

– Ә кем булырга тагын? Башка һөнәр белмим шул. Ат та җигә белмим хәтта.

– Шаяртып кына әйтәм. Композиторның да бер дигәне син! Түлке менә албан егетләрен табып китерергә туры килә инде үзеңә.

– Анысы проблема түгелдер инде. Югославлар янында алар да укый торгандыр.

– Университетка тагын барырга туры килә инде.

Шуннан соң Салих тагын ике албан егете белән очрашып, албан җырларын тыңлады. Аларның җырлары да югославларныкыннан әллә ни аерылмый, төрек җырларына да охшаган булып чыкты. Таҗи пьеса өчен җыр текстларын да язып китерде. Дүрт урында җыр булачак икән. Дүрт җыр язарга кирәк.

– Пьесаны укымыйча торып, җыр язуы кыен булачак. Син башта пьесаңны тәмамла инде, аннары җыр турында уйлармын, – диде Салих.

– Менә, монысын укый тор алай булгач, – дип, Таҗи аңа пьесаның каралама нөсхәсен бирде. – Җырларын яза башласаң да була.

– Яхшы, килештек.

Салих шулай итеп дәртләнеп эшкә чумды. Аның өчен фантазиягә мәйдан җитәрлек иде.

Таҗи абыйсы аның янына көн дә кергәләп йөри башлады. Кергән саен берничә вариант уйнап күрсәтте Салих. Ул тиз эшләде. Һәр җырны берничә вариантта язып карады. Таҗига барысы да ошый кебек иде. Ләкин Салих үзе канәгать түгел, йә бер урыны килеп җитми, йә икенче. Көе белән генә түгел, сүзләренә дә үзгәрешләр керттерде.

– Таҗи абый, сез бөтен җирдә бары тик кызлардан гына җырлатасыз. Партизаннар да, шәфкать туташлары да – кызлар. Бер урында фельдшер

кыз Хәмидә урынына аннан отып калган итеп «Әдрән диңгез» җырын Дәүраннан җырлатсагыз, әйбәт килеп чыгар иде, – диде Салих. – Ир-егетләр тавышы өчен бик килешле җыр.

– Җыр беренче башкарылганда, Дәүран госпитальдә, бик авыр хәлдә ята бит. Җырларлык түгел, сулыш алырлык та хәле юк.

– Ул урында түгел, каядыр соңрак кертеп җибәрергә була.

– Ярар, уйлап карармын.

– Әйбәт булыр иде. Менә көен яздым. Тыңлап кара әле, – дип, Салих фортепианода уйнап, үзе үк җырлый башлады.

Әдрән диңгез, гүзәл диңгез,
Әй, гүзәл диңгез.
Күп яуларны күргән диңгез,
Күргән ул диңгез.

Тау батыры Искәндәргә,
Искәндәргә
Җан дәвасы биргән диңгез,
Биргән ул диңгез.

Әдрән диңгез, даулы диңгез,
Тирәләре таулы диңгез.
Хәлен җуйган син бөркеткә
Шифа бирсен изге диңгез.

Йә, ничек?

– Кабатлаулар керттеңмени?

– Озын албан көйләренә охшап китте. Диңгезнең кодрәтен, көчен дә күрсәтә торган булды кебек.

– Шулай дисеңме?

– Албан егетләренә тыңлатып карарга кирәк яңадан. Алар нәрсә диярләр тагын.

– Яхшы, килешәм. Болай матур гына килеп чыккан кебек. Ягымлы, моңлы көй. Албан көйләре аһәңнәре бар.

Икенче көнне Салих Таҗи абыйсын шатландырып, тагын бер җырны уйнап күрсәтте.

– Таҗи абый, Хәмидәнең «Язгы кар суы» дигән җырына да көй туды бит.

– Менә әйбәт булган! Башкарып та күрсәт инде.

– Тик мин ул җырга «Динар тавы» дигән исем бирер идем. Монысын да ирләр башкарса, әйбәтрәк яңгырар иде.

– Минем пьесада бөтен җырларны да фельдшер Хәмидә җырлый бит. Ничек итеп ирләрдән җырлатасың инде аларны? Беләсеңме, Салих?..

– Белмим.

– Белмисең, әлбәттә. Мин шуны әйтергә телим: бу җырларны бит халык спектакльдән соң аерым җырлар итеп тә җырлый башлаячак. Менә күрерсең, алар бит мөстәкыйль җыр булып та бик матур яңгырыйлар. Синең бөтен җырларың да шундый бит. Кайчандыр спектакльдә җырланганнар да аерым җыр булып киткәннәр.

– Шулай инде анысы. Йә, ярар, тыңла. Җырлап карыйм:

Биек тә биек Динар тавыннан,
Динар тавыннан, ай, тавыннан,
Ага ыргылып язгы кар суы,
Язгы кар суы, кар суы.
Безнең йөрәкнең әрнеп ярсуы,
Әрнеп ярсуы,
Әйләнеп тиздән ачу көченә,
Ачу көченә,
Тупланып гомум халык үченә,
Халык үченә,
Китәрбез ташып, ярлардан ашып,
Ярлардан ашып,
Киң далаларны үтәрбез басып,
Үтәрбез басып.

– Беләсеңме, Салих, бу җырны тыңлаганнан соң каядыр очасы, талпынасы, бөтен тавышка кычкырасы килә!

– Син, Таҗи абый, бу җырны тыңлаганда, Дәүраннан да шушы сүзләрне әйттерәсең бит.

– Мин әле язганда көе булмаган килеш җырны шулай күз алдына китердем. Ә хәзер чынлап та шулай, каядыр очасы, талпынасы килеп китте. Беләсеңме, шундый туры килеп тора! Оста да инде үзең! Мин спектакльнең уңышлы булачагын күрәм! «Изге әманәт» кебек иләмәсләр монысын, шәт иншалла!

– Шулай булсын инде.

Таҗи Гыйззәт шулай да Язучылар союзына да, театр белгечләренә дә бик ышанып бетмәде. Уку вакытында әсәрне туздырып ташларга күп сорамаслар, дип шикләнде. Пьесаны алып, Мәскәүгә барып кайтырга уйлады. Анда берәр драматургкамы, театр белгеченәме укытып, фикерен Татарстан белгечләренә җиткертәсе килде. Шулай эшләде дә. Русчага тәрҗемә ясаттырып, Мәскәү Язучылар берлеге идарәсе секретаре Сафроновка укытты. Ул аны хуплап, куярга кирәк, дигән резолюция белән өлкә комитетына хат юллады.

Пьесаны Язучылар союзында уку вакытында тискәре караштa утыручылар күренсә дә, тикшерү вакытында, хәтта икеле-микеле чыгыш ясаучылар да куймаска кирәк дигән сүзне әйтмәделәр.

Премьера зур уңыш белән узды. Куелган саен тамашачы арткannан-арта барды. Халыкны спектакльдә барган вакыйгадан бигрәк көен Сәйдәш иҗат иткән җырлар үзенә тарта иде.

Спектакль 92 мәртәбә уйналганнан соң репертуардан төшсә дә, анда яңгыраган җырлар халык күңеленә мәңгегә кереп калды.

**16**

Тормышлар рәтләнә бугай. Театрда, музыкаль драма булмаса да, спектакльләргә көйләр яздыра башладылар. Кырык сигезенче ел сезонына репертуарга Нәкый Исәнбәтнең «Мулланур Вахитов» драмасын керткәннәр. 1928 елда ук куелган «Наёмщик»ның яңа версиясен эшләргә кушылды. Салих үзе күптән уйлап йөргән әсәрен язарга керешергә булды. Ул Болгар ханлыгының Батый хан тарафыннан яулап алыну чорларына караган

балет язарга хыялланып яши иде. Кыскасы, эш бар, җиңнәреңне сызган да рәхәтләнеп иҗат ит!

Шул елны Сәйдәшкә әтисенең туган якларына, Дөбъяз районы авылларына кайтып килергә насыйп булды. Казан консерваториясенең теория-тарих факультетында укучы бер төркем студентлар аны Казан арты авылларына экспедициягә чакырдылар. Салих рәхәтләнеп риза булды. Аның Кәрим Тинчурин һәм Ситдыйк Айдарский, Таҗи Гыйззәт һәм Мингали Дәүләтшиннар белән төрле елларда музыкаль драмалар өчен материал туплаганда, Казан арты авылларындагы сәяхәтләрен искә төшереп кайтасы килде. Гомумән, бу якларны ул үз күрә, күптән инде бер кайтып, күреп килергә дип хыялланып йөри иде. Бу юлы да алар күп кенә авылларда булдылар. Әтисенең туган авылы Өбрәне дә, әнисенең әтисе Миңлебай туган Битаманны да күрделәр. Студентлар халык арасында йөреп, халык авыз иҗатына караган күпләгән җырлар, бәетләр, мөнәҗәтләр язып алдылар. Кайберләре әкият, мәзәк, табышмак, мәкаль ише нәрсәләрне дә сораштырдылар. Студентларның эшләре беткәч, Габделхәй Вахитов атлы егет Салих абыйсын үзенең туган авылына кунакка чакырды. Ул Мәмдәл авылыннан икән. Салихның моңа кадәр дә, әле сугыш елларында ук, фронт фондына җибәрү өчен бәрәңге уңышын җыеп алу кампаниясе вакытында Мәмдәлдә булганы бар иде. Аның хәтта бу яктан чыккан бер дусты да бар. Мәмдәлнең күршесендәге Юртыш дигән авылдан Галләм Саттаров. Галләм Сәйдәштән биш-алты яшькә өлкәнрәк. Мәмдәл мәктәбендә укыган, җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Казанга китеп, Шәрык клубында театр уйнап йөргән. Аннары Мәскәүдә белем алган. Мәскәүдә «Эшче» театрында Газиз Айдарский, Сара Садыйкова, Разия Измайлова, Мәкәрим Мәһдиевләр белән бергә Советлар Союзы буйлап спектакльләр куеп йөргәннәр. Алар Сара Садыйкованың апасы Разия белән өйләнешеп, соңыннан Уфага китеп, шунда яшәп калалар. Галләм хәзер Башкортстан дәүләт академия театрының режиссёры булып эшли. Сәйдәш театр белән Уфага гастрольгә килгән чакларда Галләм аны гел якташ дип, үзенә кунакка алып кайтып китә иде. Озаклап сөйләшеп утыралар. Туган якларын искә төшерәләр. Габделхәй Вахитов аны менә шул дустының авылына кунакка алып кайтты.

Габделхәй әнисе Сәрвәрне ялгыз калганнан соң Мәмдәлдән үзләренә, Казанга алып китә, ә аларның өендә төп нигездә өч кызы Гөлира, Флёра һәм Люция белән атасы Каюмның бертуганы булган Сара апасы яшәп кала. Аның ире, колхозда тимерче булып эшләгән Ковалёв Андрей Фёдорович, сугыштан әйләнеп кайтмаган. Сара апа үзе яшь чагында Казанда кызлар мәдрәсәсендә укып белем алган. Аларның әтиләре Габделвахит абзый шактый гына хәлле, гыйлемле кеше була. Бөтен балаларына да белем бирергә тырыша.

Казанда консерваториядә укып йөрүче, яшь чагында театр техникумында укып, артист булырга хыялланып йөргән, пьесалар язып танылган, үзенә Хәй Вахит дигән тәхәллүс алган авылдашларының күренекле композитор Салих Сәйдәшев белән кайтуы авыл халкы өчен зур бәйрәм булды. Көндез мәктәптә, кичен клубта балалар һәм колхозчылар белән очрашулар оештырдылар. Балалар Салих абыйларына сораулар яудырдылар.

– Син үзең, бәгырь, кем малае соң? – дип сорады Салих, әти-әнисе, туганнары, балалары турында бер-бер артлы сорау биргән малайдан.

– Укытучы Фатыйма апай малае, – диде малай.

– Әтиең юкмыни?

– Әти сугыштан кайтмады.

– Шулаймыни? Ә исеме ничек иде соң әтиеңнең?

– Вафа. Вафа Шакиров.

– Үз исемең ничек әле?

– Роберт.

– Роберт Вафа улы Шакиров буласың инде алайса!

– Ие.

– Сиңа ничә яшь соң инде?

– Ун.

– Үскәч кем булырга телисең?

– Очучы булам мин. Самолёт белән үзебезнең авылга хәтле очып кайтам да, авыл башыннан әйләнеп, малайларга сәлам биреп китәм.

– Безне дә утыртып кына алып кайтырсың инде алайса самолётыңа.

– Утыртырмын. Ә сез безгә рояльдә уйнап күрсәтәсезме соң?

– Күрсәтәм. – Салих шулай диде дә залның бер почмагында моңаеп торган рояль артына барып утырды.

– Көйлисе бар аны, Салих абый, – диде шунда Фәүзия Әхмәдуллина дигән укытучы.

– Хәзер, карап карыйбыз. Уйнап булмаса, көйләп калдырырбыз, – диде Салих.

– «Кызыл Армия маршы»н уйнагыз әле, – диде залда утыручы балаларның берсе.

Салих уйный башлады. Рояль шактый гына бозылган иде шул. Кайбер клавишалар тиешле көйне чыгармый торган булып чыкты. Ул шулай да, көйне боза-боза булса да, маршны уйнап бетерде.

– Юк, моның белән уйнап булмый икән. Очрашу тәмамланганнан соң көйләп карарбыз, – диде. – Сүтәр өчен кайбер инструментлар кирәк булачак. Хезмәт укытучыгыз бармы? Балта-чүкеч, шөреп боргыч, карга борыны кебек нәрсәләр китерсен әле.

Салихның шул сүзеннән соң барысы да гөрләшеп көлешеп алдылар.

– Хәер, балта-чүкече кирәкмәсә дә ярый, – дип куйды Салих, елмаеп. – Ярар, рояль торып торсын, гармуныгыз юкмы соң? – диде ул.

– Скрипка бар, – диде Фәүзия Әхмәдуллина.

– Скрипка да ярый.

Кайсыдыр йөгереп кенә, укытучылар бүлмәсеннән скрипка алып килде.

– Кем җырлый белә? Әйдәгез, скрипкага кушылып берәр җыр башкарабыз.

Әхмәдуллина җырлый да белә булып чыкты.

– Мөмкинме мин җырласам?

– Әлбәттә, бәгырь, нинди җыр җырлыйбыз? – диде Салих.

– «Хуш, авылым»ны.

– Шулаймыни? Әйдә, бәгырь, мин уйныйм, сез җырлагыз, алайса.

Салих скрипканың кылларын тарттырып, яңгырашын тикшерде,

көйләде, аннары уйный башлады. Укытучы апалары аңа кушылып, «Күзләр» спектакленнән «Хуш, авылым» җырын җырлады.

Очрашудан соң чәй эчеп алгач, Салих рояльне төзәтергә кереште. Ул шактый таушалган, кипкән булып чыкты. Ике көн буе азапланса азапланды, шулай да рояльне уйнарлык хәлгә китерде.

Мәмдәлдән кайткач, Казанда Салихның кәефен кырган күңелсез хәлләр булып алды. Композиторлар союзында бер-бер артлы композиторлар иҗаты турында сөйләшүгә багышланган ике утырыш үткәрелде. 22 гыйнварда узган РСФСРдагы милли республикалар композиторлары конференциясендә дә, Татарстан Композиторлар союзының 17 февральдә үткән җыелышында да Мәскәүдән килгән Литинский, Лебединский кебек профессорлар Сәйдәшев иҗаты турында уңай яктан сөйләсәләр дә, үзебезнекеләр Сәйдәшев адресына шактый ук чәнечкеле сүзләр әйттеләр. Җыелышның резолюциясендә: «Кайбер композиторларның белемнәре тиешле дәрәҗәдә түгел. Мозаффаров, Фәйзи, Хәбибуллин, Сәйдәшев кебек композиторлар ниятләгән эшләрен ахырынача җиткереп бетерә алмыйлар», дигән нәтиҗә ясалган иде.

Сәйдәшнең моның ише акыл сатуларга әллә ни исе китмәде, билгеле. Бу чыгышларның аның иҗатына бернинди дә ярдәм итмәвен ул аңлый һәм боларны бары тик кемнәргәдер аңа типкәләп узар өчен мөмкинлек чыкты дип кенә кабул итә иде. Ничек кенә типкәләсәләр дә, ул берсенә дә үпкә белдермәде, ачу сакламады; аларга бары тик узып барган кешегә капка астыннан өреп калган көчекләргә караган шикелле генә карый бирде. Хәтта кайчандыр үзен кулыннан тотып, нота графикасын өйрәткән Җәүдәт Фәйзинең шундый җыелышларда: «Сәйдәш – безнең үткәнебез», дигән чыгышына да ул көлеп кенә карады. Шәкертенең остазына карата шундый сүзләр әйтүенә каршы бары тик бер кеше, утыз җиденче елларда әдәбият-сәнгать әһелләре бер-берсенең башын ашаганда, барысы да, газетада кайсыбызны тәнкыйтьләп чыгар икән дип, котлары алынып торган Фатыйх Мөсәгыйт кенә: «Сәйдәшев – безнең киләчәгебез!» – дип яклап чыкты.

Моның ише чыгышларның үзенә карата әзерләнгән гаять тә җитди һөҗүмнең хәбәрчеләредер дип башына да китермәде Сәйдәш. Һәм менә сиңа мә: берничә көн үтүгә уналтынчы мартта аны эшеннән үк чыгарып аттылар! Ул җәмгыять өчен кирәкмәгән, артык кешегә әйләнде.

* * *

Кекин кибетеннән чыккач, Салих кая барырга белмичә аптырап басып торды. Тоттылар да, берни әйтми-нитми, сәбәбен дә аңлатып тормыйча эштән куып чыгардылар. Бер тиен акчасыз урамда калды менә хәзер. Болай да 89 сум хезмәт хакы ала иде. Хәзер анысы да булмаячак. Кая барыр, кемгә барып ялыныр? Нинди дәүләт соң бу талантларын хөрмәт итми торган? Халык бит ничек ярата! Ә җитәкчеләр?.. Мәдәният, сәнгать белән идарә итүчеләр?..

Шуларны уйлады да, Салих күңеле тулып, урамда ук елап җибәрә күрмим тагын дип, өенә юнәлде. Ярый әле, ерак барасы түгел, театр ишегалдында гына. Өйдә, хатынына берни әйтми-нитми, үзенең эш бүлмәсенә кереп

китте, өс-башын да алмаштырып тормыйча, караватка барып ятты да тыела алмыйча үксеп-үксеп елады.

Инде нишләргә? Хатынына ни дип әйтергә?

Театр һәм радио аның өчен изге нәрсәләр иде бит. Ул татар музыкаль драма театрын тудырган кеше, татар радиосының беренче музыкаль редакторы булган кеше! Бер үк вакытта театр һәм радио аннан композитор ясады; алар аны дөньяга таныттылар. Һәм менә хәзер ул аларга кирәк түгел. Хәтта Композиторлар союзы җитәкчеләре арасында да аның хәленә кергән, аны эш белән тәэмин итәргә теләгән кеше күренми. Ә бит композиторлар барысы да кайсы кая хезмәттә: кайсы консерваториядә укыта, кайсы радиокомитетта, кайсы музфондта, кайсы Фольклор үзәгендә. Бер Сәйдәш эшсез калды. Ә бит ул беренче татар профессиональ композиторы! Аннан соң үсеп чыккан композиторлар барысы да музыка иҗат итәргә аннан өйрәнделәр, аның мәктәбен уздылар.

Бертуктамый миен бораулап торган бу уйлардан ничек котылырга? Салих һаман шуны уйлады.

Бу бит аның өчен стресс. Ә бит стресcның ахыры ничек бетәсе билгеле. Аның ахыры бер генә.

Юк, дөнья бит әле моның белән генә бетми. Бер-бер юлы табылыр. Эштән кыскартылса да, быелгы репертуарга кертелгән спектакльләрне чыгарасы бар. Аларга музыка язасы, бизисе бар. «Гөлнара»ны язып бетерергә кирәк.

Салих икенче көнне эшкә дип, өйдән чыгып китмәде. Өченче көнне дә. Асия берни дә сорамады. Ул Салихның эштән кыскартылуы хакында ишеткән иде инде. Бу хакта сүзне ул дүртенче көнне үзе башлады.

– Нәрсә, Салих, шулай күпме аунарга уйлыйсың ул караватта? Берәр эш табарга кирәк бит инде, болай булмый, – диде.

– Эш бар, Асия, бәгырь. Эш бар.

– Булгач, эшләргә кирәк. Аунама ул караватта көннәр буе. Тор, эшкә тотын.

– Тотынырга кирәк, бәгырь. Үзем дә шулай уйлыйм. «Наёмщик»ка тотынырга кирәк.

– Ул «Наёмщик» наёмщик кына булмады инде. Кайчаннан бирле шуны сөйлисең. Әле опера дисең, әле музыкаль драма. Әллә кайчан куелган «Наёмщик» кемгә кирәк соң ул хәзер?! Мин бит сиңа атаклы композитор дип кияүгә чыккан идем. Ә син монда беркемгә дә кирәкмисең икән. Урам себер әнә. Урам себерү дә – эш. Акчаң булыр ичмасам. Ә болай, йөрисең, хәсрәт булып.

Салих хатынының сүзләрен берни әйтмичә, башын аска игән килеш тыңлап утырды. Нәрсә әйтсен соң? Дөресен сөйли бит. Ашарга ул әзерли. Ризыкны аңа табасы. Ул акчасын гына кайтарып бирергә тиеш. Ә акчасы юк. Кияргә киеме дә юк бит аның. Костюм эченнән кияргә күлмәге дә юк. Күкрәк ягына иске күлмәктән кисеп тегеп куелган муляж. Шуңа күбәләк ябыштырылган. Адәм көлкесе.

– Юк, Салих, мин болай яши алмыйм. Мин улыма яздым. Ул мине килеп алып кайтып китәчәк Уфага. Эшкә урнашып, адәм рәтле хезмәт хакы алып яши башласаң, кире кайтырмын.

Салихның моңа да җавабы юк иде. Фәрхәд Уфага күченеп киткән. Салихның эштән кыскартылуын белгәч, Асия аңа үзен килеп алып кит дип, хат язып җибәрде.

Ул берни дә әйтмичә генә, башына бүреген киеп, иңенә пәлтәсен салды да чыгып китте. Театр ишеге төбендә Мөхәммәт Садри басып тора иде.

– Исәнмесез, Салих абый, – диде ул, аны күргәч.

– Исәнме, бәгырь, исәнме.

– Ни хәлләр бар, Салих абый?

– Хәлләр... үзең беләсең, Садри. Шәптән түгел.

– Ишеттем шул.

– Акча  юк. Хатын акча даулый.

– Хатыннар шулай инде алар.

– Радиодан гонорар аласы бар да инде болай. Ул каһәр суккан Зәйнәп бирмәс шул. Эт шикелле, ырылдарга гына тора.

– Әйдәгез, Салих абый, икәү бергә кереп сорыйбыз. Минем белән матур сөйләшә ул.

– Шулай дисеңме? Юк, бәгырь, син үзең генә кереп сорап кара инде. Мин ишегалдында көтеп торырмын.

Зәйнәп Хәйруллина Мөхәммәтне зәһәр елмаеп каршы алды:

– Нәрсә, эчәргә акча кирәк булдымы? – диде.

– Нишләп эчәргә булсын? Син, Зәйнәп, алай сөйләшмә әле. Салих абыйның гонорар аласы бар икән. Үзе керергә читенсенә. Шуны бирмәссезме дип кергән идем.

– Читенсенәдер шул. Эчәргә акчасы беткәндер. Өченче көн эштән куылгачтын ук, Кекин кибетендә икәүләшеп эчеп утырганнар Таҗи абый белән. Кеше күрә дип тә курыкмыйлар. Бар, йөрмә. Акча юк.

– Күп түгел бит инде, нәнә. Ике йөз иле сум дидеме.

– Юк. Мин бухгалтер түгел. Әнә, нәчәлстводан сорагыз.

Садри ни дип җавап бирергә дә белмәде. Чыгып әйтсәм, Сәйдәшнең кәефе кырылыр инде дип уйлады да радиокомитет председателе Долгов белән сөйләшеп карарга булды. Кереп, гозерен әйтте:

– Михаил Филиппович, Салих Сәйдәшевнең радиодан 300 сум гонорар аласы бар икән. Шуны бирә алмассызмы икән?

– Юк, Мөхәммәт, өч йөз түгел, өч сум да бирә алмыйбыз, – диде дә, Долгов өстәл өстендә яткан кәгазь өеменнән бер бит алып, шундагы саннарның берсенә төртеп күрсәтте: – Менә, күрәсеңме, кичә генә Нәҗип Җиһановка соңгы тиеннәрне кырып-себереп, 3000 сум биреп чыгардык. Бер тиен дә калмады. Бераз соңрак бирербез Салих абыеңа.

Суга төшкән чебеш кебек бөрешеп чыгып килгән Садрины күргәч, Салих:

– Әйтәм бит, йөрмә, дип. Бирмәячәкләрен белә идем инде, – диде.

– Бер тиенең дә юкмыни соң, Салих абый? Менә, миндә берничә сум бар. Биреп торам, – диде Мөхәммәт.

– Кит инде, бәгырь. Мин бит синнән акча сорамадым. Мин ул акчага калмаган. Мине бит Казанда туксан тугыз җирдә туксан тугыз кайнаган самовар көтеп тора. Минем бит халкым бар! Халкым ач итмәс! Әйдә, киттек Фукс бакчасына.

– Туктале, Салих абый, минем эшкә кереп чыгыйк әле. Минем анда җыр өчен дип язган берничә шигырь бар иде. Син шуларга көй язарсың да, мин аларны дуслардан «Совет Татарстаны»нда бастырырмын. Гонорар булыр әзрәк үзеңә.

– Әйдә соң. Тик анда кергәч, кеше ияртеп чыкма. Икебез генә йөрик.

– Яхшы.

Садри эшли торган музыкаль фольклор кабинеты Бутлеров урамындагы Галимнәр йорты бинасында иде. Ерак ара түгел. Алар шунда атладылар. Салих кереп тормады, Садри тиз генә кереп, шигырьләрен алып чыкты.

– Киттек. Алдым, – диде Садри, кулында бернинди кәгазь дә булмавын күреп аптырап калган Салихка. – Кесәгә тыктым. Кеше-карага әйтеп тормас өчен.

– Киттек, – диде Салих һәм Фукс бакчасына таба китмичә, театрга таба атлады.

– Нишләп анда киттек?

– Өйгә кайтабыз.

– Нишлибез анда?

– Ничек инде нишлибез. Җыр язарга.

– Хәзер үкмени?

– Ә кайчан тагын? Кая, бир, укый-укый кайтыйм әле шигырьләреңне.

Мөхәммәт, кесәсеннән шигырьләрен алып, аңа тоттырды. Салих юл буе аларны укып, эченнән генә шыңшый-шыңшый, сызгыргалап кайтты.

Өйдә бер кеше дә юк. Хатыны да каядыр чыгып киткән иде.

– Асия җиңгәң туганнарына барып кайтам дигән иде. Шуларга киткәндер, – диде Салих.

Алар чишенеп, пәлтәләрен ишек төбендәге чөйләргә элделәр дә, Салих, бүлмәсенә кереп, пианино артына утырды. Кулындагы кәгазьләрен алдына куеп, клавишаларга баскалый да башлады. Үзе авыз эченнән җырның сүзләрен мыгырдады.

«Нинди текстны җырлый икән? дип, Мөхәммәт аның янына килеп, кәгазьгә бакты. «Чишмә буенда». «Әһә, Мәрьям Рахманкуловага багышланганын сайлаган икән».

Салих авыз эченнән генә мыгырданды да шунда ук җырлый да башлады:

Әле айлы кич җитмәгән,
Янмый күктә йолдызлар.
Ашкыналар саф чишмәгә,
Киенеп гүзәл кызлар.

Балкырлар бөтен йолдызлар,
Елмая безнең кызлар.
Елмая яшь кызлар –
Җирдәге йолдызлар.

Йә, ничек?

– Әллә яздың дамы, Салих абый?

– Ник, ишетмисеңмени?

– Ишетәм. Шуңа аптырап сорыйм бит.

– Яздым шул. Гонорар була диДең бит.

– Хи, әле кайчан була ул? Кайчан бастырып чыгаралар?..

– Шаяртам гына. Ярар, калганнарын башка вакытта язармын.

– Шулай бик тиз. Ничек шулай яза аласың син аны, Салих абый?

– Ничек тиз булсын? Фольклор кабинетыннан кайтканда шыңшый-шыңшый кайттым бит. Тиз түгел инде. Ярты сәгать бар да бар. Артык булмаса.

– Барыбер тиз инде. Мин шигырьне дә алай тиз яза алмыйм.

– Бу шигырь түгел бит. Монда уйлап торасы юк. Язылган әзер текстка шыңшыйсың да бетте-китте, вәссәлам. Җыр әзер! Кая, ноталарын сызгалап ташлыйм да тиз генә.

Ул шулай диде дә, пианино өстендә яткан нота кәгазьләрен алып, клавишаларга баскалап карый-карый, тиз генә җырның ноталарын язып чыкты.

– Менә хәзер Фукс бакчасына барсак та була.

– Мәрьям Рахманкуловага багышлап язган шигырь иде бу, Салих абый.

– Күрдем шул, бәгырь. Шулай дип язып куйгансың бит.

– Ничек соң шигыре, ошадымы? Көе бик матур чыкты. Ни арада гына яздың! Үзенә әйтсәк, ни дияр икән?

– Пока әйтмичә тор әле. Газетада басылып чыксын. Сюрприз булыр үзенә. Матур шигырь.

Алар чыгып киттеләр. Мөхәммәтнең күңеле күтәренке иде.

– Әйдә, Салих абый, берәр кафега кереп чыгабыз, – диде ул.

– Кекингамы?..

– Юк, анда түгел. Анда Зәйнәп шикелле звирләр күп йөри. Бу тирәдән ераккарак китик әле, – диде Мөхәммәт, радиода Зәйнәпнең әйткән сүзләрен искә төшереп.

Алар Горький урамыннан барып, Толстой урамындагы бакчага килеп чыктылар. Чаттагы сыраханәдән берәр кружка сыра алып чыктылар да кешеләр үтеп-сүтеп йөри торган сукмак читеннән читтәрәк аулаграк урын сайлап барып утырганнар гына иде, каян күреп алгандыр, яннарына кулына таяк тоткан, Салихтан беркадәр өлкәнрәк бер абзый килеп туктады.

– Исәнме, Салих, – диде ул.

Салих башта аның йөзенә игътибар итмичә генә җавап кайтарды:

– Исәнмесез.

– Әллә танымыйсыңмы? – диде агай.

– Танып бетермим шул, бәгырькәй.

– Хәтерлисең микән, Шәрык клубы каршында «Буфф» дигән кинотеатр бар иде.

– Бар иде. Күптән бит инде ул.

– Менә шул театрда син дә, Мансур Мозаффаров белән, малай чагыгызда, берегез скрипкада, берегез мандолинада уйнап йөрдегез.

– Булды андый хәл. Әйтәм бит, күптән бит инде ул.

– Күптән шул. Менә мин үземнең кем икәнемне исеңә төшермәкче булам.

– Йә, йә, шуннан?

– Шуннан шул: «Буфф»ның хуҗасын беләиДеңме?

– Белә идем. Тимершаһ Соловьёв иде. Озак эшләмәде бит ул «Буфф». Бер-ике елдан ябылды.

– Ябылды шул. Мин шул Тимершаһның улы булам. Фоат исемлесе.

– Саллави! Сезмени?! Сезне дә күрер көн бар икән!

– Әтиемне кинотеатрда патшага каршы коткы таратып ята дип гаепләделәр. Синең җизнәң белән дуслар иде бит алар. Җизнәң исәнме әле? Утызынчы елларда утыртканнар икән дип ишеткән идем.

– Исән, ун ел утырып кайтты да хәзер өйдә генә ята.

– Әткәй, мәрхүм, былтыр гына вафат булды, Мәскәүдә. Хөсәен абыем шунда ук җирләде дә.

– Урыны җәннәттә булсын. Яхшы кеше иде. Мин беләм бит аны. Соңыннан Казанда күрештек. Сез бит ул елны Оренбургка киткән идегез.

– Әйе. Аннары егерме беренче елны Казанга кайттык. Ул бит Исхак Казаков, Шаһит Әхмәдиевләр белән дус иде. Шулар чакырып кайтардылар Казанга. Наркомпроста балаларны азык-төлек белән тәэмин итү идарәсендә эшләде әткәй. Синең бабаң туган Битаман дигән авылдан бер егет белән бергә эшләделәр. Исхак Әхмәров исемле иде бугай. Аннары каядыр Мәскәүгә китеп юкка чыкты ул егет. Шунда укып, каядыр чит илләрдә эшләп йөри, диделәр. Сез нәрсә, ял итәргә чыктыгызмы? Сыра чөмереп алырга?

– Әйе, менә, йөреп кайтыйк бераз дигән идек Мөхәммәт дус белән. Мөхәммәт Садри дигән егет бу.

– Таныйм. Язучыларны, артистларны яхшы беләм мин. Алар гына мине танымый. Йә, ярар, комачауладым бугай. Сез утырыгыз. Мин китим әле.

Абзый шулай диде дә, саубуллашып, үз юлы белән китеп барды.

– Әллә кемнәрне беләсең син, Салих абый, – диде Мөхәммәт.

– Китүе хәерле булды әле. Бик кызыклы кеше бу. Фоат Саллави исемле. Минем хатынны да белә торган. Ахры, Асиянең миңа кияүгә чыкканын белмидер. Югыйсә сорашкан булыр иде. Минем хатын бит Казаковлар токымыннан, Апанаевлар кызы. Шуларны искә төшерсә, әллә ниләр сөйләп бетерергә мөмкин. Минем бу вакытта Толстой бакчасында сыра эчеп утырганымны да хатынга сөйләве мөмкин. Аллага шөкер, белми бугай.

– Мин бит сине әллә кемнәр дә белә дип әйтүем.

– Әйтәм бит, бәгырь, мин сиңа: мине бөтен дөнья белә! Минем өчен Казанның туксан тугыз җирендә туксан тугыз самовар кайнап тора! Бик исем китте ул Зәйнәпләргә.

Сәйдәш шулай дисә дә, аның эчендә ут кайный иде. Гарьләнмәслек тә түгел шул. Татарның иң талантлы улы! Заманында Кутуй аның турында чыгыш ясап: «Сәйдәш – татарның музыкада Тукае!» – дип әйткән иде. Менә шул кеше бүген урамда. Шул кешене эшеннән сөреп чыгардылар. Әле ярый утыртып ук куймадылар. Җизнәсе Шиһап Әхмәров, шагыйрь Һади Такташ, шанлы комиссар Шамил Усманов, язучылар Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш һәм әле тагын дистәләгән язучылар, артистлар шикелле үк ул да бу җәмгыять өчен кирәксез, артык кешегә әверелде. Менә шулар өчен гарьләнә иде ул.

## Эпилог

Романны укып чыгучылар: «Ни өчен Сәйдәш гомеренең соңгы көннәренә хәтле чорны да язмадың?» – дигән сорауны бирергә мөмкиннәр.

1948 елдан соңгы калган гомере аның упкын өстендә үткән еллары гына лабаса. Бу чорда ул инде театр өчен спектакльләргә музыка язмый, бары тик Мөхәммәт Садри, Әхмәт Ерикәй, Гамир Насрый, Шәйхи Маннур, Мәхмүт Хөсәен, Гали Хуҗи кебек шагыйрьләрнең сүзләренә җырлар яза да, үзенең иҗат гомеренә йомгак ясагандай, соңгы әсәре итеп, Муса Җәлил шигыренә «Җырларым» җырын иҗат итә.

Җырларым, сез шытып йөрәгемдә,
Ил кырында чәчәк атыгыз.
Күпме булса سездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хаккыгыз!

Сездә минем бөтен тойгыларым,
Сездә минем керсез яшьләрем.
Сез үлсәгез, мин дә онтылырмын,
Яшәсәгез, мин дә яшәрмен...

Әйе, яши аларның җырлары: Җәлилнеке дә, Сәйдәшнекеләр дә. Җырларында аларның рухлары яши. Җырларында алар үзләре яши.

Казан өстен Сәйдәш рухы иңли. Менә ул үзе туган элекке Мещанский (хәзерге Нариман) урамы өстеннән очып үтә. Аның ул туган йорт урнашкан ягы композитор Сара Садыйкова исемен йөртә. Нигә дип әле икенче ягын, Салих Сәйдәшев исеме белән атамаска?! Югыйсә иң кадерле, газиз кешеләре Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш, Шамил Усманов, Галимҗан Ибраһимовларны, күпләгән дусларын бер гөнаһсызга гаепләп, сорау алып интектергән һәм җәзалап үтергән Пләтән төрмәсе урамын аның исеме белән атаганнар! Бу бит аның исемен кимсетү, шәхесен түбәнсетү, рухын мыскыллау белән бер! Җитмәсә, Казанның иң ямьсез, шыксыз, кеше яшәми торган пычрак, ташландык урамнарының берсе.

Менә Сәйдәш рухы – ул беренче музыкаль җитәкчесе, беренче оркестрын оештыручысы булган, сәхнәсендә беренче музыкаль драма жанрын тудырган Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры өстендә! Каршы якта аның һәйкәле тора. Театр алдындагы мәйданда халык ял итә, андагы фонтаннарга карап хозурлана, Кабан күленә карап, җанына тынычлык ала. Нигә дип әле менә шул мәйданны Салих Сәйдәшев исеме белән атамаска?! Югыйсә аның алдында гына Тукай мәйданы бит. Яшеллеккә төренгән бакча уртасында Тукайның мәһабәт һәйкәле карап тора. 1940 елда Салих Сәйдәшев иҗатына багышланган кичәне башлап: «Әдәбиятта Тукай булса, музыкада Сәйдәш бар!» – дип әйткән Гадел Кутуй мең кат хаклы! Тукай белән Сәйдәш янәшә торырга тиеш! Мәйданнары да, һәйкәлләре дә, урамнары да! Чөнки алар татар халкы күңелендә янәшә!

Юк, Сәйдәш тә, аның бу җәмгыять өчен артык булып яшәгән барлык дуслары да татар халкы өчен артык түгел. Алар барысы да аның бәгыреннән өзелеп төшкән үксез балалары!

Салих Сәйдәшев рухына багышлап язган әсәремне моннан күп еллар элек, әле Казан уртасына аның һәйкәле куелганга хәтле, 2003 елда ук язган шигырем белән тәмамларга телим.

## И бәгырь...

Әйтә торган сүзе булган аның,
Сөеп әйтә торган: и бәгырь.
Ул хәзер дә безгә шушы сүзен
Әйтер кебек тоела нигәдер.

Ул татарның бер бәгыре булып
Тоеладыр һаман кемгәдер.
Аның кебек моңлы була ала
Тик яралы бәгырь генәдер.

Ул яралы бәгырь иде җирдә,
Моңнар тулы бәгырь иде бер.
Кадерсезгә калган бәгырь булып
Әле булса җаны иңридер.

Казанның бит үзәк җирендә бер,
Йә театр тирәсендәдер,
Ул торырга тиеш иде безгә
Һәйкәленнән карап, и бәгырь!..

Ул Казанның тик Пләтән дигән
Урамыннан гына, нигәдер,
Үз исемен мәңгеләштерер җир
Таба алган бары. И бәгырь!..

Әйтә торган сүзе булган аның,
Сөеп әйтә торган: и бәгырь.
Ул хәзер дә безгә шушы сүзен
Әйтер кебек тоела нигәдер.

Юк, үпкәләп түгел, бу юлы да
Безне бары сөеп кенәдер...
Без гөнаһлы бүген Синең алда,
Кичерә күр безне, и бәгырь!



Лениза
Вәлиева

## МИН ИНДЕ МИН ТҮГЕЛ ШИКЕЛЛЕ...

* * *

Алма чоры... Күңелләр дә тулып ташкан.
Буш хыяллар, томан булып, күккә ашкан.

Өметләрең акламадым. Сөйдем бары.
Яңгыр булып үрсәләнә җанның зары.

...Сукранып син, иртә килгән көзне тиргәп,
Җәен ачык тәрәзәңне куйдың бикләп.

Җилләр түгел, җансыз салкын пыялага
Парә-парә телгәләнгән күңел кага.

* * *

Җир әйләнә, адәмнәр дә башка хәзер.
Бер сорауга туксан тугыз җавап әзер.
Үзгәрүчән бу тормышта иң кыены:
Җуймый юлың, югалтмаска үз уеңны.

Тайпылмыйча, максатыңа бару кирәк.
Син белгәннән офык чите күпкә киңрәк.
Ит иҗтиһат, табылыр бер тормыш җае.
Төннең дә бит юк кояшы, тик бар ае.

Тауга мендем дип кычкырма, син шуны бел:
Күпме генә эзләсәң дә, хакыйкать бер.
Без беркемнән артык түгел һәм түгел ким.
Син дә патша түгел монда, мин дә хаким.

Лениза ВӘЛИЕВА (1986) – *шагыйрә, «Диңгездә йолдыз коена», «Хәят күгем» китаплары авторы. Казанда яши.*

* * *

Галәмнең асылы – туктаусыз хәрәкәт...
Ноктадан ноктага омтылу арасы –
Мәңгелек каршында нибары бер мизгел –
Атала «яшәде» дип адәм баласы.

Шаукымга бирешми, сау саклау күңелне –
Бу шаулы дөньяда иң читен мәсьәлә.
Җаныңны Иблискә сатмыйча саф калу,
Үзеңне югалтмау бик кыен нәрсә лә...

Нык иман, чын ният, туры юл булганда,
Гаурәтең капларлык яулыгы табыла.
Галәмнең асылы – туктаусыз хәрәкәт.
Тарихның һәр бите ачылып ябыла.

Мөмкинме яшәве йөзеңне югалтмый,
Кыйблаңны бутамый, абынмый дөньяда?!
Кем идек, кем булдык – киләчәк бәяләр,
Бәһасез гомернең – чиге юк җиһанда.

* * *

Дәрьяларны очып кичәр канат барда
Сарыф итмә күңел көчең вак юк-барга.

Җиһан шаулый, җир әйләнә, чаба бәндә...
Кабатлана бу күренеш һәр дәвердә.

Аргы ярга җитәм диеп гомер итә.
Дулкыннарга каршы йөзеп, хәле китә.

Бирешмә, иш: кул чыныга чоңгылларда.
Күк капусын ачар хыял – маяк алда.

* * *

Киердем дә хисләремне җилкән итеп,
Чиксез хәят дәрьяларым киттем гизеп.
Җилкендерә күңелемне дулкын шавы.
Хыялларның иң самими, алсу чагы.

Ымсындыра ярсу җанны иркен киңлек.
Һичбер нинди кыса да юк, тарлык, чиклек...
Дөнья матур, гүя ширбәт яшәү тәме,
Хөр күңелдә икән ләса тормыш яме.

* * *

Хәтердә: ул язда, ашкытып күңелне,
Гөрләвек йөгерде урамнан.
Тарсынып чикләрен, тамырлар буйлатып
Уйнады талпынып, шаулап кан.

Ул язда таңнарда уятты иркәләп
Ал йөзле гөлләрнең хуш исе.
Таш урам юлына мәңгегә уелды
Илаһи тарихның пар эзе.

Хәтердә, хәтердә: ул язда күзләрең
Нурында коенды сурәтем.
Тын фонарь яктысы ишетте нибары –
Серләрнең берсүзсез шаһиты.

Мәңгегә йөрәккә уелды ул язда
Җыр булып, моң булып исемең.
Шул мәлдән гөлләргә күмелде тын бакчам –
Мәңге яз хәяте күңелем.

* * *

Күңелнең ишеген кагалар
Бик әкрен, бөтенләй тавышсыз.
Мин тыныч, ишетмим, янәсе.
Кем йөрмәс вакытлы-вакытсыз?!

Юрганым бөркәнәм башымнан.
Ә ишек ныграк шакылдый.
«Мин бүген өйдә юк, китегез!» –
Йөрәгем түзмичә пышылдый.

Арылган. Күзләрем йомыла.
Колакны телгәли дөбердәү.
Мин ятам һаман да тын гына.
Әйдә, как, шакылда, дөбердә...

…Хәбәр бир югыйсә, дәш, чакыр!
Күңелгә үтмәкче бу яңгыр.

Ут-ялкын ялмады җанымны.
Учакта дөрли һәр күзәнәк.
Болай да ябулы ишеккә
Бик салам тиз(е)рәк-тиз(е)рәк.

Югыйсә тирә-як – ут тоташ.
Җаныма үрмәли бу кояш.

Тирбәтеп бишектә, биеккә –
Болытка ук әйди уемны.
Тырышам, бирешмим, җибәрмим
Туфракка ябышкан кулымны.

Учларым астында – җылы җир...
Бөтереп алмакчы була җил.

Каршымда – дулкыннан кыя-тау.
Хыяллар беркайчан ялгышмый.
Күңелнең ишеген ачам да
Атлыймын язмышка карышмый.

Җан хәзер мәңгелек сәфәрдә.
Әйләнеп кайтуы икеле.
Син инде эзләмә, соңардың.
Мин инде мин түгел шикелле.

* * *

Бушатып күңелне яулаган уйларны,
Ак кәгазь битенә сыйдырып гамьнәрне,
Ирeккә чыгарып богаудан хисләрне,
Ниһаять, тынычлап уздыру төннәрне –
Шул теләк йөгертә кәгазьдән каләмне.
Башта уй өермә шикелле тузгына.
Туктатып агышын, тынычлык табарга,
Юк итеп шикләрне, шөбһәне, куркуны,
Онытып җанымны кимергән борчуны,
Теләгем – елмаеп каршылау таңнарны.
Мин, ахры, өзлексез, даими саташам.
Миллион уй оча арыган башымнан.

Колакта яңгырый бер китап сүзләре:
«Тынычлык – ул үлем!» Ә бит аз яшәлгән.
Иртәрәктер, димәк, тынычлык табарга.
Исәннәр тиештер каядыр чабарга,
Көрәшеп яшәргә, яхшыга омтылып...
Шикләнеп карыйлар тормыштан ризага.
Канәгатьсең икән, димәк, син үлгәнсең,
Дөньяда исәбең-хисабың өзгәнсең...
Мин тере, мин исән, мин уйлыйм, мин яшим!
...Яңакны көйдерә шатлыклы күз яшем.

* * *

Мин сине тоям, нәнием, төп-төгәл беләм.
Барлыгыңны сизеп торам тәүге көнеңнән.

Бар вөҗүдемне чолгады илаһи халәт.
Шул дулкында тибрәлүе искиткеч рәхәт.

Әлегә нәнисең бик тә, багалмам минем.
Юксынып көтәм дөньяга килүең синең.

Йөрәк моңымны кушармын бишек җырыма,
Иркәләп сөярмен сине, алып кулыма.

Син тугач, бәхет касәбез мөлдерәп тулыр,
Өебез кояш нурыдай яп-якты булыр.

Бәхетең белән ту, балам, ямьлә дөньямны.
Зарыгып көтә күңелем нәни улымны.

## Әниемә

Алга әйдәп, куәт бирә җылы карашың.
Барыр юлым нурга күмеп балкып торасың.
Куеныңда ярсу җаным таба тынычлык.
Бер елмаеп күз сирпүең өсти көч, ныклык.
Тормыш дәрьясын кичкәндә, сөюең – җилкән.
Күзеңдә күрү сурәтем – бәхет шул икән.

* * *

Ул язда ошбу хис моң булып уелды күңелгә,
Һич алмыйм хәзер дә әлеге халәткә күнегә.

Җан кылын рәхимсез суырып алсын да тәкъдирме,
Ярсыган күңелнең сыкравын басарга мөмкинме?!

Ихластан шатланып ирешкән безнең һәр уңышка,
Көенеп, әлегә көчебез җитмәгән узышка,

Янәшә атлыйсың син ялгап киңлекләр арасын,
Коенам нурында горурлык тулы күз карашың.

Шикләнми сүз бирәм акларга өметең һәр эштә,
Син минем саклаучы, яклаучы иңемдә фәрештә.

Еламыйм, әтием, күрсәтмәм яшемнең тамчысын,
Моң булып уелды тик сине югалту ачысы.

## Карсыз кышта

Борма-борма баскыч илтә югарыга.
Һич хакың юк менгән чакта абынырга,
Төпсез упкын кочагында югалырга,
Җир йөзеннән хәтта ис(е)мең юылырга.

Саксыз адым – аткан коштай укталырга,
Тик шулай да һич исәп юк тукталырга.
Атылсаң да, йолдыз булып яктырырга,
Сәмруг коштай ут эчендә юк булырга

Һәм балкырга кабат-кабат канат җилпеп,
Бу мәйданга без китәргә килдек җиңеп.
...Юк, уйлама саташуым бары диеп.
Хакыйкатьтәй канга сеңгән, җанга иңеп.

Безнең язмыш буран булып дулый тышта...
Өн белән төш тоташыр күк карсыз кышта.

* * *

*«Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч...»*
Г.Тукай

Күпме генә дуламасын ярсу дулкын,
Бәрелә дә кыяларга кире кайта.
Кояш баер эңгер-меңгер инде вакыт.
Дәрья шавы, ялкын булып, җанны өтә.

Аһ-зарымны минем тоеп тетри ярлар,
Кайтавазы йөри мәгърур кыяларда...
Без кем идек һәм кем булдык?! Ник соң болай
Комга уйган эзләремне дулкын йота.

Тормыш – түгел татлы җимеш тулы бакча,
Кануннары катгый, кырыс көрәш кыры.
Көч калмыйча, инде ничә сынды кылыч
Һәм өзелде шартлап күпме күңел кылы.

Риза түгел әмма күңел җиңелүгә,
Аваз сала, диеп: «Иртә. Бирешмәле».
Җан таләбен өстен куеп, калебемнең
Язмыш белән якалашып яткан мәле.

Галимҗан Гыйльманов

# ИБЛИС КОТКЫСЫ

КЫЙССА

**13**

Шәмси карт аны аңламады. Гомумән, Мәүлетнең төннәр буе шикле урыннарда йөрүен өнәмәде. Җитмәсә, намаз иясе бит әле.

– Килешми, олан, бер дә килешми. Изге, иманлы юлга баскансың икән инде, бу илаһи юлдан дөрес барырга кирәк. Гөнаһлының тормышы гел аһлы булырга мөмкин югыйсә.

– Бәй, мин Иблис йөргән җирдә йөрмәсәм, аны ничек тотыйм, ди?

– Син аны күрергә түгел, иң элек тоярга тиеш. Гөнаһлыны табам дип, гөнаһ җыеп йөрү бер дә килешми.

– Шәмси бабай, әйт әле – иң гөнаһлы кеше кем?

– Изгелек битлеге киеп йөргән бәндә.

– Ничек була инде – үзе изге, үзе гөнаһлы?

– Әйе, нәкъ шулай. Алай да була!

– Изгелек – бик киң төшенчә бит ул.

– Син хаклы, аның иге-чиге юк, олан.

– Шулай икән, аның мәгънәсе дә югала, шулаймы?

– Иң беренче һәм бердәнбер изгелек Аллаһыбыз тарафыннан кылынган. Аллаһыбыз дөньяны, табигатьне, яшәешне, тереклекне һәм аның иң күркәм таҗын – кешелекне тудырган. Ә калганы изгелек түгел. Калганы – илаһи ихтыярны бертуктаусыз дәлилләп торудан башка берни дә түгел!

– Телевизорны ачсаң, һәр ике кешенең берсе – изге, урамга чыксаң, эшкә барсаң, халык арасында йөрсәң, һәркайда изге җаннар. Чынлыкта, күкрәк киереп, эш кырган булып йөрүче чиновниклар, депутатлар, дәүләт кешеләре. Гел изгелек турында сөйлиләр, хастаханәләр ачалар, юллар төзиләр, балалар бакчалары һәм мәктәпләр җиткерәләр; үзләре шундый җитди – хәләл акчаларына эшлиләрмени?! Халыкның салым акчасына лабаса! Унар, йөзәр меңгә җиткән эш хакларыннан тыш, халыктан мактау көтәләр, дан өмет итәләр. Нүҗәли шайтан коткысы җитәкче даирәләрне дә шаукымлап өлгергән инде, ә, Шәмси бабай?

– Мәүлет олан, байлар-фәкыйрьләр хакында болай гади генә сөйләшү дә

*Дәвамы. Башы 8 нче санда.*

дөрес түгелдер, бәлки. Бөтен гаепне чиновник җитәкчеләргә дә, шулай ук илне тутырган фәкыйрь-мохтаҗларга да сылтап калдырасы килми. Аларның берсе дә үзе теләп, Иблис кочагына барып кермидер. Ни өчен шулай димме? Чөнки шул ук фәкыйрьлек тә турыдан-туры Иблис коткысы белән бәйләнергә мөмкин. Коръәннең кайсыдыр сүрәсендә, «Хатыннар» сүрәсендә булса кирәк, Аллаһы Тәгаләбез, ачыктан-ачык: «Шайтан үзенә ияргәннәрне фәкыйрьлек белән куркытыр», ди. Күрдеңме нәрсә ди? Бер яктан, фәкыйрьлек – үзе үк шайтан коткысы каршында көчсез әйбер, икенче яктан, Иблис армиясенә кушылган байлар, бигрәк тә бай җитәкчеләр, гади халыкка, мохтаҗларга ярдәм итә алмыйлар. Шул ук сүрәдә бу турыда да әйтелә: «Шайтан кулына төшкән кешеләр фәкыйрьләргә ярдәм итә алмас», диелә. Менә бит нидә хикмәт!

Шәмси картның, «Әй!» дигәнне белдереп, кул селтәп куюы Мәүлетнең уен хуплау булып аңлашылды. Димәк, шайтаннар башлыгын иң элек министрлыклардан, югары советлардан, парламентлардан эзләргә кирәк! Тик аңарчы чын фәкыйрьлек белән очрашасы бар әле аның. Олы, затлы йортларда яшәүче шәһәр халкыннан качып, шул сәләмә тормышлы, сәләмә киемле, ачлы-туклы яшәүче кешеләр тормышына кереп сыенмаганмы ул хәйләкәр мәлгунь?!

Мәүлет Казандагы андый урыннарны белә. Һәркем белә андый җирләрне. Ләкин ул бистәләрне урап узарга тырышалар. Кемдер чирканып, сагаеп керми, кемдер, намусымны ирештермим, күңелемне саклыйм дип, читләтебрәк узарга тырыша. Мунчадан ерак та түгел шундый бер бистә бар. Әллә юри, әллә чынлап кушканнар: «Җиләкле» дип атала ул. Җиләкнең җе хәрефе дә юк-югын... Бәлки, кайчандыр киң, чәчәкле, җиләкле аланлык уртасына урнашкан булгандыр бу авыл кыйпылчыгы. Ләкин аны зур шәһәр куып җиткәндер дә, таш куллары белән бугазыннан тотып алгандыр, шулай сулыш алырга ирек бирмичә, йөзәр ел аны утсыз-сусыз, юлсыз, эшсез, мәктәпсез, кибетсез, гомумән, бәхетсез тормышка дучар иткәндер. Иблиснең көфер почмагына әйләнгәндер шулай.

Мәүлетнең ул бистә аша ике тапкыр гына үткәне булды. Икесендә дә бик авыр тәэсир калган иде. Менә бүген өченче тапкыр бара. Җәяүләп кенә керде ул тарихтан берничә гасыр соңлап яшәүче бистәгә. Заман җил-яңгырларыннан тузып, кыршылып беткән, буялмаган капка-коймалар. Койма, читән артларында алма бакчалары шәйләнә. Урамда миләш, шомырт куаклары тезелешкән. Ләкин аларның күпереп торган ябалдашлары җиргә сеңгән, хәтта, бер якка кыйшаеп, ава ук башлаган авыл йортларын дөнья күзеннән каплап куя алмаганнар.

Чынлап та, ниндидер башка җир, башка дөнья монда. Башка гасыр дип тә әйтергә мөмкиндер. Тормыштан, тарихтан артта калган гына түгел, хәтер куласасыннан очып чыгып киткән, онытылган бистә... Әнә тузган чәчле ике бала уйнап утыра, берсе кыз, икенчесе малай булса да, икесе дә бертөрле озын, киң итәкле күлмәк кигәннәр. Кулларында ниндидер аңлашылмый торган агач уенчык. Нишләп аңлашылмасын?! Комнан өелгән мичләрендә икмәк пешерәләр ләбаса болар! Үзле балчыктан әвәләнгән ипиләрен, агач көрәкләре өстенә тезеп, мичкә тыгып-тыгып алалар. Юктыр, бүгенге шәһәр балалары мондый уенны уйный белмидер. Ә менә бу авылда беләләр. Чөнки бу авыл балаларының әниләре, әбиләре ипине әле дә шулай пешерә!

Мәүлет балаларга бирәр конфет тоттырды. Балалар саф татарча рәхмәт әйтеп алдылар, шундук ашарга тотынмадылар, кесәләренә салып куйдылар.

– Нигә ашамыйсыз? – дип сорарга булды Мәүлет.

– Әнигә алып кайтабыз. Әни аны энекәшебез белән икебезгә урталай бүлеп бирә.

– Сез хәзер ашасагыз, әниегез дә, башкалар да күрми бит, ашагыз...

Балалар бер-берсенә караштылар да, нәрсә әйтергә белмичә, аптырап калдылар.

Мәүлет аңлады: бу авылдагы балалар алдашуны, хәйләләшүне белмиләр икән бит! Ә менә өлкәннәр белән ничек? Мәүлет кесәсенә махсус салып килгән бер уч кәнфитне, учларына алып, балаларга сузды:

– Менә, рәхәтләнеп ашагыз. Өйдәгеләргә дә җитә...

Кыз бала юмарт булып чыкты:

– Абый-абый, безгә бер кәнфит җитте, боларын үз балаларыгызга алып кайтыгыз, яме!

Мәүлет учындагы конфетларны кабат чалбар кесәсенә шудырды. Шулай да берничәсен, кире алып, малай белән кызның алдына куйды. Аннары җәһәт адымнар белән ары таба китте. Бу бала-чагалар тирәсендә нинди шайтан йөрсен, фәрештә чаклары бит әле аларның! Ничек тә өлкәннәрне күрәсе иде, алардан бер-бер хикмәт чыкмый калмас, дип уйлады.

Әнә алар – янәшәдәге җилкапкадан өчәү чыгып киләләр: яшькә әлләни өлкән булмаган ир белән хатын. Яннарында бер чибәр кыз да күренә. Менә алар, капкаларыннан гәпләшеп, үзара матур шаулашып килеп чыктылар да капканың ян як бәпкә агачына беркетелгән бауны беренче койма тактасына эләктереп куйдылар, аннары, алма тутырылган кәрзиннәрен тотып, урам буйлап Мәүлеткә каршы килә башладылар. Шунда ук күзгә ташланды: өсләренә кигән киемнәре бик иске, кояшта уңып беткән, әмма чиста, үтүк йөгертелгән кебек пөхтә һәм ипле. Ничек кенә туктап сорашасы килсә дә, Мәүлет бу тату, бәхетле гаиләнең юлын бүлмәде, авылча сузып исәнләште. Мәүлет белән иң элек ата кеше исәнләште, аннары аңа берьюлы ана белән бала кушылды:

– Исәнмесез... сез...

Бер-берсе белән елмаешып-сөйләшеп барган, нурлы йөзле бу ир белән хатын Мәүлет күңелендә якты хисләр генә уятты. «Юк, мондый гаилә бәхетсез була алмый, бу гаиләгә Иблис коткысы да үтеп керә алмый!» дип уйлап та өлгермәде, каршысында тагын бер төркем пәйда булды. Ап-актан киенгән бер карчык 5-10 яшьләр тирәсендәге, берсеннән-берсе кечерәк, бәлки, киресенчәдер: берсеннән-берсе зуррак дүрт ир баланы ияртеп, каядыр ашыга иде. Дүрт баланың башында да иске генә түбәтәйләр. Өс киемнәре дә мактанырлык түгел. Әмма чиста, пөхтә. Әбинең кулында үтә күренмәле пакет, аның эчендә шешә белән сөт һәм берничә телем ипи шәйләнә. Юл өстендә капкалап ала торган ризыкларыдыр, күрәсең.

Әйе, тагын бер матур күренеш. Дүрт малай да, әле артына, әле алдына төшеп, дәү әниләре тирәсендә бөтереләләр. Дәү әниләре дә, утырган тавык кебек, балаларны барлап кына тора, һәрберсенең соравына һич иренмичә җавап биреп бара. Каян булсын – шайтан мәлгуньнәрнең әсәре дә юк монда! Аннан-моннан гына тәннәрен каплаган сәләмә күлмәк-ыштаннар кигән бу фәкыйрь балалардан да бәхетлерәк җан иясе бар микән әле бу минутта?!

Бу юлы Мәүлет дәү әниләре белән бик мөһим сәфәргә чыккан дүрт малайны туктатырга булды.

– Исәнмесез! Хәерле көннәр! Ачуланмагыз, зинһар, сез мине белмисез, мин сезне белмим. Эшем шул: урамда сораштырулар үткәрәм. Сезгә дә бер сорау бирер идем.

Малайлар аптырабрак калдылар, ә менә әбекәй бик чая карчык булып чыкты. Шундук үз кеше булып сөйләшә дә башлады.

– Бир, бир, биргәнне алабыз без. Нәрсә бирәм дидең әле, улым?

– Сорау бирәм, дигән идем, әбекәй.

– Ә-ә, алаймыни?! Сора, тик менә җавабы ошар микән? Без бик гади кешеләр бит. Матур итеп сөйләшә белмибез.

– Бик матур сөйләшәсез, әбекәй. Соравым да бик гади: ихлас, чын күңелдән әйтегез әле: сез бәхетлеме?

Әбекәй бераз уйланып алды. Янындагы малайларның һәрберсен җентекләп карап, өйрәнеп чыкты, аннары шактый җитди итеп әйтеп куйды:

– Бер дә гади түгел, кеше өчен иң катлаулы сорау бу, балам. Мин бәхетлеме соң? Белмим, белмим. Ләкин шуны төгәл әйтә алам: мин тормышымнан да, яшәлгән һәм яшәгән гомеремнән дә тулысынча разый. Аллага шөкер, булганына канәгать булып, бер кайгысыз яшәп ятабыз. Картым исән-сау, умартачы, малаебыз, техникумнан соң, урман кисүчеләр янында мастер булып эшли, киленебез бер шәһәр мәктәбенә җыештыручы булып керде, менә оныкларыбыз да тупырдап үсеп киләләр. Өебезгә аракы кергәне юк, аны һәрвакыт дога белән сафландырып торабыз. Шулай булгач, без нинди инде: бәхетлеме, бәхетсезме?

Мәүлет түзмәде, кычкырып диярлек җавап бирде:

– Бәхетле, сез, һичшиксез, бәхетле, әбекәй. Бу малайлар белән ничек бәхетсез булмак кирәк?! Ә, малайлар? – Мәүлет малайларга таба борылды. – Әйтегез әле: дәү әниегезне, дәү әтиегезне, әниегезне, әтиегезне бәхетле итәр өчен сез нәрсәләр эшлисез? Йә, кем башлый?

Малайлар башта каушап калдылар. Шулай да өлкәнрәге елгыррак булып чыкты. Аңа башкалар кушылды:

– Мин аларга булышам.

– Мин әтиемне, әниемне тыңлыйм.

– Мин дәү әти белән дога укыйм.

– Мин дәү әнине яратам! – Малайларның иң кечесе, ике-өч адым араны йөгереп, юк-юк, очып үтеп, дәү әнисен кочаклап ук алды.

Мәүлетнең чын-чынлап күңеле тулды, катлаулы, зарлы, еш кына күз яшьле шәһәр тормышыннан соң мондый татлы авыл һавасы күңелгә сискәндергеч, хәтта ышанып булмаслык дәрәҗәдә авыр кабул ителә иде. Ләкин бу авырлык – табигый, тормышчан авырлык иде. Бу тойгы бәхет катыш өмет, сабырлык, горурлык, җаваплылык хисләреннән укмашып йомгакланган иде. Мәүлетнең бу гаиләгә ничектер якты йөз күрсәтәсе, ярдәм итәсе килде. Ул кечкенә сумкасын ычкындырып, күпме бар, шулкадәр акчасын алды да әбекәйгә сузды.

– Менә сезгә сорауларга дөрес җавап биргән өчен! Зинһар, каршы килмәгез, алыгыз. Малайларның мәктәпкә барыр көннәре җитә, шуңа булыр.

Карчык тәмам аптыраешта калган иде. Күрәсең, аңа моңарчы беркемнең дә бушка гына акча биргәне булмаган. Аның йөзенә хәтта курку чалымнары кунган иде. Шунда олырак малай тагын авыр хәлдән коткарды.

– Дәү әни, ал, ал, абыйның сорауларына җавап бирдек бит, эшләп алган акча ул, ал. Әле бүген иртән генә: «Үсеп беттегез, яңа киемнәргә каян акча табарбыз икән», – дип сөйләнгән идең. Бабай да: «Ходайның рәхмәте киң, көтмәгәндә чыгарып бирә ул», – дигән иде. Менә чыгарып бирде бит, ал, дәү әни, ал! Яңа күлмәк белән мәктәпкә барырбыз, ал. Әле китап-дәфтәрләргә дә җитә монда. Ал, дәү әни.

Ләкин карчык акчаны тиз генә алмады әле. Алмыйм, да димәде. Бары тик малайларга гына карап:

– Ягез, бер читтәрәк уйнап торыгыз әле, минем абыегызга сүзем бар, – диде дә Мәүлеткә якынрак килде.

– Улым, синең соравың башка иде бит. Хәзер шул соравыңны бир. Күреп торам: күңелеңдә кысылып калды ул сорау. Нәрсә борчый сине, нәрсә тынгысызлый? Акча турында шуннан соң сөйләшербез. Анысы өчен рәхмәт. Ләкин һәр ярдәмнең хакы бар. Бу хак синең сораудан тора.

Бу юлы Мәүлет каушап төште. Телсез калып, бераз торганнан соң гына зиһенен җыеп ала алды. Ә сорауга килгәндә... Сорау күптән әзер.

– Апа җаным, әйт әле: сезнең бу авыл бистәсенә Иблис ләгыйнь иярченнәренең, ягъни, шайтаннарның кергәне бармы?

Әбекәй ничек күзләрен шар ачып карап торган булса, шул килеш катып калды. Бу сорау – үз гомерендә ишеткән иң сәер сорауларның берсе иде, ахры. Шулай да ул үзен бик тиз кулга алды. Халык белән җанлана башлаган авыл урамына күз йөртеп чыкты да, тыныч кына әйтеп куйды:

– Юк, Иблисне күргәнем юк, ә менә җеннәр бар. Җеннәрнең әйбәтләре. Алар безгә булышалар, ярдәм итәләр, мин моны төгәл әйтә алам. Менә шул җеннәрнең кайберләре үз шайтаннары белән күренгәли. Ләкин безнең үз җеннәребез андыйлардан бик тиз котылалалар. Әйе-әйе, һәр кешенең үз җене була. Юк, фәрештәләр түгел, нәкъ менә җеннәр. Фәрештәләр – Аллаһы Тәгалә ихтыярын үтәп йөрүчеләр. Ә җеннәр, кешеләр кебек үк, үз тормышлары һәм язмышлары белән яшиләр, тик Аллаһыбыз шулай әмер иткән: алар кеше күзенә күренмиләр, әмма үзләре кешеләрне күрәләр. Җеннәре көчсез, зәгыйфь кешеләргә шайтаннар, башка төрле яман рухи һәм сихри затлар, әйтик, албастылар, убыр-өрәкләр ияләшүчән була. Бездә алар бик сирәк күренә. Аларны күбрәк абыз бабалар сөйләве буенча беләбез.

– Ә ни өчен шулай? Ничек сез Иблис коткысына, шайтан вәсвәсәсенә бирешмичә яши аласыз? Шуны аңлатыгыз әле.

Мәүлет, сорауның төбенә төшеп, кат-кат сорашса да, карчык җәелеп китеп сөйләшүдән тыелды. Күрәсең, бу аның өчен тыелган тема иде. Шулай да, бераздан, уйчан, хәтта картлар күзендә генә була торган тоньк карашы белән урамның әле бер башына, әле икенче башына карап алганнан соң, әйтеп куйды:

– Аптырарлык берни дә юк монда. Нәфес, хөсет булмаган җирдә шайтан да булмый, шуны колагыңа киртләп куй. Бу җирдә алар юк.

Шуның белән сүзен кырт кисте карчык, малайларга гына карый-карый, китәргә җыена башлады, үрелеп, кечкенә сабыйның күлмәк-ыштаннарын рәтләргә кереште.

Мәүлет кулына йомарлап тоткан акчасын кая куярга белмичә торганда, аның янына олы малай килеп басты. Дәү әниләре телгә алган шайтаннар хакында, шул шайтаннарны җәлеп итә торган нәфес, хөсетлек турында аның үз фикере бар иде, ахры. Ул һич кыенсынмыйча, ләкин дәү әнисе ишетмәслек итеп, ярым пышылдап:

– Абый, бирегез акчагызны. Дәү әни белән дәү әтигә дару алырга булыр. Аннары укырга барасы бар. Әтигә эш хакын агач-такта белән бирәләр, әниебезгә вакытында зарплата түли алмыйлар. Юк, без барыбер акчагызны бушка алмыйбыз. Дәү әнинең төенчегендә берничә кило алма бар, шуны сезгә сатып бирәбез, – диде.

Мәүлет, риза булуын белдереп, баш какты. Бу юлы акча бик тиз малай кулына күчте. Карчык барысын да күреп торды, ләкин әлеге сәер һәм серле алыш-бирештән оныгын тыймады...

Мәүлет Казан эчендә югалып калган бу татар бистәсеннән эчке бер канәгатьләнү белән кайтты. Ләкин бер үк вакытта күңелен тырнап торган уйларга яңа борчулар өстәлде: «Иң чиста, ихлас һәм гөнаһлардан хали татарларыбыз нилектән шундый мохтаҗлыкта яши? Алар кайчан, ничек һәм кем гаебе белән замана арбасыннан төшеп калганнар? Кем гаепле? Бу мөлаем һәм еш кына наив, самими, әмма татарның саф генофондын талап яшәүче кешеләр үзләре генәме? Һәр җирдә «Татарның җаны авылда яши» дип шапырынырга яратабыз бит. Берәр милли оешма вәкиленең, шәһәр җитәкчесенең яисә депутатның килеп күргәне бармы бу бистәне? Аның тормышы, язмышы, киләчәге хакында уйланганы бармы? Юктыр шул. Юк икән, димәк, бу җитәкчеләрнең барысы да Иблис коткысына бирелгән, алар үзләренең тар шәхси мәнфәгатьләре карамагында калганнар».

**14**

Киңәшләшергә әлеге дә баягы Миндияр бар. Көне буе сагалап, каравыллап йөри торгач, Мәүлет, ниһаять, кичке эңгер-меңгер алдыннан гына тотып алды үзен. Күреп тә алды, әйтеп тә салды:

– Миңа ничек тә депутатларга якынаерга кирәк, булыш, әзи!

– Кит моннан! Юләрме әллә син?

– Вакытлыча гына, дим. Алар коткыга, шаукымга тиз бирешә, диләр. Иблис ләгыйнь шул тирәгә оя кормады микән? Ничек тә беләсе иде. Булыш, ә? Кемең бар?

Мәүлет кире какмаслык итеп, әмер биргәндәге кебек сорады. Күренеп тора: кире каккан очракта, аның тагын да саллырак дәлилләр китерәчәге, Дәүләт Советына юл-сукмак таптырачагы көн кебек ачык иде.

Миндияр биреште. Бәйләнчек дустыннан тизрәк котыласы килгән кебек басынкы тавыш белән әйтеп куйды:

– Бер дустымның депутат дусты бар. Булышчы эзли. Миңа да чыгып караганнар иде. Әйдә үземнең урынга сине тәкъдим итәм. Ләкин акчасыз эш. Зато күңелле, минем йөреп караган бар иде инде.

– Кем ул?

– Дустыммы?

– Юк ла, депутат дигәне кем инде?

– Тәбәрәков. Бизнестан килгән, ахры. Бик ачык күңелле, милли җанлы

кеше, ди. Үз исемен куеп, мәчет салдырган. Авылларда кечкенә кибетләр тота, ди. Үзем якыннан белмим. Ярдәмчегә чын татар кешесен эзли, имеш.

Чынлап та, депутат Тәбәрәков бик ачык йөзле кеше булып чыкты.

– О-о, синмени инде ул Мәүлет дустыбыз? Бик шат, бик шат. Синең хакта фикерләр, рекомендацияләр әйбәт, матур гына эшләрбез дип уйлыйм. Әйдә, уз, аз гына көтеп тор, яме, хәзер документ әзер була, аны промышленный палатага илтәсе булыр...

– Ә-ә... Ни бит...

– Сезгә документ кирәкме? «Депутат ярдәмчесе» дигән таныклык Сез әйләнеп килүгә әзер булыр. Чыгышлый кадрлар бүлегендә фотога төшеп китәргә онытмагыз...

Мәүлет, мунчадагы хезмәтеннән бераз ял алып, яңа эшенә керешеп китте. Эш дигәч тә... Нинди эш инде ул?! Курьер. «Тегендә бар, монда кил» дигән эш. Ялкыткыч, хәтта мәгънәсез эш... Ике көн узгач ук баш тартырга да уйлаган иде, өченче көнгә чыккач, Тәбәрәков кабинетындагы бер сөйләшүдән соң ул парламентта тагын беразга калырга булды. Ул көткән сөйләшү иде бу. Иблис мәлгунь турында. Тәбәрәков телефоннан кем беләндер сөйләшкәндә нәкъ шулай диде: «Ул Иблис мәлгуньгә җитмәсә дә җитмәс икән!.. Шәһәрнең ярты җирен алды бит инде, нәрсә, шул җир белән тыгынырга уйлый микән әллә ул? Әллә тегендә алып китәргә ниятлиме? Югары даирәләрдә яклау тапкан, ахры... Казан арты бит... Бу кадәр нахаллашмаса... Балалар бакчасына дигән җирне тартып алган бит, ләгыйнь! Шәһәр уртасында кызына өч катлы йорт салмакчы, ди... Без дә авыз ачып тормыйбыз анысы... Тегесен тотып алабыз, монысын салып куябыз, дигәндәй. Ну без балалар өлешенә кермибез! Шулай бит? Шулай, диген... Алайса, мин синең үзеңнән дә шикләнә башлаячакмын...»

Тәбәрәков гади кеше түгел иде. Шушы бер сөйләшүдән үк Мәүлет чамалап алды: үзенә тиешлесен дә, тиеш булмаганын да умырып алып яшәргә күнеккән Юпитер Марсовичны имансыз дип тә әйтеп булмый иде. Исем-аты бераз сискәндерсә дә, Актаныш ягыннан булуын белгәч, тынычлап уйлап куйды: шул яклардан килә бит инде төрле әкәмәт исемнәр. Югары даирәләрдә эшләвен, депутатлыкка сайлануын да Актаныш ягыннан булуы белән аңлатырга булыр иде, әмма... Һич кенә дә акылсыз бәндә түгел бу, хәтта акыллы дияргә мөмкин. «Үземә дә, кешегә дә» дигән фикер белән яши Тәбәрәков. Әйе, шушы ике көн эчендә ул, өйдә «эшләү» шарты белән хатынын шактый төшемле эшкә урнаштырды, төзелеп ята торган коттеджы өчен кул астындагы бер тресттан төзелеш материаллары китертте, кайсыдыр район башлыгыннан бура сөйләште, сөйләшеп кенә калмады, «син миңа тиеш, оныттыңмыни, кара аны» дип, аның һушын алды. Шулай да чиновниклар башбаштаклыгы хөкем сөргән бер чорда ул үзенең игелеклелек, кешелек сыйфатларыннан баш тартып бетермәгән: балалар, өлкәннәр, ятимнәр, гарипләр мәнфәгатен булдыра алган кадәр кайгыртырга тырыша. Дәүләт Советының Җир һәм төзелеш комитетында җаваплы урын биләгән депутат буларак, ул күпләргә үрнәктер дә әле. Әнә бит, балалар бакчасына бирелгән урынны чит-ятка бирмәс өчен җәнҗал куптаруга кадәр барып җиткән. Ахыр чиктә, ул бу җирне саклап калды, чып-чын татар балалар бакчасы төзү хакында

Хөкүмәт карары чыгарттырды. Юк, Тәбәрәков Иблис нәселеннән була алмый, ә менә аның ачуын китергән кеше – Иблиснең дә Иблисе инде! Ничек тә шуны күрәсе иде. Фаш итәсе иде!

Икенче көнне эшкә килеп керсә, Тәбәрәковның йөзе качкан, борыны салынган, кәефе төшкән. Әллә бераз салган да инде? Күз төпләрендәге караңгы бөжралар аның йокламаганлыгы, нindидер авыр стресс кичергәнлеге хакында сөйлиләр иде.

– Мөмкинме?

– Кер...

– Бер-бер хәл булмагандыр бит, Юпитер Марсович?

– Булды шул.

– Барысы да исән-саулардыр бит?

– Анысы – да.

– Шулай булгач, бик борчылмагыз, Юпитер Марсович.

– Ну, ничек борчылмыйсың инде, ничек?! Бүген төнлә минем йортка ут төртергә булашканнар, ничек борчылмыйсың, ди?! Ул бит ут, ут!

– Хәтәр хәл икән шул. Полиция чакырдыгызмы?

– Кая ул чакыру?! Ул әле регистрация да үтмәгән. Ягъни мәсәлән, исәпкә кертелмәгән. Юк ул йорт, әлегә юк, аңлыйсыңмы шуны?

– Юк, аңламыйм.

– И-и, бигрәк тугодум булып чыктың әле син! Кайчандыр, ничектер ярдәм иткән өчен дуслар салып биргән йорт ул. Левыйрак.

– Хәзер аңладым.

– Аңладың, ди! Синең шакмаклы башың аңларлыкмы соң бу хәлне! Беләм мин монда кем кулы уйнаганын. Кичәге теге Иблис сыңары гына, башка кеше түгел. Кичә үзеннән тартып алган җир өчен үч алмакчы була. Җиңдем дип уйлый инде хәзер. Җиңелде, ди! Юкка гына планеталар исеме йөртәммени мин! Актаныштан чык та җиңдереп тор, имеш.

Шунда Мәүлеткә әллә нәрсә булды, кинәт кыюланып, хәтта зирәкләнеп киткәнен сизми дә калды ул.

– Юпитер Марсович, минем сезгә бер тәкъдимем бар. Каршы килмәгез, зинһар, әйтергә рөхсәт итегез...

– Әйт, тиз бул! Баш чатный, ул ярылганчы әйтеп кал.

– Җибәрегез мине шул кеше янына. Берәр йомыш тапкан булыгыз, разведка ясап кайтыйм әле. Нинди бәндә, чынлап та улмы? Ул булса, барыбер сиздерәчәк, бер-ике дөрес сорау гына бирергә кирәк.

– Кара, син психолог та икән әле. Каян килеп чыктың соң син, Хода бәндәсе? Йә, ярый, барып кара. Ләкин үзеңнең башың үзең белән булсын, берәр бәлагә юлыксаң, мине кыстырма!

– Аңлашылды, нинди пакет бирәсез?

Очраклы гына бер пакет алып, Мәүлет юлга кузгалды. Аның күңеле күтәренке иде: алдап-йолдап булса да, теләгенә ирешә бит, хәзер ул Иблис токымыннан булган теге хәшәрәт зат янына барачак һәм аның бөтен серен алачак, фаш итәчәк. Әнә бит нишли явыз – җир үзләштерү генә җитмәгән, шул җир өчен җинаять юлына басарга да риза, гөнаһ шомлыгы!

Мәүлет бик тиз эзләп тапты Рамазан Асаев дигән бу кешене. Аның офисы Казандагы иң биек биналарның берсе булып чыкты. Ишек төбендә

үк әзмәвердәй ике сакчы егет каршы алды аны. Мәүлет, кемнәрдер ике як беләгеннән китереп тоткач, чак астына җибәрмәде.

– Стоп! Кая барасыз?

– Рамазан Асаевка пакет китердем. Срочно.

– Кемнән? Каян? Документыгыз?

Мәүлет аңлатып бирде. «Депутат ярдәмчесе» дигән документын күрсәтте. Аны эчкә кертеп җибәрделәр.

Кабул итү бүлмәсендә тагын бераз утыргач, ниһаять, эчкә чакыртып алдылар. Пакет алданрак кереп киткән иде, шуңа күрә дә хуҗа кеше Мәүлет белән сөйләшүгә әзер иде инде. Ләкин әңгәмә эш буенча бармады.

– Юпитер үз өендәге хәлләрне миннән күрәме?

– Нинди хәлләрне?

– Йә, уйнап булашма, егеткәй. Мин аны яхшы беләм. Син дә юкка килмәгәнсеңдер. Дөресен генә әйткәндә, мин үзем дә шулай эшләр идем. Так вот, дускай: юк, мин ут төртмәдем аның өенә! Кирәге бар иде! Ну, рәнҗетүен рәнҗетте ул мине, анысы хак. Бер очы чыкмыйча калмас бу рәнҗешнең дә. Полиция булып китте инде минем офиста, гомеремдә беренче тапкыр тентү оештырдылар, сорау алып булаштылар. Хурлыгы ни тора!

Хуҗа кеше, артына борылып, стенага кертеп ясалган шкафны ачты, бер шешә коньяк чыгарды. Шул ук шкафтан бәллүр бокал алып, төбенә генә бер йотым коньяк койды. Шул йотымны да эчеп бетермәде, иреннәренә генә тидереп куйды. Димәк, эчү – аның максаты түгел. Димәк, аның сүзе бар. Һәм ул гади сүз түгел.

– Ә бит ул ялгыша, кустым. – Мәүлет шундук чамалап алды – башкорт ягыннан икән бу кеше, әнә ничек, иренен бөтереп, кустым дип сөйләшә. Татарча дустым дип әйтмәкче инде ул. – Юпитер нык ялгыша. Мин аның дошманы түгел. Ул минем дошманым түгел. Җир бит ул күп, аның өчен хәзер талашып ятасы да юк. Әйтик, шушы Казанны гына алыйк. Аның утыз проценты бесхозный җирләр бит. Кем ала, кем карап тора, алабута үстереп, кеше өркетеп, бомжлар җыеп ятканчы, коймалап алып, тәртиптә тотыгыз, аннары күз күрер, дигәч, бер ун еллар чамасы элек алып куйган идем. Бәясе дә әллә кем түгел иде. Менә шулай килеп эләкте миңа ул җирләр. – Рамазан тагын бокалын иреннәренә тидереп алды. – Нигә сиңа сөйлим боларны, беләсеңме? Белмисең. Синең йөзеңнең нуры бар, син ихлас, дөрес кешегә охшагансың. Аннары, син – Юпитер кешесе түгел. Мин моны шундук чамаладым. Син аның янына очраклы гына эләккәнсең, минем янда да очраклы адәм син. Беренче һәм соңгы мәртәбә. Башка дөнья, башка максат, башка гамь кешесе син. Шулаймы? Дөресе шул бит? Синдә җир кайгысы түгел, синең кайгың – мин. Минем кемлегемне беләсең килде синең. Юк, Юпитер өчен түгел, үзең аңлар өчен. Шуңа күрә дә сөйлим сиңа. Аңласын, төшенсен дип сөйлим. Сиңа моның нигә кирәген белмим, әмма сөйлим. Тыңла. Шуннан хәл итәрсең.

Рамазан бераз тын калып торды. Аның әле яшьлек матурлыгын югалтмаган, әмма инде җыерчыкка чорнала башлаган йөзе тартышып куйды, күзләре, иреннәре кысылды, болай да утырыбрак үскән, чал керә башлаган чәчләре тагын да ныграк үрә баскан кебек булды.

– Мин Казанга хыялланып килдем. Уфа артындагы бер тупыйк авылдан чыгып, шул ук Уфасында калырга мөмкин булыр иде. Юк, Казанга киләсе

килде. Казан бит ул – татарларның мәркәзе, башкаласы! Монда милләт каймагыннан май языла, язмыш тудырыла, татарның киләчәге әвәләнә. Кыскасы, зур өметләр баглап килдем Казанга. Укырга кердем, укыдым, эш башладым. Яшьлегем 90 нчы елларга туры килде, аннары яңа гасыр башланды. Азатлык хәрәкәтендә катнашып киттем. Ничек кызу башланган булса, ул шулай кинәт кенә бетеп тә куйды. Җиңелдек. Милли хәрәкәтне җитәкчелек белән бәйле функционерлар үз кулына алды. Чын милләтчеләр, чын көрәшчеләр урамда калды. Урамда да озак яшәп булмый, көрәшеп булмый, шундук алып китәләр. Хәлдән таеп, арып егылганчы кыйныйлар, изепме-изәләр. Соңгы тапкыр нык кына кыйналып, чүплек базына илтеп ташлангач, кан коса-коса ант эчтем: «Моннан соң милләт дип, авыз суымны корытасым юк, бизнеска китәм, акча эшлим, барысына да төкерәм!» – дидем. Шулай эшләдем дә. Күн эшкәрттем, кирпеч суктым, хатын-кыз эчке киемнәрен саттым, аннары агач эшенә керештем. Безнең авыл – осталар авылы бит. Балта осталары, агачтан җиһаз ясаучылар. Мин дә шул осталар янәшәсендә үстем ләбаса. Минем фирма мебельне авылчан итеп, милли бизәкләр белән эшли башлады, татар байларының күңеленә бик хуш килде бу җиһаз. Күпләп акча керә башлады. Өйләндем, малаебыз туды. Фатирлар, шәһәр читендә йортлар алдым. Ләкин акча шулкадәр күп иде, мин аны «җиргә тыгарга» булдым. Нәкъ шул вакытта республика, шәһәр җитәкчеләре, ниндидер бик мөһим вакыйга алдыннан: «Казан эчендәге ташландык җирләрне, җимерек йорт-каралтыларны алыгыз, чистартыгыз, карап торыгыз», – дип, байларга мөрәҗәгать итте. Мин шундук Казан ханлыгы чорыннан калган иске картаны җәеп салдым. Элеккеге каберлекләр, гыйбадәтханәләр... Казан алынгач, һәлак ителгән меңнәрчә татар каһарманының хәләл сөякләре әрдәнәләп өелгән ул каберлекләрдә. Мин ул урыннарны чистартып, өстенә чирәм чәчтем. Коймалар белән уратып алдым. Изге урыннар бит, берәр таш-һәйкәл булса да куйыйк, мәңгеләштерик дип, шәһәр җитәкчеләренә берничә тапкыр мөрәҗәгать итеп карадым. Акча юк, диделәр. Нәрсәгә ул, болай да, дин, тел дигән булып, русларның кәефен җибәреп торабыз, диделәр.

Һәм менә... Юпитер Марсович шул җирне ерткычларча тартып алды. Баштарак сатулаштым, бәхәсләштем, көрәштем хәтта. Чөнки бөтенесе дә ап-ачык ласа: бу җирләрне сатып алган кеше (татар булса ярый ла ул) борынгы бабаларның сөякләре яткан туфрак өстенә йә мунча, кибет, йә автосервис, автомойка салып куячак. Ләкин урындагылар белән ярышып булмый, барыбер аларныкы өстә. Аннары, шуңа да тынычландым бугай: бу изге җиргә балалар бакчасы салалар, имеш. Ул сөякләр балаларны гына күтәрә алыр дип уйлыйм. Бигайбә! Юк, бернинди үчем дә юк. Бер дә борчылмасыннар. Кайтып әйт. Тагын шул: балалар бакчасы яисә ятимнәр йорты торгыза калсалар, матди ярдәм күрсәтергә дә риза. Ихластан әйтәм. Ләкин башка юньсез проектларына бәхиллегем юк. Теләпме, теләмичәме – комачау итүемне көтсеннәр дә торсыннар!

**15**

Мәүлет депутат ярдәмчесе булып озак эшләмәде. Мунча графигындагы ялларына туры китереп, ара-тирә генә аралашып, үзенә беркетелгән депутатның кайбер йомышларына йөреп, төрледән-төрле чиновниклар һәм

эшкуарлар белән очрашулар оештыруда катнашып, бер атнага якын йөрде дә Юпитер Марсовичка кереп әйтте:

– Булды, җитте, Юпитер Марсович! Башка кеше табыгыз, бу – минем эш түгел. Мин – гади җир кешесе, дөресрәге, мунча кешесе. Килегез безнең мунчага, аркагызны ышкып, миллек белән чабып-сыйпаштырып җибәрермен. Сихәтен бер ел буе тоеп яшәрсез. Менә «ярдәмче» таныклыгы. Рәхмәт сезгә, миңа күрсәткән ышанычыгыз өчен. Урамнан килеп кергән булсам да, куып җибәрмәдегез. Ачуланмагыз, бераз эшләгән дә булыр идем, вакытым бик аз калды.

Юпитер Марсович Мәүлетнең көтелмәгәнчә килеп керүенә әллә ни аптырамады. Шулай булырга тиеш кебек кабул итте. Тавышында үкенеч төсмере яңгырап китте китүен. Әмма ул бу сөйләшүне көткән кебек иде.

– Алайса сорауларыңа җавап таптың инде?

Мәүлеткә дөресен әйтеп җавап бирүдән башка чара калмады. Шулай да, җавап биргәнче, «Карале, каян сизенгән минем ниятләрне?!» дип уйлап алырга өлгерде.

– Таптым.

– Бик тиз таптың әле. Кешеләр кайбер сорауларга гомер буе да җавап таба алмыйлар.

– Җиңел таптым, чөнки соравы дөрес түгел иде.

– Нинди сорау икәнен әйтмисең инде?

Мәүлетнең күңеле бүген ачык иде. Ул икеләнеп тә тормады:

– Мин сезнең арагыздан Иблис токымын эзләдем, – диде.

Юпитер Марсович Мәүлеткә кискен карап куйды. Ләкин аның бу җитди карашында бер тамчы да усаллык юк иде. Ә гаҗәпләнү бар:

– Шулай укмы?! Юк дисең инде алайса?

– Юк.

– Бу хакта ике-өч көндә белеп буламы? Сорау бик җитди бит.

– Әмма сорау дөрес булып чыкмады.

– Сорау дөрес.

Бу юлы инде Мәүлет кискен борылып карады:

– Дөрес?

– Нәрсә, аптыраттыммы? Кабатлап әйтәм: сорау дөрес. Җавабын белмим. Дөрестерме, юктырмы? Унбиш ел буе шушында утырып та белмим. Утыз ел буе олы бизнеста булып та белмим. Кырык биш ел буе югары даирәләрдә кайнашып та – белмим. Белмим, белмим!

– Ә мин өч көндә дә белдем, төшендем: бу тирәдә Иблис юк.

– Ник алай дисең? Син бит безне белмисең. Мине белмисең.

– Беләм. Балалар бакчалары төзү өчен башка байлардан җир тартып алган кеше Иблис токымыннан була алмый.

– Бик тиз генә хәл итәсең әле син. Ә беләсеңме? Мин кайчакта үзем дә: «Мин Иблис түгелме?» дип уйлап куям. Кайчагында шундый гамәлләр кылып, шундый карарлар, кануннар кабул итеп куябыз, безнең эшкә бөтен шайтан әһеле кызыгып карап торадыр кебек.

– Фәрештә булмау әле шайтан дигән сүз түгел. Сез фәрештә түгел, әмма Иблис тә түгел. Мин аны башка җирдән эзләячәкмен.

– Ә нигә ул сиңа? Нигә үз башыңа шундый бәла аласың, нигә шундый ачы, кара тәкъдир чакырасың? Иблис белән шаярырга ярыймы, йә?!

– Мин сүз бирдем. Җиде көннән Иблис кешелек өстенә кара япмасын ябачак. Шуңа кадәр мин аны табарга, фашларга тиеш!

– Син үз аңыңдамы?! Мунча төтене башыңа китмәгәндер бит?! Нинди япма?! Нинди җиде көн?! Төш белән өнне бутадыңмы әллә? Ә мин сине бик җитди, акыллы гына егет дип уйлаган идем.

– Төш хакында дөрес әйтәсез. Чынлап та, төш күрдем мин. Менә шул төштә әйттеләр дә инде: ундүрт көн эчендә Иблисне тапмасаң, барыбызга да кыен булачак, диделәр...

– Тәк... Син... Син шаяртмыйсың, димәк? – Юпитер Марсович бүлмәсендә арлы-бирле йөренде.

– Шаяртырга вакытым юк, дидем бит инде. Төшемдә Хозыр-Ильяс үзе әйтеп китте: «Син җаваплы», – диде.

– Алай икән... Ничә көн калды дисең әле? Җиде көнме? Күп түгел икән. Әмма аз да түгел! Бу уенга мин дә катнашып китимме? Әйдә бергә эзлибез теге мәлгуньне! Мин дә күп беләм Иблис коткысына бирелгән бәндәләрне! Шул ук торгашларны ал син, күпме анда шайтани затлар. Ә банкирлар? Алар арасында да баш җитмәслек процентлар белән халыкны талап ятучылар күп. Эре магнатлар кулындагы корпорацияләр хакында әйтеп тә тормыйм инде! Кайчакта шундый тәэсир кала: җир астыннан табыла торган газ белән нефть тә Иблис кулында кебек. ЖКХ дигән Иблис тә бар, бигрәк тә караучысыз калган картлар яхшы белә ул каһәрне! Мин үзем ЖКХ дигән ул Иблискә каршы өч ел көрәштем. Әмма минем кебекләр өч ел буе әзерләгән канун кабул ителмәде, кире кагылды. Димәк, ул, теге Иблис мәлгунь, һаман яшәячәк, мохтажларны, ярлыларны, гарипләрне, караусыз калган ялгыз, авыру картларны, ятим балаларны йотып торачак.

Алар шактый сөйләшеп утырдылар. Әмма бер карарга гына килә алмадылар. Юпитер Марсовичны тыңласаң, Иблис бөтен җирдә булып чыга, әмма ныклап эзли башласаң, бер җирдә дә юк. Иблискә карата булган ышанычы тәмам какшый башлаганчы, Мәүлет бу халык депутаты яныннан тизрәк китәргә булды.

Менә алар, тагын очрашырга сүз куешып, туганнарча аерылыштылар, арка кагышып саубуллаштылар. Әмма Мәүлет чыгып китәргә өлгерми калды, ишектән телевизор экраннары аша яхшы гына таныш Әнвәр Мусин килеп керде. Танылган галим, профессор. Тарихчымы, журналистмы, әллә тел белгечеме – Мәүлет анык кына хәтерләми, үзенең ялкынлы чыгышлары белән ул халыкны шундук үзенә җәлеп итте. Бигрәк тә милләт язмышы хакында күп сөйли ул. Эшләгән эшләре хакында халыкка берни дә мәгълүм түгел, ә менә сөйләвен әйбәт сөйли, дөрес сөйли.

Юпитер Марсович икесен бер-берсе белән таныштыра башлады:

– Бусы Әнвәр абыең була, ә бу егетнең исеме – Мәүлет. Сез таныш түгелдер? Юк? Әнвәр дусны күбрәк тарихчы-публицист дип беләбез, ә менә безнең Мәүлет Иблиснең үзен койрыгыннан эләктермәкче.

– Ничек-ничек? Иблисне? Койрыгыннан? Кызык бу. Йәле, сөйләле, дустым, нинди уңышларың бар бу өлкәдә? – Ниндидер мавыктыргыч сүз тыңларга җыенып, галим кеше стена буендагы кәнәфигә барып

утырды, күзлек пыялаларын сөрткәләде, җыйнак мыек-сакалларын сыпырыштырды.

Ләкин Мәүлетнең, кабат бу темага кайтып, сүз озайтырга һич теләге юк иде. Яңа кунакның үҗәтлеге чамадан тыш булып чыкты, ул Мәүлеттән Иблис хакында кат-кат сорашты, гүя дусты янына шул Иблис хакында гына белешергә кергән иде. Мәүлет, «Сез дә ярдәм итегез», дигән кебек ялварулы караш белән бүлмә хуҗасына күтәрелеп бакты.

Иблис тарихын профессорга Юпитер Марсович мавыктыргыч итеп сөйләп бирде. Әнвәр Мусин әкияткә тиң бу сөйләкне һич бүлдермичә тыңлап торды, урыны-урыны белән баш кагып, хуплап куйды, ара-тирә, гаҗәпкә калып, хәтта «Булмас!» дигән кебек башын чайкады...

Иблис легендасы тыңланып беткәч тә, бераз баш кагып, баш селкеп утырды әле ул. Яңагына таянган килеш, тәрәзәдән күренеп торган «Рухият» кошының һәйкәл-сурәтенә карап, берничә минут уйланып торды. Депутат та, Мәүлет тә, аның бу җитди халәтен бозарга кыймыйча, бер-берсенә карашып, тик басып тордылар.

Менә профессор, уйлар гаменнән айнып, уянып киткәндәй булды. Сакал-мыекларын сыйпаштырып куйды да торып, бөтен бүлмә стенасын алып торган тәрәзә каршына килеп басты. Күзләре һаман да «Рухият» кошына төбәлгән. Ниһаять, ул кискен генә Мәүлеткә таба борылып:

– Беләм мин Иблисне каян эзләргә кирәген! – диде.

Мәүлет тә, депутат та, үз-үзләрен белештермичә, аңа таба бер адым атлап куйдылар. Аннары икесе бердәм рәвештә бер үк сорауны бирделәр:

– Каян?

Профессор кабат кәнәфигә барып утырды. Бу юлы үзенең каршында басып торучы Юпитер Марсовичка күтәрелеп карады.

– Беләм!

– Белгәч, әйт инде, ник сузасың?

– Беләм! – Профессор карашын Мәүлеткә күчерде. – Дустым, син аны урамнан эзлисең, менә шушындый затлы кабинетлардан караштырасың... Эчкечеләр, зиначылар, җинаятьчеләр, чиновниклар, башкалар – алар нәтиҗә генә. Иблиснең соңгы продукты, икенче төрле әйткәндә. Шушы ак сакаллы яшемә җитеп, моңа кадәр һич аңламаганмын икән ләбаса: Иблис ул – рух, дөресрәге, рухсызлык. Антирух. Менә әле шуны тагын бер мәртәбә аңлап утырам. Рәхмәт сиңа, кем... Мәүлет энем. Иблис тәгълиматын көн тәртибенә куйганың өчен. Ник онытабыздыр: ә тормышыбыздагы бөтен бәла әнә шул рухсызлыктан, рухиятебезнең зәгыйфьлегеннән бит...

– Туктале, аңлатыбрак сөйләле, сабакташ! Монда без конкрет зат турында, Иблис мәлгунь турында гәп куертабыз, аның кайдалыгы, кем кыяфәтендә, кемнең шкурасында яшәве хакында борчылып уйланабыз... Ә син абстракт рухият турында фәлсәфә сатарга керешәсең...

– Нинди фәлсәфә булсын?! Мин үзебезнең реаль тормыш-яшәешебез, кайдадыр тарихи барышның билгесез чатларында югалып, адашып калган язмышыбыз хакында әйтәм. Милләтебез язмышы хакында.

– Барыбер аңлатып сөйлә. Конкретрак...

– Йәгез, менә уйлап карагыз: Иблис төшсен дә, ди, кешеләрне, халыкларны ялгыш юлга кертеп җибәрергә уйласын да, ди. Шушы бер атна

эчендә аны фашламаган очракта, ул кешелеккә, әйтик без – татарларга, гомумән, милләткә, милләтләргә коточкыч бәлаләр җибәрсен дә, ди. Ничек күз алдына китерәсез соң бу галәмәт хәлләрне? Нинди юллар белән һәр кешенең йөрәгенә, җанына, димәк, язмышына барып җитә алыр икән ул? Аллаһы Тәгалә дә моны эшли алмый. Ул тикле Ул да: «Үзенә ярдәм иткәнгә генә ярдәм итәрмен», – дигән. Ходаебыз ихтыярыннан узып, ул мәлгунь бу явызлыкны эшләргә ничек батырчылык итәр икән?

– Ничек барып җитәме? – Юпитер Марсович та төшеп калганнардан түгел икән. Мәүлетне таң калдырып, ул Иблис хакында барлык ишеткән-белгәннәрен сөйли башлады. – Иблис, Иблис булганчы, Аллаһның иң көчле, иң продвинутый фәрештәсе булган. Газазил булган! Димәк ки, ул илаһи көчкә ия булган. Шул илаһи көч-куәте белән үсенеп китеп, Аллаһ каршында тәкәбберлек күрсәтә башлаган да инде ул. Шул сәбәпле Җиргә сөрелгән. Җирдә ул шайтаннар армиясе булдырган. Чынлыкта, аның үз идеясе, партиясе булган. Менә шул армиянең, шул партиянең лидерына, башлыгына әверелгән ул. Анысы ничек булгандыр, белмим. Трибунлыгы, сүз көче, акыл көче, мәкер-хәйлә көче белән дә ирешкәндер ул бу статуска. Юктан гына Аллаһның беренче фәрештәсе булмагандыр бит инде ул. Илаһи-магик егәрлеге, шаукым көче дә булган, әлбәттә! Әнә, безнең кайсыбер лидерларда чагылып китә андый иблислек. Шундый ук трибуннар, шундый ук хәйләкәрләр. Ләкин алар Иблис түгел. Бар дөньяны, халыкны, милләтне үз ихтыярларына буйсындырырга, ягъни Иблис булырга телиләр генә алар. Ләкин була алмыйлар. Аларның көчле идеяләре, тәгълиматлары юк. Үзләренең көндәлек, тар мәнфәгатьләрендә буталып, югалып калалар, күпчелек очракта иң гади-гадәти акча колына әвереләләр, шул гына... Ә Иблис ул башка! Иблис бар, аның үз максаты-идеясе, кодексы-конституциясе бар. Ниһаять, армиясе бар! Шайтан армиясе. Изге китапларда ук язылган лабаса: һәр кешенең үз фәрештәсе булган кебек, аның үз шайтаны да бар. Фәрештә туганда ук синең белән булса, шайтан гомер барышында ияләшә. Синең һәр гөнаһың, һәр яман эшең – шайтаныңа бер адым ул, хәтта явызлык, яманлык кылу ниятең дә шайтаннарга көч бирә, аларны сиңа якынайта. Тәүбә генә дә булыша алмый инде бу очракта. Аллаһка ныклап сыену, аның йола-гамәлләрен тоту, ислам тәгълиматы аша Аллаһка якынаю гына коткарып калачак кеше-бәндәләрне, минемчә.

Юпитер Марсович кинәт туктап калды. Бу мәлдә галим дусты аңа: «Синме соң бу? Мин синең бу кадәр акыллы булуыңны белми идем», дигән кебек аптырап, шаклар катып карап тора иде. Мәүлет исә, гомумән дә, кечерәеп, баласынып калды бу «фикер гигантлары» янында. Ул хәтта: «Нишләп йөргән булам соң мин бу Иблис гаме белән, барсыннар да үзләре тотсыннар, фашласыннар шул мәлгуньне», дип уйлап куйды. Ләкин профессорның әңгәмәгә керешеп китүе аңа бу уйларын дәвам итәргә мөмкинлек бирмәде.

– Дустым, мин синең бу дәлилләрең белән килешкән дә булыр идем. Әмма синең сүзләрең проблеманың тышкы, формаль өлешенә генә карый. Хәзерге сүз белән әйтсәк – технологиясенә, принципларына. Син сөйләгәннәрдән Иблисне күрү, хәтта тою кыен. Ә менә эчтәлеге, идеологик

асылы хакында төгәл генә әйтелми синең тәгълиматта, анда аңа урын юк. Чынлыкта, Иблис без уйлаганнан күпкә акыллырак. Шуңа да аны тоту кыен, фаш итү дә кыен. Ул бик сак, күзгә бәрелеп тормый, ләкин аңа карап, халык күңеленә керә алмый, аңа йогынты ясый алмый, дип тә әйтә алмыйбыз...

– Туктале, кордаш, аңлатыбрак сөйләле! Нәрсәдер әйтмәкче буласың, тик, нәрсә? Һич төшенеп җитә алмыйм.

– Сабырлык, дустым, сабырлык. Әле мин сүземне башлап кына киләм. Әйтәсе килгәнем шул: сәяси технологияләргә, яшәү, хәтта алгарыш принципларына караганда да, идея, бу очракта милли идея мөһимрәк. Шул идеяне халыкка якын җибәрмичә, буып тору бара, минемчә, бүгенге җәмгыятебездә.

– Бөтен бәла дә шунда лабаса: милли идеяне билгели алмый җәфаланабыз түгелме соң?!

– Ул күптән билгеле инде. Аны ачыклау өчен бер генә сорау куярга кирәк: тарих барышының иң кыен дәверләрендә татарны нәрсә саклап калган? Шул сорауга җавап милли идеягә алып чыга да инде!

– Йә, шуннан, нәрсә саклап калган инде?

– Мәктәп.

– Һәм динме?

– Мин алай дип әйтмәдем бит әле. Минемчә, мәктәп өстенрәк. Дингә кеше үз күңеле, үз йөрәге аша килә. Үз иманы аша. Иманлылык – ул индивидуально! Диндә эго күп. Ә мәктәп система булырга тиеш. Милли идея системалы булырга тиеш. Җәмгыятьнең дә, кешенең дә һәр күзәнәгендә булырга тиеш. Нинди генә авыр чорларда да татарны мәктәп саклап калган. Милли мәктәп. Милли рух милли мәктәптә тәрбияләнә. Мәдрәсә – ул шул ук мәктәп. Дини тәгълимат мәктәпнең эчтәлеген баеткан гына, аннары бер үк вакытта Аллаһы Тәгаләгә сыену аша егәрлеген арттырган. Рухи егәрлеген. Рух ныклыгын. Рухи ихтыяҗга омтылышны, хәтта ки, мессия дәрәҗәсенә күтәргән. Язмыш иткән. Менә! – Бер мәлгә тын калып, арлы-бирле йөренеп алгач, профессор шундый ук ярсулык белән дәвам итте: – Кайсы гына дәвердә дә шул ук хәл: хәлиткеч моментта милли мәгариф ярдәмгә килә һәм язмышы кыл өстендә торган татарны соңгы чәч яисә сакал бөртегеннән тәкъдир юлына сөйрәп чыгара. Ә бүген... – Профессор тагын тукталып калды, бер Юпитер дустына, бер Мәүлеткә карады, аннары якындагы кәнәфигә барып утырды.

Юпитер Марсовичка шул гына кирәк иде. Хәзер инде ул торып басты.

– Синең логика белән килсәк, бүген безнең милли идеябез юк? Шулаймы? Милли мәктәп таркатылды бит. «Юк» дип кистереп әйтеп булмаса да, «Бар» дип тә ныклап әйтә алмыйбыз. Беләсеңме, бүген милли идея дәүләтчелеккә якынрак тора. Чөнки мәктәп дәүләт кысаларына кымшана да алмаслык дәрәҗәдә кертеп утыртылган. Бүген милли мәктәпләрдә прокуратура вәкилләре шымчылык итеп, тыкшынып йөриләр. Тел дәресләре берән-сәрән генә калды, әдәбият-мәдәният дәресләре, федераль стандартларны сәбәп итеп, үзләштереп булмаслык дәрәҗәгә төшерелде. Дәүләт кенә түгел, дәүләтчелек тә көлке бер хәлдә калган вакытта милли идеягә ризык бирердәй җирлек бетә, шулай түгелмени?!

– Шулай, нәкъ шулай! Хәзер мин аңлый башладым, дустым: ни өчен тарихыбызның иң кискен моментларында да татар рухы исән калган?

Чөнки милли мәктәп булган, милли идея булган, димәк ки... Иблискә үз иблислелеген кылырга җирлек һәм мөмкинлек булмаган! Чөнки шайтани ихтыярын инсани затларга тагу өчен аңа иң элек җәмгыятьнең, халыкның, милләтнең рухы какшавы, киләчәккә өмете сүнүе кирәк! Шулай түгелмени?! Шул яклап килеп карасак, бүген нәкъ шундый вазгыять туып килә. Иблис мәлгунь шуңа да төшкән инде татар арасына! Сизгән, тойган ул безнең какшый башлаган рухыбызны! Хәсис димичә, ни дисең инде?! Иң башлы, иң хәйләкәр мәләк булган шул ул. Юкка гына, тәкәбберләнеп, Аллаһы Тәгалә белән сатулашып йөрмәс иде!

Профессорның бу сүзләрен Юпитер Марсович та, Мәүлет тә бик авыр кабул иттеләр. Бигрәк тә Мәүлет каршылыклы тойгыларга бирелде. Бу уй-тойгылар шулкадәр авыр иде, ул, бу авырлыкка түзмичә, якындагы бер урындыкка барып утырырга мәҗбүр булды. Чынлап та, шулай булып чыга: Иблиснең, җиргә төшеп, һәр кешегә коткы таратып йөрүе дә кирәк түгел икән бит. Әнә шул мәгариф системасы башында торучыларны исәңгерәтергә дә, исәңгерәмәгәннәрне нык кына куркытырга да, курыкмаганнарны акча, йә булмаса җылы урын бәрабәренә сатып алырга да. Ә Иблиснең коткы-карарларын алар үзләре игълан итәчәк. Кешенең рухын какшата торган, аның илен, телен, ихтыярын тартып алуга корылган гамәлләр башланачак. Һәм бу иң элек татарда шулай!

Мәүлетнең уйларын профессор дәвам итте:

– Һәм бу хәл иң элек татар язмышына төшкән! Шушы йомшаклыгыбыздан, татарлыгыбыздан файдаланып, Иблис мәлгунь, коткы юлында безне сайлаган, хәерсез! Шайтаннарын өстергән. Юк-юк, кеше-бәндәләрнең үзләрен җен-шайтанга әверелдергән!

Кәнәфиенә сеңеп утырган Юпитер Марсович та мондый ачыштан уянып киткәндәй булды:

– Иң элек шул хакимияттә утыручы шайтан-кешеләр арасыннан эзләргә кирәк ул мәлгуньне, значит... Мәүлет, ишетәсеңме? Синең эчкечеләр арасыннан, зиначылар, җинаятьчеләр, карьерист-чиновниклар, депутатлар арасыннан Иблис эзләп йөрүең гел кирәк булмаган. Аларны тудыра торган, алар өчен шайтани җирлек әзерләү белән шөгыльләнгән, милләт кайгысы дигән хистән мәхрүм конкрет бәндәләрнең бугазыннан барып тотарга кирәк сиңа, белдеңме инде?! Чынлап та, шулай бит: рухсызлыктан, имансызлыктан, кыйбласызлыктан, димәк ки, боларның барысына да сәбәпче булган мәктәптән, милли мәгарифтән, дөресрәге, аның юклыгыннан күрергә кирәктер ул рухи гарипләрнең ачы язмышын.

– Кыскасы, Иблис инде бар, хәтта без аның кайда һәм кемнәр шкурасында яшәгәнен дә беләбез, – дип, сүзгә Юпитер Марсович кушылды. – Димәк, без аларга дәгъва куя алабыз. Ләкин бер каршылык бар, дускайларым: бу кешеләр үзләренең Иблис коткысы белән агуланган булуларын белмиләр. Алар инде үзләре Иблис. Ә Иблис бервакытта да тәүбәгә килми. Юу-у-к, монда башка бер чара табарга кирәк. Син ничек уйлыйсың, кордаш?

– Мин шуны уйлыйм: Иблис ул – иң элек сихер, шаукым, магия. Без шул хакта онытмыйк. Әйдә, Иблис тарихының, җеннәр-шайтаннар тарихының ничек башланганын тагын искә төшерик. Бу хакта без Иблиснең Җиргә сөрелгән тарихыннан кала нәрсә беләбез? Ә, кордаш?

– Ну... Иблиснең Җирдәге тарихына килсәк, легендалардан шул мәгълүм: Җир тормышы өчен Аллаһ инсаннарны гына түгел, җеннәрне дә яраткан. Адәм һәм аның нәселе уттан һәм балчыктан яратылган булса, җеннәр бары тик уттан гына яралган. Шуңа да алар кешеләрдән көчлерәк дип санала. Җеннәрнең көчләре тагын шунда, Аллаһы аларга тагын аң биргән. Кешеләргә дә аң биргән, әмма җеннәргә ул, аң белән бергә, кешеләр күзенә күренмичә яшәү сәләте биргән. Әйе-әйе, алар кешеләрне күрәләр, әмма кешеләр аларны күрә алмый. Шуңа күрә җеннәр кешеләр хакында аларны сукыр дип уйлыйлар. Менә шул: Җиргә сөрелгән Иблис иң элек шул җеннәрне үзенә буйсындырырга теләгән. Үзенең яман ниятләрен гамәлгә ашырганда, җеннәр армиясе бик кирәк булгандыр шул. Чынлап та, ул җеннәрне бик тиз арада шаукым юлы белән үзенә хезмәт иттерә башлый. Иблис йогынтысына бирелеп, аның ихтыярында яманлыклар кылып яши башлаган җеннәрне шайтан дип атый башлаганнар. Аларның җитәкчеләрен Гыйфрит дип йөрткәннәр. Ә-ә, тагын шул да мәгълүм булсын: барлык җеннәр дә Иблис коткысына бирелмәгән, аның иярчененә яки хезмәтчесенә әверелмәгән кешеләр кебек үк аларның бер өлеше Мөхәммәд пәйгамбәр динен кабул иткән. Мөселман дип йөртәләр аларын, бу җеннәр мөселман кешеләргә хәерхаһ булулары, гел булышып торулары белән данлыклы. Шайтан җеннәр дә, мөселман җеннәр дә теләсә кем кыяфәтенә керә ала, хәтта табигать күренешләре яисә әйберләр рәвешенә дә. Шуңа да кешеләр тормышында алар сизелеп, тоелып, хәтта күренеп алалар. Адәмнәр арасында төрле ырым-ышанулар, имеш-мимешләр туугa сәбәпче булалар. Мин белгәннәр шулар.

Юпитер Марсович та үз сүзен әйтергә көтеп кенә торган:

– Беләсегез килсә, Коръәндә җеннәргә кешеләргә караганда да күбрәк урын бирелгән. Димәк, алар көчлерәк тә, мөһимрәк тә. Аллаһы Тәгалә ихтыяры гына аларны баланста тота. Һәм һәр тәүлектә җеннәрнең хакимлек итәр өчен билгеләнгән үз вакытлары бар: Кояш баегач та, берара төн уртасында, көн уртасында дөнья шайтаннар кулына күчеп ала, бу вакытта мунча керергә дә ярамый хәтта. Мунча шайтан-җеннәрнең яраткан урыны бит ул. Мунчага кергәндә дә, тамак кырып керергә кирәк. Юкса тегеләр үзләренең яман эшләрен башкарачаклар. Бу инде халыкта күптән билгеле.

Бигрәк тә үз балаларын бишектә яткан кеше баласына алыштыралар алар. Аеруча беренче кырык көндә сак булырга кирәк, диләр. Исем кушуны да озакка сузарга ярамый, исеме дә юк, иясездер бу дип, хәзер килеп җитәләр, ди, алар...

Ул арада Мәүлетнең башына сукты: ул да бит мунчада эшли. Димәк, аны очраклы гына сайламаганнар. Димәк, җеннәр аны яхшы белә. Ул үзе дә алар хакында яхшы белергә тиештер. Күпме эшләп, үзе аларны күргәне булмады, ә шайтаннар аның хакында әйбәт белә, димәк. Аллаһы Тәгалә менә ни өчен Мәүлетне сайлаган! Әнә бит ул да нинди сынаулар үтәргә тиеш, бу юкка түгелдер, юкка түгелдер.

Шул вакытта сүз кабат профессорга күчеп өлгерде:

– Менә хәзер Иблистән, аның шайтаннар армиясеннән котылу юллары ачыклана башлады. Алардан котылу өчен мөселман җеннәр белән элемтәгә керергә кирәк. Ярдәм итсә, алар гына ярдәм итә алыр. Аллаһы Тәгалә алар яклы бит әле! Җеннәрне җеннәр генә җиңә ала, бу – көн кебек ачык!

– Аларын каян табарга соң?

Шунда Мәүлет балаларча самимилек белән сикереп торганын сизми дә калды:

– Мин беләм! Җеннәрне ничек табарга, алар белән ничек сөйләшергә кирәклеген мин беләм!

Мәүлетнең бу хәбәреннән соң бүлмәдәге әзмәвердәй затлар урыннарыннан кузгалып куйдылар. Аннары, «Йә, тагын нинди авантюрага бирелерсең икән?» дигән кебек шомлы-сынаулы карашлары белән егеткә текәлделәр. Шулай итеп, «Иблис тарихы» кабат үзенең башлангыч өлешенә кайтты. Иблис коткысы белән бәйле гыйбрәтле тарих, чынлыкта, милләт язмышы Мәүлетнең шушы яңа хәбәреннән тора булып чыкты.

– Әйе, мин беләм, – дип кабатлады ул. – Җеннәр белән сөйләшә торган кешем бар минем. Шул әйтте миңа Иблис коткысы хакында! Шул юрады минем ул сәер төшемне...

– Кем соң ул, ник башта ук әйтмисең аны?

– Кем, йә?

– Юраучы кыз, экстрасенс! Безнең кебек түгел ул. Югалып та тора ала. Шуңа да имче, юраучы, экстрасенс. Хәтта офисы да бар.

– Менә сиңа мә! Бүгенге көндә дә андый конторалар бармыни әле? – Профессорның зиһене тәмам чуалып киткән иде. Юпитер Марсович та каушабрак калган иде.

– Безнең бу югары пафослы сөйләшүебез шул сихерче ихтыяры янында сүз боткасы булып кына каламы инде?

Профессор аны тынычландырырга ашыкты:

– Юк, кордаш, без үз әңгәмәбездә бик мөһим нәтиҗәгә килдек: Иблис коткысына бирелеп, шайтанга әверелгән җеннәрне Ходай ихтыярындагы фәрештә-җеннәр җиңә алачак, дигән фикер әйттек. Мәүлет дустыбыз бу фикерне практик яктан гамәлгә ашыру юлын әйтте. Мең юлның берсен әйтте, дип уйлыйм.

– Аңлыйм анысын... Ләкин Иблис хакындагы шомлы хәбәрне ачып салган сихерчедән теләсә нәрсә көтәргә дә була, дип кенә әйтүем. Үзе үк Иблис иярчене түгел микән соң ул? Бу тарихка тартып китереп, кешеләр рухы, аларның җаны, зиһене, ихтыяр көче белән юри уйнамыймы ул? Дин сихергә, юрауларга, гомумән, ырым-шырымнарга каршы бит? Шулай түгелмени?

– Ләкин шуны да онытма, кордаш, Коръәннең, ихлас динебезнең кодрәте шулкадәр киң, без аны бу сөйләшүдә генә аңлап-төшенеп бетә алмаячакбыз. Пәйгамбәрләребезнең хикмәти, легендар тарихларын, аларның тылсымлы, серле-шаукымлы яшәешләрен, инде менә ничә гасырлар барлык мөселман өммәтен дулкынландырып торган язмышларын кая куясың?! Минемчә, Коръәндә андый язмыш шаукымнары күп, һәм алар, әлбәттә инде, Аллаһыбызның ихтыяры белән турыдан-туры бәйләнгән.

Теләсә нинди җитди әңгәмәнең ахыргы кәлимәләре булырдай бу сүзләрдән соң бүлмәдә серле, хәтта шомлы тынлык урнашты. Беренче булып Мәүлет торып басты. Кул сәгатенә күз төшерде. Карашларын сәгатеннән аермыйча гына сорап куйды:

– Абзыйлар, миңа барып караргамы соң ул юраучы янына? Шуны әйтегез дә... Миңа китәргә кирәк, озакламый мунчада сменам башлана.

## 16

Очрашырга сүз куешып, тыныч кына аерылыштылар. Мәүлет хәтта аптырады: ничек ярсып, эчке бер инану белән гәп куерткан абзыйлар, имче-юраучы турында ишеткәч, әллә ничек югалып, басылып калдылар. Матур, дөрес сүзләр сөйләүче бу милләт агалары, сүзгә оста булсалар да, ниндидер төгәл карарга килергә, катгый гамәлләр кылырга сәләтсез булулары белән Мәүлетнең күңелендә авыр тойгы уяттылар. Шулай да ул Юпитер Марсович белән профессорга бик рәхмәтле иде: әңгәмә барышында яңа фикер әйтелде, әле моңынчы Мәүлетнең башына да килеп карамаган «җеннәр тәгълиматы» өскә калыкты.

Җеннәр... Чынлап та, Иблис коткысына каршы торырлык көчне, идеяне иң элек алардан эзләргә кирәк! Чынлыкта, җеннәр шуның өчен – нәкъ менә шайтан коткысына каршы торыр өчен яратылган бит! Ничек кенә хәтердән чыккандыр: Иблис токымыннан булган шайтан гомер буе кешелеккә хөсетлек кылып йөри ләбаса. Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиәссәлам белән Газазил-Иблиснең икесен бергә Җиргә төшергәндә үк: «Бер-берегезгә дошман булып кыяматкәчә яшәгез!» – дигән бит. Авыл картлары шулайрак сөйләшә иде. Нигә башта ук бу хакта искә алмады икән ул? Ә бит Газраил да Иблиснең җанын иң соңыннан алыр, ди. Шуңа кадәр адәм заты белән шайтан кавеме бергә, янәшә яши, имеш. Димәк? Димәк, Иблис белән алышу, көрәшү мөмкин хәл түгел? Илаһи ихтыярдан да көчле ни бар? Бу авыр хәлгә ничек тарыды соң ул? Гап-гади төштән ниндидер баш җитмәслек зур мәгънә чыгарып, гап-гади башы белән Иблиснең үзен эзләп йөри түгелме соң?! Дивана дими, кем дисең инде аны?!

Мәүлет мәсьәләнең һаман катлаулана барганын аңлады. Аның атна-ун көн буе Иблис фәлсәфәсе белән хыялланып, шайтан коткысы турында уйлап яшәве эзсез калмады, ахры, ул зиһененең бер өлеше кителә баруын, аңының зәгыйфьләнә башлавын тойгандай булды. Аның тәмам күңеле төште, кәефе кырылды...

– Һайт! Тпру!.. На! Һайт!..

Очсыз-кырыйсыз уйлар әсирлегендә иләсләнеп, соңгы көннәрдә яшәү гамен билгеләгән ният-хыялларыннан йөз чөереп барган Мәүлет артындагы ят тавышка сискәнеп китте. Кискен борылып карады. Һәм телсез-аңсыз калды. Шәһәрнең үзәк урамы буйлап көймәле арба җиккән атын куалап, җәйге эссегә дә карамастан, өстенә авыр кожан, башына эшләпә кигән авыл агае килә иде. Шул килгән уңайга, бу галәмәт олы юл читеннән тротуарга сикереп чыгарга өлгергән Мәүлетне «һайт»лап узып, якындагы тыкрыкка кереп тә китте. Мәүлет исә арбадагы сөт бидоннарын гына шәйләп калырга өлгерде. Казан тикле Казанга сөт алып килгән бит, менә нинди батыр кеше, ә! Аты да ныклап хәтердә кала торганнардан иде бу Хода бәндәсенең. Җен кебек бер хайван заты иде ул. Ала-кола бу ат тәнендәге бөтен йон төкләре дә шырпыдай тырпайган кебек тоелды аңа. Авылда андый котсыз атларны «җен атлары» дип йөртәләр.

Туктале, туктале... Атлар... Җеннәр... Күршедәге Шакир карт атларның җеннәрне күрүе хакында сөйли иде ләбаса! «Ул «тирес аяк»ларны атлар гына күрә ала», – ди торган иде күрше карты. Ул шулай дип, җен-шайтаннарны атый иде. Янәсе, җеннәргә үз исемнәре белән, ягъни, «җеннәр» дип, авыз

тутырып әйтергә ярамый, шундук артыңнан иярәчәкләр. «Олтырак», «чабата», «себерке» дип кенә җибәрә иде карт. Ләкин күп очракта «тирес аяк» дип әйтә иде.

Ай-һай, күп нәрсә сөйләп калдырды ул җен-шайтаннар һәм җен-пәриләр хакында. Әйтик, кичләрен яисә төнлә читән коймалар буенда бик йөрергә ярамый. Чөнки пәриләр читән буенда йөрүчән икән. Бигрәк тә сукыр пәриләр читәнгә тотынып йөри, имеш. Әгәр дә инде дөм караңгыда читәнгә тотынып барырга туры килсә, бармакларны як-якка җәеп җибәреп тотынырга кирәк. Аеры бармаклар арасыннан сукыр пәриләр очып чыга алсын өчен шулай тотыналар, ди. Күрше карты кичләрен ялгызы гына урам буенда йөргән кыз-кыркынны да өйләренә куып җибәрә иде. «Йөрмәгез ялгыз башыгыз, ичмасам, чәнчә бармагыгызны аерып куегыз!» – дип әйтә иде. Яныңда кеше булмаса, чәнчә бармак та сиңа иптәш була ала, диюе булгандыр, күрәсең. Тагынмы? Тәрәзәдән озак карап торырга ярамый, имеш, җеннәр чакырасың. Тагын... Яшенле яңгыр астында ялгыз йөрергә ярамый. Янәшә яшәүче җеннәр хәтәр яңгырдан ялгызак кешеләргә ышыкланырга тырышалар икән. Яшен яшьнәү дә – Күкнең шайтаннарга ачулануыннан башка нәрсә түгел. Күктәге мәләкләрнең Иблис токымыннан үч алулары бу.

Менә шул Шакир агай колхоз атлары карый иде, бөтен гомерен атлар белән үткәрде. Димәк, җеннәрне дә тоеп, хәтта күреп йөргән ул. Соңгы сулышын да ат өстендә алды мәрхүм. Атына атланып, төшке ашка кайтканда, Буранының муеныннан кочаклаган килеш «җан очырган».

Менә шул карт әйтә иде: «Җеннәр дә кешеләр кебек. Алар да атларга атланып йөрергә яраталар. Ләкин кеше күзенә күренмиләр. Шуңа күрә, ялан-кырдан манма тиргә батып чабып кайткан атларга элеккеләр һич аптырамаганнар, «җеннәр шаярган» дип әйткәннәр».

Иң кызыгы, атларга җеннәрне – кешеләр белән янәшә яшәүче рухи затларны күрү сәләте бирелгән, ди иде Шакир карт. Шуңа күрә дә ул атларга илаһи бер җан иясенә караган кебек карый иде! «Әгәр кеше күзенә күренергә теләсәләр, алар бәндәләргә атлар булып күренергә тырышалар», – дип тә җибәрә иде.

«Җеннәр нинди алар?» – дип, бик нык сорашкач, Шакир карт малайларга кешеләр белән янәшә дөньяда яшәүче рухи затларны күрсәтте. Әйе-әйе, чып-чын сихер-михер сеансы булды ул. Иң элек шуны кисәтеп куйды ат караучы:

– Курыкмагыз, атлар тирәсендә әйбәт җеннәр генә була... – диде. – Аларның яманнары чүплек буйларында, ташландык йортларда, яркомлыкларда, кыргый әрәмәлектә, урман буйларында бөтерек җил, давыл булып яши, кайчакта чучка борынлы кара мәче, эт булып күренә. Җиде кат җәһәннәмнән җир өстенә чыккан мәлгунь-пәриләр алар, – диде. – Мин күрсәтә торган җеннәр – әйбәтләре. Алар явыз рухлар – шайтан җеннәр белән көрәшеп яшиләр, ул хәшәрәтләрне инсани затларга, ягъни мәсәлән, безгә якын җибәрмәскә тырышалар.

Әле дә хәтерендә Мәүлетнең: ул көнне күрше карты үзе тирәсендә бөтерелгән малай-шалайны бер төркемгә җыеп алды да бер-бер артлы тезеп бастырды. Аннары яңа гына тугарылган атының стенга сөяп куелган

дугасын барып алды, аны, бер башыннан ике куллап тотып, дуганың өске өлешенә йөгән бавы бәйләү өчен беркетелгән тимер боҗраны беренче малайның йөзенә якын ук китерде.

– Кара, әнә шул боҗра тишегеннән кара, берәр нәрсә күрәсеңме? – Үзе хәйләкәр елмайган була, картлач.

Малай, берни дә аңламыйча, читкә тайпылды. Рәсим исемле бу малай бүтән сафка басмады. Хәлим дигәннәре кыюрак булып чыкты. Ул нык-нык адымнар белән атлап килде дә, кереп китердәй булып, әлеге тимер боҗра тишегенә төбәлеп карап тора башлады. Аксыл керфекләре боҗра тимеренә тияр-тимәс күпме торгандыр, менә бервакыт аның кысынкы күзләре киң җәелеп, хәтта бүртенеп ачыла башлады. Күз алмалары үз тамырларыннан кубарылып чыгар хәлгә җиткән малайны дуга алдыннан Шакир карт тартып алмаса, бер-бер хәл була иде, билләһи! Хәлим исә, бер сүз дәшмичә, күзләрен йодрыклары белән уа-уа, читкә китеп барды. Аңардан тимер боҗра аша күргәннәрен сорашучы да булмады, һәркемнең дуга тимерендәге тишеккә үз күзләре белән карыйсы килә иде.

Хәлим артында басып торган Мәүлет серле боҗра каршына куркып, теләр-теләмәс кенә килеп басты. Әле генә дус малае белән булган күренештән соң аның күңелендә шик-шөбһә көчәя барды. Ләкин барыбер кызыксынуы җиңде: «Нинди тишек ул? Нәрсә бар анда? Нинди алар – җеннәр?»

Мәүлет башта берни дә күрмәде. Дөресрәге, һаман шул таныш йөзләрне күрде: гомердә булмаганча җитдиләнеп калган ат караучы карт, һаман күзләрен уып басып торучы Хәлим, Мәүлет тирәсенә җыелып, кызык көтеп зар булган малайлар.

Менә бервакыт тимер боҗра артындагы дөнья җемелдәп тора башлады. Бөтен тирә-як көмеш нурларга күмелде. Җемелдәвек исә, көчәйгәннән көчәя барып, көмеш дулкын күбекләренә әверелде. Бу күбекләр бераздан кеше сыннарын хәтерләткән, әмма үтә күренмәле гәүдә-сыннарга охшаша башлады. Шулай итеп, күз алдында адәм балаларына охшаш затлар пәйда булды. Җеннәр! Нәрсәсе белән җеннәр соң алар? Әйе, үтә күренмәле. Әнә – йөрәкләренә кадәр күренеп, сәгать йөргәндәй, тибенеп, эшләп тора. Күзләре зур, кечкенә таба кадәр булыр. Әмма куркыныч түгел. Хәтта мөлаем. Шәрә дисәң... Бик сәер бу: алар киемле дә, киемсез дә түгел. Алар бары тик җемелдәвек нурдан гына торалар! Үзләре туктаусыз хәрәкәттә, арлы-бирле йөренәләр, чабышалар. Нидер эшләгәннәре дә күренми, әмма шул аңлашыла: аларның барысы да эштә. Берсеннән кала... Әнә ул, бу якка йөзен борган да, кул бармаклары белән ияген тотып, уйланып басып тора. Менә бервакыт Мәүлетнең карашы аның утлы карашлары белән очрашты. Йөрәге жу итеп китте, җаны табанына төшеп яткандай булды. Иң кызыгы бу да түгел әле, теге җен дигәннәре Мәүлеткә таба килә башлады. Килеп җитүгә, күзләрен кыса-кыса, бераз иелебрәк, Хәлим карап торган тимер боҗраның икенче ягыннан караныргa кереште. Шунда Мәүлетнең күзләре шартлар хәлгә җитте дә инде, йөрәге ярыла язды. Шакир карт дугасын тартып алмаса, Мәүлет, зиһене какшап, тәмам акылыннан язар иде, мөгаен.

Ат караучы хәлне бик тиз аңлап алды һәм дуганы малайларның буе җитмәслек кадакка элеп куйды. Соңрак, карт урынында булмаганда, качып

кына килеп, шул дугадагы тимер божра аша җеннәр күрергә тырышучы малайлар булды булуын, ләкин элемтә тәмам өзелгән булып чыкты, аларны башкача күрү мөмкин булмады.

**17**

Мәүлет, башта ук уйлаганча, имче кыз янына китте. Сменасына кадәр берәр сәгать бар иде әле. Ике катлы йортны бик тиз эзләп тапты ул. Әнә таныш подъезд каршындагы таныш эскәмия дә үз урынында. Ул инде кыскарган, берничә кеше утырырлык кына калган. Аның йорт ягындагы башында япа-ялгыз, баштанаяк чүпрәккә төренгән бер хатын-кыз бөрешеп утыра. Мәүлет чамалап алды: яки авыру, гарип кеше бу, яки бу Хода бәндәсе үтә дә тәкъва мөселман затыннан булырга тиеш. Имче кыз янына ярдәм сорап килгәндер, мескенкәй.

Мәүлет аның яныннан җәһәт кенә үтеп, ачык подъезд ишегеннән кереп чумарга уйлаган иде дә... Каяндыр, башка дөньялар төпкеленнән яңгыраган кебек ишетелгән тавышка борылып карарга мәҗбүр булды.

– Мәүлет...

Мәүлет подъезд ишегенә кулын сузган килеш тукталып калды. Борылып карамыйча да аңлап алган иде инде ул: эскәмиядә утыручы хатын-кыз – аның төшен юраган кыз иде. Шулай да, юраганы юш килсен өченгә генә булса да сорарга булды:

– Си-и-н? Син имче кыз бит, әйеме?

– Әйе, мин – имче кыз. Таныдың, димәк, син минем хакта уйлап йөргәнсең.

– Уйламыйча хәл юк монда, шул төш аркасында әллә нинди хәлләргә тарып беттем. Ләкин төшнең дә, өннең дә, хәтта уйлаган уйларның да очына чыга алганым юк. Менә тагын, аптырагач, синең янга кереп чыкмакчы идем. Ә син нишләп монда утырасың әле?

– Мин хәзер кешеләр кабул итмим. Сиңа төш юраганнан соң мине бу шөгылемнән тыйдылар.

– Ничек инде тыйдылар? Кемнәр? Кешенең Ходай тарафыннан бирелгән сәләтен тыеп була димени?!

– Юк, Мәүлет, ялгышасың. Юрау, им-том – сәләт кенә түгел, ул – сихри һәм илаһи көч, үзеңнең генә түгел, башкаларның да рухлары, җаннары белән уйнау, шушы уеннан язмыш тудыру ул. Кемнәр тыйганлыгы турында әйтә алмыйм. Бу хәбәрдән синең зиһенең тагын да авыраячак кына. Юк-юк, Аллаһы Тәгалә түгел. Аның алдында хисапны без соңыннан бирәчәкбез. Ә бит без бәндәләрнең, бигрәк тә имчеләрнең, юраучыларның, шаукым ияләренең бер ягында фәрештәләр изгелеккә көйләсә, икенче ягында Иблис коткысы таратучы җен-шайтаннар туй итә.

– Әйт әле, кем... Кем дип әйтим соң үзеңә?

– Сания дип әйт.

– Ни өчен Сания?

– Чөнки шаукым, сихер дөньясында минем исемем шундый. «Сания» «ике» дигәнне белдерә. Борынгылар уйлавынча, бу исемне йөрткән кеше ике дөньяда да үз көче һәм илаһи шаукымы белән яши.

– Кызык икән. Сания алайса... Менә әйт әле: син хәзер имче-томчы да

түгел, ди. Юрау, дәвалау белән шөгыльләнмисең, ди. Шулай да булсын... Тик минә минем кебекләр бар бит әле. Бу шаукымлы, серле-сихерле хәлләрдән соң, мин хәзер кемгә барып киңәш сорыйм?

– Мәчет картларына. Син күбрәк шунда булырга тиеш, минем янда түгел. Тик... бүген мин сине кабул итәм. Синең өчен генә күңел көчем, рухи егәрлегем җитә әле... Беләсеңме, ни өчен? Юк? Чөнки син – минем иң соңгы клиентым. Ә безнең сеанс әле бетмәде... Ул сеанска минем хокукым бар...

– Кызык әйберләр сөйлисең син, Сания...

– Алай ук кызык димәс идем... Йә, сине миңа нинди борчу китерде? Хәзер шул хакта сөйләшик... Дөресен генә әйткәндә, мин күп нәрсәне беләм. Тик син күңелеңдәгеләрне үзең сөйләргә тиеш.

– Бүлмәгә кермибезмени?

– Юк, кермибез. Мин бит монда тормыйм...

– Әйдә алайса минем торакка. Болай урамда утырып булмый бит инде. Ерак яшәмим мин, бер маршрут буенча гына барасы.

Кайта-кайта, Мәүлет уйланып барды: аның язмышына төшкән Иблис шаукымы өчен беркем дә үзенә җаваплылык алырга теләми, беркем дә кистереп кенә, аңа нәрсә эшләргә кирәген, кая барырга, кемгә таянырга икәнлеген әйтә алмый, әллә әйтергә теләмиме? Кемдер җеннәргә сылтый, хәтта югары урындагы кешеләр дә, бәндәләрнең зиһененә үтеп керергә сәләтле сихерчеләр, имчеләр дә мәчеткә төртеп күрсәтә.

Ара-тирә зур гына төенчек күтәргән Саниягә күтәрелеп карый Мәүлет. Кызның йөзендә дә, күзләрендә дә арыганлык чалымнарын күрми мөмкин түгел. Элеккеге мөлаем, нурлы йөздән берни дә калмаган. Ә! Калган икән! Нindидер инанычлы җылылык, газиз туганлык хисләре бөркелә иде Сания ягыннан. Бу кыз аның язмышына ныклап кереп бара, ахры. Беренче күрүдә үк гашыйк була язып калган иде, юктан гына булмаган, күрәсең. Ләкин... Сихерче бит ул, бәлки әле, берәр пәридер, юха яки убырдыр? Барыбер сак булырга кирәк. Дивана димә инде, күрәләтә торып, аулак өенә чакырды бит үзен!..

Мәүлет, үзе дә сизмәстән, күңеленнән генә берничә саклану догасы укып куйды. Хәтере ярты-йорты гына саклап калган булса да, бу дога кыйпылчыклары аның күңелен урынына утыртты. Кайтып кергәндә, Мәүлетнең күңеле тәмам тынычланып җиткән иде инде. Аеруча «Кунут» догаларының соңгы кәлимәсе аның колагында нindидер илаһи моң белән хәтсез вакыт яңгырап торды. Нәкъ менә шул дога аны шайтан вәсвәсәсеннән, шул ук вакытта сихер шаукымыннан да, саклап торган кебек иде: «...Вә нәхәләгү вә нәтрүкү мән йәфҗүрүкә» (Сиңа (Аллаһка) гыйсъян иткәннәрдән ерак торабыз, аларга кушылмыйбыз).

Мунча ишеге төбендә аларны авыз эченнән генә догамы, җырмы көйләп торган Шәмси бабай каршы алды. Ул, Мәүлеткә бөтенләй дә игътибар итмәгәндәй кыланып, бер баштанаяк төренгән кызга, бер Мәүлет кулындагы зур төенчеккә карап сорап куйды:

– Барысын да уйлап эшлисезме, балалар? – Аннары, җавап көтеп тә тормастан, Мәүлет ягына карап, сүзен дәвам итте: – Сине эзлиләр монда, олан, ду китереп эзлиләр. Тиздән сменаң башлана, җәтрәк кылан, җәме!

– Ярый, Шәмси бабай! Рәхмәт, Шәмси бабай! Соңрак сөйләшербез әле. Сөйләшәсе сүз күп җыелды. Рәхмәт!

– Бар, бар, тиз бул, күп сөйләнмә. Синең хәзер сөйләшергә кешең бар. Барысы да әйбәт булыр дип ышанырга гына кала. Аллаһыбыз иман-тәүфыйктан аермасын!

Сания Мәүлетнең кысан гына бүлмәсенә һич аптырамады. Күп мәртәбәләр булган кеше кебек кулындагы әйберләрен бер читкә куйды да өстәлдә торган ике яклы плитә янына килде. Чәйнеккә краннан су агызып, ут төкәндереп җибәрде. Аннары зур, матур күзләре белән Мәүлеткә күтәрелеп карады. Бу яшькелт күзләр аның төшенә кереп йөдәтә иде, менә алар бер тамчы да үзгәрмәгәннәр.

– Чәй эчеп алырга өлгерәсең әле. Миндә тәмле әйберләр дә бар.

– Әлегә үзең генә эч, ял ит. Эшне җайлагач, кереп чыгармын. Чәен дә эчәрбез, сөйләшербез дә.

– Миңа бүлмәңне азрак тәртипкә китерергә ярыйдыр бит?

– Мәшәкатьләнмә. Мин шушы тормышка күнеккән инде. Ну, әгәр кулың кычыта икән инде, үзең кара, яме.

Мәүлет өстен тиз генә алыштырып, йөгереп чыгып китте.

Ул сменасы барышында, гадәттә, ике сәгать саен үз бүлмәсенә кереп, чәй эчеп, бераз ял итеп чыга. Бу юлы аның түземлеге ике сәгатькә дә җитмәде, залның икенче башында хезмәт итүче абзыйга үз белемәләренә күз-колак булырга кушып, өенә ашыкты. Әмма ул үз бүлмәсен танымады. Хәтта ишекне ачкач, ялгыштым бугай дип, ишекне кире ябып чыгып китмәкче булды. Кухня почмагында чынаяклар сөртеп торучы Санияне күргәч кенә, бүлмә эченә үтте.

Өстендәге калын киемнәрен салып ташлап, билбау белән генә буылган җиңелчә халат киеп алган, кыска, әмма куе кара чәчләрен җилбәгәй таратып җибәргән кыз шулкадәр мөлаем күренде, Мәүлет, телсез калып, аңа озак кына төбәлеп карап торды. Саниянең:

– Алай карама, күз тидерәсең бит! – дигән сүзләре генә аны уятып җибәргәндәй булды.

– Сихерче-парига күз тия димени?!

Мәүлетнең шаяртырга тырышып әйткән бу сүзләре Саниянең кәефен җибәрде. Ул хәтта бермәл йөзен чытып, күзләрен йомып торды. Аннары үрсәләнеп, ярсып эндәште:

– Мин сихерче түгел, Мәүлет, пәри дә түгел! Мин – кеше, инсани зат! Мин, мин – мөселман кызы! Син һаман ышанмыйсыңмы? Менә кара... Пәри затларның кендекләре булмый, ә минем бар ул, бар!

Ул арада Сания өрсәң очып китәргә торган юка халатының бавын чишеп җибәрде. Шулвакыт, як-якка ачылып киткән халат чабуларын аралап, актин-ак, сафтин-саф, сылудан-сылу хатын-кыз сыны килеп чыкты. Ир кешеләр кулы тимәгән, тәннең һәр хәрәкәтенә калтыранып җавап бирә торган йомры күкрәкләр, тыгызланып тулышкан зифа ботлар, сөешергә генә яратылган янбашлар, ниһаять, кешеләрне рухи затлардан аерып тора торган кендек уентыгы... Кешеләрнең инсани анадан туганлыгына дәлил булып йөргән серле-сихерле урын.

Баштарак каушап, нишләргә белмичәрәк торган Мәүлет, үтә дә авыр ике-өч адымны үтеп, Сания каршына килде дә идәнгә шуып төшә башлаган халатны үрелеп тотып алды, аннары аны кызга кабат япты, билбавын бәйләп

куйды. Аның бөтен тәненә, йөзенә, хәтта күз төпләренә кайнар тир бәреп чыккан иде. Мәүлет кызны сак кына кочаклап алды, аркасыннан сыйпап-кагып куйды, аннары гына:

– Син шәрә... Син мине ымсындырасың, шаштырасың... Бу – сихерме? – диде.

Сания бу сорауны көтмәгән булып чыкты. Ул үз-үзен кочаклаган килеш кискен генә Мәүлеттән аерылып китте дә тәрәзә янына барып басты.

– Син мине бөтенләй дә белмисең, Мәүлет. Мин – гап-гади авыл кызы. Нәселебездә булган имчелек сәләте белән тудым, анысы хак. Ләкин монда мактанырлык берни дә юк. Барысын да алдан белеп торгач, нинди яшәү инде ул?! Яшәү бит ул – ымсыну, өметләнү, хыяллану. Нindидер максатлар куеп, шуңа ирешергә омтылу. Ә миңа барысы да ачык иде. Шуңа да миңа яшәү кыен булды. Һәм миннән бик күп файдаландылар. Бер генә нәрсә миңа билгесез булган: синең белән очрашу, Мәүлет. Безнең очрашу сихердән өстен. Безнең очрашу – Аллаһы Тәгалә ихтыяры. Синең бөтен кешелек өчен борчылып йөрүең, Иблис ләгыйнгә каршы көрәшкә чыгуың – барлык сихердән дә мөһимрәк, минемчә. Барлык сихердән дә өстен, аңлыйсыңмы шуны?!

Күз яшьләре белән үзенең хәзерге хәлен-халәтен ачып салган кыз Мәүлеткә иң бөек һәм газиз затларның берсе булып күренде. Сания, чыннан да, бу минутларда илаһи дәрәҗәдә ихлас иде. Мәүлет үзе дә сабый бала кебек ихлас-самими иде бу мәлдә. Шуңа да ул:

– Син кем? Үзең хакында сөйлә әле, Сания? – дип сорарга тиеш иде.

Сания ялындырмады. Керфек очларына кунган ике бөртек яшен бармак очлары белән сыпырып алды да ишетелер-ишетелмәс кенә тавыш белән сөйләп китте:

– Сихер шаукымы – әнием ягыннан килә торган сәләт. Урман эчендәге ерак авылда яшәдек без. Бүлнис-фәлән юк. Бер-бер хәл булса, кырык чакрымдагы район үзәгенә барасы. Шуңа да бөтен кеше әнием янына килә иде. Ул имләп, дәвалап җибәрә, хәтта терелтеп булмый торган авыруларны, гарипләрне дә аякка бастыра иде. Тора-бара чит авыллардан, еraklардан килә башладылар. Өйне халык сырып алды. Әтиемә бу ошамый иде. Һәм ул бердәнбер көнне әнием белән икебезне куып чыгарды. Без Казанга киттек. Әнием химия заводына эшкә урнашты. Мин ерак туганыбыз булган бер апа карамагында калдым. Бик холыксыз апа иде ул. Сугарга, кыйнарга да күп сорамый. Ә мин үземчә кыланам: сугарга дип кулын гына күтәрә, шундук уйлап куям: «Күтәрелгән кулың көне буе шулай күтәрелеп йөрсен!» – дим. Шулай йөри иде мәрхүмә. Хәзер дә оялып, кыенсынып куям. Бик тинтерәткәнмен икән үзен. Казанга китүебез үкенечле булды. Нинди генә шаукым көченә ия булсам да, әниемне саклап кала алмадым, ул заводтан агуланып кайтып, ике көн эчендә җан тәслим кылды. Тылсым көчен дә, сихерне дә күп кулланып карадым, әмма әниемнең хәлен җиңеләйтә алмадым. Аннары безне үзенә сыендырган Гөлсем апам мине үз кулына алды, имче итеп тотты, игъланнар таратып, бик зур бизнес оештырды. Ул үзе начар кеше түгел иде, тапкан мал уртак булды. Шулай биш-алты ел узды. Кыенлык белән булса да, мәктәпне тәмамладым. Күңелемне укуга түгел, шаукым сеансларына бирдем. Чынлап та, мин күп кешене аякка

бастырдым, күп кешене табарга булыштым. Ләкин бердәнбер Аллаһы Тәгалә каршыма сине китереп бастырды. Теге сәер төшеңне юраттың. Миңа ул төшне юрарга ярамый иде. Ә мин аны эшләдем, сине күргәч, бөтен тыюлар хакында оныттым. Син миңа ошадың, Мәүлет. Шуңа күрә һич кенә дә үкенмим. Миндә им-том, юрау сәләте беткәч, Гөлсем апа мине куып чыгарды. Шундый чакта син мине килеп таптың. Ә мин киләсеңне белә идем инде. Шаукым сәләте тиз генә бетми бит ул. Вакыты-вакыты белән, көтмәгәндә, әле дә зиһен офыклары шар ачылып китә, ике дөнья чикләре юкка чыга да, бөтен фани, бакый дөньялар күз алдына килеп баса. Йә мәрхүмнәрдән, йә рухлардан, җеннәрдән, иң соңгы чиктә Иблис токымындагы шайтаннардан, гыйфрит затлардан сора, ни кирәген шундук әйтеп бирәләр. Иблис бик өстен йөри ул дөньяда. Шуңа күрә аны җиңү мөмкин хәл түгел. Чөнки Аллаһы Тәгалә аңа, Газазил чагында ук, беркемгә бирмәгән зиһен куәте биргән. Сине шул кызыксындыра иде бит, шулаймы? Әле дә шул борчый сине, беләм...

Мәүлет, сак кына барып, һаман әле тәрәзәгә карап торган Санияне иңеннән кочаклап алды.

– Кадерлем минем, кал минем янда... Әйдә бергә яшибез, бергә гомер кичерәбез. Бергә бәхетле булабыз.

Сания кискен генә Мәүлеткә йөзе белән борылды.

– Юк, Мәүлет, без бәхетле була алмаячакбыз. Безне шаукымлы төш таныштырды, арада сихер булганда, бәхет читтә йөрергә тырыша. Ә бергә яши алабыз, бер-беребезгә таяныч булып, дус булып.

– Юк, Сания, мин моңа гына риза түгел. Минем синең белән яшисем килә, синең белән буласым килә. Ир белән хатын кебек. Мин сине бүтән җибәрмим, менә хәзер күтәреп алам да үземнеке итәм!

– Ал мине, ал, тик үкенмәслек булсаң гына ал, Мәүлет. Газиз кешем минем.

Билбавы бәйләнеп бетмәгән халат Саниянең сылу тәне буйлап идәнгә шуып төшеп китте...

## 18

Мәүлет эшенә соңга калды. Моның өчен аңа нык кына эләкте. Мунча хуҗасы штраф салу, премиясен кисү белән янады. Ләкин Мәүлет боларның берсенә дә артык исе китеп тормады, чөнки ул бәхетле иде. Ул бүген үзенә яңа дөнья ачты. Ул бүген яңадан туды! Аның тормышына нур, яшәешенә мәгънә иңде. Мәүлеткә үзенең шыксыз бүлмәсе дә инде күркәм оҗмах почмагы булып күренде.

Кичен эштән кергәч тә, алар бер-берсеннән аерылыша алмадылар. Кич буе сөешеп туймадылар. Сихри назларының, татлы сүзләренең иге-чиге юк иде. Ахырга кадәр аңлашылып бетмәгән, нindидер сәер дә, серле дә яшәешләреннән соң, шундый ук сәер, серле юллар белән бер-берсен табып, күңелләрен яңа тормышка ымсындырып, онытылып сөешеп яткан бу ике яшь йөрәк, чынлап та, зур бәхеткә тарган иде.

Иртән күзләрен ачканда, Мәүлет янында Сания юк иде. Аның йөрәге жу итеп китте: «Әллә? Әллә төш кенә күрдеме? Төштә генә килдеме теге сихерче кыз? Сихерче-имче бит ул – теләгән вакытта зиһен капкачыңны

ачып, күңелеңне иләсләндереп, тиле яисә дивана итеп китә ала. Нишләп сихерче булсын ул?! Гап-гади авыл кызы, татар кызы. Язмышына авыр сынаулар төшкән, ахырда япа-ялгыз урамда торып калган бәгырь кисәге. Йөрәк түрендә шундый авыр язмыш йөртсә дә, искиткеч матур, татлы сөю мизгелләре бүләк итте ул Мәүлеткә. Төштә генә булса да, алар бергә бәхетле булдылар. Әйе-әйе, алар урамда очраштылар. Мәүлет үзе эзләп тапты. Эскәмиядә утыра иде ул. Кайттылар, аңлаштылар, бергә яшәргә килештеләр. Өн бу, әлбәттә, өн! Төштән дә татлырак өн. Алайса кайда соң ул – аның сөйгәне, хәләле, хатыны?

Кызны төштә күрү-күрмәвен Мәүлет төгәл генә хәл итеп бетерә алмады, ә менә бүген күргән бер төшен аермачык хәтерли Мәүлет. Шушы серле-илаһи тарихның сәбәпчесе булган Хозыр Ильяс бабай килде аңа төнлә. Бик җитди иде ул. Хәтта борчулы иде. Ләкин барыбер мөлаемлеген югалтмаган. Шуңа күрә дә аны шәйләп-күреп алгач та, Мәүлет шомлы-шөбһәле хисләр кичермәде, күптәнге танышын очраткандагы кебек башын кагып исәнләште. Акка төренгән карт та «Яле, бер дога!» дигән кебек ияген кагып куйды да учларын кушырып, алдына күтәрде.

Төштә еш була торган хәл: алар күңелләре белән генә сөйләштеләр. Мәүлет хәтеренә ягылып калган сурәтне төгәл хәтерли. Карт сөйли, әмма аның иреннәре аз гына да кыймылдап карамый. Мәүлет үзе дә авыз ачып сөйләшми. Күңеле белән, дөресрәге, күңелен дөньялык белән бәйләп торган күзләре, карашлары белән сөйләшә.

«Йә, Мәүлет, дөньяга, инсани яшәешкә коткы таратучы Иблис мәлгуньне таба алдыңмы?»

«Таптым да, тапмадым да. Мин аның кайда икәнен, ни өчен килгәнен, ниндирәк эшләр майтарачагын, нинди коткы таратачагын чамалыйм, әмма аның минем алга, үрә катып, үзе килеп басмаячагын да беләм.»

«Кайда ул? Нинди коткы таратачак? Алайса, әйтеп тә бир инде. Бу сөальләргә җавап бирә алган кеше Иблисне тапкан була, аңлыйсыңмы шуны? Димәк, син үз теләгеңә ирешкәнсең, үзеңә йөкләнгән авыр эшне башкарып чыккансың?»

«Юк-юк, мин Иблисне таптым дип әйтә алмыйм. Мин хәзер аның турында күп беләм дип кенә әйтә алам. Ул шундый: бар да, юк та. Ул һәр кешенең йөрәгенә үтеп керә ала, аның һәр тән һәм җан күзәнәгендә яши. Ул, минемчә, бер караганда Аллаһы Тәгаләнең, аларны сынау өчен, рухи чыныктыру өчен, үзләренең кеше булуларын исләренә төшереп тору өчен Җиргә, кешеләргә җибәрелгән ихтыяр көче, имани тәгълиматы. Икенче караганда, күктән сөрелгән бу фәрештә затын һәр кеше үзе тудыра, чынлыкта, һәр кешенең үз иблисе, үз шайтаны. Хөсетлек, нәфес шаукымы, сугыш шаукымы, үч шаукымы, үтереш, каргыш, дошманлык, вәсвәсәчелек, хәтерсезлек, хыянәт кебек яманлыклар иң элек кешенең үзеннән тора. Икенче төрле әйткәндә, Иблиснең үзе юк, коткысы гына бар. Шулай түгелмени?! Мин ник ялгышаммы?»

Карт бу юлы җавап бирмичәрәк торды. Аның борчулы йөзе тагын да караңгыланып киткәндәй булды, йөз җыерчыклары тирәнәйде, күзләрендәге нур тоныкланып калды. Әмма ул үз сүзен, дөресрәге, уен Мәүлеткә әйтеп, белдереп калырга ашыкты:

«Син хаклы, Мәүлет, боларның барысы кешеләргә хас сыйфатлар. Әмма сыйфатлар гына. Бу яман сыйфатлар аңа гомер барышында ягыла. Ихтыяры, иман көче йомшак кеше аларны бик тиз үз йөрәгенә җибәрә һәм гомерлеккә үзенә авырлык ала, зәгыйфь күңел, бозык әхлак белән яши. Иң мөһиме бу түгел, Мәүлет, иң гыйбрәтлесе: һәр кеше фәрештә кебек чиста, саф, гөнаһсыз булып туа. Яшәү барышында ул төрле шаукымнарга, кызыкларга, алдауларга, капкыннарга юлыга, бик тиз авыруга сабыша, имгәнә, зәгыйфьләнә. Туганда ук Аллаһы Тәгаләдән иңгән чисталыкны, сафлыкны саклап калу – кешелекнең төп максаты. Шуңа күрә дә Иблис коткысына кеше илаһи иман көче белән каршы торырга, Аллаһыдан тапшырылган әлеге илаһи максатны гамәлгә ашырырга тиеш».

«Мин дә шулай дим бит».

«Юк, син кешенең язмышын аның үзенә генә тапшырмакчы буласың, ә кеше ул – иң элек Аллаһ колы, аның ихтыяры, чисталыгы, иманы. Шуңа да кешеләр, шулай ук җеннәр дә, «Нас» сүрәсендә әйтелгәнчә, иң элек Аллаһка таянырга тиеш. Менә ул сүрә: «Кул әгузү бираббил нас. Мәликин нас. Илаһин нас. Мин шәррил вәсвасил Ханнас. Әлләзи йүвәсуиеү фи судурин нас. Минәл җәннәти уән нас». Мәгънәсе: «Диде ки: җеннән булсын, инсаннан булсын, инсаннарның күңелләренә шөбһә вә икеләнү салган вәсвәсәче, астыртын эш йөртүчеләр (шайтанның вә кешенең) явызлыгыннан инсаннарның Раббенә, инсаннарның падишасына (тулы хуҗа вә хакименә), инсаннарның илаһына сыенырмын». – Бераз уйланып торганнан соң Хозыр-Ильяска охшаган карт дәвам итте: – Сиңа динебезгә якынаерга кирәк, Мәүлет. Син аны таныгансың, кабул иткәнсең, әмма күңелеңә алып бетермәгәнсең әле. Башкаларга карап кына гыйбадәт кыласың, үткән-сүткәндә генә намаз укыйсың. Алдагы Ураза ае турында да оныттың. Ә аңа бөтен тәнең, җаның белән әзерләнә башларга вакыт иде инде. Дин – инсаннарны тугрылыкка, яхшылыкка юнәлтмәк өчен Аллаһ пәйгамбәрләр арадашчылыгы белән билдергән илаһи коралдыр. Аллаһыбыз тарихның һәр борылышында пәйгамбәрләре аша инсаннарның көндәмлегенә кирәкле кораллар – диннәр иңдергән. Боларның иң соңгысы һәм иң камилләшкәне – безнең динебез Исламдыр. Сиңа зур рухани язмыш билгеләнгән, Мәүлет, син бу турыда бервакытта да онытма. Иблис вәсвәсәсенә, шайтан коткысына каршы көрәшкә чыгуың – шуның бер дәлиле».

«Ни өчен мин? Мин бит бер гади татар малае... Иң гади банщик, кеше пычрагын юып, көн күрүче бер бәндә... Ни өчен мин?»

Әйтергәме, юкмы, дигән кебек карт тагын бераз уйланып, күзләрен йомып торды. Ул әллә шулай илаһи затлар белән, бәлки, Аллаһы Тәгаләнең үзе белән сөйләшәдер? Менә ул күзләрен ачты.

«Мәүлет... Мәүлет хәзрәт... Аллаһның мәрхәмәте һәм рәхмәте иксез-чиксез. Ул синең омтылышларыңны бәяләде һәм синең язмышыңа олы гамәлләр билгеләде. Ни өчен синме? Бу бик гади. Җиргә иңәчәк Иблис коткысы хакында син күргән төш Җир йөзендә яшәгән һәр кешегә җибәрелгән иде. Күпчелек аны күрергә теләмичә сикереп торды, тирә-ягына төкеренде, кемдер куркып, кемдер саташып уянды. Кемдер, күрүгә үк, бу төшне онытты, онытырга тырышты. Кемдер үз эчендә генә яшереп

калдырды, шуның белән күңеленә авырлык алды. Кемдер көлде, әкияткә юрады, зур гөнаһка ия булды. Кемдер дога белән, гыйбадәт йолалары белән чикләнде. Кемдер күңелен Аллаһка сыгындырды. Аллаһтан ярдәм сорады, аның мәрхәмәтенә өмет итте. Тагын кемнәрдер Җиргә, кешелеккә төшәчәк бу авырлыкны Аллаһның үз ихтыярына тапшырды, Аның имани көченә ышанды, инанды. Ләкин синнән башка беркем дә Иблисне эзләргә, аны фаш итәргә чыгып китмәде. Ә бит алар арасында танылган имамнар, хәзрәтләр, дин галимнәре, гомерләрен Исламны алга җибәрүгә багышлаган тәкъва затлар бар иде. Хәзер аңладыңмы инде: ни өчен син?»

«Аңладым. Әмма бу мине, ни өчендер, сөендерми. Күңелдә шом гына артты, җанга тынгысызлык иңде».

«Бу шулай булырга тиеш тә. Дин юлы ул – бертуктаусыз борчылу, күңелеңдә җаваплылык тоеп борчылу. Бу борчылуларда сиңа бары тик Аллаһы Тәгаләбез һәм аның Коръәне генә терәк була ала».

Менә бервакыт карт томан эчендә калды. Аннары тагын аермачык булып күренде, бераздан тагын томанга чорнала башлады.

«Син китәсеңме, әй, Хозыр бабай?»

«Миңа китәргә вакыт җитте, Мәүлет хәзрәт. Без башка бервакытта да очрашмаячакбыз. Син хәзер Аллаһ ихтыярында. Әмма язмышың синең үзеңнеке. Шуңа да синең язмышыңнан китәм. Мин үз бурычымны үтәдем. Йә, хуш. Мин әйткәннәрне онытма. Догада булыйк!»

«Ә Иблис... Иблис белән нишлибез, Хозыр бабай?»

Томан эчендә юылып юкка чыккан карт Мәүлетнең соңгы соравына җавап биреп өлгермәде. Димәк, шулай кирәк. Димәк, Иблис мәсьәләсе хәзер инде мөһим түгел. Әллә аны әһәмияте арткан гынамы? Һәм ул тулысынча Мәүлет язмышына күчкәнме?

Мәүлет, нык кына бер фикергә килә алмыйча, үз уйларында буталып калды, Хозыр-Ильясны йоткан ак томан бер як читеннән таралып, юыла башлады. Карашларны камаштырып торган аклык күз ачып йомганчы юкка чыкты, Мәүлетнең күз алдында үзенең аулак бүлмәсе пәйда булды.

**19**

Таң алдыннан күргән төше хакында уйланып, хәтсез ятты әле Мәүлет. Таң алдыннан күргән төш изге була, диләрме әле? Хозыр-Ильяс, аның әйткәннәре аермачык булып хәтеренә язылып калса да, ул бу хакта тирәнгә кереп уйларга теләмәде. Шуны гына күңеленә беркетеп куйды: димәк, серле гомер юлына, язмышына кереп кенә бара әле ул. Һәм ул – япа-ялгыз. Ичмаса, теге Сания дигән кыз да бер хыялый уйдырма, хикмәтле, татлы төш кенә булып чыкты. Туктале... Каян белә соң әле ул аның исемен? Сания... Сания... Кем син? Кайда син?

– Мин монда, Мәүлет. Синең янда.

Ул арада бүлмәнең ерак почмагында урнашкан «кухня» башында ниндидер хәрәкәт барлыкка килде. Менә бервакыт бүлмәдәге һава дулкынланып киткәндәй булды, шул дулкыннарга ияреп, Мәүлетнең күз алдында биленә алъяпкыч бәйләгән, кулына ашъяулык тоткан таныш кыз – Сания пәйда булды!

– Син? Син чынмыни?!

– Нигә алай дисең, Мәүлет? Мин – инде кичәдән бирле синең хатының. менә, ирем уянуга дип, тәмле ризыклар пешереп йөрим.

– Мин саташтым, Сания. Өнем белән саташтым. Соңгы вакытта мин чын-чынлап саташып яшим, ахры.

– Юк, Мәүлет, син саташмыйсың, синең өнең, тормышың, язмышың шундый. Хикмәтле төш кебек. Ничек диде әле төшеңдәге изге карт? «Язмышың хәзер үзеңнеке», дидеме? Язмышың ачыкланды, кадерлем, хәзер сиңа яшәргә дә яшәргә! Безгә бергә яшәргә. – Сания, якын ук килеп иелде дә түшәгеннән әле һаман торып китә алмый торган Мәүлетне җылы тәненең бөтен күзәнәкләре белән кочып алды, аны, маңгаеннан башлап, йөзен, күзләрен, күкрәкләрен, кулларын үбеп чыкты.

– Син... Син ул карт хакында каян беләсең, Сания?

– Нишләп белмәскә, беләм. Үзең кайчандыр шул изге затның әйткәннәрен белергә теләп, төш юратып киткән идең, оныттыңмыни?!

– Юрату бер хәл. Бүгенге төшемне каян белдең? Бу бик сәер бит.

– Минем кем икәнне онытма инде, кадерлем. Әйттем бит: минем соңгы сеансым калды, һәм ул синең төшең белән бәйле, дидем. Бүген шул сеанс булды. Бу хикмәтле, сихри тарихка нокта куярга кирәк бит инде. Кичә син мине шуның өчен эзләп таптың, шулаймы, кадерлем?

– Шулай, сөеклем. Язмыш юраучым, гомер юлдашым, күкнең җиденче катыннан төшкән фәрештәм минем.

Бу юлы инде Мәүлет Санияне үзе кысып кочып алды һәм янына түшәккә аударды. Ләкин алар бөтен тәннәре, җаннары белән сөешергә өлгерми калдылар, каты гына ишек шакыдылар. Сания елмайды, аннары көлеп үк җибәрде. Мәүлет исә шомланып калды: «Кайсы хәерсезе йөри анда мәхәббәтнең татлы мизгелләреннән мәхрүм итеп?»

Ул арада ишек артында таныш тавыш яңгырады:

– Мәүлет балам, син өйдәме? Бу Шәмси бабаң иде.

Миндияр тавышын да беркем белән бутап булмый:

– Әзи, ач тизрәк, ату ишегеңне бәрермен дә җимерермен. Смотри-ка, бездән башка гына өйләнеп ята. Ә үзе брат булып йөри, пон-ним-маешь!..

Мәүлет белән Сания үзләрен тәртипкә китергән арада әллә нәрсәләр әйтеп бетерде Миндияр. Әмма бу мишәр егетенең шаяртуы шундыйрак, аннан ды якынрак дусты юк икәнен күптән аңлады инде Мәүлет.

Шәмси карт белән Миндияр яңа кәләш белән танышырга, ә Мәүлетне гаилә тормышы башлавы белән котларга кергәннәр. Кочакларын тутырып, күчтәнәчләр, тәм-томнар күтәргәннәр. Үзләре иң элек Саниягә ябырылдылар:

– Кем була инде бу чибәркәй? Исән-сау гынамы, кызым? Син каян, кем баласы? Ничек таныштың безнең җегет белән?

Мәүлет шундук араларына керде:

– Йә инде, Шәмси бабай, бимазалама минем кәләшне. Бу хакта соңрак, яме. Ә хәзер, әйдәгез, чәй өстәле янына.

Миндияр әйтми кала димени инде:

– Ну әзи! Аптыраттың только... Гомердә өйләнмәс буйдак кебек йөри идең. Удивил, брат. Яхшыга булсын. – Аннары Саниягә таба борылып, мишәрчә каты итеп әйтте: – Рәнҗетмя безнең әзине, пажалыста... Ул бик

нечкя күңелле кеше, әмма куәтле кеше. Аның нинди уйлар белән йөргәнен белсәң, аптырап үлярсең, билләһи!..

Өстәл янында беренче сүзне Шәмси карт әйтте:

– Ураза аен никах белән башларга кирәк, балалар. Керүем дә шуңа иде. Менә шаһитым да бар. Чәйгә кадәр, оланнар, Аллаһыбыз кушканча укып, дога-теләкләрне урынына урнаштырып куйыйк.

Барысы да, риза булып, баш кактылар. Кунаклар кай арада гына уңган кәләш куллары белән пөхтә итеп җыеп куелган түшәк читенә урнашты, Мәүлет үзе артсыз урындыкка чүкте.

Кәләш, төенчегеннән шәльяулыкларын алып, чаршау артындагы юыну почмагына, үзен никах йоласына әзерләргә кереп китте. Ябылып бетмәгән чаршау читеннән аның ничек итеп яулык ябынуы, аны ияк астыннан уратып, артка кысып бәйләве, иңенә ябылган шәленең киң ябалдаш-почмаклары белән ачык түшен капларга тырышуы күренеп тора иде. Шунда ук медер-медер килеп, нindider дога-әфсеннәр укуы ишетелеп калды. Бу хәлне Шәмси карт кызның диндарлыгына, тәкъвалыгына юрады.

Кәләш үз почмагыннан шактый озак торып чыкты. Ләкин аны беркем дә ашыктырмады. Хәтта Мәүлет тә булачак хатыны янына кермәде, аны ашыктырып, бимазаламады, чөнки ашыгасы җирләре дә юк иде. Шулай да, бераздан, кияү кеше, Миндиярнең тозсыз мәзәкләреннән аерылып, чаршау буена килде һәм уртада калдырылган аралыкка йөзен куйды. Битенә нindider майлар сөртеп булашучы кәләш аны сизмәде булса кирәк, авыз эченнән генә нindider догамы, әфсенме көйли-көли, көзге каршында утыруында булды. Ә көзгедә! Көзгедә аның чырае түгел иде. Мәүлет, алдында пәйда булган сәер күренештән котылырга теләгәндәй, күзләрен кыскалап та, башын як-якка чайкалап куйды, ләкин хәл үзгәрмәде: аның кеше йөзен сыйдырырлык кына көзгесендә бөтенләй башка сурәт иде! Котсыз бер затның гайрәтне чигәрерлек чырае җанны өшетеп тора бирде. Күбрәк шайтанга, җенгә охшаган бу сурәтнең шардай күзләре күмердәй кызарып, хәтта җемелдәп яна, шәмәхә-көрән төстәге йөзендә очлы, алга кәкрәеп төшкән борыны, шулай ук очлы ияге, өскә таба очлаеп торган зур колаклары, төрле якка тырпайган кара чәчләре, иренсез авызлары чак-чак беленеп тора. Авыз эчендәге озынча, еланныкы кебек очы урталай ярык, ут теледәй, галәмәт озын теле бертуктаусыз кереп-чыгып тора.

Сизде... Кәләш дога көйләвеннән кинәт туктап калды, бер мизгелгә шым калып торды, аннары, берни булмагандай, көзгегә таба үрелеп, кулындагы майларын йөзенә сөртергә кереште.

Мәүлет игътибарын тагын көзгегә юнәлтте. Анда инде теге котсыз зат сурәте урынында Саниянең мөлаем, якты, нурлы йөзе эленеп тора иде. Мәүлет, сак кына кереп, көзге каршына килде, кулына эләгеп кергән өстәл сөлгесе белән көзгене сыйпаштырып куйды.

Ниһаять, кәләшнең теле ачылды:

– Әйе шул, кадерлем, көзгеңне юып, чистартып куясы бар. Никахтан соң иң беренче эш итеп, бүлмәңне... бүлмәбезне тазартып чыгармын, яме?

Нәрсә булганын аңышмыйча, һаман әле телсез калып торган Мәүлеткә, Сания әйткән сүзләрне хуплап, баш кагып куясы гына калды.

Никах йоласы тыныч кына, матур гына узды. Башта Шәмси карт

гаилә тәртипләре хакында кыска гына вәгазь сөйләде, аннары яшьләрдән «Шәһадәт» кәлимәсен әйттерде, догалар укыды, теләкләр теләде. Кияү белән кәләш бер-берсенә ризалык-вәгъдәләр, бүләкләр бирешеп, мәҗлеснең «рәсми» өлешен төгәлләделәр, аннары чәй гаменә керештеләр.

**20**

Шулай яшәп киттеләр. Җир йөзендә тагын бер матур гаилә барлыкка килде. Мәхәббәтле, тату гаилә. Бәхетлеме? Анысын тормыш күрсәтер. Мәүлет шулай уйлый: бәхет ул акрынлап, аз-азлап килә. Бәхеткә дәлил кирәк, әйе, тормыш-яшәештәге һәр мизгел, һәр гамәл белән үз бәхетеңне, һәрхәлдә, бәхеткә лаек булуыңны раслап, дәлилләп торырга кирәк.

Сания әйбәт хатын иде. Мәүлет эшкә кереп киткәндә, үбеп озатып кала, эштән кайтканда елмаеп каршы ала. Тән назын да, җан җылысын да иреннән кызганмый. Беркайда эшләмәсә дә, хәлле иде. Акчага, ризыкка мохтаҗлыклары юк. Нәрсә генә кирәк булса да, Сания шундук барып алып кайта. Мәүлет исә «Каян акча алдың?» дип сорамый. Им-том сеансларында җыйган акчасы бардыр дип фикер йөртә дә шуның белән шикле уйларының очын төенләп куя. Болай җайлы, нигә тирәнгә кереп торырга?..

Тагын бер ачыкланып җитмәгән шик-шөбһә калды калуын. Әйе, Мәүлет эштә чакта Сания дә каядыр барып йөри, һәм ул моны иреннән яшерми дә. «Барып кайтасы җирем бар, югалтма мине», – ди дә Мәүлет артыннан ук чыгып китә. Аның кайда йөргәнен, кайчан кайтканын белми Мәүлет, иң мөһиме, ул кайтуга өй пөхтә итеп җыештырылган, тәмле ашлар пешкән, ятак-түшәккә кадәр җылытып куелган.

Сания белән тормышы тәмам җайланып, көйләнеп җитте. Хатынының башларны әйләндерерлек, ис-акылларны җуярлык назларыннан, тәмле аш-сыеннан, хуш исле җылы түшәгеннән мәңге аерылмаслык булды Мәүлет. Гаилә тормышы гына түгел, эше дә ошый башлады хәтта. Шәмси карт белән дусты Миндияр гына, хатын алгач безне оныттың, дигән кебек үпкәләбрәк йөриләр.

Хәтта Иблис гаме дә онытыла башлады. Дөнья кайгысы да, тирә-яктагы кешеләр һәм янәшәдә генә күренмичә яшәүче җеннәр кайгысы да онытылды. Ләкин... Ләкин никах көнендә юыну бүлмәсендәге көзгедә күргән сурәт хакында һич оныта алмады Мәүлет. Ул инде күптән алыштырды ул хикмәтле көзгене. Бәласеннән баш-аяк дигәндәй, итәк-чатакларын җыйды.

Барыбер тынычлана алмады. Саниягә әйтергәме-юкмы дип, төннәр буе уйланып чыккан чаклары булды. Ләкин җен-пәриләр белән кабат борчыйсы килмәде хәләл җефетен, бик теле кычытса да, дәшми калды. Иренең уйларын сизгән кебек бер көнне Сания бу хакта үзе сүз кузгатты. Аш-су хәстәрләп йөргән вакытында Мәүлет өстәл артына килеп утырган гына иде, хатын тәмле телләнеп:

– Борчылма, кадерлем, ул пычрак көзгене алыштырдык бит инде. Яңасы ялт итеп тора, йөзләребезне чибәр итеп кенә күрсәтә, шулай бит? – диде. Аннары, йөзенә җитди кыяфәт чыгарып, теге көзгегә карап янады: – Ә кемдер, нәрсәдер безнең бәхетебезгә каныга икән инде, мин аны хәзер тәмуг кисәвенә әверелдерәм. Мәңге пыскып ятарлык итәм! – Ул арада Сания Мәүлет алдына пар-буларын бөркеп торган аш китереп куйды. – Яле,

кадерлем, мин пешергән ашны авыз ит. Бөтен борчуларың шундук бетеп китәр. Телеңне йотып җибәрә күрмә тагын!

Мәүлеткә кыен булып китте. Мәхәббәт назларына исереп, ул кем белән яшәгәнен онытып җибәргән икән бит! Телеңне генә түгел, үзең дә сизмәстән җаныңны йотып җибәрерлек икән ләбаса бу дөньялар. Шунда ул тагын бер мәртәбә Сания белән икесе арасындагы серләрнең ачылып бетмәгән булуын исенә төшерде. Әлбәттә инде, бу серләрнең Иблис ләгыйнь тарихы белән бәйләнгәнлеген дә чамаларга була иде. Әнә нәрсә ди бит хәләле: «Тәмуг кисәвенә әвереелдерәм», – ди. Шаярткан булып кыланса да, ай-һай, куркыныч сүзләр әйтте аның хатыны. Каян бу? Элеккеге имче-юраучы тормышыннанмы? «Шаукым дөньясыннан киттем», дигән иде бит. Тагын шул сихер эшенә керешкәнме әллә? Аллам сакласын!

Беркөнне Мәүлет хатыны артыннан барып карарга булды. Эшенә кереп, берәр сәгатькә барып киләсе җире булуын әйтте дә йөгереп, урамга чыкты. Гаҗәеп хәл: хатыны, аны көтеп алган кебек ишек төбендә таптанып тора иде. Арткы ишектән килеп чыккан Мәүлет шунда ук янәшәдәге юкә агачы артына яшеренде. Менә бервакыт Сания кызу-кызу адымнар белән урам буйлап китте. Агачка яшеренеп качып торган Мәүлет аның артыннан кузгалды. Бик сәер күренеш иде бу: шпионнар турындагы кинолардагы кебек, артына карана-карана, кабаланып Сания атлый, аның артыннан урам буендагы агачларга ышыкланып, кискен хәрәкәтләре белән урамдагы халыкны өркетеп, кача-поса Мәүлет бара. Шулай куыша-куыша, алар үзәк урамнарның берсенә җиттеләр. Сания адымнарын акрынайтты, менә ул Үзәк банкның биш катлы мәһабәт бинасы каршында туктап калды, як-ягына каранып алды, аннары, стенага беркетелгән төймәгә басып, нидер әйтте. Ишек дигәннәре уң як стенага шуып кереп китте, ул арада тау кебек банк Санияне үзенә йотты.

Менә кайда икән хикмәт! Акча! Ничек шунда ук башына килмәгән аның?! Беренче чиратта акча янында була Иблис мәлгунь, әлбәттә, акча янында, банкта! Иң элек акчага котыра бит инде кеше дигәннәре. Шайтан коткысы нәкъ шул акча буладыр да инде! Һәм бу хәл ничектер аның Саниясе белән дә бәйләнгән! Язмышның тагын берәр шаяруымы бу?! Әллә?.. Әллә аның Саниясе ире өчен тырышып, җанын куркыныч астына куеп, Мәүлет өстенә йөкләнгән бурычны үтәп, башкарып йөриме? Ничек кенә булса да, бу хәл Мәүлетне шомландыра, куркыта, чөнки мондый хәлләр шаукымлы сихердән башка гына була алмый. Акча сихере – иң хәтәр сихер, дип әйткәлиләр иде, шул дөрестер, ахры.

Мәүлет бераз җилкәсен кашып, таптанып торды да кайтып китәргә уйлады, әмма бу ниятеннән бик тиз баш тартырга туры килде, банк ишегеннән кулына зур гына төргәк тоткан Сания килеп чыкты. Егерме минут эчендә банкта нәрсә генә эшләгәндер, әмма ул үз эшеннән бик канәгать булса кирәк. Йөзенә чыккан самими елмаю бу минутта аның эчке дөньясында ниндидер сөенечле вакыйгалар барганлыгы хакында сөйли иде. Менә ул кулындагы төргәген тагын бер барлап алды да йөгерә-атлый, күрше тыкрыкка кереп китте. Мәүлет, бераз ара калдырып, биек диварларга ышыклана-ышыклана, аның артыннан иярде. Сания озак бармады, ике квартал араны йөгереп диярлек үтте дә йөзгә-биткә шактый искергән,

диварлары кыршылып өлгергән бинаның пыяла ишегенә кереп китте. Аның артыннан ук килеп җиткән Мәүлеткә ишек читендәге язуны укыйсы гына калды: «Ата-аналары ташлаган сабыйлар йорты». Элмә тактаның аскы өлешенә кемдер кулдан гына җәя эченә алып, «3 яшькә кадәр» дип өстәгән.

Шулвакыт эчке яктагы ишек хәрәкәткә килде. Сания дип белеп, Мәүлет башын кискен генә читкә борды. Ләкин аның бу кыланмышын бик тиз күреп-тотып алдылар, ахры. Ишектән килеп чыккан хатын-кыз тавышына ул кабат борылырга мәҗбүр булды.

– Сезгә кем кирәк?

– Юк-юк... Мин болай гына...

– Болай гына безгә беркем дә килми. Дөресен әйтегез: сезгә нәрсә кирәк, әллә берәрсе кирәкме?

– Юк-юк, борчылмагыз. Мин хәзер китәм.

– Алайса, әйтегез: әле генә безгә кергән хатын сезгә кем була?

Мәүлеткә алдап-йолдап торасы калмаган иде инде:

– Минем хатыным була.

– Шулай диегез, нигә яшереп торган буласыз?

– Ә сез каян белдегез аның минем хатын икәнен?

– Бәй... Әле генә үзегез әйттегез ич.

– Сез бит белгән кебек сөйләшәсез. Әүлия кебек...

– Әүлия булырсың да... Бу урында әүлия булмый чараң да юк. Көнгә бишәр бала ташлап калдыралар безнең ишек төбенә. Кемнән, каян икәнне юрап утырган чаклар еш була. Ярый ла исемен, туган көнен язып, берәр кәгазь кисәге калдырган булсалар. Күп очракта анысы да юк. Болары инде Иблис токымындагы затлар, күңелләрендә бер генә кешелек хисе калмаган бәндәләр. Ташлап калдыра торган булгач, ник табалардыр ул сабыйларны. Ана сөте, ана назы күрмичә үсәчәк бит алар. Ярый ла, берәрсе уллыкка яисә кызлыкка алса. Менә сезнең кебек изге затлар килеп чыкса гына инде.

– Безнең кебек? Изге затлар? Без нәрсә эшләгән соң?

– Бәй, сезнең игезәк ике баланы уллыкка-кызлыкка алуыгыз хакында әйтәм ләбаса. Сезгә, бәлки, бу изгелек эшләү кебек тә түгелдер. Безнең өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән ярдәм кебек. – Бермәл уйланып торгач, нindидер кадерле кеше хакында сөйләгән кебек тавышын тагын да йомшартып, сөйләп китте: – Санияне берничә ел беләбез инде. Бер баланың каян, ничек икәнен ачыкларга бардым мин ул имче-юраучы кызга. Аннары икенчесен, өченчесен күтәреп бардым. Бу яклап, ул безгә гел ярдәм итте, балаларның ата-аналарына кадәр төгәл әйтеп бирә иде. Шулай сөйләшеп, аралашып киттек. Берсендә үзе дә безнең янга килеп чыкты. Һәр баланы бөртекләп карады, имләде, сафландырды, кара шаукымнан арындырды. Ә бит монда эләккән балаларның барысында да бар ул зәхмәтле энергетика. Иң мөһиме, им-том гына да түгел әле. Сания безнең төп спонсорыбыз булып китте. Һәр килгәнендә, үз шөгыле белән эшләп тапкан акчасын безгә биреп китә иде. Юк-юк, документлар белән беркетеп, әлбәттә. Шулай килеп йөри башлады фәрештәбез. Балалар да аңа ияләште. Бигрәк тә игезәк ике бала аны үз итте. Шушы ике яшьлек сабыйлар аңа «әни» дип дәште. Әлегә ул көн саен килеп йөри, рәсмиләштереп алып китәргә мөмкинлеге юк. Фатир мәсьәләсен хәл итәсе бар. Аннары балалар бакчасын. Бала алган кеше эшкә

дә урнашырга тиеш. Бу хакта үзегез дә беләсездер. – Шунда ул кул сәгатенә карап алды, кабаланып ишек тоткасына ябышты. – Карагыз әле, дөньямны онытып сөйләнеп торган булам, сез – әйбәт кеше, ахры, әйбәт кеше белән сөйләшкәндә, шулай онытылып китәсең. Ә сез нишләп кермисез соң әле? Әйдәгез, сабыйларны да күреп китәрсез...

– Икенче вакытта инде, яме, апа кеше, бүген без ашыга идек. Монда гына көтеп торам фәрештәмне. Сез шулай дидегезме әле?

– Әйе шул, фәрештә. Аның да иң сафы, чистасы, мәрхәмәтлесе, чын мәгънәсендә тылсым иясе. Йә, ярый, мин киттем, балаларым көтә. Сания хәзер чыга, хәйрия акчасын тапшырып, документларны рәткә китерә дә.

Сабыйлар йортының ишеге ябылгач, Мәүлет бермәл тын алырга да куркып, телсез-аңсыз калып торды. Бераздан соң гына зиһене яшен тизлегендә эшли башлады. Менә сиңа мә! Бу юлы да ялгышты ул, хәтта, шик-шөбһәгә төшеп, тәмам пошамангa калды, үз хатынына әллә нинди ялалар яга язды. Иблис белән бәйләргә маташты. Адәм көлкесе! Баксаң, ул әнә нинди изге эшләр кылып яши! Фәрештәнең дә фәрештәсе икән бит аның хәләле! Хәзер ничек күзенә карарга инде? Китеп тә булмый. Мөгаен, теге апа кеше аңа иренең ишек төбе саклавы хакында кереп әйткәндер.

Мәүлет уйларын уйлап бетерә алмый калды, сабыйлар йортының ишеге киң итеп ачылып китте дә аннан шат елмаеп, Сания килеп чыкты.

– Мәүлет, кадерлем! Нишләп торасың? Мин керерсең дигән идем. Хатыны артыннан күзәтеп, ярты шәһәрне үткән кешенең сабыйлар йортына гына керергә батырлыгы җитәр дип уйлаган идем...

Мәүлеткә бик тә оят иде. Шулай да кайтыр юл Мәүлет яклы иде, Саниянең күзенә туры карамыйча барырга була... Ләкин ярсынып типкән йөрәкне ничек тыярга?.. Мәүлет, ниһаять, карашларын, аяк астыннан алып, Саниянең йөзенә күтәрде.

– Сания, син минем ияреп йөргәнне башта ук белдеңме?

– Ник белмәскә?! Бөтен урам халкын өркетеп йөрдең бит...

– Кичер мине, Сания, ниндидер шайтан коткысына бирелеп алдым мин бүген... Дөрес эшләмәдем...

– Шулай кирәк булгандыр, Мәүлет. Аның каравы, син хәзер минем хакта беләсең...

– Беләм... Барысын да беләм. Шуңа да кыен миңа. Кичер, яме...

– Барысын да белмисең шул, Мәүлет...

– Нигә алай дисең, Сания?

– Нигә акча хакында сорамыйсың? Син бит акчаның Иблис кочагына туры юл икәнен бик яхшы беләсең. Ә мин бүген, банкка кереп, бер кочак акча алып чыктым. «Бу акча – нинди акча?» дип ник сорамыйсың? Акчаның әһәмияте аның нинди изге эшкә тотылуында түгел, ә ничек табылуында, шулай түгелмени?

– Алайса, сорыйм: бу нинди акча, Сания?

– Бу акча – үзем эшләп тапкан акча, кадерлем.

– Шул хакта сөйлә әле, Сания. Чынлап та, мин синең хакта берни дә белмим икән бит.

– Белмәвең дөрес иде. Акча хакында сөйләсәм, алар синең күңелеңә шундук коткы кертерләр иде. Нәфесеңне котыртырлар иде. Акча гаме чын, саф

хисләреңне басып китәр иде, Мәүлет. Шуңа күрә ул хакта мин сөйләмәдем. Бәлки, сөйләмәгән дә булыр идем. Минем арттан күзәтү оештырырга үзеңнең акылың җитте. Мин бит башта ук белеп килдем, әмма тукталмадым, сине дә туктатмадым. Димәк, шулай булырга тиеш дип уйладым. Дөресен генә әйткәндә, мондый шпионлык галәмәте миңа ошап бетми. Күңелеңдә шик бар икән, тот та сора, туры әйткән сүз генә хакыйкатькә алып бара. Ә акчага килгәндә, ул кадәр акча каян, дисеңме? Хәзер сөйлим...

Сания юлда очраган беренче эскәмиягә барып утырды. Аннары Мәүлетне күтеп алды да аның кулбашына башын куеп, күзләрен йомды. Ире аны киң кочагына сыендырды, чигәсеннән үбеп, чәчләреннән сыйпады.

– Беләсеңме, Мәүлет, мин – бик бай кеше. Банктагы акчаның исәбен үзем дә белмим. Минем син белгән апам кайчандыр Казанның «Пороховой» заводында эшләде. Бервакыт шул заводта янгын чыкты, берничә бина шартлап, егермеләп кеше хәрабәләр астында калды. Алар арасында апам да бар иде. Ерак тормый идек, ишеттем дә йөгереп килеп җиттем. Башта якын җибәрмәделәр. Ләкин мин качып кердем. Һәм шундук апамны табып алдым. Ул вакытта ук мин үземнең табигать биргән шаукымга дучар икәнемне белә идем. Мин ул нур баганасын әллә каян күреп килдем. Тирә-якта андый баганалар тагын бар иде. Ләкин бу нур көлтәсе ачыграк, куерак һәм биегрәк иде. Сихердә, магиядә туганнарың белән шулай була, алар ныграк беленә, кан һәм җан туганлыгы үзенекен эшли. Менә шул: бардым да кечкенә кулларым белән кирпеч ватыкларын, тимер-томырларны актара башладым. Кул-бармакларым тырналып, кара канга батты. Елый-елый чокыдым да чокыдым һәм апамның кулына барып чыктым. Мин аның фирүзә ташлы йөзеген шундук танып алдым. Үзен тартып алу мөмкин түгел иде. Мин бар көчемә кычкыра башладым. Мине ишетеп, каскалы кешеләр йөгереп килде. Алар апамны казып чыгардылар. Бәхеткә апам исән иде... Мине сырып алдылар. «Ничек таптың?» – диләр. Мин каушап калдым. Ни әйтергә дә белмим. Нур баганалары хакында әйтсәм, көләчәкләр бит. Шунда бер олы гына абзый кеше килде дә минем алга тезләнеп сорады: «Апаң яткан җир өстендә берәр билге бар идеме?» – ди. Мин әйтәм: «Әйе», – дим. «Нинди тамгалар бар иде, шуларны күрсәтсәң, башкаларны да коткарып булачак, балакаем, әйт: нәрсәләр күрдең кешеләр басылып калган җир өстендә?» – ди. «Якты баганалар бар, әнә алар, бөтен җирдә», – дим. «Яле, яле, күрсәт, кайда?» – дип, мине сырып та алдылар. Миңа күрсәтәсе генә калды. Шулай бик тиз арада әллә күпме кеше таптылар. Мин әйтә торам, шул нур баганалары чыккан урынга казык кагалар, арттан килүче төркемнәр казык урыннарын казый да башлыйлар...

– Ә акча, шулкадәр акча ничек килеп керде соң кулыңа? Казый-казый акча да тапмагансыңдыр бит ул дары базларында? – Мәүлет, түземсезләнеп, бу тарихка сәбәпче булган серне ачарга теләп интизар булды.

– Әле әйтмәдеммени? Шулай кешеләрне табып, аларның гомерләрен саклап калган өчен завод җитәкчеләре саклык кассасына минем исемгә бик күп акча салганнар. Аның счётын апага биргәннәр. Мин балигъ булгач кына алып була торган счёт иде ул. Апам миңа шуны әйтмичәрәк йөргән. Әйе, үзе дә ала алмаган, миңа да әйтмәгән. Шул заманда завод җитәкчелегендә булган бер кеше очрап әйтте. Апа белән ике арада килеп

чыккан киеренкелекнең тагын бер сәбәбе шул. Аның бу акчаны бөтенләе белән аласы килгән, ә мин аңа бер өлешен генә тәкъдим иттем. Чөнки мин инде ятим сабыйлар йортына ярдәм итә башлаган идем. Ә ул миңа үпкәләде. «Газиз апаңнан өзеп, ташландык балаларга тотасың акчаңны», – дип, минем үземне рәнҗетә башлады.

– Син бит аны үлемнән алып калгансың. Ул хакта онытканмыни?

– Белмим, бәлки, оныткандыр да. Без ул вакыйга хакында бервакытта да сөйләшмәдек.

Кайтырга кузгалдылар. Бераз сөйләшми бардылар. Ләкин икесе дә белә иде: бер мәсьәләгә ачыклык кертәсе бар.

Мәүлет үзалдына сөйләнгән кебек кенә әйтеп куйды:

– Сабыйларыбызның исемнәрен булса да әйт инде.

Сания ялт итеп, Мәүлеткә күтәрелеп карады. «Сабыйларыбыз» диде бит. Димәк, икесенеке дә. Димәк, алар бер гаилә. Шундый ук тыныч тавыш белән җавап бирде ул:

– Гайшә, Мөхәммәд...

Мәүлет пәйгамбәрләр тарихын авылдан ук белә иде. Мөхәммәд пәйгамбәр белән аның беренче хатыны Гайшә турында дәү әнисеннән күп тапкырлар ишеткәне булды.

– Изге исемнәр... Бәхетләре булсын.

– Булыр, нишләп булмасын. Ләкин бәхет ул – бергәлек, бергә яшәү, бергә гомер итү, борчуын да, шатлыгын да бергә күрү, Мәүлет.

– Мин дә шулай дим бит: бергә булырбыз, бәхетле булырбыз, дим.

– Рәхмәт, Мәүлет.

– Үзеңә рәхмәт, Сания. Һич көтмәгәндә, уйламаганда, ике нарасый бүләк иттең.

Алар, карт юкәнең куе ябалдашлары астында туктап, бер-берсенә сыенышып тордылар, тыйнак кына үбешеп алдылар. Аннары ары киттеләр.

Һәрберсенең үз уе, үз гаме иде. Мәүлет үзе бер көндә бер гомер яшәгән кебек булды. Шушы берничә сәгать эчендә утка да керде, суга да төште. Бәхетсез дә, бәхетле дә булып өлгерде. Шул арада Иблис шаукымы да үртәп алды, фәрештәләрнең канат җиле дә назлап куйды. Ә күпме яңалык! Һәрберсе – язмышка тиң! Бүген кич ныклап сөйләшәсе темаларын да билгеләп куйды Мәүлет: балаларны гаиләгә алу, аларны балалар бакчасына урнаштыру, Саниягә эш табу. Бәлки, бу яклап таныш депутат абзыйлар булышыр? Юпитер Марсович, мәсәлән. Мәүлет кинәт тел шартлатып куйды. Карале, ул таныш-белешлек, кода-кодагыйлык белән шөгыльләнеп ята түгелме соң? Шайтан коткыларының берсе шул бит! Адәм көлкесе!

**21**

Соңгы яңалыклардан соң, аларның тормышлары көрәеп, рухи яктан баеп китте. Сөйләшергә сүз күбәйде, уйлаган уйлар матуррак, мәгънәлерәк була барды. Алар инде зуррак фатир турында, яңа эш урыннары хакында килешеп куйдылар. Балалар янына да бергә йөри башладылар. Мәүлет әлегә аларны кулына алырга курка. Сулыш җиленә дә җилфердәп куя торган аксыл чәчләреннән сыйпап, маңгайларыннан үбеп ала да сабыйлар кулына яңа уенчык тоттыра.

Бер көнне кибеттән яңа уенчык алып кайтып килгәндә, юлында Миндияр очрады. Мәчеттән кайтып килә икән. Уразага кергәч, өйлә намазын да мәчеткә кереп укый башлаган. Мөмкинлек булса, икенде, ахшамнарын да шунда башкара икән. Кыскасы «мәчет карты»на әйләнеп бара бу мишәр егете. Кызы да бар икән. Тумышы белән мари ягыннан, ди, Гөлсем исемле бу татар кызы.

– Димәк, барысы да әйбәт? – дип, соңгы сорау белән гомумиләштереп куйды Мәүлет.

– Синеке белән анологично, – диде тегесе, телен заманча кыландырып. – Әнә бит кай арада өйләнешеп, балалар табып куйгансыз.

– Ник кермисең? Элеккечә бер сөйләшеп утырыр идек, ә?

– Утырырбыз әле, Алла теләсә.

– Ничектер, килергә теләмәгән кеше кебек кенә сөйләшәсең, Миндияр. Сүзләреңдә мишәр кайнарлыгы юк, понимаешь.

– Ну... Алайса, әйтергә туры килә инде. Үзең теләдең, әзи... Дөресен генә әйткәндә, куркам мин синең хатыныңнан. Ул караса, йөрәгем жу итеп китә. Җен утыра аның эчендә, әллә шайтанмы? Ачуланма, синең кәләшең – гади кеше түгел. Минем әби дә имче иде. Менә ул әйтә иде: «Кешенең эче белән тышы бер түгел. Артык әйбәт булса, җүнлегә түгел», – дип...

– Туктале, Миндияр, уратып сөйләшкән кебек сөйләшәсең. Нидер әйтеп бетермисеңме?

– Ну... Бөтен серне алып бетерәсең, болай булгач. Әйтсәм әйтим инде: беркөн урамда очраттык хатыныңны. Минем кыз мари ягыннан бит. Ә алар, марилар, сихернең нәрсә икәнен беләләр. Хатын да күп белә бу турыда. Менә шул: минем булачак хатын әйтә: «Сихерче килә, – ди. – Узып киткәндә, күзенә карама – җаныңны ияртеп китәчәк», – ди.

– Булды, җитте! Бүтән дәшмә! Күңелгә шик кертмә, Миндияр! Матур итеп яшәп кенә киттек. Шуның өстенә, бернинди сихерче дә түгел, изге җанлы бер кеше ул, аның кылган изгелекләрен без синең белән гомер буе да эшләп бетерә алмаячакбыз!

– Әйттем исә кайттым! Бөтен сүземне кире алам, дустым. Ну... кереп йөри дә алмыйм... алмыйбыз, үпкәләмә, яме?!

Шулай аерылыштылар. Әмма Мәүлетнең күңеленә шөбһә корты кереп өлгергән иде инде. Шунда ук көзгедәге җен сурәте исенә төште. Тагын әллә нәрсәләр... Кыскасы, өенә кайтып кергәндә, йөзеннән – якты нур, күңеленнән киләчәк белән бәйле татлы хис-тойгылар качкан иде инде. Сания аның халәтен шундук сизде һәм беренче булып дәште:

– Йә, сора, Мәүлет, шигең булса, шундук сора, күңелеңдә асрама шикле сорауларыңны. Йөрәгеңне бетермә... Йә?..

Мәүлет сорады, Саниянең йөзенә бәреп сорады:

– Син кем, Сания? Җенме, кешеме? Әллә Иблиснең үземе?

– Мин сиңа әйткән рас килә, Мәүлет. Өйләнешер алдыннан мин әйткән идем, хәтерлисеңме: шаукымлы кеше белән тормыш, ай-һай, авыр булачак, дигән идем. Ә миндә шаукым бар, син аны үзең дә беләсең. Мин аны бастым, бик еракка яшереп, бастырып куйдым, әмма ул бар бит, бар! Ләкин мин Иблис түгел, хәтта аның шайтаны да түгел! Ышан, Мәүлет, син дә ышанмасаң, миңа кем ышана инде?! – Бераз тын калып торгач, Сания иң

мөһим сүзен әйтергә булды, ахры, һәр сүзенә аерым басым ясап, сөйләп китте: – Миңа бик көчле шайтан җибәрделәр, сиңа минем аша чыкмакчы булалар. Соңгы вакытта гел шул хакта уйлыйм. Әмма кем икәнен белмим, дөресен генә әйткәндә, белергә дә теләмим. Син миңа караганда да күбрәк беләсең бу хакта. Кем шик кертте күңелеңә, шуннан сора. Миндиярмы? Аның янында кем хәзер? Сары чәчле, сипкелле кызмы? Мин шул кызны күрәм, һәм ул кыз явыз ният белән йөри.

– Әгәр син әйткәннәр дөрес икән, мин аларны болай гына калдырмыйм! – Мәүлет ярсынып йөренә башлады. – Миндиярын әйтер идем инде. Мари ягыннан, имеш, сихер белә торган кыз, имеш. Шул пәри кызына гашыйк булган булып, минем җанга ук үрмәләмәкчеләр!

– Монда дустыңның бер гаебе дә юк. Ул үзе, шайтан шаукымына эләгеп, аң-зиһененнән язып бара. Үзен коткарырга кирәк аның!

– Барыбер мин аңа ачулы! Ияртеп йөрмәсен әтрәк-әләм җәһәннәм кисәвен! Күрим генә әле! Ни әйтергә белермен.

– Тукта, кадерлем, кызма. Алдагы ай болай да тыныч узачак. Ураза аена керәбез, оныттыңмыни? Уразада бөтен шайтан халкы, богауланып, ерак атауга ташланачак. Аллаһы Тәгалә ихтыяры шундый. Безнең рухыбызны ныгытырга, итәк-чабуларыбызны җыярга бер ай вакытыбыз бар. Укыган догаларыбыз, тоткан уразаларыбыз, кылган гамәлләребез файдага китсен, аларның әҗер-саваплары зур булсын. Гамәлләрнең иң олысы, изгесе – ятим балаларны уллыкка-кызлыкка алу. Без бу айда шуны эшләячәкбез. Килешәсеңме? Әлегә үзебезнең бүлмәдә яшәрбез, көзгә яңа фатирга күчәрбез.

– Аллаһ боерса диген, Сания.

– Аллаһ боерса. Аллаһ теләсә.

Ләкин Мәүлет үзе һаман тынычлана алмады, ахры. Иблис гаменнән котыла алмады.

– Сания.

– Әү, кадерлем.

– Иблисне фашлауның көне-сәгате иртәгә бит. Нишлибез?

– Иртәгә Ураза гаетенә керәбез, иртә торасыңны онытма.

– Син мине ишетмәдең.

– Ишеттем, Мәүлет. Аллаһы Тәгаләнең мөмкинлекләре киң. Әнә ул нишләде: Иблис тантана итәргә тиешле көнгә Ураза гаетен туры китерде һәм аны бер айга булса да, богау салып, җир читендәге дәрьяның атавына илтеп ташлады. Шикләнмә дә: ул аннан көчсезләнеп чыгачак. Әлбәттә, аның көче кайчан да булса кайтачак, әмма ул Аллаһы Тәгаләгә баш бирмәгән Газазил булмаячак инде, йолкыш бер мәлгунь кыяфәтендә генә кайтачак. Аңарчы без дә каршы торырлык тән көче һәм җан көче, ихтыяр көче туплаячакбыз, шулаймы? Безгә ул көчне әҗер-савапларыбыз бирәчәк. Әйт әле: ни өчен Иблискә каршы тору өчен нәкъ менә сине сайлап алган Раббыбыз? Саваплар күп җыйгансың син. Синдәге әҗер-савапларны кайбер кеше гомер буе яшәп тә җыя алмыйдыр. Ничә еллар буе, ел саен, ай саен, көн саен кешеләрнең тәнен юу, җанын сафлау белән шөгыльләнгәнсең. Син – дөньяны, кешелекне чистарту белән шөгыльләнүче изге затларның берсе. Аллаһы Тәгалә һәм аның иярченнәре алдында синең йөзең чиста,

тәнең чиста, бәгырең, йөрәгең чиста. Аллаһы каршында син шулай гына карала аласың, аңладыңмы?

Аңлады Мәүлет, ник аңламаска?! Бу «чистартучы», «сафландыручы» («чистильщик») дигән кеше – әүлияләргә тиң кеше, бу хакта Шәмси карт Мәүлеткә сөйләгән вәгазьләрендә дә еш сөйли. Чөнки кешенең гомерен нәфес гаменнән башка күзаллау кыен, ә нәфес белән проблема килеп чыга икән инде, димәк, шайтанның мәйданга чыгуын көт тә тор! Рухи чисталыкка кадәр тән чисталыгы кирәк, икенче төрле әйткәндә, намазга кадәр, догага кадәр тәһарәт алу зарур.

Саниянең сүзе бетмәгән икән әле.

– Иблис белә синең ниятеңне, үз өстеңә алган бурыч хакында, хаклыкта, сиңа йөкләнгән йөкләмә хакында да белә. Ләкин синең белән шаукымлы уен уйнау кызык түгел аңа. Син – иң гади кеше баласы. Ә менә сине яклаучылар, синең ярдәмчеләрең аны ныграк кызыксындыра, ахры. Миндиярның бүгенге хәлен беләсең. Шәмси картның авырып торуы да шуннан. Мин үзем дә Иблиснең коткы-шаукымын бөтен җаным-тәнем белән тоеп торам. Чөнки мин дә синең ярдәмчең, ярдәмчең генә түгел, хәләлең. Дөресен генә әйткәндә, минем бөтен рухи көчем аның әнә шул шаукымлы тәэсиренә, сихер-зәхмәтенә каршы торырга сарыф ителә.

– Сөйләле шул хакта: ничек каршы торасың? Гомумән, күргәнең бармы аны? Нинди ул?

– Аны синең дә күргәнең бар.

– Кайчан? Кайда?

– Иң элек төшеңдә, аннары юлда, аннары көзгедә.

– Көзгедә? Кит аннан!

Шунда Мәүлетнең күз алдына көзге каршында чәчен тарап утырган Сания килде, ә янәшәдәге көзгедән яфраклары очлаеп киткән колагын тырпайтып, озын, кылыч борынлы, эчкә баткан төртке күзле, тузган чәчле, таркау сакал-мыеклы, җен дисәң, җен түгел, кеше дисәң, кеше түгел бер шыксыз, котсыз, йөнтәс зат чагылып киткәндәй булды.

– Сания, ә, Сания... Син ул җен шайтаны хакында белә идеңмени?! Күземә Иблис үзе күрендеме әллә дип, җан чыкты ул вакытта. Синең хакта әллә нәрсәләр уйлап бетердем.

– Исәрем минем! Боларны күңелеңә авыр итеп алма. Оныт. Ул галәмәтләр күбрәк минем өчен. Күбрәк мине бимазалап йөриләр. Төрлечә үртиләр, юлдан яздырырга тырышалар. Ләкин көчләре җитми. Ә менә Миндияр аша якынаерга тырышулары шомландыра. Бик каты зәхмәткә ия кызыйны җибәргәннәр. Әлегә ул берни дә эшли алмый. Аның сихереннән догалар яклый, ураза-намаз гыйбадәтләре саклый. Чынлыкта, Аллаһы Тәгалә һәм Аңа барып ирешкән әҗер-савапларыбыз пәрдәсе каплап тора безне сихер-зәхмәттән.

*(Ахыры киләсе санда.)*

# ШИГЪРИЯТ РӘСҮЛЕ

*Дагстанның халык шагыйре Рәсүл Гамзатовның тууына 100 ел*



*Фото www.rasulgamzatov.ru сайтыннан алынды.*

Сибгат Хәкимнең бер шигыре бар.

*Рәсүлнең артында таулар,*
*Биек-биек таулар ич...*
*Таяныч кирәк язганда,*
*Минем кайда таяныч? –*

ди ул анда. Миңа соңгы дистә елда күп мәртәбәләр Кавказда, аның да безнең телгә авыштырганда, «Тау иле» дигән мәгънәне белдергән Дагстан Республикасында булырга туры килде. Язучылар берлегендә эшләгәндә, ел саен диярлек 8 сентябрьдә Рәсүл Гамзатовның туган көне уңаеннан уздырыла торган «Ак торналар» фестивалендә катнаша идем. Бу фестивальгә әле моннан утыз биш ел элек Рәсүл Гамзатов үзе нигез салган.

Һәр барган саен Дагстанда әдәбиятка мөнәсәбәтне күреп, исем китеп кайта идем. Һәр авылда бер милләт яшәп яткан, авар, кумык, ногай, лезгин, лак, даргин, табасаран, төп милләтләр булып саналган бу республиканың Язучылар берлегендә шушы милләтләр буенча секцияләр эшли. Махачкалада Россиядә генә түгел, бөтен дөньяда бердәнбердер – Поэзия театры ачылган. Дагстан Язучылар берлеге рәисе Мөхәммәт Әхмәтовның алтмыш яшьлек юбилей кичәсен республиканың Башлыгы Рамазан Абдулатыйпов үзе алып барды! Кызганыч, Мөхәммәткә быелгы форумны күрергә язмады, былтыр ул озакка сузылган каты авырудан соң фани дөнья белән хушлашты. Быелгы фестиваль тагын да колачлырак итеп, Россия күләмендә, ил һәм хөкүмәт башлыклары катнашында үткәреләчәк, диләр. Чөнки ул Рәсүл Гамзатовның тууына 100 ел тулуга багышланачак.

Рәсүл Гамзатов – Советлар Союзында милли республикаларда әдәби хәрәкәтне әйдәп баручы зур язучылар Мостай Кәрим, Кайсын Кулиев, Алим Кешоков, Давыт Көгелтинов, Рәсүл Рза, Олжас Сөләйманов, Чыңгыз Айтматовлар буынының иң күренекле вәкиле. Аның «Торналар» шигыренә композитор Ян Френкель иҗат иткән җыр менә 60 ел инде Бөек Ватан сугышында һәлак булган каһарманнар рухына халык күңелен тетрәндергән музыкаль һәйкәл булып тора.

Моннан ун ел элек Казанда Рәсүл Гамзатовның 90 еллык юбилее уңаеннан татар шагыйрьләре тәрҗемәсендә аның шигырьләр китабы басылып чыккан иде. 100 еллык юбилее уңаеннан журналыбызда шагыйрьнең бер бәйләм шигырьләрен тәкъдим итәргә булдык.

**Рафис КОРБАН**

## Рәсүл Гамзатов

# СИН ЙОЛДЫЗ БУЛЫП БАЛКЫЙСЫҢ, ВАТАН!

### Ватан турында

**1**

Аңламый идем, хәзер аңладым –
Инде шәрехләү һич кирәк түгел, –
Көзге кәрваннар очканда күктә,
Ник моңсу җанга,
Ник елый күңел?

Мәгънәсез булып тоела иде
Җиргә коелган яфрак моңнары.
Сагына алар үскән ботагын –
Аңламый идем элек шуларны.

Аңламый идем, аңладым бары
Чаларгач чәчем – тау кыясыннан
Ычкынган ташның нигә дип шулай
Ыңгырашуын, тере җан сыман.

Чит-ят җирләргә ташласа илтеп
Язмыш, аерып туган иленнән,
Шатлык – ямансу,
Җырлар да моңлы,
Сөю – гел сагыш икән, мин беләм.
И газиз Ватан...

**2**

Моңлы азаннарың белән
Исемеңне данлыйм.
Сине азан сүзләреннән,
Авазыннан таныйм.

Әгәр дә бер төн йә таңда
Җырым калса тынып,
Димәк, дөнья куйганмын, җир
Минсез калган торып.

Мин бер бөркет кебек язда
Күкләр гизеп очам,
Иңемдәге ул канатлар –
Синең исем, ышан.

Әгәр беркөн каерылса
Канатларым җилдә,
Эзләмә дә, инде исән
Булмам мин бу җирдә.

Мин – бер хәнҗәр. Мин сугышта
Булдым ярсу, хәтәр.
Калкан булам синең өчен,
Кирәк булса әгәр.

Кирәк чакта, сине яклап,
Басалмасам сафка,
Син исәннәр арасында
Мин юк диеп сана.

Мин чит җирләр буйлап атлыйм,
Ят сүзләр ишетәм.
Түземсезлек белән безнең
Очрашуны көтәм.

Әгәр инде күзләреңнең
Качкан булса нуры,
Бел син, минем гомернең дә
Тынган, димәк, җыры.

**3**

Ни дип җырлана тәгәрмәчләрнең
Келтер җырында,
Кошлар чыр-чуы, каен шавында?
Ватан, бары тик Ватан турында.

Нинди моңнар бар күкләрне иңләп
Очкан болытлар,
Китеп баручы кораб җырында?
Ватан, бары тик Ватан турында.

Тирән хәсрәт, авыр кайгылар
Килсә ишелеп, кем безне яклар?
Кем сузар кулын?
Ватан. Ул бары тик газиз Ватан.

Шатлык килгәндә,
Күңел көлгәндә,
Нинди тойгылар, хис була җанда?
Ватан, бары тик Ватан турында!

Кем шатлыгын да,
Хәсрәт-моңын да
Бәйли Туган ил, Ватаны белән,
Кара төндә дә
Син йолдыз булып
Балкыйсың шуңа,
И газиз Ватан!..

## Торналар

Тоела миңа кайчак – канлы сугыш
Кырларыннан кайтмый калганнар,
Әйтерсең лә, ак торналар булып,
Һаваларга юллар алганнар.
Шул чаклардан бирле тавыш биреп,
Алар күктән безгә дәшәләр.
Шуңамы соң, салып сагышларга,
Шул солдатлар искә төшәләр.
Торналарның күрәм кичке күктә
Томан ярып очкан сафларын,
Хәтерләтеп гүя солдатларның
Кырлар буйлап үткән чакларын.

Кемнәрнеңдер таныш исемнәре
Ишетелә кебек кошлардан.
Шуңамы соң минем авар телем
Торна тавышына охшаган?
Канатлары талган төркем оча
Томан ярып кичке һавада.
Сафларында бер буш ара калган,
Минем урындыр шул арада.
Бер көн килер, торна төркемендә
Зәңгәр күктә мин дә очармын,
Кош тавышы белән, җирдә калган
Дусларымның исемен атармын.

## Теләкләр

Мөмкин түгел бер кайгысыз яшәү,
Ә мин телим сезгә, дусларым:
Бәхет килсен сезгә оныттырып
Кайгыларның җирдә булганын.

Шатлык җыры гына яңгырасын,
Шәраб белән тулсын касәләр.
Һәркем үзенә дип кабул итсен,
Берегезгә теләк әйтсәләр.

Дуслар берсен-берсе котлап әйткән
Теләктән дә көчле ни бар соң?
Чын күңелдән әйтелгән бу теләк
Мең бәладән сезне коткарсын.

Мин телимен, дуслар, тагын шуны:
Балалар гел көлеп торсыннар.
Кызларыбыз бар да чибәр булсын,
Ә егетләр зирәк булсыннар.

Егет – кызны, кыз егетне әгәр
Үпкәләтсә, гафу сорасын.
Үпкәләшү – ярату билгесе,
Белсен үлеп гашыйк буласын.

* * *

Ике генә сәбәп була ала
Ир-егетне дәшкән изге яуга.
Беренчесе: Туган илен яклап, –
Кермәс өчен дошман чиктән атлап.

Икенчесе – ата-бабалардан
Ир-егеткә бурыч булып калган:
Хәтәр астында хет калсаң кал син,
Хатын-кызны яклап, хәнҗәр ал син!

Җырлыйм дисә дә, җыр чын йөрәктән,
Ике сәбәп күңелен тибрәткән:
Берсе аның – Туган илне сөю.
Икенчесе – хатын-кыз дип көю!

* * *

Таң атканда уяндым мин –
Күктә юк һичбер болыт.
Кичә генә яңгыр һәм җил
Ишелде күз яшь булып.


Кем соң анда биек менеп,
Ул болытларны күктән,
Күз ачып йомган арада,
Барын сибереп түккән?

* * *

Мин, агачлар шау чәчәктә, дисәм,
Аларны бит тик кар баскан икән.
Син дә мине яратасың, дисәм,
Нихәл итим, ялгышканмын, иркәм.

Юлга чыксам, анда яңгыр коя.
Чикмәнем дә өйдә онытылган.
Син дә, бәгърем, салкын хәтта боздан.
Әйтче, нишлим, җылыт мине, кызган.

*Русчадан* **Рафис КОРБАН** *тәрҗемәләре.*



Кәрим
Кара

# ЧТД

хикәя

Укытучылар тормышын мин якыннан беләм. Ни әйтсәң дә, дистә еллар мәктәп коридорлары тузанын сулаганмын, укучылар арасында бөкрем чыккан. Мин үземнең укытучым турында сөйләргә җыенган идем. Безнең заманнарда укытучы иң зур хөрмәткә лаек кеше иде. Әти-әниләр киләчәктәге яхшы тормыш белән кызыксындырырга теләсәләр, укы, тырыш, укытучы булырсың, дип тукыдылар безгә. Шәхсән, минем үземнең планнар икенчерәк иде. Космонавт булып, күк йөзен айкап төшәргә иде исәп. Ул чакларда малайлар космос белән җенләнә иде. Гагарин, Титов, Комаров, Беляев фотоларын түш кесәгә салып йөри идек. Ләкин бөтен теләк тә тормышка ашмый инде ул, әнинең юраганы юш килде, дәфтәр тикшереп үтте гомер. Укытучылар тормышы кызыгырлык иде шул. Авылда иң матур киенгәннәр – алар, билле пәлтәләр, әллә ниткән башлыклар – аларда, аякларында – күн бутыйлар. Ә авыл халкы барысы бертигез: сырган фуфайка, галушлы киез итек. Чусинкә диләр иде аны безнең якларда. Соңыннан гына белдем, анысы «чесонка» дигән сүз булган икән. Укытучыларның капка төпләренә бушлайга утын китереп аударалар, хәтта эшләгән эшләренә акча түлиләр! Акча безнең әти-әниләрдә юк. Көн буе эшләсәләр, бригадир наряд кәгазенә бер таяк тарта, анысы труддин дип атала. Шуның белән вәссәлам. Без, балалар, укытучылар белән гел исәнләшеп йөрдек, туры карарга да курыктык, дәрестән тыш нидер сорасалар, кирпечтәй кызарып чыга торган идек. Әгәр сыйныф җитәкчесе сезнең өйгә киләм дисә, гаиләдә гарасат куба иде. Әни, мескенкәй, утлы табага баскандай кылана иде. «Тәртибең начардыр, нәрсә майтардың анда? Укуыңның рәте юктыр, бер утырып дәрес карамыйсың, китапларыңны иртән генә алыштырып аласың бит, барып чыккан эт ялкавы», – дип, пыр туздыра инде. Апаларны эшкә җигеп, өйдә тәртип урнаштырырга тотына. Пәрдәләр алып юыла, синькага маныла, идән-түшәмнәр ялт итеп юып алына, бар әйберләр пөхтәләп, тартмаларга тутырыла, күрше Сәрвәр

әбидән ак он алып, коймак коела. Дәрестән соң сугылган класс җитәкчесе озак тормый. Сандык өстенә утырып, соңгы араларда минем укуым йомшаганын хәбәр итә. «Болай башы эшли үзенең, бераз ялкаурак кына», – дип нәтиҗә ясап куя. Әни минем укуымны күзәтеп барырга вәгъдәләр бирә. Кызарып чыккан йөзен алъяпкычы белән сөрткәләп, кунакны чәй эчәргә кыстый. Чәй эчүдән баш тарта Фазыла апа, минем класс җитәкчесе. Баланы күзәтүне сорап, хушлашып чыгып китә. Без, бер табын булып, майда йөзгән коймаклар белән тәмләп чәй эчәбез. Әни минут саен миңа таба усал карап, бармак яный:

– Иртәгәдән, кайтуга дәрескә утырасың, бетте урам киләпләүләр, – дип, каты тотына. Укытучыны искә алып, аның турыда әллә күпме мактау сүзләре әйтәләр апалар белән. Ул безгә чит планетадан килгән зат төслерәк күренә. Әнинең тәрбиясе озакка бармый. Ике-өч көннән соң укытучының кисәтүләре онытыла. Мин тагын мәктәптән кайтуга сумканы мич арасына олактырам да, өстәлдә нәрсә калдырганнар, барысын хап-хоп ашап, урамга чыгып чабам.

Монысы үзем турында. Төрле катыбашлар бар иде, кәнишне, укучылар арасында да, укытучылар арасында да. Минем артык яраткан укытучым булмады, ахрысы, фәннәрне дә аерып карамадым, «өчле» яисә «дүртле» эләктеме, шул җиткән. Иптәшеңнең киң аркасы артына качып, берәр атна хәл җыярга була. Йә китаптагы рәсемнәргә сакал-мыеклар өстәп ясарга, чиста битләренә иптәшеңә запискалар язарга. «Бүген кинога барасыңмы? Басмачлар турында», дигән төслерәк.

Ә гомерем буена мине озатып йөргән укытучым Галимҗан абый белән очрашу болайрак булды. Математикадан укыта иде ул. Без аны залда гына очратабыз. Мәктәп зур, меңнән артык бала укый, укытучылар саны – җитмешләп. Безне математикадан Мирсәет абый укытты. Нәрсә өйрәткәндер, валлаһи, исемдә калмаган. Шул тапкырлау таблицасын гына су урынына эчәм, анысына рәхмәтлемен. Контроль эш була калса, без аның өстәленә яңа гәзит җәеп куя торган идек. Тактага мисалларны язгач, ул шул гәзиткә мөкиббән китә. Без, кыштыр-кыштыр китап ачкалап, җаваплар күчерәбез. Кыңгырау шалтырауга укытучыбыз да гәзитнең азагына чыга, без дә эшләрне тәмамлыйбыз.

Бердәнбер көнне, безнең бәхеткә, укытучыбыз чирләп килми калды. Завуч алыштырып өлгермәгәндер инде, әллә белми дә калгандыр. Ду килеп тәртип боза идек без, тавышыбыз коридорда яңгырап торгандыр. Кемдер куышып уйный, кемдер чүпрәк бәргәли, малайлар көрәшеп, көч сынашалар, кызлар яңа җыр өйрәнә. Ахырзаман инде, кем әйтмешли. Күпмедер вакыттан соң ишек ачылып китте, анда Галимҗан абый күренде. Без тынып калдык.

– Бераз уйнап алдыгызмы инде? – диде ул, хәйләкәр елмаеп. – Әйдәгез хәзер бер мәсьәлә чишеп карыйк әле. Бер бабай... – дип, үзе артыннан ияртеп алып китте ул бар классны. Ул биремне мин әлегә кадәр хәтерлим. Краннан су агып тора икән. Янындагы савытка шуннан төгәл җиде литр су агызып аласы. Янда гына сигез литр һәм өч литр сыешлы ике савыт тора. Шулар ярдәмендә ничек чишелеш табасы? Барыбыз да дәфтәрләргә иелдек. Каләм кыштырдаган тавыш кына ишетелә. Мин дә чынлап торып

уйларга тотындым, чәч төпләре тирләп чыкты хәтта. Ничек инде ул, өч тә биш, кушсаң сигез, кирәк җиде... Шылт иткән тавыш юк. Ә Галимҗан абый, кулларын артка куеп, рәтләр буйлап йөри, кемнәрнеңдер дәфтәрләренә күз салып ала. Чибәр кеше иде ул: дулкынланып торган көмеш түгел, бераз карасу, кургаш төсендәге чәчләре артка таралган, үзенә таман гына күрәнсу чалбар-костюм, бер дигән ботинкалар. Кием ягына килгәндә, бар укучылар да инкубатор чебешләре төслерәк иде. Малайларда – иләмсез кәчтүм, кызларда – күрән төстәге күлмәк. Хәллерәкләрне аерырга аларның материалы төрлеләнә иде. Ситсысы була, аннан соң юньлерәк дигәне – сатин, иң кыйммәтлесе – штапель. Кара алъяпкычы булганы шуны яба. Ә ак алъяпкычлар бәйрәмнәрдә генә. Анысы да барысында да юк. Шул бер форманы ел әйләнәсе киясең. Каникулга чыкканның икенче көнендә үк форма чалбарыннан чыгып тузанда ауныйсың. Чыдамлы була торган иде алар, төймәләре генә ярылып төшә иде нәләтләрнең. Икенчесен кайдан аласың, тегеп бирергә әниләрнең вакыты да юк, өйгә кайткач онытыла да ул. Җаен таба торган идек. Нык бау эзләп табасың да, элмәкләре аша үткәреп, билне тарттырып бәйләп куясың. Чап та чап теләгәнчә! Тик ашыгыч чакларда нык уңайсыз була, теге төен тиз генә чишелми. Чибәр-чибәр кызлар да шул күрән күлмәкләрен салмыйлар. Җыелышып урам урасалар да – шул, җиләккә барсалар да – шул. Ә абый безгә кинодагы артистларга тиң булып күренде. Мине шул көнне тәмам әсир итте ул үзенә. Хәер, барыбызны да, кызлар турында әйтәсе дә түгел инде. Елмая төшеп, тамак төбе белән сөйләшүе, башын ташлап көлеп җибәрүе шул кадәр дә килешле иде. Әлеге өч сан арасында мин бөтенләй буталдым, елардай булдым менә. Ә менә бер йомрыбаш малай тәки тапты бит җавабын. Чатнатып әйтеп салды. Барыбыз бер тында «и-и-и» дип җибәрдек. Шулай гади генә икән дә. Галимҗан абый теге малайның көндәлеген сорап алды, шәп-шәп дип, нидер язды да урыныннан торып, язганнарын бар класска күрсәтте.

– Менә мин иптәшегезгә «алтылы» билгесе куям. Молодец! – дип, кат-кат кулларын кысты комачтай кызарып, дер-дер калтырап торган баланың. Шул чакта кыңгырау шалтырады. Галимҗан абый чыгып китте, ә без барыбыз, этешә-төртешә, кызыл кара белән язылган чикләвектәй эре «алтылы» билгесенә капландык. Бу могҗиза иде безнең өчен. Дәресен әйт син, күз ачып йомганчы үтте, сизмәдек тә. Теге малай соңыннан ул билгене, көндәлегеннән лезвие белән кисеп алып, озак вакытлар түш кесәсенә салып йөртте. Бар класстпашлары арасында да кинәт дәрәҗәсе үсеп китте. «Алтылы» билгесе ал әле син, бу уен-муен түгел! Өстәп шуны да әйтергә кирәктер: математика бераз аксаклап йөргән бу малайның иң яраткан дәресенә әйләнде. Әти-әниләре дәфтәр җиткерә алмый башлаганнар моңа. Өйгә эшкә бер мисал бирелсә, теге биш тапкыр арттырып эшләп килә торган иде. Соңыннан классташым, Ленинградка барып, бә-әк югары уку йортына кергән. Аспирантуралар тәмамлап, тәки бу фәнне зыр әйләндергән. Шулай дип сөйли торганнар иде аның хакында авылдашлар.

Әйткәнемчә, ул төгәл фән белән минем артык дуслык булмады, хәзер дә юк. Кибеткә керсәм, сатучылар күз дә йоммый алдап чыгаралар. Кайдан беләләр диген минем йомшак якны? Ә шулай да мин укытучымның

беренче дәресен ныклап үзләштердем. Яхшы сүз кешеләрне күкләргә күтәрә икән! Кешеләрнең яхшы якларын күрә белергә кирәк. Һәркем мактауга мохтаҗ.

Ул елда мин озайтылган көн төркеменә йөри идем әле. Бераздан йөрүдән туктадым. Анысы икенче мәсьәлә. Нигә йөрим соң? Якын дустым шунда бара, бер көн калдырмый. Уйнарга иптәш юк. Өйдә буш, нәрсә эшләп утырыйм. Кызыктырган икенче ягы да бар әле. Озайтылган көнгә гел начар укыган укучыларны чакыралар, дәресләрен әзерләтәләр. Берәр сәгать күнегүләр эшләгәннән соң тәнәфес, аш бүлмәсенә өелешеп керәбез. Ак халатлы Сара апа һәрберебезнең алдына кырлы стакан белән өяләмә кесәл куя. Аһ, ул кесәлнең тәмлелеге! Әле аның белән генә бетми. Иптәш малай тәрбияче апага хәбәр сала:

– Менә ул кичә «бишле» алды, – ди.

Тәрбияченең әллә мине бу төркемдә йөртәсе дә килмәгәндер, мөгаен. Килеп утыра авызын ачып, барысын белә, өйрәтәсе түгел бит инде. Артык тамак, әгәр тикшерә башласалар, ничек итеп җавап бирәсе, – дип уйлый торгандыр. Мин, юаш малай булып, башымны аска иеп торган булам. Ә күңел җилкенә, менә хәзер, хәзер...

– Ә-ә, шулаймыни? – дип, тәрбияче апа теләми генә, тартмадан алып, минем алга ике печенье куя. Монысы начар укыганнарны кызыктыру чарасы, әмма ул гел миңа эләгә. Безнең өйгә кергән сый түгел ул. Без шикәр комын да берәр килолап кына алабыз. Сала калсалар да, бер чәй калагыннан артыгын салмыйлар чынаягыңа. Ә булган бер уч таш кәнфит комод тартмасында йозак астында ята. Ачкычны бер әни белә. Көтелмәгән кунак килеп керсә генә, теге серле тартма ачыла, җәннәт сыйлары якты дөньяга чыга. Ә авыз тәмләргә без как кулланабыз. Җиләк кагы, чия кагы шунда. Җәй көне җиләкләрне чиләкләп җыябыз да как коябыз. Анысы турында башка вакытта сөйләрмен әле. Теге дус малай турында чак кына алга китеп... Тәки рәтле-башлы укымады ул. Класста утырып калып, сигезне чак тәмамлап, колхоз эшләрен ерып эшли башлады. Хәзерге көндә аны танымассың. Зур эшләр йөртә, баеганнан-байый. Укуда гына түгел шул хикмәт, янында бәхет дигәне дә кирәк икән шул... Менә шулай итеп, мин озайтылган көн төркеменә йөрим, дәресләрне вакытында әзерлим. Һәм көтелмәгән яңалык: Мирсәет абый урынына Галимҗан абый безне укыта башлаячак! Теге укытучы әллә гаиләсе белән күчеп киткән, әллә хәрбиләр чакыртып алганнар. Балалар белән уртак тел тапмаса да, башы эшли иде аның. Элек тә нindидер исәпләүләр үткәрә икән, дип сөйли торганнар иде аның турында.

Хуш, тын алырга куркып, яңа укытучыны көтәбез. Ниләр булыр алда? Юк, куркыныч түгел иде ул, ничектер якын туган кебек. Көлеп-шаярып сөйләште әле. Соңыннан миңа туп-туры карады да тактага өй эшен язарга кушты. Мин шактый батыр гына чыгып бастым. Барысы тәртиптә, дәфтәрдә эшләнгән, күчерәсе генә. Язам такта тутырып, бит очлары акбур булып беттеләр. Нindидер теорема исбат итәсе иде шикелле. Галимҗан абый рәт араларында йөри, калын тавышы белән: «Дөрес, дөрес...» – дип кабатлый.

– Шулаймы, укучылар? – дип, башкалардан да сорап куя. Сүз әйткән

кеше юк, барысы мин язганнарны күчерәләр. Галимҗан абый керәсен белми, дәрес әзерләми килгәннәр инде алар. Менә минем йөзем якты, өй эше дәфтәрдә, шатырдатып язам тактага...

Язып тәмамлап, авызны ерып, такта читенә барып бастым. Шулчак рәт арасыннан кинәт кузгалып, Галимҗан абыем җил-җил атлап килде дә мин язганнарны аркылыга-торкылырга сызып ташлады:

– Дөрес түгел!

Күк күкрәдемени! Мин күзләремне чытырдатып йомып алдым хәтта. Нәрсә, ничек соң, нигә шул вакыт бер сүз әйтмәде ул? Класстагы берничә бала кыюсыз гына кул күтәрделәр:

– Абый, безнеке алай түгел...

Әлеге беренче партада утырган, «бишле»гә генә укыган чәчбикәләр инде. Укытучы барып, теге кызларның дәфтәрләренә күз салды, канәгать калды.

– Сез ял итегез, үз эшләрегез белән булашыгыз. Әмма беркемгә күрсәтмәгез чишелешне. Без класс белән хәзер хаталарны эзләп табарбыз.

Кырык тапкыр ялгышып, бер-беребез белән сүз көрәштереп, урында утырып чыдый алмый, бар класс бирем өстендә эшләде. Төп авырлык минем җилкәгә төште. Ләкин исбатлауның азагында, дөрес җавапны язып куйганда, миннән дә бәхетлерәк кеше булмагандыр. Иң соңыннан Галимҗан абый минем кулдан акбурны алып, зур хәрефләр белән «ЧТД» дип язып куйды. Безнең аңламый торганны күреп, аңлатып бирде:

– ЧТД – что требовалось доказать!

Эшләр уңышлы тәмамланса, аның шулай итеп әйтеп куя торган гадәте бар икән. Бу гадәтне без дә класс белән үзләштереп алдык. Дәрестә булганнарны күп тапкырлар күз алдыннан үткәргәннән соң, мин үзем өчен шундый фикергә килдем. Төркемгә иярмә! Син нәрсә турындадыр оран салыр алдыннан кырык тапкыр сүзләреңнең дөреслегенә инан, шуннан исбатла!

Математика дәресләрен көтеп ала торган идек без. Хәер, дәресләре дә икенчерәк була торган иде Галимҗан абыйның. Кулларны кулга куеп, тын да алмый, читкә карарга да куркып утырмый идек без аны дәресләрендә. Нәрсәләрдер турында бәхәсләшеп, гөж киләбез. Хәтта парта артыннан торып, икенче рәттәге укучының дәфтәренә күз салырга хакың бар. Артыңа каерылып карап, иптәшләрең белән бергәләшеп, ниндидер биремне эшлисең, рәт белән рәт ярыша, яисә берсе такта янына чыгып, бар класс белән алыша. Дәреснең тәмамланганын сизми дә кала идек. Кыңгырау шалтырагач та, әле күпләр ашыгып-ашыгып, дәфтәрләренәниләрдер язалар, мисалларның бетмәгән өлешен тәмамларга тырышалар. Бигрәк тә математика фәне атналыклары безнең өчен бәйрәмгә тиң була торган иде. Дүшәмбе көн линейкада абый бу хакта тантаналы игълан итә. Коридорга озын обой кисәгенә чыгарылган стена гәзите эленә. Беренче тәнәфестә үк без аны дәррәү сырып алабыз. Ни генә юк ул гәзиттә! Математика фәне хакында төрле кызыклы, фәһемле хәбәрләр, шарадалар, ребуслар, мәгънәле викторина сораулары, катлаулы башваткычлар. Һәркем уйлый, җавап табарга тырыша. Кайсы башваткычны төнлә йоклый алмый уйлап ятасың әле. Җавабын таба калсаң, йокы бөтенләй кача. Иртәгә, күкрәгеңне

киереп, ничек иптәшләргә чишелешен аңлатачагыңны уйлап, рәхәт кичерәсең. Киләсе линейкага аеруча актив катнашканнар өчен бүләкләр дә булачак бит. Зур түгел, әлбәттә, сигез тиенлек блокнотлар, унике тиенлек альбомнар, арзанлы буяу каләмнәре. Һәр дәфтәр исәпле чакта, андый бүләк тә бик ярап куя. Аннан соң, иптәшләрең ничек көнләшеп карыйлар сиңа... Бу бүләкләрне абый үз акчаларына алгандыр, дигән шик бар минем күңелдә. Ни өчен дигәндә, гадәттә, башка бәйрәмнәрне йомгаклап, яхшы укучыларның фамилияләрен генә санап үтә торганнар иде. Атналык барган көннәрдә дәрестән соң абый өстәлдә тимерчыбыктан, рейкадан ясалган төрле детальләр калдырып чыгып китә. Без әнә шуларны сүтеп җыярга тиеш булабыз инде. Беренче көннәрдә хәлләр бетә. «Әнә теге өлешеннән уңга бор, түгәрәге аша чыгар, кыска таягын өскә күтәр...» – дигән ише киңәшләр яңгыраудан туктамый. Ә атна азагына күз йомып җыя-сүтә башлыйбыз инде без ул хикмәтләрне.

Кеше хәтере кызык корылган. Әнә шул ярты гасыр элек баш ваткан мәсьәләләрнең берсе һаман да хәтердә саклана. Күпме кәгазь пычраттык, ничә кара савыты ваттык икән без дөрес җавап табар өчен. Бәлки, сез дә кызыксынып китәрсез дигән өмет белән эчтәлеген кыскача сөйлим әле. Бер бабай улына базарда атын сатарга кушкан. Егерме сумга сата алсаң, бихуш, дигән. Егет тыңлаучан булгандыр, күрәсең. Якшәмбе көнне иртә таңнан юл тоткан бу базарга. Карый, кызыксына, башкалар атлары өчен егерме биштән ким сорамыйлар, утызны каерырга теләгәннәр дә бар. Моның янына ике мосафир килеп туктаган. Тегеләр атны берләшеп алырга телиләр. Егет ни, файда чыгарырга теләп, егерме бишне сорый инде. Хуш, унике сум иллешәр тиен чыгарып түлиләр болар, атны җитәкләп алып китәләр. Шатлыктан авызы ерылган егет хәрчәүнәгә керә, бер каз китертә, тегесен-монысын. Каеш асты бушаган моның, гел бәрәңге боламыгы ашап йөреп. Ялт иттерә бу казны. Өч тәңкә түләп куя казга. Йөгерә-атлый кайтып китә. Авыл якында була. Кайтып, әтисенә калган егерме ике сум акчаны суза бу. Егерме бишкә сатканын әйтеп сала. Өч сум йөргән юл өчен булды инде, ди. Никтер әтисе аның сүзләреннән пыр тузып тиргәшә башлый. Ишкәнсең ишәк чумарын, ди. Егермедән арттырмаска куштым мин сиңа, ди. Бар, берәр сум акчаларын булса да кире кайтарып бир дип, кире йөгертә. Берни эшләр хәл юк, ата сүзе закон. Тиргә төшеп барып керә егет базарга. Бәхетеннән, теге мосафирлар кайтып китмәгәннәр икән. Берәр сумнарын кайтарып биреп, гафу үтенә. Кайтып барганда, күңеленә шик төшә моның. Берәр сум кире кайтарып биргәч, һәрберсе унбер сум илле тиен түләделәр килеп чыга бит инде. Аларны кушсаң, егерме өч сум. Ә ул үзе каз өчен өч сум түләп ашады. Егерме өчкә өчне кушсаң, егерме алты сум була түгелме? Кайдан килеп чыкты ул артык бер сум акча? Әнә шул артык акчаны эзләп, баш вата идек без. Күпме эзләсәк тә таба алмадык. Зуррак үскәч кенә моның алогизм булганына төшендем кебек. Ә шулай да, юк-юкта теге бер сум күңелне тырнап куя. Шундыйрак берәр файда чыгарырга булмыймы икән сату-алуда?

Уртакул укытучының, гадәттә, дәресләре болайрак үтә. Кереп, урындыкка артын төртүгә ул кашларын җимереп, журнал актара башлый. Укучылар, мескеннәр, тиз-тиз китап битләрен актаралар, ни

дә булса укып калырга ашыгалар, күршесенең дәфтәреннән күчерергә омтылалар. Ашап туймаганы, ялап туеп буламыни? Әзерләнмәгәнсең икән, бәргәләнүләрнең файдасы юк. Хөкем ителгән, башын иеп, такта алдына чыгып басарга мәҗбүр. Менә, ниһаять, өй эшен тикшерүләр тәмамлана, куеласы «икеле»ләр куела. Укытучы яңа теманы аңлата башлый. Барысы да җиңел сулап куя. Күпмедер вакыт яңа теманы аңлатканнан соң, бүген үзләштергәнне ныгыту өстендә яңа мисаллар эшлиләр. Соңгы минутларда аңлатылып, өй эше бирелә, кыңгырау шалтырый. Вәссәлам, дәрес тәмам! Ике йөз ун көн дәвамында бер үк сюжет кабатлана. Галимҗан абыйның дәресләрендә ялыктыргыч бертөрлелек булмый торган иде. Килеп керә ул хәйләкәр елмаеп, шунда ук тактага мисал яза.

– Бүген өй эшләрен тикшереп тормыйм. Сез булдыра алган кадәр тиз генә бердән йөзгә кадәр булган саннарның суммасын исәпләп чыгарыгыз.

Һу-у монда эшләр! Бергә куш икене, анысына өчне ялга... Йөзгә кадәр бит әле. Бераз безнең кәҗә майларын чыгаргач, укытучыбыз әйтеп сала.

– Бу мисалны сездән дә бәләкәйрәк ун яшьлек малай, минут эчендә җавабын чыгарып укытучысына тапшырган.

Безнең, әлбәттә, күзләр маңгайга менә. Шул кадәр саннарны... булмас...

Шуннан укытучыбыз, дәртләнеп, безгә бөек математик Карл Гауссның тормышы турында сөйли башлый. Укытучылары, ничек итеп бераз тынычлыкта утырырга теләп, аларга бу мисалны биргәнен, кечкенә Гауссның аны гаҗәпкә калдырганын күз алдына бастыра. Мисалның ничек эшләнешен аңлата. Без ул дәрестә бөек шәхеснең тормышына үтеп кергәндәй булабыз. Минем, әлбәттә, сезнең, югары белем алган кешеләрнең, фикер йөртә белүегезгә шигем юк. Шулай да биш минут эчендә саннарның суммасын әйтә алырсызмы? Мин сезгә кечкенә Карлның фикерләү юнәлешен дә әйтә алам. Булачак талант беренче һәм соңгы саннарның суммасына игътибар иткән: йөзгә берне кушсаң, йөз дә бер...

Икенче юлы Галимҗан абыебыз 1832 елның 30 маенда булган вакыйганы искә ала. Француз егете Эварист Галуаның күп еллар беркем чишә алмаган теорияне исбатлавын сөйли. Шул ук көнне, бу дөньякүләм әһәмиятле ачышыннан соң, егерме бер яше дә тулмаган Галуаны дуэльдә атып үтерәләр. Әлеге теорияне исбатларга ул иртәгәсе көнне булырга тиешле дуэльгә кадәр вакытны тизрәк үткәрергә теләп алынган була. Вакытсыз өзелгән гомер безне тетрәндерде. Әгәр яшәсә, әллә нинди гүзәл ачышлар ясаган булыр иде ул!

Без бөек математиклар белән син дә мин кебек яшәдек. Эйлер, Риман, Пуанкаре, Евклид кебекләр безгә яхшы танышлар иде. Хәтергә Дарбу дигән фамилия дә язылып калган.

Хәзер ничектер, ул вакытларда ачык дәресләрне еш үткәрәләр иде. Галимҗан абый кебек ачык дәресләрне беркем дә үткәрә алмагандыр. Үчлерәк укытучылар сөйләп йөргәннәр, ахрысы. Имеш, абый безгә җавапларны алдан әйтеп куя. Улмыни инде андый түбәнлеккә бара торган кеше?! Ә арада бар иде укытучы исемен күтәргәннәр. Районнан методист киләсе булса, ачык дәреснең репетициясен үткәрәләр иде. Кем нәрсә әйтә, кайсы төштә кул күтәрә, барысы планга теркәлгән була торган иде. Аларны искә дә аласы килми. Бер фәһемле сүзләре, гамәлләре сакланмаган хәтердә.

Ә менә Галимҗан абый ни сәбәп беләндер дәрескә килә алмаса, без класс белән улап җибәрә торган идек:

– У-у, абый килми-и бүге-ен, дәрес булмы-ы-ый...

Вәт, юләрләр!

Галимҗан абыйның кайсы укучыга булса да, нотык укыганын хәтерләмим мин, тавышы көр булса да, йөзен ертып кычкырмый иде, син тәртипле бул, син намуслы бул, дип акыл өйрәтмәде. Ә шулай да әкрен-әкрен тәрбия минутлары үткәрә иде ул безнең белән. Мәсәлән, дәрес барганда, бер тын вакыт табып, тәрәзә төбендәге гөлләр янына барып баса, әкрен генә шул аллы-гөлле гөлләмәләргә кагылып ала, хисләре белән уртаклаша:

– Менә шул чәчәкләр дә табигатьнең могҗизасы бит, – дип сөйли ул, әсәрләнеп. – Күрегез, бер чәчәктә ничә төрле төс: алы да, кызылы да, шуның янында шәмәхәсе дә. Энә очы хәтле генә орлыктан яралганнар, бер үк туфракта үскәннәр, һәрберсенең үз фигыле, үз матурлыгы. Гаҗәп бит бу, дусларым. Галимнәр әйтә: шул үсемлекләр кешенең хисләрен тоялар, үзләренчә җавап бирәләр, диләр. Әгәр берәр гөл каршына килеп, көн дә аны начар сүзләр белән тирги башлыйсыз икән, күпмедер вакыттан соң ул сулыга, корый башлый. Баш җитмәс эшләр. Табигать серләре чиксез ул. Сез менә үсеп җитеп, зур ачышлар ясарсыз алдагы көннәрдә...

Тәнәфес вакытында очраклы рәвештә генә (без малайлар бит!) әлеге гөл яныннан үтеп китәбез, кытыршы яфракларына кагылып алабыз. Чыннан да, ниндидер җылылык таралган төсле үзләреннән. Мин үзебезнең өйдә үскән фикус гөленә, тәрәзә төбендәге канәфер чәчәкләренә игътибар итә башладым. Чынлап та матурлар икән бит, чукынчыклар.

Аның тагын бер әңгәмәсе истә калган.

– Төн уртасына кадәр кулдан китап төшмәде. Бик талантлы язучыны укып яттым, «Повести гор и степей» дип атала китабы. Укыганыгыз юкмы? Һичшиксез, укып чыгыгыз...

Без, әлбәттә, класс белән, тәнәфес җитүгә узыша-узыша, китапханәче Ләйлә апа янына йөгерәбез. Сакландымы икән хәзерге көннәргә кадәр Чыңгыз Айтматовның ул әсәрләр җыентыгы? Түземсезлек белән чират җиткәнен көтеп алып, мин бик яратып укып чыктым ул китапны. Абый белән берләттән, сезгә дә тәкъдим итәм.

Дәрестән тыш та, Галимҗан абыйның мине гаҗәпләндергәне истә калган. Баштан ук сөйләргә кирәктер. Без авыл мокытларын бераз тәрбиягә тартырга теләптер инде, һәр җомга көнне кичләрен түбән катның залында танцылар оештырыла торган иде. Яңгырап торган зур радиола бар, шунда пластинка әйләндерәләр. Пластинкаларны өйдән ташыйлар. Кемнеңдер туганы Ташкенттан җибәрә. Ул вакытта үзбәкләрдә иде завод. Мәскәүнең Апрелевский заводы да бар. Ләкин безнең авылдан башкала белән алыш-биреш итүче кеше юк иде. Ә Ташкент үзебезнеке. Ярты татар Үзбәкстанда яши. Күчеп бетеләр җылы якларга, җиләк-җимешләргә кызыгып. Ул вакытларда әле бостон, шейк, твист биюләрен кинодан карап өйрәнәләр. Шулай да күбрәк вальс әйләнәләр. Кайбер кызлар әлеге көрән күлмәкләрен чәчәклегә алыштырып, купшыланып киләләр. Менә шул кичәләрне тәртипле генә үткәрергә җаваплы бер укытучы билгеләнә. Укытучылардан берәрсе гозерләнеп сорагандырмы, көтмәгәндә,

Галимҗан абый оештыручы булып килмәсенме! Төз гәүдәле, ялтырап торган ботинкалар, ап-ак якалы күлмәк. Бродвейдан килгән, диярсең. Вальс көе башлануга, югары класслардагы бер кызны биергә чакырды абыебыз, күз иярмәс җитезлек белән әйләнергә тотынды. Менә сиңа мә! Кайда монда математика? Һәр алынган гамәлен күңел салып башкара иде ул. Барлык укучыны дәртләндереп биеде, уйнады-көлде, рәхәтләнеп күңел ачты укытучыбыз, башкаларны да уятып җибәрде. Фәкать мин үзем ул дәртләнгәннәр исәбенә кермәдем. Гомердә биергә өйрәнә алмадым мин. Аякларым чалыш-чолыш килде, кызларның кулына кагылсам, башым әйләнде, музыка, ритм дигән нәрсәне белмәдем. Яшәп-яшәп тә, бер җир селкетеп биемәгәч, ни кызыгы бу тормышның? Әнә шулай бер китек ягы булды гомеремнең. Галимҗан абыйның биегәнен искә алам да һаман сокланам. Бар яктан талантлы кеше иде шул ул!

Бер дәрестә абыйны көлдергәнем хәтердә калган. Төрле сораулар бирә идек без аңа. Бер нечкә генә тавышлы, үтә күренмәле кызый абыйга сорау бирде:

– Абый, нәрсә була ул – коммунизм?

Без ул чакларда алда барыбызны да коммунизм көткәненә чын күңелдән ышана идек. Ничек ышанмыйсың, кукурузлар яраткан ил җитәкчебез Никита Сергеевич: «Сиксәненче елларда коммунизмга аяк басачакбыз», – дип югары трибунадан вәгъдәләр бирде, ант итте бит. Иң арттагы партада утырган Сәлим исемле малай сикереп чыкты:

– Һи-и, шуны да белмәгәч! Бар нәрсә бушлай була коммунизмда. Ат җигеп барасың да теләгәнеңне кибеттән төяп алып кайтасың. Түлке өлгеррәк булырга кирәк, бар кешегә җитмәскә мөмкин.

Абый Сәлимнең төптән ялгышуын аңлатып үтте. Киләчәктә бар кешеләрнең дә яхшы якка үзгәрәчәген, алдашу, урлашу, хөсетлек кебек начар холыкларның бөтенләй бетәчәген сөйләде.

– Менә, Сәлим, мисал өчен, ул чакта кибеттән әйберне үзенә ташымый, башта әлеге классташ кызына илтеп бирә, бу аңа әйтеп бетерә алмаслык шатлык хисләре бирә.

Сәлим бу сүзләрдән соң:

– Гы-гы-гы... – дип, партасына капланып ятты. Андый тузга язмаган хәлне күз алдына китерә алмады бугай. Мин шунда сорау бирдем. Ул вакытларда күрше класстан бер кызый күңелемне җилкетә иде. Барып, сүз кушарга батырлыгым җитми, бик тә оялчан идем мин. Әмма кич йоклый алмый боргаланганда, теге чәчбикәне күз алдына китереп, әллә нәрсәләр турында хыялланып бетә идем, әкәмәт. Йә шуны кечкенә кулларыннан җитәкләп алып, урман-кырларда йөрим, йә йолдызларга карап, күңелемне ачам, матур-матур сүзләр сөйлим. Галәмәт инде менә. Алга китеп, шуны әйтим: тәки бер авыз сүз әйтә алмадым ул кызга. Башка егет тегенең йөрәгенә ачкыч яратты. Әлеге кызның йөзе, серле карашы, чылтыратып көлүләре, өрфия гәүдәсе әсир итә иде мине. Шуларны уйлап, сорауны бирдем дә инде.

– Абый, коммунизмда кешеләр бер-берсен тышкы кыяфәтләренә карап яратырлармы икән? Барысы да яхшы гына булгач...

Абыем, башын артка ташлап, рәхәтләнеп көлде, күзләреннән яшьләре

атылып чыкты хәтта. Абыйга кушылып, балалар да хихылдаган булдылар, котсызлар. Җавап бирде миңа абый, аңлап кына җитмәдем.

– Барысы да алай гади генә түгел, Кәлимов. Яхшылык төшенчәсе гаять киң ул.

Яши-яши белдем, кайсы яхшылардан тизрәк йөгереп качасы килә икән ул. Алардан күргән яхшылыклар бик кыйммәткә төшә. Бик сак булырга кирәк кешеләр белән аралашканда.

Кышның зәмһәрир салкын көннәрендә мин чирләп, урын өстенә егылдым. Ай-һай, уеннар кызыклы була торган иде без бәләкәй чакларда. Төн уртасына кадәр урамнан кайтып керми идек. Өскә кигән кием чамалы гына: бер кат чалбар, эчтән трико-фәлән киелмәгән. Анысы нинди мода тагын, юк өчен акча бетереп. Кибеттә юк та ул, физкультура дәресенә кызлар да өч сумлык сатин чалбарлар киеп йөриләр. Аякта тишек пималар, аннан чолгауның бер очы чыгып тора. Шул тишекләрне ямап бирергә әти һич вакыт таба алмый. Булыр әле дип, кышлар үтеп китә. Оекбаш белән мактанып булмый. Бер дустым әйтмешли, мин унсигез яшемә кадәр тузмый-тишелми торган оекбаш киеп йөрдем. Бик пычранып китсә, мунчада сабынлап юып аласың да йөри бирәсең. Чебиләп кенә йөрәккә тия торган иде. Яланаяк йөрдем, дигән сүз, кыскасы.

Чирләп ятам шулай мич артында, җылыда, болай да температура күтәрелә. Дару бар барлыкка: күршеләрдән өч-дүрт төймә аспирин алып чыктылар. Гел эчәсе килә инде. Тәүлек әйләнәсендә тамакны чылатып кына торырга кирәк. Авырайган башны калкытып, алюмин чүмечтән су чөмерәм дә тагын баш астындагы иске фуфайкага авам. Гел саташтыра: ут күзле шайтаннар куалап йөртәләр, этләр көтүе ташлана. Атна буе тартыштым чир белән. Атларга хәл булмаса да, баш әйләнеп торса да, атна башында киттем мәктәпкә. Артта калам югыйсә иптәшләрдән. Тәки артта калынган. Иптәшләр икс белән ниндидер тигезләмә төзиләр дә, күз ачып йомганчы, мәсьәләне чишәләр дә куялар. Мин дә чишәм. Ләкин бөтенләй башка юл белән, икссыз-микссыз, авыр юл белән. Берара тартыштым да әйттем Галимҗан абыйга. Абый мине дәрестән соң алып калды. Аның кабинетында кечкенә бүлмәсе бар иде. Шунда кертеп, өч-дүрт җөмлә белән теге теореманың асылын аңлатты да куйды. Гади генә икән ул икс белән тигезләмә. Мин чыгарга җыенганда, абыем, көлемсерәп:

– Кәлимов, монда кара әле. Синдә өмет бар, егет. Мисал чишүдән әйтмим. Гомумән. Син өметле егет, читкә чалулап кереп китмә түлке. Кара, сүзләремне тот!

Мин очып чыгып киттем ул кысан бүлмәдән. Өйгә кайтып җиткәнче, аякларым җиргә тимәде. Чирләр дә сыпырып алгандай юкка чыкты. Тирә-ягыма карангалаганымны хәтерләп калам. Менә болайрак уйладым шикелле:

– Син, үшән сыер, печән ашап торган буласың монда. Ә син, кәкре койрык, нәрсә ләңгелдәп өрәсең? Бу кызылтүшләр өерләре белән очкан була. Беләсезме, кем урам уртасыннан атлый монда? Абзыегыз булыр бу. Әнә нинди сүзләр әйтте аның турында укытучысы...

Алдашасым килми, яхшырак булып күренү юк теләгемдә. Мин инде андый яшьтән узган, хәер, яшьрәк чакта да кемгәдер яраклашырга

яратмадым. Шуңа күрә күп кенә югалтулар кичердем, ахрысы. Икенче яктан караганда, намусың чиста булса, тыныч йоклыйсың. Минем әни мәрхүмә әйтә торган иде: «Ач тамагым – тыныч колагым». Миңа да шулайрак яшәлде шикелле. Хәзер үкенеп утырып булмас. Нәрсә дип алдашмыйм соң? Тормыш булгач, төрле чаклар булды. Төпкә тәгәрәгән чаклар да, гөнаһка батканнар да, җир тишегенә керердәй оялган чаклар да. Андый чакларда келт итеп менә шул сүзләр искә төшә иде минем. «Тукта әле, өметеңне өзмә, син бит өметле егет, хәтерлисеңме? Кара башыңны күтәреп, йолдызлар балкыймы күк йөзендә? Барыр сукмакны чамалап буламы? Алай булгач, барысы да тәртиптә. Мүкәләп булса да тор, соңгы көчеңне туплап, беренче адымны ясa. Калганын күз күрер...» – дип, үз-үземне үгетләгәннәрем хәтергә уелып калган.

Гаҗәеп кеше иде ул Галимҗан абый. Авыл халкы аны нык хөрмәт итте, күтәреп йөрергә риза иде. Әле ул заманнарда телевизор ике-өч кешедә, информация юк дәрәҗәдә. Булганын да эш кешесе бик аңлап җитми. Шуның өчен Галимҗан абый клубта теләгәннәр өчен политинформацияләр үткәрә. Ул көнне клуб алдына ватман кәгазьгә игълан язып элә: «Бүген авыл мәдәният йортында халыкара хәлгә багышланган доклад укыла. Докладчы: укытучы Ядгаров Галимҗан Сафиевич. Башлана сәг. 7дә. Соңламый килүегез сорала».

Халык агылып килә иде андый җыелышларга, артистлар чыгышлары бер читтә торсын. Утлары ялт итеп торган сәхнәдә зур ярымшарлар картасы эленеп куелган. Кулына указка тоткан Галимҗан абый иң башта әлеге вакытта ил-көндә булган вакыйгаларны анализлый, яңалыкларны сөйли, капиталистик илләргә мөһер баса, шуннан инде залдагы кешеләрнең сорауларына җавап бирә. Кайчак бик тамагы кибеп китсә, кызыл бәрхет ябылган өстәл уртасында торган графиннан су эчеп куя. Ике-өч сәгатькә сузылган мондый җыелышлардан соң, кешеләр клубтан чыккач та таралып китмиләр, тәмәкеләренә кайнап, ишеткәннәре турында гәпләшәләр, Галимҗан абыйны өенә кадәр озатып баручылар була. Әле атна буе бу хакта сөйләшүләр тынмый. Шулай барысын да ничек белеп бетергәндер яраткан укытучыбыз? Усал телле кешеләр сөйлиләр иде, имеш, Галимҗан абый өйдә кыл да кыймылдатмый икән. Мәктәптән кайта да китап кочаклап урын өстенә ята, йокыдан тора да кулына китап ала. Патшалар җәяү йөри торган җиргә дә култык астына китап кыстырып йөри, дип җиппәрәләр иде. Алары арттырудыр, авыл кешесе кулына сәнәк-көрәк тотмый булмас, мәгәр укырга, белем алырга әвәслеге хәттин ашкан иде.

Шул елны минем әти, безне ташлап, яшь хатынга чыгып китте. Ул апаны минем моңа кадәр күп тапкырлар күргәнем булды. Артык яшь тә түгел иде, төскә-башка да безнең әнидән күпкә кайтышрак. Минем әни алай тавышлана, тиргәшә торган да кеше булмады, нәрсә бүлешә алмаганнардыр, азагына кадәр төшенә алганым булмады. Шулай итеп әти гаиләдән китте, өй ятимләнеп калды. Кинәт кенә ир-ат кулы кирәккән эшләр килеп туды: тегендә койма такталары купты, монда киртәләр ишелеп төште. Гел шулай була бит ул. Әтинең китүе минем өчен зур фаҗига иде. Барыбыз өчен дә инде. Минем апалар усал иде. Теге хатынның бер тәпәш кенә кызчыгы да

бар. Шул кызны бер почмакка кертеп кысканнар апалар. «Кайтар безнең әтине!» – дип, котын алганнар. Шул хәлдән соң ул кыз безнең өйне өске урамнан урап йөри башлады. Барысына үземне гаепле итеп тойдым мин. Менә мин начар малай булганмын, шуңа да безне ташлап чыгып киткән ул. Һәр очраган кеше гел минем начарлыгым турында уйлыйдыр төсле тоелды. Артымда кемнәрдер бармак төртеп көләләрдер юньсезлегемнән. «Шул кирәк сиңа!» – дип, зәһәрләрен чәчәләрдер. Мәктәптә бигрәк тә мескен итеп сизә идем үземне, андый халәтне әйтеп аңлатып булмый. Беркөнне мин мәктәпкә соңлап килдем. Нәрсә эшләптер беренче дәрескә килеп өлгермәдем. Берәрсенең күзенә чалынмаска тырышып, техничкаларның чиләкләре янынарак барып бастым. Күпмедер вакыт үтте, Галимҗан абыйның килгәне күренде. Мин шул чакта җир тишеге булса, шунда сикерер идем. Ул мине күреп алды, йомшак елмаеп, яныма килде. Ул, әлбәттә, безнең гаилә тормышыннан хәбәрдар иде. Миңа шундый кыен иде бу минутта. Укытучым акыл сатмады, ниндидер тапталган сүзләр әйтмәде, юатмады. Үзенчә әйтте. Авыр кулын кулбашыма салды да:

– Син, Кәлимов, гел башыңны аска иеп йөрмә. Анда җирдән башка нәрсә күрмәссең. Өскә дә кара, анда бит нурларын чәчкән кояш бар, гәрәбә йолдызлар ялтырыйлар, ак болытлар агылалар киләчәк тарафына. Син әнә шулар белән дә серләш...

Башка сүзләр әйтмәде, авыр атлап китеп барды. Аның кул җылысы гына торып калды иңемдә. Шул көнне дәресләрдән соң мин абзарга чыгып, гадәти эшләрне эшләдем. Соңыннан печән кертергә чыккан җиремнән, кулларымны як-якка ташлап, башланган кибән өстенә менеп яттым, игечиге булмаган күк йөзенә карадым. Дөнья тын иде, чип-чиста үтә күренмәле күк йөзе фирүзәгә тиң булып күренә. «Синең әле барысы да алда», – дип, кемдер пышылдаган төсле булды шул чакта. Кинәт тамагымнан ургылып ыңгырашу ателеп чыкты, мин күз яшьләремә ирек бирдем. Елаганда да рәхәт була икән ул. Йөрәк турысында торган ниндидер бер төер эреп юкка чыккандай булды, күңелем тынычланып калды. Шул чакта малайлык белән саубуллаштым бугай мин. Тормышта төрле чаклар була. Хәсрәтләрне күтәрә алмый баш та иелеп төшә. Андый чакта минем укытучым күз алдыма килә, әйткән сүзләре искә төшә. Үз-үземне җиңеп, мин карашымны күккә төбим, башымны күтәрәм. Чынлап та, болытлар тарала, балкып, кояш чыга, чишелмәстәй тоелган төеннәр чишелә, тагын тормышның тәмен тоя башлыйсың.

Менә сез нигә җил искәнен беләсезме? Ә мин беләм. Безнең авылдан район үзәге ерак түгел, автобуслар да еш йөри. Егерме биш тиен акчаңны түлисең дә кереп утырасың. Бердәнбер көнне, ниндидер йомыш табып, мине районга куаладылар. Кулга бер сум акча тоттырдылар:

– Илле тиен – барып кайтырга, илле тиене – ашханәдә ашарга, – диделәр.

Автобус авылдашлар белән тулы. Хатын-кызлар базар тирәсенә баралар. Кем йомырка сатарга, кайсы – каймак, кайсы сөт күтәргән. Аларның хәбәрләре бетми инде. Кем кайда, кем белән, сәгать ничәдә, ничегрәк... Тикшерәләр барысын. Тавышлары яңгырап тора. Берничә ир-ат бар. Берсе табибка бара, икенчесе – тимер кибетенә, сөйләшүләре шул бетмәс авыл эшләре турында. Ике егет кереп утырды. Берсенең кулында магнитофон,

аның тавышын ачкан, икенчесе нидер сөйләп маташа: «Чувак, чувиха...» Анысы нинди сүзләр була торгандыр? Шулчак ишектән Галимҗан абый килеп керде, кычкырып исәнләште. Гөж итеп торган автобуста тавыш тынып калды. Әлеге озын малайлар торып, урын бирделәр, үзләре итагатьле генә ишек төбенә барып бастылар.

– Җил бүген, – диде Галимҗан абый, урынына урнашкач. – Ә сез беләсезме, җил ничек барлыкка килә?

Шунда ук табигый кануннар турында кыскача гына лекция дә сөйләп алды.

– Һава агымнарының басымы төрле үлчәмдә булса, көчлерәк агым алга ургыла, шул җил китереп чыгара, имеш. Монда кояш факторының да сәбәбе зур, әгәр һава җылынса...

Автобус кузгалып китте, халык тын калып, Галимҗан абыйны тыңлады. Йомырка хакы, яисә күрше хатыны турында сөйләшүләр бетте. Югары материя яулап алган иде кешеләрнең уйларын. Галимҗан абый туктагач, янымда утырган Гомәр абый миңа фәнни сорау бирде:

– Ә менә син арба тәгәрмәче белән тавык йомыркасы вата аласыңмы?

Мин, әлбәттә, уңай җавап бирдем. Шундый авыр тәгәрмәч белән йомырка ватуның ни авырлыгы булсын?

– Юк шул менә, – диде күршем, миңа тантаналы карап: – Йомырка бит почмакта ята. Ә түгәрәк тәгәрмәч һич тә почмакка якын килә алмый.

Мине тәмам җиңелүгә дучар иткәч, урынында өрәеп утырып барды Гомәр абый. Миңа башкача сүз кушмады. Шундый надан белән сөйләшеп торырга монда. Әнә шундый кешеләргә тәэсир итү көче бар иде Укытучымның. Ул якынлашуга, тирә-яктагы һава агымы үзгәрә, флюидлар, аура якты төскә керә. Кешеләр үзләрен икенчерәк, яхшырак, акыллырак, кирәклерәк итеп тоя башлыйлар иде.

Мин җиденче класска кергәндәме икән, Галимҗан абый мәктәптән китте. Олыларның чыш-пышларыннан шуны аңладык: директор белән бик каты сүзгә килгәннәр икән. Галимҗан абый үзе холык күрсәткән. Аның ялгышуын гына көтеп торган директорыбыз Усман Закирович туры районга әләкләргә чапкан. Эштән төшерү турында приказны алып та кайткан. Баш иеп, тупсалар таптый торган кеше түгел иде Галимҗан абый.

Атна эчендә аны бездән сигез чакрым ераклыкта булган Саргы авылына директор итеп куйдылар. Алтын кисәге нинди халәттә дә үз сыйфатын югалтмый, алтын булып кала. Кыска гына вакыт эчендә Галимҗан абыйны күккә күтәрделәр, өрмәгән җиргә утыртмадылар күрше авылдагылар, фатирына итен-маен ташыдылар, атна саен өенә кайтарып куйдылар, атна башында ат җигеп килеп алдылар. Бер ел эшләде абыебыз чит авылда. Ә язга таба безнең мәктәптә үзгәрешләр булып алды. Тикшерү килеп, директорыбызның бар гөнаһларын чокып чыгардылар, ялган документлар төзеп, хөкүмәтнең әллә күпме акчасын үзләштергән икән. Үзен эштән кудылар. Икенче уку елы башында Галимҗан абыебыз мәктәпкә кире кайтты. Директорлык вазифасын да тәкъдим итеп караганнар, үзе баш тарткан, диделәр. Мәктәптә тагын озак эшләргә язмаган икән укытучыбызга. Район түрәләре җыелышып килеп, Галимҗан абыйны авыл советы рәисе итеп сайлатып куйдылар. Берничә еллар бар авыл халкы өчен рәис хезмәтен

башкарды ул. Авыл халкына да, авыл өчен дә күп яхшылыклар эшләде. Безне дә тартты әле ул кайбер эшләргә. Үз кеше булып, классыбызга килеп керде. Бездән ярдәм сорады.

– Шундый зур авылда урамнарның исеме юк. Олы урам, Югары як, Түбән як, Өске урам. Конвертка шундый адрес язып булмый бит инде. Сез ничек уйлыйсыз, егетләр?

Мондый ышаныч белдерүдән без бердәм шаулашып алдык. Безнең фикер белән кызыксыналар бит. Кем дисең әле, авыл советы рәисе, яраткан укытучыбыз!

– Исемнәр язылган әзер калайлар кайтартылган, сезгә шуларны тыкрык башларына, урамнарга кагып чыгарга кирәк. Хезмәт дәресләре укытучысы Рамил абыегыз җитәкчегез булыр. Бераз акчасын да түләрбез. Булдыра алырсызмы?

Булдырмыйбызмы соң! Без бертавыштан риза булдык, әлбәттә. Шул көннән башлап дәресләрдән соң җыелышып эшкә тотындык. Артык авырлыгы юк иде. Өйләр тәбәнәк безнең якларда. Кемдер баскычны тотып тора, кемдер кадак кадаклый, кемдер бакчаларга керергә юл яра. Арып китсәк, эшләрне алыштырып та алабыз. Башкарып чыктык кушканны, яраттылар эшебезне. Авыл безнең тырышлык белән матурланып киткән төсле булды. Акчаны класс җитәкчесе исеменә күчерделәр. Күп өлешен без чыгарылыш кичәсенә тотарга булдык. Ә бер өлешенә тәм-томнар алып, табигать белән хозурланырга экскурсиягә бардык. Таудан йомырка тәгәрәттек, көлгә күмелгән бәрәңге ашадык, эч күпкәнче сөтле чәй эчтек. Соңыннан бар белгән уеннарны уйнап чыгып, кичкә таба гына авылга кайттык. Элек бар иде шулай экскурсиягә йөрүләр, хәзер онытылды шикелле инде. Бер таныш укытучы белән бу хакта сүз кузгаткан идем, кул гына селтәде.

– Авыртмаган башка тимер таяк. Нәрсәгә кирәк? Берәрсе аягын авырттыра, икенчесе чалбарын ерта, йә елан чагар үзләрен, чирләп кайтырлар. Ю-ю-к, өйдә генә утырсыннар, – диде. Ә безгә нык ошаган иде ул истәлекле көн. Рәхмәт инде Галимҗан абыйга.

Андый хәлләрнең чуты-саны булмагандыр дип уйлыйм мин рәис тормышында. Күп кешеләр ихлас күңелдән рәхмәт укыганнардыр укытучыма. Ул эшләгәндә, багана башларына лампочкалар куелды, һаман да авылның яме булып торган парк эшләнде. Ул парк турында киребеткән адәмнәр гел кирегә сукаладылар. Нигә кирәк, фәлән-фәсмәтән, шәһәрдә юк нәрсә авылга төсме, берәү дә аяк басмас. Үз сүзендә торды Галимҗан абый, трактор белән җирне тигезләделәр, бар авыл халкы, без, укучылар шул исәптән, урманнан кайтартып төрле агачлар утырттык, кечкенә күл кебек нәрсә казылды. Тигез аллеялары, уңайлы урындыклары, тренажёрлары, сәхнәсе, тагын күп төрле күңел ачу урыннары булган парктан кешеләр өзелми. Мин утырткан агач та бар анда, чыршы агачы. Чыршы, гадәттә, үсеп китә алмый, бераздан соң корый. Ни хикмәт, тамырланган, күкрәп утыра.

Соңгы елларда үз теләге белән тагын мәктәпкә кайтты ул. Олыгая башлагач, җаваплы рәис йөген тарту авырлаша башлагандыр. Урыны мәктәп иде аның. Балаларга кирәгрәк иде ул. Аның укучылары булган балалар – бәхетле балалар.

Укытучым турында мин тагын күп нәрсәләр сөйли алыр идем әле. Мал җыймады, Брежнев заманнарында бер мотороллер алган иде, шул җитте аңа. Бар иде ике көпчәкле «Турист» дигән җитез матайлар. Хәзер аларны музейдан да эзләп таба алмассың. Әллә кем булып борын күтәрмәде, кешелекле, кечелекле булды. Теләсә кем аның янына килеп, сүз куша ала иде. Сораганнарга кирәкле киңәшләр бирде, юатканын юатты, кайгыларын уртаклашты, кирәк чакта шым калып янында тора белде. Яңа өй дә юнәтмәде ул, шул атайлар нигезендә гомер кичерде, шул булганына канәгать була белде. Балалары әдәпле, тәртипле булдылар, барысы югары белем алдылар, илнең төрле төбәкләренә таралыштылар. Әтиләренең исемнәренә тап төшермиләрдер дип уйлыйм.

Сирәк кенә кайткан чакларда мин зиратка барам, якыннарымның каберләрен зиярәт кылам, тәртипкә китерәм, белгәннәремне укыйм. Зират ул кайда да моңсулык урыны, ялгызлык урыны. Сак кына басып, хөрмәт белән башымны иеп, рәшәткәләр арасыннан үтәм. Танышларның фотолары куелган тактаташларга тарып, туктап калам, хәтер истәлекләрне яңарта. Бу танышлар, якыннар, авылдашлар арасында булмас инде минем җәсәдем, дип өзгәләнәм. Ник дигәндә, бик еракта минем йөргән юлларым. Кем кайтарсын мине кыйтгалар үтеп туган туфрагыма? Бик тә якын йөзне күреп, шып тукталам. Көләч йөз, болыттай чәчләр, сине үтә күрә торган акыллы карашлар. Исәнме, укытучым! Тамакка төер тыгыла. Озак яшәмәгән икән үзе. Җәмгысы алтмыш ике яшь. Бүгенге көндә мин аннан олырак инде. Әмма барыбер мин аңа укытучы дип эндәшәм, абый дим. Аның тәрбиясе һаман минем вөҗүдемдә, хәлемнән килгән кадәр мин аннан алган җәүһәрләрне балаларыма, оныкларыма күчереп калдырырга тырышам. Шулай булгач, яши әле ул минем янымда, уйларымда, хисләремдә. Миндә генәмени, йөзләрчә кешеләр аны хәтерлиләрдер, еш исләренә төшерәләрдер, рәхмәтләр укыйлардыр. Минем моңа иманым камил.

Электән миндә бер гадәт килә. Әгәр күңелемә яткан берәр яхшы эш майтарсам, шатланып елмаям да ишетелер-ишетелмәс кенә әйтеп куям: «ЧТД...» Үзем өчен генә. Әллә тагын берәрсенә барып ишетеләдер әле бу хәрефләр, кәефләнеп куядыр укучысы өчен...



*Гөлнур Сафиуллина (Хәсәншина). Кайбыч районы Кече Кайбыч авылында туган. Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлаган. Утыз елдан артык «Сөембикә» журналында эшли, баш мөхәррир урынбасары. Хикәяләре «Сөембикә», «Мәйдан» журналларында басылганы бар.*

Гөлнур
Сафиуллина

# ИКЕ БӨРТЕК

хикәя

– Кызым! Кайтып та җиттеңмени?!

Энҗе аңа күтәрелеп кенә карады да өстен дә салмыйча ашыгып, дәү әнисе яткан бүлмәгә узды. Керүгә бүлмә ишеген ябып ук куйды. Кашы-күзе җимерелгән, төсе-кыяфәте юк – ниндидер күңелсезлеккә тарыган, ахрысы.

– И-и бала...

Кинәт кенә йөрәгенең хәле китүен тойды Галия – тәрәзә янындагы урындыкка барып утырды. Бөтен нәрсәгә ияләшеп була, тик үз балаңның сине чит күрүенә, алай гына да түгел, дошман итүенә күнеп булмый икән. Сабыр итте бит инде, бик озак сабыр итте. Үсәр, үзе барысын да аңлар дип көтте, бөтен түземлеген җыеп, ничә еллар буе көтте... Кызы борчуын сөйләсә, аны Галия аңламас идемени?! Бөтен эшен ташлап, тыңламас идемени, кирәк булса, киңәшен бирмәс идеме?! Юк бит, юк, ике атна буе күрмәгән әнисенә «исәнме» дип тә дәшмичә, шул бүлмәгә керде дә китте бит әнә тагын.

Бер гамьсез болай утырып торып булмас, Энҗегә ни булганын ничек тә белергә кирәк бит. Йөрәкнең хәлсезлеге дә узды шикелле.

Туктале, елый түгелме соң бу бала? Әйе, елый шул! Нидер такмаклый-такмаклый үкси бит!

И-и Раббым, ниләр генә булды икән соң?

Галиянең әкрен генә бүлмә ишеген ачканын икесе дә сизмәде бугай: урында яткан каенанасы да, аның караваты янындагы урындыкка утырып, башын дәү әнисенең куллары өстенә салган кызы да.

– Нишләргә соң инде миңа хәзер, дәү әни? Нишләргә?! Яратам бит мин аны, беләсең... Аннан башка беркем кирәкми миңа! Айдар үзе дә: «Яратам! Синнән башкага өйләнмим!» – диде бит... Ә әнисе, әйттем бит инде: «Саниянең оныгын капкамнан барыбер кертмим! Энҗе дип авызыңны да ачма!» – дигән... Әбисенә охшаган, ди икән... Аның кебек каты күңелле дип әйтә, ди... Нигә алай ди икән ул, дәү әни? Син бит шундый әйбәт... Дәү әни, бәлки, Айдарның әнисе белән үзең сөйләшеп карарсың? Телефоннан да була бит... Мин номерын җыеп бирәм, син сөйләшерсең... Нигә яратмыйдыр сине, аңламыйм! Әгәр әнисе чынлап та Айдарга өйләнергә рөхсәт итмәсә, нишләрмен?!

Эчкә узарга да кыймыйча, ишекне ябып, кире борылып китә дә алмыйча бер урында тораташтай басып торды Галия. И Ходаем, барысы да яңадан кабатлана түгелме соң? Боларның барысы да таныш, кичә генә булган кебек таныш лабаса аңа!

...Ул кичне – кино беткәнен дә көтмичә, клубтан икәү җитәкләшеп чыгып китте бит алар. Чыктылар да, гадәттәгечә, югары очка – Галияләр урамына түгел, түбән урамга – Илшатларга таба борылдылар. Кино кайгысы калмаган иде. Илшат клубка керүгә аның янына килеп утырды да колагына: «Мин бүген әниләргә: «Өйләнеп кайтам!» – дип әйтеп чыгып киттем!» – дип пышылдады. Ул арада ут сүнде. Егет караңгыда аның кулларын эзләп тапты – шундый кайнар иде кулы...

Нигә алар икәү генә кайттылар, нигә озатырга дусларын чакырмадылар, анысын Галия ул чакта уйламады. Уйларлык хәлдә түгел иде. Ниһаять, аның җаны бүген тынычланачак. Югыйсә инде ничәмә-ничә атна күзенә йокы кергәне юк бит. Илшат нигәдер бу көнне сузды да сузды... Соңыннан бу хакта үзеннән әллә ничә тапкыр сорарга талпынса да, сүз чыгармады. Искә дә төшерәсе килмәгән кич бит ул... Хәер, җавабын чамалый иде Галия: ире ул көнне барысы да шулай тәмамланачагын алдан ук белгән, сизгән. Әмма барыбер яхшыга өметләнгән, күрәсең. Галиянең кулын кысып тотты да юл буенча эндәшмичә кайтты ул. Әйе, бер сүз дә сөйләшмәделәр бугай. Хәлим абыйлар турысына җиткәч, туктап озак кына үбештеләр – анысы истә.

Илшатлар өенең бер генә тәрәзәсендә дә ут янмый иде. Галиянең эченә шунда ук шом керде: хәерлегә түгел бу... Йокларга ятарга иртә бит әле – сәгать тугыз да тулмаган. Аннан Илшат: «Өйләнеп кайтам дип әйтеп киттем», – диде бит. Тирә-күршеләрнең берсендә дә ут сүнмәгән әнә. Бары алар йорты гына караңгылыкка чумып утыра. Ничектер куркыныч булып... Капканы ачып, ишегалдына уздылар. Веранда ишеге бикле иде. Озак кына шакыгач, өйалдында ут кабынды.

– Кем бар анда?

Илшат аның кулыннан чытырдатып кысып тотмаган булса, Галия, мөгаен, шул минутта ук борылып ишегалдыннан чыгып та чапкан булыр иде. Хәер, бәлки, чапмас та иде. Хәлләре андый түгел иде бит...

– Без кайттык, әни!

Веранда тәрәзәсенең челтәре күтәрелде.

– Ничек кайтсагыз – шулай китәрсез! Бая әйттем бит инде – алмыйсың ул кызны, дидем! Өйләнмисең аңа! Рөхсәтем юк!

– Әни!

– Нәрсә тагын? Кертмим дидем бит! Бар, озат үзен! Әнкәсен сөймим! Үзен сөймим! Ни матурлыгы, ни байлыгы дигәндәй... Тапкан өйләнергә хатын!

Каенанасының ул чакта әйткән бөтен сүзләрен дә хәтерләми инде Галия. Кайсысын ишетте, кайсысын юк. Аяк астында әкрен генә җир шуышты... Колагы, башы шаулый башлады... Веранда ишеге ачылмаячак, ачылса да, аны эчкә үткәрмәячәкләр. Аны бу йортта Илшатка тиң санамыйлар.

«Нишләрмен? Мин хәзер нишләрмен?!» Үзәге өзелеп, шулай уйлаганы исендә Галиянең. Алар ишегалдыннан ничек чыгып китте, Илшат аны ник туктатмады, ничек үзләренең капка төбенә кайтып җитте – боларның берсен дә белми. Өйләре турысына кайтып җиткәч кенә айнып киткәндәй булды. Инде ничек өйгә керергә? Юк, башта Илшатны көтәргә! Хәзер, артыннан

ук килеп җитәр ул. Юатыр, тынычландырыр. Алга таба нишләргә икәнен уйлашырлар. «Мин сине беркайчан ташламаячакмын! Ышан миңа!» – дип бер түгел, йөз кабатлады бит.

Капка төбендә шактый озак утырды ул кичне Галия. Барысын да ишетеп утырды. Клубта кино бетеп, яшьләр урамга таралды. Кемнәрдер кычкырып көлде, ул яңгыравыклы көлүне матай тавышы күмеп китте. Аннан барысы да тынды. Күрше Равилнең кызын озатып кайтып, капкаларыннан кереп китүен дә ишетте. Кәефе әйбәт иде бугай – нидер көйли-көйли кайтты. Барысын да ишетеп торды Галия, Илшатның аяк тавышларын гына ишетмәде. Килмәде...

Капка төбендә төн кунып булмый – керергә кирәк иде. Теше тешкә тими калтырый: әллә туңудан, әллә эчтәге тынычсызлыктан. Үз-үзеңне күпме кочаклап утырсаң да, җылыта алмыйсың шул.

Бер генә адым атлады да кинәт туктап калды. Менә ничек була икән ул! Балага җан керү менә ничек була икән... «Ләйсән! Ләйсәнем! Балакаем минем!» Ул карындагы сабыйның кыз бала булачагына бер тамчы да шикләнми иде. Исемне дә инде әллә кайчан уйлап куйды – Илшатка бу яңалыгын җиткергәнче үк. Ләйсән дип кушачак ул нәни кызына! Курчак кебек матур булачак ул, бик сөйкемле булачак – Ләйсән исемле кызлар башкача була аламыни?! Бу серен әлегә берәүгә дә белгертә алмавы гына менә... Әнисенә дә әйтеп булмый, апасына да. Илшат сабырсызланды шул, аның: «Юк, ярамый! Кирәкми!» – диюен ишетмәде. Соңыннан мең тапкыр гафу үтенде дә бит... «Нигә борчыласың? Без бит барыбер бергә булачакбыз!» – дип тынычландырды. Тик үзе өйләнергә генә ашыкмады. Хәтта кызның инде ут өстендә йөрүен белгәч тә. Сәбәбе булган икән...

И-и, анысы ут өстендә йөрү булмаган икән әле.

Шул кичтән соң Илшат югалды.

Икенче атнаны клубта да күренмәде ул. Галиянең ишек ачылган саен өметләнеп көтүе юкка булды. Бәлки, капка төбендә көтәдер дип, кинодан ашыгып өйгә кайтты – алар утырырга яраткан бүрәнә өсте буш иде. Килмәде...

Авылга башка кайта алмый иде инде ул. Түгәрәкләнеп килүеңне кешедән ничекләр качырып бетерәсең?! Чит-ятлардан яшерерсең дә, ә өйдәгеләргә ничек белгертмәскә? Киң күлмәк киеп кенә котыла торган хәлмени?!

Егерме бер атна, егерме ике, егерме өч...

Бала көткән хатын-кыз вакытны атналап кына саный.

«Син бит корсаклы» дигән сүзне иң элек эштә әйттеләр. Ике-өч бала тапкан хатыннар синдәге мондый яңалыкны сизмимени инде?!

– Нишләргә уйлыйсың? – диде Альмира апасы, беркөнне кайтырга чыккач. – Көтәбез, көтәбез, үзең һаман ачылмыйсың. Инде декретка китәр вакытың җитә түгелме?!

– Белмим...

Башка әйтер сүз тапмады Галия.

– Илшат дип авыз да ачканың юк. Егетләр шулай инде алар, үз дигәннәрен алалар да югалалар... Авылга да кайтканың юк шикелле, өйдәгеләрең беләме әле?

– Юк...

– Тулай торакка сине бала белән кертмәячәкләр. Монысын, шәт, беләсеңдер инде?

– Беләм...

Күңелен бушатыр, киңәш сорар бер якыны юк икән бит Галиянең. Юк андый кешесе, юк! Кырын караучысы, гаеп итүчесе әнә адым саен. Үзе дә, тиздән туачак кызы гына бар икән аның. Эшкә барганда да, кайтканда да, күңеленнән гел сабые белән сөйләшеп йөрде Галия: «Син борчылма, Ләйсәнем, бар да әйбәт булыр! Барыбер бер юлы табылыр!» Бертуктаусыз шулай кабатлап йөрү күбрәк үзен тынычландыру өчен кирәк булган икән аңа. Югыйсә бит бу уйлардан акылдан шашарсың...

Башта апасы килеп китте.

Галия ул көнне кичке сигездә генә кайтып керде. Соңгы вакыт эштән чыккач, автобустан төшеп кала да ике-өч тукталыш әкрен генә җәяү атлый. Һавада йөрү дә була, аннан бүлмәдәге кызлар янына кайтып керәсе килмәве дә хак. Сораулы карашлар болай да ардырды. Гел ялгыз каласы килә. Көнгә бер булса да елап, бушанып аласы. Тик инде хәзер елау да хәлне җиңеләйтми – күңелдә авырлык кына кала...

Бүлмәдәш кызлар апасына яңалыкны җиткерергә өлгергәннәр – Галия моны ишекне ачып керүгә аңлады. Апасының күзләрендә ачу, үпкә, нәфрәт, тагын әллә ниләр... Җәлләү юк, кызгану да. Аңларга теләү дә.

– Булдыргансың! Хәзер миңа да караучы булмас инде... Сеңлесе кебек җилбәзәк, диярләр. Берүзең ничек үстерергә уйлыйсың инде балаңны?! Кайда яшәрмен дип беләсең? Әллә бала күтәреп, авылга кайтырмын дип өметләнәсеңме? Аннары безгә нишләп бетәргә? Миңа, эти белән әнигә? Ә Илшатыңны көтмә – Себергә чыгып киткән ул...

Ни гомерләр Илшат турында бер хәбәр ишетмичә яшәгән иде. Менә ишетте...

Әнисе Яңа ел алдыннан килде.

Кызлар эштә, Галия өйдә берүзе, кер үтүкләп ята иде. Әнисе елады да елады. Түгәрәкләнеп тулган кызына күтәрелеп карамаска тырышты, гел читкә карап сөйләде.

– Әтиең авылга бала күтәреп кайтмасын дип әйтеп җибәрде... Болай да халык сөйли инде. Кемдер сине автобуста күргән, корсаклыга охшаган дигән. Урамнарга чыгып, күренеп йөрмә инде. Без сине сораучыларга: «Укый да, эшли дә быел. Бик еш кайтып йөри алмый», – дибез...

Шуның белән шул... «Кызым, хәлең ничек?» – дип тә сорамады. Кайчан туар бу бала да димәде, аннары нишләргә, кайда яшәргә уйлыйсың дип тә кызыксынмады. Акчаң бармы, балага нәрсә булса да алдыңмы әле, дип тә белешмәде. Галиянең ясап куйган чәенә дә кагылмады – ул шул килеш суынды.

– Без икәү генә, кызым... Син дә мин...

Әнисе артыннан ишек ябылгач, Галия тагын шул сүзләрне кабатлады.

– Без синең белән ике бөртек, кызым... Ике ялгыз бөртек...

...Бала тудыру йорты тулай торактан ерак түгел иде – җәяү генә дә барып җитеп була. Тулгак кызлар эшкә киткәнче үк сиздерде, әмма йокларганга салышып, түзеп ятты. Аннары әкрен генә җыенды.

Ике урам узып барып, бала тудыру йорты ишеген ачып керү – сират күперен кичү белән бер булды. Бил тирәсендәге авыртуга түзмәслек түгел иде әле. Яңа аңлады – бүгенгә кадәр күңелдә барыбер өмет яшәгән икән. Илшат кайтыр... Бүген булмаса, иртәгә кайтыр. Иртәгә булмаса, берсекөнгә...

Үзе белән алып китәр... Инде аңлады, кайтмаячак... Ходай җәлләсен – бала тапканда гомерен алсын иде. Нишләрләр, кабере янында елап басып торырлармы икән? Әтисе, әнисе, апасы? Ә Илшат күмәргә кайтырмы икән? Аңа бит барыбер кемдер хәбәр итәчәк. Юк, күмәргә үк кайтып өлгерә алмас, еракта ди бит, кабере янына аннары ялгызы гына килер инде. «Кичер», – диярме икән? Галиянең күзләренә мөлдерәп яшь тулды...

Аны кабул иткән шәфкать туташы хатынның күзләреннән бертуктамый аккан яшькә игътибар да итмәде. Телефоннан кем беләндер сөйләшә-сөйләшә, алдындагы кәгазьләрне тутырды.

– Туган көнгә сине дә чакырдымы? Барырга уйлыйсыңмы соң? Мин нәрсә кияргә белмим әле... Әйе, ул күлмәкне кисәм була. Ә бүләк белән нишлибез? Икәү кушылып алсак? Ярар, алайса, шулай итәрбез... Карале, теге Максимованың баласын алдылар бит. Сөйләгән идем ич, курчак кебек матур малай дип. Безнекеләр чират торып карарга йөрделәр... Шундый әйбәт гаилә алып китте. Бөтенебез сөенеп калдык. Максимова ул балага нәрсә бирә ала иде инде? Ни эше, ни торыр җире юк... Ә болар икесе дә урында эшли, диделәр. Балалары булмаган. Ире гаебе белән, ди, ахрысы... Яхшы яшәүләре күренеп тора. Бәхетле бала булган икән, әйеме...

Тулгак араларын санарга кушты да, «Әле иртә», – дип, табиб та чыгып китте. Галия палатада берүзе калды.

Бер минут, ике, өч, дүрт, биш... Авырту бөтен гәүдәне куырып ала. Аннан берни булмагандай юкка чыга. «Җибәрде бугай», – дип куанырга өлгермисең, тулгакның икенче дулкыны кузгала... «Әйбәт гаилә алды», – диде теге кыз. Андый гаиләләр тагын бардыр бит ул. Ләйсән бәхетенә дә берсе килеп чыкмый калмас... Бер, ике, өч, дүрт, биш... Кызын күтәреп, кая барсын соң Галия?! Аны бит беркайда да көтмиләр. Баласын – бигрәк тә... Бер, ике, өч, дүрт... Кызым! Алма бөртегем, сиңа шулай әйбәтрәк булачак... Әниеңә ышан... Бер, ике, өч... Чынлап та әйбәтрәк булачак... Әйбәтрәк...

– Кызымны... Кызымны күрсәтегез әле!

Аның тирә-юнендә кайнашкан табиблар нигәдер ашыгалар иде. Тәүлекнең кайсы вакыты соң? Төнмени?

– Күрерсең! Әле бик күп күрерсең... Күрә-күрә арып бетәрсең!

Бер генә күз салса да, ул аны гомергә дә онытмаячак иде. Күрсәтмәделәр... «Аннары», – диделәр. Ял итәргә куштылар. Колакта елаган тавышы гына яңгырап калды...

Баш табиб бүлмәсендәге соңгы сөйләшүне дә сүзен сүзгә хәтерли Галия.

– Әйтте диярсең, баланың атасы янына киләчәк, бергә булырсыз... Аз гына сабыр ит. Кайт авылга. Куып чыгармаслар. Никадәр ачулансалар да, син дә аларга бала бит, кичерерләр... Кызыңны синнән артык яратырлар әле...

Башын аска иеп, дәшмичә генә тыңлады аны Галия.

– Сез аларга... Баланы алган кешеләргә: «Исемен Ләйсән дип кушыгыз», – димәссезме икән? Ул үзен Ләйсән дип белә, мин аңа сөйләшкәндә гел шулай дәшә идем...

Каршында утырган хатынга нидер аңлатырга тырышуның вакыт үткәрү генә икәне баш табибка көн кебек ачык иде инде. Тавышы кинәт кырысланды.

– Куша алмыйм! Анысы инде алар эше, минеке дә, синеке дә түгел!

Ә табиб дөрес әйткән! Нәкъ ярты елдан Илшаты ул торган бүлмәнең

ишеген шакыды. Җеназага кайткан. Әтисенең йөрәк өянәге белән кинәт вафат булуын ишеткән иде Галия.

– Җыен! – диде ул ишекне ачуга. Исәнләшеп тормады. – Әйберләреңне җый, авылга кайтабыз... Әни ризалыгын бирде. «Галиягә өйләнмим икән, авылга башка аяк басмыйм», – дидем. Ул минем төп нигездә калуымны тели...

Ияреп кайтты Галия аңа. Бүлмәдәш кызлары: «Шушы хәлләрдән соң да аны гафу итәсеңме? Һаман яратасыңмыни?» – дип шаккатып калсалар да, ни өчен ризалашуының сәбәбен ул үзе белә иде.

Бергә бер атна да яшәмәгәннәр иде әле, Галиянең әти-әниләренә икәүләп барырга да өлгермәгәннәр иде. Каенанасы ул көнне Коръән ашына чакырулы иде. Хатын тәвәккәлләде.

– Илшат, безгә Казанга барырга кирәк...

– Нәрсәгә? – дип сорады ире, аптырап. – Бүлмәңдә берәр әйберең онытылып калдымы әллә?

– Калды шул... Калды... Кызыбызны алып кайтырга кирәк безгә...

– Син аны төшермәгән идеңмени?!

Бала тудыру йортыннан чыкканнан бирле елый алганы юк иде Галиянең. Ул көнне түгелде генә... Ничә көн буена Илшатның бала хакында бер сорау бирмәве җанын тәмам кыйнаган булган икән...

Шәһәрдән буш кул белән кайтты алар.

Таныса да, баш табиб Галия белән сөйләшергә дә теләмәде – ул җыелышка ашыга иде.

– Тәрбиягә алдылар инде кызыңны... Юк, бернишләп булмый! Баланы курчак дип белдеңме әллә?! Нинди гаилә икәнен әйтә алмыйм – хакым юк...

Алга таба яшәп китә алмам дип курыккан иде ул чакта Галия. Яшисең икән... Моны яшәүгә санасаң инде...

Җанындагы бер бетмәгән авырту каенанасының кыланмышларына күз йомарга булышты. Берсе бигрәк тә истә. Ләйсәннең туган көне иде ул. Галия елдагыча иртүк күз яше белән уянды... Кемнәрдер аның кызын бәйрәм белән котлыйдыр, бүләк әзерләгәннәрдер. Ул аларга: «Әни! Әти!» – дип дәшәдер. Кочып аладыр... Кемгә охшаган икән? Чәче ни төсле икән... Озын итеп үстергәннәрдер инде... Кызлар бит шулай хәзер. Энҗенең дә бер дә кистерәсе килми әнә.

Бу көнне Галия гел томан эчендә йөргән кебек йөри. Быел да шулай булды. Үзе генә монда, ә уйлары әллә кайда... Очларына чыга торган түгел...

Каенана өстәл янына утыруга тавыш куптарды – Галия ашка тоз салырга оныткан икән. Беррәттән килененең мең гаебен искә төшерсә, бер хәл – ашны кәстрүле белән терлек чиләгенә илтеп салды. Монысы артыграк иде... Хәтта башка вакыт алар арасына кысылмаган Илшат та:

– Әни, тозны өстәп тә була иде бит аны! – дип дулап, ишегалдына ук чыгып китте.

Икенче көнне өстәлгә артык бер тәлинкә, кашык китереп куйды Галия. Буш урындык, буш тәлинкә... Ләйсәннең урыны булачак бу!

– Кемне көтәсең? Килер кешең бармы әллә?

Каенанасының соравына җавабы әзер иде.

– Кемгә икәнен беләсең... Энҗенең апасына. Аның бит апасы да бар!

Галиянең тавышында, үз-үзен тотышында беренче тапкыр ныклык тоеп: «Исәр!» – дип кенә куйды да башка берни дәшмәде каенанасы.

Өстәлдәге артык буш тәлинкәгә озакламый барысы да ияләште. Ә Галия шул көннән каенанасы өчен «исәр»гә әйләнде. Илшатка нидер әйткәндә дә: «Теге исәр... Синең исәрең», – дип кенә сөйләшә торган булды. Ире кайчагында: «Әни, булды, җитте инде!» – дигәләсә дә, Галиянең үзенең исе китмәде. Әйтәсе килсә, әйтсен... Баштагы елларда да: «Нәрсәм ярамый икән соң бу әнигә?» – дип, гаепне гел үзеннән эзләп җүләр булды. Аннан аңлады – Илшат кемгә генә өйләнсә дә, барысыннан да гаеп табар иде ул. Аңа берәү дә ярамаячак. Олы улының хатыны белән дә шулай аларның аралары. Тик тегеләргә рәхәт – авылга сирәк кайталар. Ә Галия көн саен аның янында.

Каенанасына бер генә нәрсәне кичерә алмады ул – кызы Энҗене үзенә каршы котыртуын. Киленен яратмаса да, оныгын яратты. Бердәнбер яраткан кешесе Энҗе булды. Тегесе дә «дәү әни» дип үлеп тора бит. Кечкенәдән шулай иде. Урамга чыгарга теләсә, рөхсәтне дәү әнисеннән сорады, яңа киемне кибеттән аның белән генә барып алдылар, сере булса – аңа гына сөйләде... Хәтта мәктәпкә ата-аналар җыелышына да дәү әнисе баруын тели иде ул. «Мин аның кызы!» – дия иде. Озакламый дәү әнисенә ияреп, Галиягә дә «исәр» дияргә тартынмый башлады.

– Син аны аңлыйсыңмыни, исәр!

– Мин аны үзем дә беләм, исәр!..

– Син исәргә нәрсәгә әйтеп торыйм!

Энҗегә үпкәләмәскә тырышты Галия. Бала гына бит әле, үсәр дә, аңлар әнисен. Бер якынаерлар әле. Һич югы үзе әни булгач...

Җаны бик авырткан мәлләрдә Галия гел: «Каенанам урынга калсын иде дә, күземә карап ятсын иде», – дип тели иде. Кайлардан теленә кергәндер бу теләк... «Сезгә ышансаң, олыгайган көнеңдә картлар йортына илтеп тапшырырсыз әле!» – дигән сүзне бик еш кабатлый иде шул. Җай чыккан саен... «Юк, әни, алай итмәбез!» – дип акланып утырып булмый бит. Башыңны аска иясең дә үз эшеңне эшлисең. Ә эчтән генә теге теләкне телисең: «Минем кулга калсаң гына ярар иде...»

Теләге кабул булды әнә – өченче ел урын өстендә.

Килгән-киткән кеше шакката: «Ничекләр өлгерәсең, Галия?! – диләр. – Сания апаның урын-җиренең чисталыгы, башындагы яулыгының аклыгы!» Хәл белергә килүчеләрнең барысы да рәхмәт әйтеп чыгып китә, ул сүзне каенанасыннан гына ишеткәне юк.

...Энҗе тагын елый башлады.

– Дәү әни, акчасын үзем бирәм, төшер, дисең дә син, минем бит баламны табасым килә... Белеп торам – кыз булачак ул... Инде исемен дә сайладым. Ләйсән булачак! Айдарга да ошый... Матур исем, әйеме?!

Ләйсән диме?! И-и Раббым, бу нинди кабатлану соң?! Ул исемне ялгыш та берәүгә дә теленнән ычкындырганы булмады бит Галиянең.

– Кызым!

Каенанасы да, Энҗе дә ишек төбендә басып торган Галиягә борылып карады.

– Кызым! Төшермә, тап балаңны! Үзем үстерермен!

Энҗе шундук торып басты.

– Әни!

Энҗенең – кызының күзләре шундый җылы да була ала икән бит...

*Ләбибә Ихсанованың тууына – 100 ел*
*Венера Ихсанованың тууына – 90 ел*



*Татар балалар язучысы, прозаик, тәрҗемәче, публицист Ләбибә Ихсанованың ире, шагыйрь, тәрҗемәче Шәрәф Мөдәррис (1919–1963) белән сугыштан соң төшкән фотосы.*



*Ләбибә Ихсанова (сулда) һәм аның бертуган сеңлесе, журналист, мөхәррир Венера Ихсанова.*



*Гариф Ахунов Татарстан Язучылар союзы рәисе итеп сайлангач. Утырганнар (сулдан уңга): Шәйхи Маннур, Мирсәй Әмир, Гариф Ахунов, Ләбибә Ихсанова, Әмирхан Еники; басып торалар: Рафыйк Нәфыйгов, Атилла Расих, Шәукәт Галиев, Рафаэль Мостафин, Гали Халит. 1968 ел.*



*Классик язучы Чыңгыз Айтматов (сулдан беренче) бер төркем каләм ияләре белән. Сулдан өченче – Венера Ихсанова. 1972 ел.*



*«Казан утлары» журналы редакциясендә. Утырганнар (сулдан уңга): Абдулла Сәләхетдинов, Ринат Мөхәммәдиев, Ләбибә Ихсанова, Әхсән Баян; басып торалар: Рим Шириязданов, Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов. Узган гасырның 70 нче еллар ахыры.*

*Фотолар «Казан утлары», «Сөембикә» журналлары архивыннан алынды.*

# ЯНӘ ДӘ «ИДЕГӘЙ» ХАКЫНДА

*Фольклордагы теләсә кайсы эпик әсәр килеп чыгышы һәм формалашуы белән халык иҗаты жанрында үзенә кадәр урнашкан тотрыклы традицияләргә нигезләнә, эпос-дастаннар тарихында архаик чорлардан ук ныгып урнаша килгән кануннар кысасына сыеша. Бу кысаны, иң беренче чиратта, эпоста билгеле бер сюжетлар һәм мотивлар, деталь, элементлар кулланылу дәрәҗәсе билгели. Шуның белән бергә халык иҗаты әсәрләре сюжеты, каһарман образы, сәнгати чаралары белән үзенә кадәрге төрле тарихи чорлардагы карашларны, тормыш-көнкүреш чынбарлыгын да чагылдырмый калмый. Шуңа да теге йә бу эпик әсәрнең асылына төшенү өчен аның мәгълүм вариантларын барлап чыгу мөһим.*

*«Идегәй» дастаны, барлыкка килүеннән алып, алты гасырлык юл үткән, әсәр, яңара-яңара, безнең көннәргә килеп җиткән. Хәлбуки, мәшһүр дастанның эпос жанрындагы күп гасырлык традицияләрне чагылдыра алу потенциалы бик югары. Россиянең генә түгел, Евразия территориясенең күп өлешен үз туган туфрагы дип инанып гомер итүче татарларның эпик фольклорында «Идегәй» сюжетына игътибар шактый зур. Идел буенда, Себердә, Әстерханда гомер итүче татарларда да бу дастан бар. «Идегәй» әсәренең катлаулы язмышы аны озак елларга онытып торырга мәҗбүр иткәнен беләбез. Урау юллар аша булса да, мәшһүр дастаныбыз халыкка килеп җиткән, аның төрле вариантлары, шөкер, исән!*

*Игътибарыгызга татарның иң атаклы дастаны «Идегәй»нең поляк шагыйре, Көнчыгышны өйрәнгән галим, күп телләр белгече Александр Ходьзко тарафыннан Әстерханда татар кешесеннән – Галибәк Шараповтан 1830 елда татар телендә ишетеп, фарсычага тәрҗемә ителгән, соңыннан шулай ук А.Ходзько тарафыннан инглиз телендә Лондонда бастырып чыгарылган[1], шактый катлаулы юл үтеп, безгә килеп ирешкән вариантын тәкъдим итәбез.*

*Бу вариантта алгы планга татарларның үз араларыннан чыккан гайрәтле батыр Идегәйнең туган халкын чыңгызыйлар хакимлегеннән арындырырга омтылуы чыгарылган. «Идегәй» эпосы киң вакыт аралыгын һәм гаять зур тарихи вакыйгаларны колачлаганга күрә, дастанда әлеге мәгълүматларның әсәр эчендә таралып урнашканлыгы игътибарны җәлеп итә. Мәгълүм эпик мотивлар «Идегәй» дастаны сюжетында бер-берсенә бик нык керешеп киткәнлек тә үзен нык сиздерә. Фәнни җәһәттән дә, әдәби ядкяр буларак та, шулай ук, катлы-катлы тәрҗемәләр аша килеп ирешүенә карамастан, эпоска хас сурәтле телгә ия булу белән дә А.Ходьзко варианты – энҗе бөртегенә тиң милли хәзинә. Бу әсәрдә мәшһүр Сыбра җырау аһәңнәре җиңел тоемлана, фольклордагы эпик традицияләр чалымлана.*

*Тәрҗемәдә бирелгән материал Александр Ходзьконың кереш сүзе белән ачыла. Астөшермәләрнең авторы күрсәтелгәннәрдән калганнары барысы да – А. Ходзько искәрмәләре. Тыныш билгеләре, текстның махсус билгеләр белән аерымланган урыннары А.Ходзько тәкъдим иткән тәртиптә калдырылды. Әлеге вариант татар телендә әле беренче кат дөнья күрә.*

---

[1] Adiga / Chodzko A. Astrakan tatar songs // Specimens of the popular poetry of Persia. – London, 1842. – P. 348 – 362.

# ИДЕГӘЙ[2]

## Кереш

Бу тулгауны мин Әстерханга килгәч, 1830 елның кышында татар дусларымның берсе Галибәк Шараповтан ишеттем. Укымышлы һәм туган телен тирәнтен белүче кеше буларак, ул миңа, сүзен сүзгә фарсы теленә тәрҗемә итеп, тулгау эчтәлегенең мәгънәсен аңлатып бирде, ә мин ул әйтеп торганнарны язып алдым.

Соңыннан миңа әйтүләренчә, әлеге тулгау җыентыгы рус теленә тәрҗемә белән тулыландырылып, Кырымдагы ефәк тукучы фабрика инспекторы Фон Коппен (Von Koppen) әфәндегә җибәрелгән, ул аны бастырып чыгарырга ниятләгән булган. Әмма басылып чыккан җыентыкны беркайчан да күргәнем булмады, аның турында берни ишетелмәде, шул сәбәпле биредә текстның үзен бирергә булдым, мин аны Али Бек (Галибәк) һәм шул илнең җыраулары аша миңа килеп ирешкән вариантта бирәм.

Бу эпик поэмалар бик борынгы санала. Алар Уралдан алып, Кумагача[3] яшәгән татарлар арасында бик популяр. Җыентыкка урнаштырылган җырларның иң борынгысы, мөгаен, XIV йөз ахырына таба яисә XV йөз башларында иҗат ителгән булгандыр. Профессиональ җырауларның (алар безгә скандинав скальдларын хәтерләтә) нәселдән нәселгә тапшырыла килә торган осталыклары бүген көннән-көн югала бара. Алар нинди булганнар соң, дигәндә, иң яхшы үрнәк, бәлки бердәнбердер дә, ул – үзе шагыйрь дә, үзе тарихчы да, ватанпәрвәр һәм ханның зирәк, гадел киңәшчесе Сыбра җырау.

**Александр ХОДЗЬКО[4]**

## ИДЕГӘЙ

[Җыентыкта бирелгәннәре арасында иң озыны һәм әстерхан татарларында иң популяры булган бу тулгау халыкны монгол бәйлелегеннән азат итү дәвере хакында сөйли. Ул нугай татарлары диалектында язылган; аның иң матур өлеше Сыбраның җавабы белән төгәлләнә. Башка өлеше, миңа калса, апокрифик характерда һәм шактый соңгырак чорда шигый татарлары тарафыннан өстәлгәнгә охшаган. Анда көнчыгыш поэзиясенең кайбер нечкә үрнәкләре чагылыш тапкан, әмма шул ук вакытта ул борынгырак беренче өлешенә хас гомерча гадилектән мәхрүм.]

Куркусыз Идегәй вакытында аның халкы рәхәт яшәгән, аның биләмәләре чәчәк аткан. Аның кул астындагыларның бергә җыела торган гадәтләре булган, шул чакта хан бияләр суярга, бал куярга әмер биргән. Бөтен кабилә-ыруны чакырганнан соң ул Сыбра җырауны – тешләре селкенеп торган, әмма зирәк акыллы, кеш бүрек кигән өч йөз алтмыш яшендәге картны – үз алдына китерткән.

«Идегәй сугышчы улы булган, Раббыга ул балачактан хезмәт иткән. Идегәйнең туры атының ялы ерактан ук ялтырый. Идегәйнең Аллаһ ярата торган сыйфаты бар: каршысына килүче кеше аннан бер генә яшькә өлкәнрәк булса да, Идегәй: «Солтаным минем! Ни телисең? Сөйлә!» – дип, хәлен белешә».

---

[2] Материал тәрҗемәгә түбәндәге чыганактан алынды: Эдиге: ногайская эпическая поэма / под ред. Н.Х. Суюновой; Карачаево-Черкесский институт гуманитарных исследований при Правительстве КЧР. М.: Наука, 2016. 512 с. А.Ходзьконың кереш сүзе белән бирелгән «Идегәй» дастанының әлеге варианты җыентыкның 55 – 64 нче битләрендә урнашкан. – Л.М.

[3] Карачай-Черкессиянең көнчыгышындагы калкулыктан башлангыч алып, Каспий диңгезенә коя торган елга исеме, гидроним. – Л.М.

[4] Александр Ходзько – Александр Леонардович Ходзько-Борейко (1804 – 1891), полякча Aleksander Chodźko, поляк шагыйре, көнчыгышны өйрәнүче белгеч, күп телләр белгән филолог. – Л.М.

***

«Мәрхәмәтле бәндәләр! Сез миңа әйтәсез: «Сөйлә безгә ни дә булса, әй, җырау!» – дисез. «Яхшы, сөйлим, әмма ни сөйләргә соң сезгә, әй, мәрхәмәтле тыңлаучым? Бу үз атасының мактаулы улы, гайрәтле ир, үз анасының бердәнбер баласы. Тумышыннан ул асылу җәзасына хокукка[5] ия. Ул бар китапны да укыган, күктән иңгән дүрт китапның дүртесен дә ахырынача укып чыккан: Библияне, Псалтырьны, Инҗилне, Коръәнне. Ул изге Мәккәдән кайтартылган зәмзәм сулары белән тәһарәтләнгән. Келәм җәяргә кушып, ул аның өстендә гыйбадәт кылган. Тугыз яшь тулгач, ул Туктамыш ханга[6] хезмәт итүгә керешкән. Ундүрт яшендә аны, мәшһүр ирләргә тиеш булганча, тәхеткә утыртканнар. Ул тәхеттә ныгып урнашкач, Туктамыш хан үзенең хатыны Тулай Ханымның Идегәйгә күзе төшәр дип, куркуга калган, шул сәбәпле ул Идегәйне эзәрлекләргә тотынган».

«Идегәй, ханның үзенә мөнәсәбәте үзгәргәнне сизеп, үзе белән тугыз кешене алып, далага казакъ чыгып киткән[7].

Туктамыш, бу хакта ишеткәч, Идегәй артыннан тугыз сугышчысын куа җибәргән. Кыргыз ыруыннан Омрук Тимер, Кырымнан Кара Хуҗа, кыпчак ыруыннан Җантай Кусса, Кенәгәс ыруыннан Кобан улы Җамбай... Алар бар көчләренә Идегәй артыннан чапканнар, чапканнар да кире борылып кайтканнар. Ни күргәннәр соң алар анда?»

«Әй, Ханыбыз безнең! – дип кычкырган Җамбай. – Тәнем корыч белән каплаулы, кылычым кынында, алай да син җанымны харап итәрсең дип куркам мин!»

«Курыкма, җаным белән ант итәм! Ни күргәнең-ишеткәнеңне барысын сөйлә миңа!»

Шул вакыт Җамбай боларны сөйләп биргән: «Әй, Ханым минем! Син миңа барырга әмер иттең, мин киттем. Мин аны, Идегәйне, куып җиттем. Әйттем аңа: «Кире кайт, бердәнбер улым минем, үз йортыңа әйләнеп кайт. Ханга күңелеңне борчыган нәрсәләр хакында үз телең белән сөйләп бир. Ханның биек ак чатыры каршында аңа баш и. Затлы кытай фарфор чынаяклардан хәрбиләрдән калганны эчеп куй. Ханның сиңа бихисап бия өере бирәсе килә, син кымыз[8] эчсен дип. Ул сиңа үз лачыннарың белән Караялның[9] җиде күлендәге аккошларны ауларга рөхсәт бирә. Ул сиңа Карадай көтүлеген бирә, ул көтүлектә ауга чыгарлык атларыңны йөртерсең дип. Алар тазарсыннар, ботлары арыслан ботыдай булсын. Ханның мәшһүр көбәсе бар, аны белмәгән берәү дә юк: ул йомшак күн кисәкләреннән яхшы корыч боҗралар белән аралаштырып эшләнгән, эчтәге күлмәге көрпәктән[10] ясалган. Шул көбәне яка итеп ал, аның тузанын кагып төшер дә үзеңнеке итеп ки. Хан чатыры каршында уң якта да, сул якта да ике кадерле урын бар, шул урыннарның уңдагысы сиңа булыр, барып ал. Анда теге яклап та, бу яклап та күпсанлы хезмәтчеләр бар, кил дә аларның барысының да агалары бул. Синең хатының Омар Бегум – Әмир Хуҗа кызың, Туктамыш идарә иткән вакытта рәхәтләнеп хөрмәтлә аны, үп аны һәм аның белән йоклап бәхетле бул!»

«Аһ син, антыңа хыянәт иткән җан! Эт син, Җанбай! Синең атаң затсыз нәселдән, ә үзең – алтын колы. Миннән ераграк кач һәм үз җырыңны миннән читтә ула, яме! Авызыңны ачмаган килеш телеңне өзеп алырмын; аңкавыңнан асып куярмын һәм дөрләп янган чыбык очы белән маңгаеңа тамга салырмын. Кире кайтмам мин, үз йортыма әйләнеп кайтмам. Мин хан алдына барып авызымны ачмам, күңелемдәге хәсрәтемне сөйләмәм, минем телем усал сүзләрдән авырайган. Мин ханга түбәнчелек

[5] Асылу җәзасына хокук – татар морзалары арасында җәзаның мондый төре өстенлекле саналган.
[6] Туктамыш хан – бу шәхес 1395 елда Тимерләнктән җиңелгән Туктамыш хан булса кирәк.
[7] Казакъ – бу сүз кыпчак далаларында гомер итүче татар, калмык, кыргыз, үзбәк һ.б. халыклар арасында законнан тыш, кануннарны санга сукмыйча, тулысынча үз коралына гына бәйле яшәүче дигәнне аңлаткан.
[8] Кымыз – бия сөтеннән әзерләнә торган эчемлек, татарлар арасында бик популяр.
[9] Караял – Идел тамагыннан ерак түгел урын.
[10] Көрпәк – сарык карынынан туганчы ук алынган бәрән тиресе.

белән баш имәм, аның биек чатырында (урдасында) муеным өстенә имән үсте, муеным агач булып катты. Ханның ташыяк чынаякларыннан аның эчемлеген эчмәм – моның өчен минем авызым артык нәзеккә әйләнде. Хан миңа барлык бияләренең сөтеннән ясалган кымыз тәкъдим итсә дә, кабып та карамам – йөрәгем артык нык авырта. Караялның җиде күлендәге аккошларны ауларга үз лачыннарымны җибәрмәм – кулымнан булдыклылык китте. Карадай көтүлегендә ауга чыга торган атларны башка көтмәм – минем авым уңышсыз. Хан миңа үзенең йомшак күннән яхшы корыч бөҗралар белән аралаштырып эшләнгән һәм аслыгы көрпәк ялтыравык көбә киемен бирсә дә, мин аны алмам, тузанын коеп, аны үземнеке итеп кимәм – җилкәләрем бик зәгыйфь. Мин урдада алгы якта уңнан урын алып утырмам – анда миңа дигән корыч казык үсеп чыккан. Мин аның уң як һәм сул як хезмәтчеләре өстеннән идарә итәргә теләмим – әмер бирү теләгем качты. Минем хатыным Әмир Хуҗа кызы Омар Бегум – шуннан нәрсә? Мин аны бик кыска гына арада да иркәли һәм үбә алырмын».

«Моннан тыш Идегәй ханга әмер итте: «Идегәйдә ни хакың бар? Ул – Аллаһ колы, үз хезмәте белән бары тик Аллаһыга гына бурычлы. Иленә тугры кеше буларак, синең бусагаңны ул беркайчан калдырмаган иде. Бик еш рәнҗетелүләр кичерде, аларның барысына да һәрвакыт түзде, хәзер шуларны үзең аның исенә төшерәсең. Мин тагын кайчан зәңгәр диңгезне һәм анда чөгәләр уйнаганны күрә алырмын – Аллаһ белә. Берәү дә менмәгән кыялар һәм кыргый далалар буйлап узасы юлымда миңа Аллаһ юл күрсәтмәс, дисеңме? Ач бүредәй, көнозын йокламаганда яисә мин, ялгыз юлчы, бәс белән капланып, җилгә каршы атлаганда, Аллаһ минем белән булмас дип уйлыйсыңмыни?»

Шулай әйтеп, Идегәй китте, ул казакъ булды. Туктамыш хан, моны ишетеп, шаккатты, аның рухы төште. Ул тирә-якка чатырлар куярга, аларны учаклар[11] белән ныгытырга әмер бирде. Күп бияләр суярга, мул итеп бал әзерләргә әмер бирде. Дәрәҗәле һәм тәҗрибәле картларны, гайрәтле һәм яшь сугышчыларны киңәшкә чакырырга кушып, төрле якка чапкыннар җибәрде. Барлык халыкны җыйды.

Иң элек ул шушы җыенның башлыгы Хәсән углы Ходайбирдегә мөрәҗәгать итте. Әмма Ходайбирде әйтте: «Мин моны аңлый алмыйм».

«Алай булса, мин Кенәгәс ыруыннан Кус углы Җамбай фикерен тыңлыйм. Минем корылтаемның[12] башлыгы син. Дәүләтемнең зур казанына син оеткы саласың. Сөйлә!»

«Әй, Ханым минем! Мин гаепле бүген. Мин ни әйтергә белмим».

«Алай булгач, Акмуса, син әйт!»

«Әй, Ханым минем! Аллаһның миннән дә картрак кешесе бар, ул инде туганыннан алып, өч йөз алтмыш яшь яшәгән, аның тешләре селкенеп тора, әмма зиһене ачык, ул кеш тиресеннән бүрек кия. Аның исеме Сыбра. Аны китерт».

«Алай булса, минем атларымны алтын арбага җигәргә куш, атларның тоягын алтын дага белән дагалат, дагалар тоякларга көмеш кадаклар белән беркетелгән булсын, ат ябуын алтыннан ясат, барсыннар да Сыбраны монда алып килсеннәр».

Алар юлга чыккан. Көпчәкләр җиргә арба тәгәрмәче бүкәне тиңентен баткан. Сыбраны тотып алып, хан каршына китергәннәр.

Хан аның сакалын тарарга һәм чистартырга әмер биргән. Тешләрен, селкенмәслек итеп, алтын җепләр белән бәйләткән.

Ул аңа хөрмәт күрсәтеп, түренә узарга чакырган.

---

[11] Учак – күчмәләрдә җир өстенә куелган рәттән ике таш йә кирпеч өстендәге казаннан гыйбарәт учак яисә мич. Алар арасында казылган җиргә йә утын, йә күмер салына һәм казан астын үрләтеп җибәрәләр. Ризык әзерләр өчен һәр гаиләнең шундый казаны бар, шуңа күрә күчмәләрдән салымны учаклар санына карап җыя торган булганнар. Мондый салымнар бездәге җан исәбенә салына торган салымнар белән бер түгел. Гади, әмма образлы татар телендә «бу кешенең учагы сүнгән» дигән гыйбарә аның дәвамчысы юк, йөрәгенә ут кабызучысы калмады дигәнне аңлата.

[12] Корылтай – Үзәк Азия күчмәләренең гомуми җыелышын аңлата торган киң билгеле термин. Чыңгызхан аны аеруча мөһим очракларда җыя торган булган.

«Әй Ханым минем! Сөйләргә әмер бирсәң, мин сөйлим. Әмма коры үләннең суы юк, коры сөякнең мие юк. Карт кешенең зиһене зәгыйфь. Хан канәгать калмас».

«Әй Ханым! Бу ак тәнле ирне эзәрлекләмә. Әгәр эзәрлекләсәң, халкың озакламый сугыш корбаны булыр. Аның нәсел башында Әбүбәкер Садыйк тора, аннан соң солтан Мөхәммәд, аннары солтан Ибраһим, аннары солтан Габбас, аннан солтан Хәмзә, аннан Хәлид, аннан Вәлид, соңыннан Госман, аннан соң Җәләлетдин, аннары Абдулхәлифә, аннан Сәлим, аннан Баба Тукла[13], аннары Турбай Курабчы, аннан Исламкая, аннан Кадыркая, аннан Котлыкая, шуннан соң бәһасе юк алмаз Идегәй».

«Әй Ханым! Син аны эзәрлекләмә. Әй Ханым минем! Мин күпләрдән өлкәнрәк. Мин бик күп бөек ирләрне күрдем, мин Әхмәтханны, синең карт бабаңның бабасы Чыңгызханны алтын киемнәрдән күрдем. Мин Караханны һәм Буракханны, Халкман Гурганны һәм Җучи ханны, Устимер ханны, әлеге тиңе булмаган ханны, мин шулай ук күрдем. Хивәдә булган чагымда егерме ханны күрдем, Үргәнечтә – өч ханны. Бохарада Габделхәер ханны, Сәмәркандта Җәйбәк ханны күрдем. Ташкентта бөек ханны күрдем, Җанибәк хан кодрәтенең шаһиты булдым. Ул чүлдә кыйммәтле зиннәтләр белән бизәлгән сарай төзетте, диварларына мең ат бәйләрлек мең бөжра тактырды.

Аның угылы Бирдебәк юмарт хан булды, мин аны да күрдем. Мин кемнәрне күрүемне ник атыйммы? Минем авызым ялган сөйли димә миңа».

«Синең яңак сөяге гайрәтле, муенында ялы уйнап торган атың тирә-юньне йотып һәм җилне узып сикертеп чаба. Белүемчә, бу качак, бу ак тәнле ир синең атыңда йөриячәк».

«Синең данлыклы көбә киемең! Аңа теләсә күпме атсыннар – аны ук тишә алмаячак. Сөңге атып карасыннар – ул һичнинди сөңгене үткәрмәс. Яңгыр койсын, давыл уйнасын – ул суны да, җилне дә үткәрми. Әлеге качак, әлеге ак тәнле ир синең көбәңне үзенә алып кияр».

«Әлеге качак, әлеге ак тәнле ир бик биек агачны туфрагыннан айбалтасыз йолкып ала».

«Әлеге качак, әлеге ак тәнле ир тугыз рәт таш өемен тупсыз да аудара ала».

«Әй Ханым минем! Синең тәхетеңне дүрт аягы һәм биш очы тота, һәр очында – якутлар. Синең чатырыңның бусагасы шомартылган корычтан ясалган һәм көзге кебек ялтырый. Баулары ефәктән, чатырың атлас белән капланган, иң очы кара кеш һәм ас тиресе белән тышланган. Чатыр уртасына терәк итеп куелган багана чиста алтыннан. Әмма бу чатырның очы, пеләш баштай, капланмаган килеш тора. Әлеге качак, әлеге ак тәнле ир синең чатырыңа керер. Аркасыз киң диванда айдай нурлы маңгайлы, лилия чәчәкләренә тиң кулларының кечкенә бакыр ыргакларга тиң бармакларын бөгеп, Җанибикә белән Каззайбикә ял итеп утыра, икесе дә кояш батканнан соңгы яктылык кебек нәфис, искиткеч гүзәл һәм алсу. Әй Ханым минем! Әүлиялыгымны тыңла: әлеге качак, әлеге ак тәнле ир аларның икесен дә бушка үзенә ала, аларны үз табышына әйләндерә ала».

«Комда аксыл таллар үсә. Әлеге качак, әлеге ак тәнле ир аларның берсен йолкып алып, аннан корык[14] ясый ала».

«Синең көтүләрең бихисап һәм анда атларның нindiләре генә юк. Әлеге качак, әлеге ак тәнле ир аларның барысын да куып алып китә ала».

«Әй Ханым минем! Син ул ак тәнле ирне эзәрлекләмә. Синең фикердәшләрең күп, алай да аны түбәнсетмә. Шушында сүзем тәмам. Авызымда куштанланып ялган

[13] Баба Тукла – әлеге персонаж кабиләдәшләр арасында мәшһүр сугышчы буларак кына түгел, ихласлык һәм тырышлык белән исламны үткәрүче дә. Ул бик күп калмыкларны мөселманлыкка кертте һәм Әстерханнан километр ярым көньяктарак Казакъ калкулыгы тирәсенә бик хөрмәтләп җирләнде, аның каберен әле дә күрергә мөмкин.

[14] Корык – очында аркан элмәге булган озын колга. Кыргый атларны тотканда файдаланылган. Черкесларның арканыннан аерыла.

сөйләү юк. Мин юраганнарның юш килмәвен телим. Мин аларның кысыр чүлдәге корыган үләнгә сыланып, үлән белән бергә юкка чыгуын телим. Әмма саклан: бу ак тәнле ир башыңны таптый күрмәсен».

«Шулай итеп, әй Аллаһ исеме белән! Син һәрвакыт Аллаһ рәхмәте мул төшкән бу кешенең акылында булдың. Син анда сакта торгандай тордың. Ул үзе гыйбадәт вакытында Галинең – Аллаһ арысланының билбавына чорналып, туры басып торды. Сугышта ул Галинең Дөлдөл атында чапты. Ялгызлыкка китеп, ул Кадер кичәсен көтте. Кадер кичәсе килеп җиткәч, ул, йокламыйча төнозын догалар укып, галим ирләр зирәклегенә ия булды: Ильяс белән Эздра аңа үзләренең могҗизаларын ачты».

«Ул, фәрештәдәй генә, көймәдә чөгә балыклары уйнап торган зәңгәр диңгезне кичеп чыкты. Иксез-чиксез чүлләрнең күрмәгән-белмәгән юлларында юлчыга Аллаһ үзе юлдаш булган. Ач бүрегә тиң, кояш батканнан алып таңгача, төнозын күз йоммыйча, ул җилгә каршы чапкан. Аның йомшак тиредәй шома маңгаена бәс сарган».

«Ниһаять, ул, күчмә халыкларның бай туктау урыныдай булып, Рамазанның ундүртенче кичәсендә күк йөзендә балкыган айга охшап, халыкка күренде. Шул рәвешендә кайтып җитеп, ул барлык дошманнарын дөньяның дүрт тарафына олактырды. Аллаһ аны гайрәтле ике дөя, ике аргамактан бердәнбер булып туган колын, ерткыч кош сыйфатлары белән бүләкләде, аны нурдан яралтты».

Ул: «Тәкъва ирләр изге Синай тавында гыйбадәт кыйлганда кайтып җиттем мин. Мин Кадер кичәсендә, фәрештәләр дөнья буйлап сибелгән вакытта дөньяга килгәнмен. Минем беренче күргән нәрсәләрем Кадер кичәсе күренешләре белән туры килде. Авызымнан чыккан беренче сүзләр «Лә Илаһы иллә Аллаһ» дигән сүзләр булды. Минем даным бөтен дөньяга таралды. Мин, белемлеләр сүзенә колак салып, изгеләр юлын өйрәндем. Укымышлы ирләр миңа сораулар белән киләләр иде, минем җавапларымнан авызларын ябарга мәҗбүр булалар иде. Мин зирәк һәм илһамлы булып тудым. Мин үземнең гыйлемем белән гарәп язмачылыгында бик тирән мәгълүматлы кешеләрне дә шаккатырдым. Мин иң катлаулы талисманнар үзенчәлеген дә бер караштан таный, шундый талисманнарны үзем төзи, муллаларга шуларны әйтеп тора ала торган булдым. Ак кисеядән уралган чалма, гади туфлиләр киеп, аһ орып елап, мин Аллаһыдан мәрхәмәт сорап ялвардым һәм ул минем догаларымны ишетте. Мин хуш исле үләннәр белән туклandым һәм Кәүсәр[15] елгасыннан су эчтем», – дип әйтә иде.

«Атланып йөрер өчен мин үземә җәннәттәге бер атны сайладым[16]. Мин, намазымда бер генә кирәкле сүз дә төшеп калмаслык итеп, сөннәт һәм ике фарызны кыйлдым. Мин Кербеледә дога укыдым һәм ком белән тәһарәт алдым. Минем тукталган җирем, гадәттә, тауләрдагы ак әрем арасы булды. Аруны-талуны белмичә, мин авыр юллар белән таулар аша үттем, мин саргаеп килә торган чүлләрне кичтем. Мин Аллаһ йортына да кердем. Мин, башымны җирдән күтәрмичә, аңа биш ел хезмәт иттем. Мин җәннәттә үземә чиста алтыннан сарай сайладым һәм анда өч йөз ел рәхәттә яшәдем. Җаным ул хәтле рәхәтлеккә түзә алмады, мин, аңымны җуеп, үлгән кешедәй, җиргә аудым. Таңда мәзиннәр азан әйткән вакытта җир өстендә уянып киттем».

«Мин Гарәфәтнең мәрмәр сарайларында булдым. Мин Пәһлеван Хәмзәнең бөек көрәштә сугышуын күрдем. Алтын тоткалы корыч кылычымны кулга алып, мин аңа ярдәмгә ашыктым. Мин Сөләйман пәйгамбәрне очраттым һәм аннан ярлыкау сорадым. Мин аннан мине падишаһ итеп билгеләвен үтендем һәм ул миңа тәхет бирде, мин аның

[15] Кәүсәр – мөселман оҗмахының күкнең сигезенче катындагы елгасы. Коръәннең бер сүрәсе дә шул исемдә.

[16] Барлык эпос-дастаннар да мөселманнарның төшләре һәм аларның экстаз хәлендә яисә әфьюн тәэсирендә күз алдына килгән күренешләре хакында сөйләнә. Мәгълүм Хәсән Сабах һәм аның дәвамчылары ырудашларының мистикага талымлы булуларына бәйле әлеге гадәтләреннән ничек файдаланырга икәнен белгәннәр.

үз кулыннан тәхет алдым. Әмма бөтен нәрсәне Аллаһ ярдәмендә башларга күнеккән гадәтем буенча мин гыйбадәтсез килеш тәхеткә утырырга теләмәдем. Кодрәтле Аллаһ минем теләгемне ишетте, Җәбраил фәрештә «Амин! Амин!» – диде».

«Шул рәвешле Аллаһ рәхмәтенә ирешеп, мин дүшәмбе көнне тәхеткә утырдым һәм үземнең сәфәремне дөньяның барлык тарафын карап чыгудан башладым. Мин, гыйлемле ирләр анда күптер дип, Тәвризгә килдем, бу зур шәһәрдә мин мәчеттә Аллаһыга өч ел хезмәт иттем».

«Минем кадерле иптәшем Ходайкол минем хәлемне белергә килде. Мин изге күңелле кешенең җаны кебек ак атымнан төшмичә рәттән ике ел ил гиздем. Мин урманлы Самара елгасыннан алып Алты Үзәнгәчә[17] бөтен илне гизеп чыктым һәм Аир Агатчы дип атала торган туктау урынына килеп җиттем. Мин Атчылы Тугайда[18] булдым, Аллабаста[19] булдым. Саяк шәһәрендә булдым, Боз Агачы туктау урынында, туфрагына тоз сеңгән Кончакта булдым. Далада Җегет Агрының теге ягында Баскынчак күле бар. Шул урында[20] мин үземнең дошманнарымны җимердем».

Идегәй үзенең Каранташ исемле атына атланып, шундый тизлек белән чабып китте, тузаннан һәм тирдән аның бите кап-кара булды. Ул ныклы бәҗралар кагарга боерды, иң җитез атларны сайлап алды һәм мөмкин кадәр күбрәк сугышчылар җыйды.

Туктамыш хан тәкәббер кыяфәттә үз гаскәре белән килеп җитте. Идегәй аның белән көрәште, аның башын үтмәс пычак очы белән ялалады да аны куып җибәрде.

Бу сугышта Идегәй бары бер генә хата җибәрде: ул үзенең Туктамыш чатырында калган каенатасы Хуҗа Котлы алдында башын артык каты иде һәм аннан үзенең элеккеге падишаһына каршы корал күтәрүе өчен гафу үтенде.

*«Идегәй» дастанының А.Ходзько варианты текстын*
*татар теленә тәрҗемә итүче, материалны журнал өчен әзерләүче һәм*
*кереш сүз авторы – филология фәннәре докторы*
**Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА**

[17] Урманлы Самара елгасыннан алып, Алты Үзәнгәчә – Кавказдан алып, Урал елгасы тамагынача дигәнне аңлата. Алты Үзән (фарсы елгасы Кызыл Үзән белән аваздаш) Идел белән Урал үзәннәрендә яшәүче Россия кыргызларының җәйге утрак урыннары буйлап ага торган елга.

[18] Атчылы Тугай – Иделнең сул як ярындагы Дербент калмыкларының җәйге туктау урыны, борынгы татар шәһәре Җагы Таҗи (оригиналда: Джаги-Таджи. – Л.М.) хәрабәләре тирәсендә («селитра шәһәре»).

[19] Аллабас – Красноярск тирәсендә.

[20] Әстерхан татарлары бу урынны, көрәш барган урын дип, ул көрәштә Идегәй монгол явын җиңгән дип, туристларга горурланып күрсәтәләр. Мин бу хакта тарихи хезмәтләрдә бер искә алу да таба алмадым. – Л.М.

# ЯШЬНӘП УЗГАН ГОМЕР

## РҮЗӘЛ ЮСУПОВКА – 85 ЯШЬ

Рүзәл Юсупов башка бик күп яшьтәшләреннән бер җире белән дә аерылып тормый: әтиләре фронтта чакта әниләре белән калган дүрт малайның берсе буларак, сугыш афәтенең бөтен михнәтен чигеп, сугыштан соңгы елларда да әле шактый вакытлар ипиләре дә булмаган килеш бәрәңге һәм аертылган сөттән пешергән умач ашы белән тукланып яшәгән бала. Меңнәрчә чордашларыныкы кебек аның да балалык еллары, хезмәт көненә бушлай диярлек эшләп, дәүләткә төрле салымнар түләп, тамаклары туймас гомер кичергән колхозчылар гаиләсендә уза. Башка күп кордашлары кебек ул да кечкенәдән үк элекке авыл тормышындагы күп төрле авыр кул хезмәтен татып үсә.

Әмма аның күпләрнекеннән аерылып торган сыйфатлары да бар. Ул үсеп җитеп, кылган гамәлләре белән сокландырырлык күркәм шәхес булып китә. Бу зат – зур галим, күренекле җәмәгать эшлеклесе, республикабызда мәгълүм кеше. Миңа аның турында язу күңелле дә, җаваплы да, чөнки аның рухи халәте һәм акыл зирәклеге өлгереп җитеп, әһәмиятле җитди гамәлләргә керешүе һәм тиздән дәүләт күләмендәге зур эшләр башкаруының күбесе күз алдында, минем шаһитлыгымда барды.

Рүзәл Юсупов дигән егет белән очрашып танышуым моннан күп вакытлар элек Казан дәүләт университетына укырга кереп йөргәндә булды. Без, бер төркем яшьләр, тарих-филология факультеты бинасының дүртенче катында кабул итү имтиханын тапшыру өчен җыелган идек. Абитуриентларның күбесе – җитлегеп килгән егет һәм кызлар, егетләрнең солдат формасындагылары да бар. Мин шунда, үзен тыйнак кына тотып, ашыкмыйча, уйлап сөйләшә торган җитди кыяфәтле бер егеткә игътибар иттем. Ул Рүзәл булып чыкты. Имтиханнарын бик яхшы билгеләргә биреп барды, һәм нәтиҗәдә укырга кабул ителгәннәр исемлегендә аның исем-фамилиясе иң беренчеләрдән иде. Без Владимир Ульянов-Ленин укыган шөһрәтле уку йорты студентлары булу бәхетенә ирештек. Бу безнең өчен чыннан бәхет иде: студент исемен алу кабул итү имтиханнары биргән абитуриентларның биштән беренә генә насыйп булды.

Рүзәлгә исә Казан университетының татар филологиясе бүлеге студенты булу аеруча истәлекле, шатлыклы һәм тормышындагы хәлиткеч вакыйгаларның берсе булгандыр. Ни өченме? Чөнки аның бу югары уку йортына килгәнче яшәгән дәвере башкаларныкыннан күпкә үзенчәлекле булган. Ул Әтнә районының Кышкар авылындагы җидееллык татар мәктәбен тәмамлагач, Казан кооперация техникумында русча укып, Курган өлкәсендә товаровед булып эшли, аннары өч ел армиядә хезмәт итә. Шулай итеп, аның мәктәпне тәмамлавына инде 8 ел узган була. Шуның өстенә, ул татар мәктәбенең 8–10 классларында укымаган. Ә университетта укырга ниятләгән белгечлек бүлегенә керү өчен татар теле һәм әдәбиятыннан урта мәктәп программасы күләмендә кабул итү имтиханнары тапшырырга кирәк була. Һәм менә шунда Рүзәлнең максатчанлык һәм үҗәтлек сыйфаты күренә дә инде. Ул үзенә, рус телен яхшы ук үзләштергән һәм мәктәптә, техникумда бик яхшы укыган егет буларак, теләсә кайсы башка белгечлек буенча укырга керү җиңелрәк булса да, татарча урта мәктәптә

укымаган килеш, татар филологиясе белгечлеген сайлап ала, туган теле һәм татар әдәбияты белгече булу максатын куя. Һәм, армиядән соң үзлегеннән әзерләнеп, тиз арада тиешле имтиханнарын уңышлы тапшыра.

Без, Рүзәлнең сабакташлары, аның эшчәнлегенә, тырышлыгына сокланып һәм кызыгып йөрдек. Ул беренче көннәрдән үк белем алуга җилкенеп керешә һәм бөтен уку дәверендә барлык фәннәрне дә югары дәрәҗәдә үзләштереп, имтиханнарның барысын да «бишле» билгеләренә генә тапшырып барды. Шул ук вакытта аңа зур җәмәгать эшләре йөкләделәр, аны тарих-филология факультетының комсомол оешмасы секретаре итеп куйдылар. Шөкер, университет җитәкчелеге аның фидакарьлеген югары бәяләде: ул университетның меңләгән студентларыннан 3-4 кешегә генә насыйп була торган Ленин стипендиясенә лаек булды.

Рүзәлнең һәм аның группадашларының университет чорындагы җанлы яшәеше, бәрәкәтле гамәлләре хәзерге укучы яшьләр өчен яхшы үрнәк булырлык. Бу группада белем алган студентлардан Лениза Галиева кебек атказанган укытучылар, халык шагыйре, Тукай премиясе лауреаты Равил Фәйзуллин, Шамил Маннапов кебек күренекле язучылар, Фарсель Зыятдинов, Фирдәвес Гарипова, Флёра Баязитова һәм мин фәкыйрегез кебек фән докторлары һәм башка күренекле шәхесләр җитлегү үзе генә дә ни тора! Рүзәл Юсуповның үз китапларында күркәм сабакташлары турында илһамланып сөйләве, аларга югары бәя бирүе очраклы хәл түгел.

Рүзәлнең үз уңышлары исә тагын да зуррак итеп сөйләүгә лаеклы. Мәсәлән, аның өченче курстан, төп белгечлеккә өстәп, «филолог-тәрҗемәче» дигән квалификация алу өчен индивидуаль план буенча укуы. Тиздән бу өстәмә белгечлек аңа бик ярап та куя. Хикмәт шунда: Рүзәлләр группасын дүртенче курстан авыл мәктәпләрендә укытучылар җитмәү сәбәпле, бер елга читтән торып уку системасына күчереп, эшкә җибәрәләр. Индивидуаль план белән укучы өч егетне – Фарсель Зыятдинов, Ленар Җамалетдинов һәм Рүзәл Юсуповны өстәмә белгечлек алу ихтыяҗы булганлыктан, мөстәкыйль рәвештә белем алырга дип, Казанда калдырдылар. Дүртенче курс өчен уку планындагы фәннәрдән имтихан-зачётларны үзлегеннән өйрәнеп тапшыру мөмкинлеге бирелгән Рүзәлнең башында кызыклы идея – бишенче курс дәресләренә йөреп, шул курс белән зачёт-имтиханнарын да биреп, укуларын бер ел алдан тәмамлау планы туа. Һәм ул гамәлгә аша: аларның өчесе дә ике курслык уку планын бер елда уңышлы үтәп чыга. Егетләр югары уку йорты дипломы алып, эшкә дә урнашалар. Башта Фарсель Зыятдинов Татарстан радиосы корреспонденты булып эшли башлый. Тиздән шунда ук Ленар Җамалетдиновка да эш табыла: аны музыка тапшырулары редакциясе редакторы итеп алалар, чөнки аның шигъри һәм музыкаль сәләтләре була. Ул арада радиода күп еллар тәрҗемәче булып эшләгән Абдулла абзый Төхфәтуллин пенсиягә китәргә була: аның урыны бушап кала. Бу урынга сынау шарты белән Рүзәлне алалар. Ләкин аңа бик кырыс шарт куела: бер айда Мәскәүдән телетайп буенча килгән хәбәр-яңалыкларны, сәгатендә-минутында дигәндәй, русчадан татарчага тәрҗемә итеп, эфирга чыгарыр өчен әзерләп бирергә кирәк була. Абдулла абзыйның бу эштә 30-40 ел эшләп теше чыккан, ә Рүзәлнең текстларны шунда ук машинисткага әйтеп торып тәрҗемә итү тәҗрибәсе булмый әле (ул кәгазьдә язып кына тәрҗемә итәргә өйрәнгән). Яшь тәрҗемәче, сынау шартын үтеп, штаттагы хезмәткәр булып эшли башлый.

Берничә айдан, Казан телевидениесенә татарча яхшы белгән кеше кирәк булып, Рүзәлне пропаганда редакциясенә күчерәләр. Тагын яңа эш, тагын яңа һөнәр үзләштерү. Рүзәл монда да бөтен күңелен биреп, уңышлы эшли. Төрле темаларга тапшырулар әзерләү, илдәге, дөньядагы сәяси вакыйгалар белән танышып бару, эш барышында күренекле шәхесләр белән аралашу редакторның рухи дөньясын баета, күңел офыкларын киңәйтә. Телестудиядә киң карашлы, сәләтле, хәерхаһлы кешеләр белән хезмәттәшлек итү Рүзәлнең күңеленә хуш килә. Ул анда эшләү дәверендә

әһәмиятле темаларга газеталарда мәкаләләр дә бастырып бара һәм аны Журналистлар союзына кабул итәләр.

Рүзәл Юсуповның шуннан соңгы тормышы фәнни-педагогик эш белән бәйле. 1967–1970 елларда ул Казан дәүләт педагогика институты ректоры Мирфатыйх Зәкиев җитәкчелегендә аспирантурада укый һәм «Русчадан татарчага тәрҗемә итүнең лексик мәсьәләләре» дигән темага диссертация яклый. Яңа гына фәнни дәрәҗә алган яшь белгечне Казан педагогика институтының татар теле кафедрасына өлкән укытучы итеп алалар. Берникадәр вакыттан соң тарих-филология факультетының партоешма секретаре итеп сайлап куялар. 1970 елларда җәмгыятьтә партиянең абруе әле көчле, шунлыктан партоешма секретарена да таләпләр югары була. Ә Рүзәл – ышанычлы кеше һәм ул, гәрчә бу эш өчен хезмәт хакы түләнмәсә дә, аны дүрт ел буена җиренә җиткереп башкарып бара. Бер үк вакытта ул, әлбәттә, төп эше – укыту-тәрбия һәм фән белән дә шөгыльләнә. Үзен аямыйча, күңел биреп һәм үҗәтләнеп, татар һәм рус телләренең үзенчәлекләрен, бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү принципларын, методларын өйрәнә. Бу елларда аның «Тәрҗемә теориясенә кереш», «Тәрҗемә мәсьәләләре», «Тәрҗемә һәм тел культурасы» дигән китаплары басылып чыга. Рүзәлнең шундый туктаусыз фәнни эзләнүләре нәтиҗәсендә, докторлык хезмәтенең дә темасы билгеләнә: ул «Рус, татар телләренең лексик-семантик һәм фразеологик системаларындагы гомумилек һәм специфик үзенчәлекләр» дип атала. Бу фәлсәфи нигезгә корылган катлаулы тема: диссертантка, күпсанлы теоретик материалны үзләштереп, бай фактик материал җыеп, зур һәм җитди эчтәлекле хезмәт язарга кирәк була. Һәм 1980 елда аның «Лексико-фразеологические средства русского и татарского языков» дигән монографиясе басылып чыга. Белгечләр бу хезмәтне тел гыйлеменең яңа өлкәсе булган контрастив лингвистикага караган зур яңалык дип бәялиләр.

1980 ел азагында Рүзәл докторлык диссертациясен язып тәмамлый, әмма яклауны тиз генә оештыру мөмкин булмый. Казанда һәм хәтта Мәскәүдә дә контрастив лингвистикага караган докторлык диссертацияләрен яклата торган фәнни совет булмау аркасында, СССР Фәннәр академиясенең Мәскәүдәге Рус телен фәнни тикшерү институтында махсус совет җыярга туры килә. Ә аны оештыру бик мәшәкатьле эш була, һәм ул шактый вакытка сузыла. Ниһаять, 1982 елның азагында Рүзәл Юсупов – авылда туып-үсеп, татар мәктәбендә белем алган егет – бөтен ил һәм дөньякүләм танылган галимнәр, рус һәм төрки телләрнең төп белгечләре – академиклар, профессорлар алдында рус, татар телләренең лексик-семантик һәм фразеологик системаларының үзенчәлекләре хакында рус телендә докторлык диссертациясен уңышлы яклый. Бу, әлбәттә, тел фәне өлкәсендә зур вакыйга була.

Тиздән институт җитәкчелеге Рүзәлне филология факультетының деканы итеп куя. Әмма аңа бу вазифаны озак башкарырга туры килми: институт ректоры Мирфатыйх Зәкиевне Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының директоры итеп билгеләп кую сәбәпле, пединститут ректоры урыны бушый. Бу урынга партия өлкә комитеты берничә кандидатура арасыннан Рүзәл Юсуповны тәкъдим итә. Шулай итеп, 1986 елның июленнән профессор Р.А.Юсупов Казан педагогика институтын җитәкли башлый. Бу вазифаны ул 2002 елга кадәр башкара.

1986–2002 еллар – Р.А.Юсуповның ректорлык чоры – Казан педагогика институты (университеты) өчен чын мәгънәсендә реформа еллары булды. Вуз нык үзгәрде, сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да күзгә күренеп үсте. Үсеш аның бөтен өлкәләрендә дә барды, ул, дәрәҗәсе (рейтингы) буенча 100 педагогика вузының беренче унлыгына кереп, Россиянең һәм Татарстанның әйдәп баручы югары уку йортларының берсенә әверелде.

Институт коллективы алдында югары квалификацияле, мәдәниятле педагог-укытучылар әзерләү, эштә югары сыйфатка ирешү бурычы куела.

Бу чорда факультетлар һәм кафедраларның саны икеләтә күбәя: факультетлар саны

алтыдан 12гә, кафедралар 30дан 60ка җитә, студентлар һәм укытучылар контингенты да күпкә арта, яңа белгечлекләр әзерләнә башлый.

Казан дәүләт педагогика университетының Чаллы филиалы оештырыла, бу уку йорты тарихында беренче мәртәбә вузның чит ил вузлары белән элемтәләре булдырыла һәм алар елдан-ел киңәя, докторлык диссертацияләре яклау советлары ачыла, укыту өчен матди база ныгый, хезмәткәрләрнең һәм укытучыларның тормыш хәле яхшыра. Бу елларда вузның фәнни потенциалы да көчәя: 1986 елда фән докторлары һәм профессорлар саны 16 булса, 2002 елда алар 60ка җитә. Фән кандидатлары һәм доцентларның, мактаулы исемнәргә лаеклы укытучыларның, фәннәр академияләре әгъзалары, Сорос профессорлары һәм доцентларының саны күбәя.

Казан педагогика институтының зур коллективының киеренке һәм тырыш хезмәте нәтиҗәсе буларак, 1994 елда вуз яңа статус ала – педагогика университетына әверелә.

Республиканы зур белемле, тагын да әзерлекле, киң кырлы укытучы-тәрбиячеләр белән тәэмин итү бурычы педагогика уку йортларыннан яңа белгечлекләр һәм дисциплиналар кертүне, уку планнарын, программаларын камилләштерүне һәм үзгәртүне, булачак белгечләрнең белем сыйфатын күтәрүне таләп итә. Яңа ректорга бу төп бурычны гамәлгә ашыру эшенә җиң сызганып керешергә, коллективны шушы бурычны үтәүгә тупларга, һәр эшкә төшенеп, кирәк чакта һәркемгә ярдәм итәргә, кешеләргә дә, үзенә дә таләпләрне арттыра барырга туры килә. Бу чорда барлык белгечлекләрнең дә уку планнарына ректор инициативасы белән яшь буынны өйрәтү һәм тәрбияләү өчен аеруча кирәкле дисциплиналар, мәсәлән, музыка тәрбиясе нигезләре, сөйләм культурасы, сөйләм техникасы, риторика, хореография дәресләре кертелә һәм тиешле кафедралар ачыла.

Уку планнарына бу һәм башка культурология дисциплиналары кертелү булачак укытучыларга эстетик тәрбия бирү һәм аларны, гомумән, профессиональ яктан әзерләү бурычын уңышлы хәл итү мөмкинлеге бирә. Казан педагогика университетының педагогика һәм башлангыч белем бирү методикасы, педагогика һәм мәктәпкәчә белем бирү, психология, педагогик юнәлешле юриспруденция белгечләре әзерли башлавы да төптән уйланып һәм тормыш таләпләрен исәпкә алып кылган гамәл була.

Җитәкчелек эшендә Рүзәл Юсупов кешелеклелек-гаделлек принцибын сакларга тырыша. «Минем төп принцибым – югары нәтиҗәле эш таләп итүне кешеләргә яхшы мөнәсәбәт, кайгыртучанлык белән бертигез тоту. Җитәкче өчен иң әһәмиятле сыйфат – кешелекле булу, масаймау, беркемнең дә кешелек намусына кагылмау, беркемгә дә кимсетеп карамау», дип яза ул.

Ул укытучы-галимнәр коллективы белән җитәкчелек итүендәге иң әһәмиятле бурычларының берсе коллективта үзара аңлашу, татулык мөнәсәбәтләрен булдырудан һәм саклаудан гыйбарәт дип саный. Әлбәттә, мәрхәмәтлелек алымы белән җитәкчелек итү үзенең уңай нәтиҗәләрен бирми калмый.

Рүзәл Юсупов ректор булганда, күп кешеләргә игелек күрсәтүгә ирешә. Хезмәт хаклары аз булган йөзләрчә укытучыларга һәм хезмәткәр-эшчеләргә системалы рәвештә матди ярдәм күрсәтеп килә: гыйльми дәрәҗәсез укытучыларга, лаборантларга, хуҗалык эшчеләренә төп хезмәт хакларына өстәмә түләү тәртибе урнаштырыла, 1990 еллар башында шактый кешене фатир белән тәэмин итү мөмкинлеге табыла. Торакны гадел юл белән, бары профсоюз оешмасы кабул иткән чират тәртибендә генә бирү гадәткә кертелә. Гади эшчеләр дә уңайлы фатирларга ия була. Гомере буе начар торакта яшәгән җыештыручы булып эшләүче Сания ханым өч бүлмәле яңа фатир алгач, шатлыгыннан ни эшләргә белмичә, бу хәлгә ышанмыйча йөри. Ул, ректорны очратканда, шатлыгыннан елый-елый аңа рәхмәтләр укый торган була. Илдә бушлай торак белән тәэмин итү системасы бетерелгәч, университет иллеләп кешене, өлешчә түләү тәртибе белән торaклы итү җаен таба. Ректор килешү белән кабул ителгән студентлардан укыган өчен гадел дифференциаль түләтү системасын кертә.

Соңыннан бу «юмартлыгы» ректорга кыйммәткә төшә: финанс-ревизия комиссиясе моны «закон бозу» дип бәяли. Әмма аңа пычрак яга алмыйлар. Рүзәл үз-үзен яклап, аклап чыгарлык көч таба.

Р.Юсупов җәмәгать эшләренә дә күп вакытын багышлый. Укытучы булып эшләгәндә, ул дүрт ел рәттән тарих-филология факультетының партия оешмасы секретаре вазифаларын башкара, ректор чагында партком, райком бюросы, горком әгъзасы, Казан шәһәре советы депутаты, анда мәгариф комиссиясе рәисе була. Аннары Рүзәл бердәнбер чын демократик юл белән (җиде кандидат арасыннан) Татарстанның Югары Советы депутаты һәм парламентның Милли һәм мәдәни мәсьәләләр буенча даими комиссиясе (хәзергечә комитеты) рәисе, президиумы әгъзасы итеп сайлана һәм иң актив депутатларның берсе була.

Аның башка төрле җәмәгать эшләреннән берсен – аеруча җитдиен әйтеп китәргә кирәктер. Ул һәм аның фикердәшләре Татарстанның республика партиясен төзиләр, Рүзәл Юсуповны аның рәисе итеп сайлап куялар. Ул бу зур вазифаны да иҗтимагый эш тәртибендә (хезмәт хакы түләнмичә) берничә ел башкарып килә.

Ике дәүләт телен өйрәнү һәм куллану ике телдә дә югары сыйфатлы аралашу проблемасын барлыкка китерде, бу исә ике тел ияләре (билингвар) куллана торган телләрнең әдәби нормаларын саклау буенча тәкъдимнәр һәм кагыйдәләр әзерләүне таләп итә иде. Профессор Рүзәл Юсуповның гыйльми тикшеренүләре үзәгендә менә шушы мәсьәләләр торды. Аның фәнни мирасы бай һәм күп тармаклы. Басылып чыккан хезмәтләре меңгә якын санала. Шуларның 75е – монографияләр, дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре. «Общее и специфическое в разноструктурных языках» дигән монографиясе, Евросоюзның «Ламберт» (Рига) нәшриятында бастырылып, чит илләргә таратылды. Бу басма хезмәтләрдә хәзерге заманның актуаль социолингвистик проблемалары: телләрнең киң планда үзара мөнәсәбәтләре һәм бер-берсенә йогынтысы, тәрҗемә теориясе һәм практикасы, сөйләм культурасы, шулай ук гомуми белем учреждениеләрендә, яңа төр мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында укыту мәсьәләләре бәян ителә. Бу хезмәтләр, гыйльми җәмәгатьчелекнең икърар итүенчә, гомуми һәм татар теле фәне үсешенә билгеле бер өлеш кертәләр. Алар республикабызда һәм башка өлкәләрдә икетеллелек практикасы белән бәйләнешле күп кенә әһәмиятле мәсьәләләрне уңышлы хәл итү өчен ныклы фәнни база тәшкил итәләр.

Үзара бәйләнештәге телләрне чагыштырып өйрәнү, бер телдән икенче телгә тәрҗемә итү теориясе һәм практикасы, икетеллелек шартларында сөйләм культурасы, туган телне һәм икенче телне укыту мәсьәләләре бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән һәм шактый дәрәҗәдә үзара кисешәләр. Алар бу телләрдәге лексик-фразеологик, грамматик һәм стилистик чаралар нисбәтендәге закончалыкларга нигезләнә. Р.Юсуповның монографияләре, дәреслекләре, уку ярдәмлекләре, программалары, фәнни җыентыклардагы күпсанлы мәкаләләре һәм мәгълүмат чараларындагы чыгышлары Татарстан Республикасы халыкларының дәүләт телләре кулланылышына бәйле журналистларга, тәрҗемәчеләр, укытучылар, галимнәр һәм башка төрле һөнәр ияләренә ярдәм итәләр.

Профессор Р.А.Юсупов тарафыннан төзелгән «Теория и практика перевода» программасын СССР Мәгариф министрлыгы илебезнең барлык педагогика уку йортларына кулланма буларак файдаланырга тәкъдим итте, һәм бу программа Мәскәү һәм Лениградтагы үзәк нәшриятларда басылып чыкты.

Сөйләм культурасы, тәрҗемә теориясе һәм чагыштырма тел гыйлеме өлкәсендә эшләүче белгеч буларак, Рүзәл Юсупов һәрвакытта да татар теленең әдәби нормаларын саклау һәм үстерү позицияләрен яклап килде, аның сафлыгы һәм культурасы традицияләре сагында торды. Бу мәсьәләләргә багышланган хезмәтләрнең зур теоретик һәм гамәли әһәмияте бар.

«Татар-рус телләренең бәйләнеше: теориясе һәм практикасы» дигән фәнни хезмәте

өчен Р.А.Юсуповка 1988 елны фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе бирелде.

«Чагыштырма тел гыйлеме» дигән тема буенча аспирантура, докторантура һәм докторлык диссертацияләре советы җитәкчесе, татар теле кафедрасы мөдире, күп еллар Россиядәге иң зур педагогик вузларның берсенең ректоры буларак, профессор Р.А.Юсуповка тел гыйлемен оештыруда, фәнни-педагогик кадрлар әзерләүдә һәм үстерүдә турыдан-туры катнашырга туры килде.

Аның җитәкчелегендә 30 кандидатлык һәм 5 докторлык диссертациясе әзерләнде һәм якланды. Хәзерге вакытта аның укучылары Татарстанның һәм Россиянең гыйльми учреждениеләрендә һәм югары уку йортларында уңышлы хезмәт итәләр.

Рүзәл Юсупов – үзе бик гади, әмма оригиналь фикерле, зур ихтыяр көченә ия кеше. Аның белән бер сөйләшеп алу гына да кешегә күп нәрсә бирә. Шул уңайдан, мәсәлән, аның бәхет турындагы фикерләре кызыклы. «Нәрсә ул бәхет һәм мин бәхетле кешеме?» дигән мәкаләсендә ул болай дип яза: «Минем тормышымда азмы-күпме уңышлар, казанышларым булган икән, аларның нигезе үз алдыма максат куеп, бөтен көч-куәтемне сарыф итеп, үземне аямыйча, шул максатка ирешә барып яшәүдә. Шулай яшәү минем гомеремнең төп принцибы булды. Болай эшләү кешедән зур ихтыяр көче, фидакарьлек һәм хәтта кайбер эшләрдә үзеңнән күпмедер дәрәҗәдә корбан да таләп итә. Шул рәвешле үз алдыңа куйган бурычны үтәү зур мораль канәгатьләнү, димәк, бәхет китерә».

Бәхетле булу өчен әле тагын, һичшиксез, гаиләдә иминлек, бер-береңне хөрмәт итеп яшәү дә кирәк. Күренекле журналист Әгъзам Фәйзрахманов Рүзәл Юсуповның тормышы турында «Шәкерт абый» дигән китап чыгарды. Ул анда болай ди: «Һич тә икеләнмичә әйтә алам: Рүзәл Юсупов гаиләсендә дә бәхетле булды. Хатыны Дилара ханым белән тату яшиләр. Кызлары Диләфрүз белән кияүләре Айдарның да тормышлары матур. Акыллы, тырыш оныклары үсеп җитеп килә. Кода-кодагыйлары белән дә даими аралашып, дус яшиләр». Рүзәл Юсупов үзе дә тормыш юлдашы Диларага бик рәхмәтле. Фән өлкәсендә зур уңышларга ирешүендә ул аның зур роль уйнавын әйтә: «Диссертацияләрне (кандидатлыкны да, докторлыкны да) язганда, иң зур ярдәм күрсәткән кешенең исемен атамасам, бу гаделсезлек булыр иде. Ул – хатыным Дилара, – дип яза Рүзәл. – Ул диссертацияләрнең икесен дә (ә бу – берничә йөз бит) комиссион кибеттән арзанга гына сатып алган иске «Москва» машинкасында басып чыкты. Аларны әле бер тапкыр гына басып калып булмый: төзәтеп, кабат-кабат басарга туры килә. Күп кенә мәкаләләрне, монографияләрне дә Дилара басты һәм хәзер дә ул башкара. Аңа зур рәхмәт хисләре саклыйм», – ди.

Күренә ки, безнең янәшәбездә генә әнә шундый олы, олпат һәм күпләребезгә чын мәгънәсендә үрнәк шәхес яши. Ул безнең халкыбызның горурлыгы! Без аңа киләчәктә дә саулык-сәламәтлек һәм халкыбызны данлый торган яңадан-яңа хезмәтләр иҗат итүен теләп калабыз!

**Әнвәр ШӘРИПОВ,**
*филология фәннәре*
*докторы, профессор*

# «ШАГЫЙРӘ КҮҢЕЛ ТӘРӘЗӘСЕН АЧА»

## ФӘҮЗИЯ СОЛТАН ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ

Шагыйрә Фәүзия Солтан поэзиягә тормыш тәҗрибәсен туплап, бу дөньяда үзенең урынын, яшәвенең максатын төшенгән чорда ныклы адымнар белән килеп керде. Бәхәс иреге, фикер төрлелеге алып килгән туксанынчы елларда әдәбият аланында каләмен чарлаган шагыйрә – бүгенге көндә үз өслүбен булдырган, укучылар йөрәгендә үз урынын тапкан әдибәләребезнең берсе. Ул үз иҗатында XX гасырның икенче яртысында дөньяга килеп, илдә барган үсеш-үзгәрешләр чорында формалашкан буынның дөньяга карашын, тормышка мөнәсәбәтен, рухи һәм әхлакый эзләнүләрен чагылдыра. Ф.Солтан шигырьләре хәзерге заман кешесенә төбәп язылган. Ул укучы белән ихлас әңгәмә алып бара, тормыш турындагы, кешелек язмышы хакындагы борчулары, күңелен биләгән уй-хисләре, өмет-идеаллары белән уртаклаша.

Танылган шәхесләре белән билгеле Балык Бистәсе районының Олы Солтан авылында дөньяга килеп, урта белемне алганнан соң, Ф.Солтан авыл китапханәсендә эшли башлый һәм Алабуганың китапханә техникумында читтән торып укый. Соңрак язмыш юллары аны гаиләсе белән Казанга китерә, биредә ул йортлар идарәсендә, Казан микробиология фәнни-тикшеренү институтында, «Спортлотоның» Урта Идел зона идарәсендә, «Татарстанкурорт» идарәсенең «Казан» шифаханәсендә хезмәт куя. Соңгысында эшләү елларында китап дөньясына, шигърияткә гашыйк ханым Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясенең китапханә-мәгълүмат бүлеген уңышлы тәмамлый. Шагыйрәнең иҗаты укучыларга вакытлы матбугатта басылган шигырьләре, хикәяләре, публицистик мәкаләре белән генә түгел, ә бәлки «Учларымда – җиләк...» (1999), «Үзәк өзелгән чак» (2003), «Баллы миләш» (2011), «Көзге шәфәкъ» (2018), «Нигез сагышы» (2022) кебек җыентыклар аша да билгеле. Бүгенге көндә татар шигъриятендә үз урынын тапкан, укучыларның һәм Н.Хисамов, Н.Акмал, В.Нуруллин, Н.Йосыпова кебек тәнкыйтьчеләрнең уңай бәяләрен алган Ф.Солтан – Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты, ТР Мәдәният министрлыгының «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» дигән күкрәк билгесе иясе, «Болгар» радиосының музыкаль премиясе лауреаты, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Ф.Солтан шигырьдә кыскалыкка, сурәтлелеккә омтыла. Аның әсәрләре традицион поэзиягә хас тасвирчылык һәм гадәти сюжет төенләнешләренә нигезләнә, сурәтләрнең яңачалыгы, детальләрнең тапкырлыгы, уй-кичерешләрнең тыгызлыгы белән игътибарны җәлеп итә. Күңел шигърияте кысаларында алып барган эзләнүләрендә мәхәббәт һәм туган якны ярату темалары аерылып чыга һәм алар белән бәйле мәхәббәтне югалту, язмышка буйсыну, якты киләчәккә өметләнү мотивлары зур урын алып тора, лирик герое тирәлекне бөтен катлаулылыгында һәм күп яклы итеп күрергә омтыла. Шагыйрәнең рухи дөньясын мәхәббәтсез күз алдына китереп булмый, сөю хисе яшәүнең нигезе, тормышның мәгънәсе буларак кабул ителә.

*Мәхәббәтне саклап мәңге*
*Сөюдә бит яну кирәк.*
*Кайнар хисләр гомер өсти,*
*Сүрелмә син мәңге, йөрәк!*

«Сүнмә, йөрәк!»

Иҗатының буеннан-буена сузылып килгән мәхәббәт сагышы белән сугарылган шигырь юлларында шагыйрә үз тормышыннан инде югалган, ниндидер сәбәпләр аркасында үткәндә калган кешегә карата хисләрен белдерә. «Төшләремдә яшим», «Ак чәчәкләр», «Күңел назы», «Сөюгә мәдхия», «Өмет», «Уйлар-буран» кебек шигырьләрдә төп фикерне укучыга ирештерү өчен кара буран, утка очкан күбәләк, күмерләнгән йөрәк, соры күз, сагыш тәлгәшләре, суык өткән яфраклар кебек символик образлар кулланыла.

Сагыш, әрнү белән өретелгән күңел лирикасы үрнәкләрендә мәхәббәт һәм хыянәт, мәхәббәт һәм гаилә, мәхәббәт һәм балалар яссылыгында ачылган проблемалар төп урынны алып тора. Шагыйрәнең лирик герое төшенкелеккә бирелгән кебек тоелса да, үзендә сынмаска-бөгелмәскә көч таба, ахыр килеп, «кеше булганга көчле син» дигән нәтиҗә ясый.

Фәүзия Солтанның мәхәббәт лирикасын ир-ат һәм хатын-кыз мөнәсәбәтләренә генә кайтарып калдыру бер яклы булыр иде. Шагыйрә туып үскән җиренә, туган ягының табигать күренешләренә, әти-әнисенә, балаларына тирән ярату хисе белән яши. Бер төркем шигырьләре туган якка мәхәббәт темасы тирәсенә туплана, аларда балачак, әни, туган нигез, туган авыл образлары калку итеп сурәтләнә. Мәсәлән, «Унбер роза» шигырендә төп эчтәлек үткәнне искә төшерү аша җиткерелә:

*Унбер роза, балачакны*
*Гүя кире кайтарасыз.*
*Ялантәпи бәбкә саклап*
*Йөргән чаклар – кайда соң сез?*
*Сай елгада су кергән чак,*
*Кайда ул елгыр балачак?*
«Унбер роза»

Шигырьнең төп сурәтләү объекты – лирик геройның балачагы – «ситсы күлмәк» кигән беркатлы кызчык образы «хәтфә үләндә тәгәрәгән», гамьсез мизгелләр аша тасвирлана. Шагыйрә еллар узган саен тормыш артка борылып карарга, самими вакытларны искә төшерергә этәрә дигән фикерне үзәккә куя.

«Нигезем», «Нигез сагышы», «Сыенамын, Җирем, сиңа», «Олы Солтаным, сиңа җырларым», «Туган авылым – Олы Солтан», «Тау иленә», «Салкын чишмә – җирнең күз яше», «Саумы, әнкәй», «Юату» һ.б. шигырьләрендә Ф.Солтанның лирик герое авыл кешесенең күңел дөньясы, авылның үткәне һәм бүгенгесе, туган як табигате һәм кешеләре, әти-әнисенә, туган авылына, туган йортына булган хисләре турында сөйли. Лирик геройның күңел халәте, туган җиренә тартып кайтарган җирсү хисе, туган ягына булган мөнәсәбәте чишмә, каен, гөлләр, имән кебек образлар аша тасвир ителә, туып үскән урыныңа кайту үз асылыңа кайту идеясе буларак тәгаенләнә. «Нигез сагышы» шигырендә шагыйрәнең туган җиренә, ата-баба нигезенә, ата-анасына булган мәхәббәте нигезне сагыну белән өретелә. Шатлыкта да, кайгыда да туганнарны бергә туплый торган урынның ташландык хәлдә булуы тату гаилә булып яшәгән мизгелләрнең кире кайтмавына үкенү хисе буларак гомумиләшә һәм, хиснең дәрәҗәсе үстерелә килеп, елап утыра торган йорт образы аша тормышка ашырыла.

*Билдән карны ерып китеп барам.*
*Тагын кайчан кайтып күрәсе.*
*Кыектагы бозның сөңгесеннән*
*Тамчы тама... Өйнең күз яше.*
«Нигез сагышы»

Шушы символик образ ярдәмендә шагыйрә кеше күңелендәге сагышны ачып кына калмый, ә бәлки татар авылларының фаҗигасен дә калку итеп күрсәтә. Нигез

турындагы уйлануларын киңәйтеп, автор Җир-ана образына мөрәҗәгать итә һәм аерым бер кеше язмышыннан гомуммилләт яссылыгына күчә, үзеңне туган җирнең бер кыйпылчыгы, халкыңның бер өлеше итеп тоюны яшәүнең төп мәгънәсе дип тәкъдим итә.

*Таралып сибелгән татарлар*
*Бирешми зилзилә-давылга.*
*Тамыры, чыгышы – туган ил,*
*Туган җир көч бирә халкыма.*
«Көрәш»

Шул рәвешле, нигез төшенчәсенә салынган хәтер саклау идеясе Ф.Солтан шигырьләрендә туган нигез / туган авыл / туган җир / туган ил кебек метафорик образлар рәтендә ачыкланып, яшәеш, халык язмышы, тамырларга кайту, туган телеңне саклау турындагы фәлсәфи уйлануларда гомумиләшә.

Шагыйрә иҗатында ике яссылыкта ачылган Ана образы зур урын алып тора. Берсе – лирик геройның үз анасы булса, икенчесе исә – лирик зат үзе. «Юату», «Ана язмышы», «Ялгыз ана», «Юрау», «Ана хыялы», «Ана хаты», «Онытмам, әнием», «Кичер, әни» һәм башка шигырьләрдә бу образ эчке матурлыгы һәм илаһи мөлаемлыгы белән ачыла. Әлеге әсәрләрдә лирик геройның иң изге хисләре, йөрәктән кайнап чыккан кичерешләре чагыла.

Шагыйрәнең бер бәйләм шигырьләрендә төрле яссылыкта ачылган мәхәббәт элегиясе белән сугарылган әсәрләре яшьлекне сагыну, тормышның тиз үтүенә борчылу хисен үзәккә куя дигән идек. Мәсәлән, «Яшьлегемне эзлим» шигырендә лирик геройның үкенү, сөйгән ярын һәм яшьлеген сагыну хисе төп урынны алып тора. Шигырьнең исеме дә ике мәгънә төсмерен бирә: берсе яшьлегенә кире кайту теләге булса, икенчесе – мәхәббәт хисеннән уянса да, яңадан очрашуга өмет югалту. Лирик геройның үкенү, сагыш хисен көктә ялгызы гомер кичергән, язмышының шаһиты – ай образы көчәйтә.

*Исәрләнгән йөрәк:*
*Килен булып төшкән*
*Ян капканы ачтым.*
*Үткәнгә кайту юк.*
*Аерым узган гомер.*
*Керә алмадым. Яптым –*

дигән юлларга символик мәгънә салынган. Бер яктан, алар лирик геройның өмете өзелү буларак кабул ителсә, икенче тарафтан, үткәннәргә алып кайта торган капканың ябылып, барыр юлларының киләчәккә таба борылуын, өмет хисенең кичереш үзәгенә чыгуын символлаштыра.

Шагыйрәнең иҗатына башыннан ахырына кадәр күзәтү ясау шуны күрсәтә: «Баллы миләш», «Унбер роза», «Ялгыз дип язылган язмыш», «Шул рәсемгә баккан уйларым», «Киттең» һ.б. шигырьләрендә лейтмотив булып яңгыраган яшьлекне сагыну, мәхәббәтнең югалуына үкенү хисе «Бул әле», «Оныттыр», «Көтеп алган бәхетем», «Юлларымда очрадың да» шигырьләрендә якты киләчәккә өмет, мәхәббәткә ышану хисе белән алышына. Башлангыч чор иҗатында шагыйрәнең бар дөньясын биләп алган сагыш, өметсезлек хисе арткы планда кала, шигырьләре бәрелгән-кагылган күңелнең дә мәхәббәткә, бәхеткә хокукы бар дигән ышаныч белән сугарыла. Бу үзгәрешнең асылын күрсәтә торган «баллы миләш» образы («Суык баллаган миләштәй, Каршылыйм гомер көзен...») аеруча кызыклы. Хатын-кызның ялгызлыкта өшегән күңелен суыклар килгәч балланган миләш җимеше белән чагыштыру һәркем өчен

таныш төшенчәләрнең мәгънә кырын киңәйтә, язмышның никадәрле ачы булуына карамастан, кешенең бәхеткә хокукы барлыгын раслый торган символга әверелә.

Хисләр үзгәрешен ел фасылларына бәйле билгеләү «Еллар – уйлар» шигырендә дә дәвам итә. Гомер юлының башыннан ахырынача күзәтү риторик сораулар ярдәмендә башкарыла һәм өмет хисенең төрле чорларга караган үсеш-үзгәрешен күзәтергә мөмкинлек бирә. Кеше күңелендәге хисләр өермәсен чагылдырыр өчен шагыйрә язгы тамчылар, назлы җилләр, тәңкә карлар, дулаган бураннар образларына таяна. Нәтиҗәдә, Ф.Солтан гомерне зая үткәрмәсәк, картлыгы да бәхетле булыр дигән фикерне калкытып куя.

Шагыйрәнең лирик-фәлсәфи эзләнүләрендә җәмгыятькә, дөньяга тәнкыйди мөнәсәбәт күзгә ташлана, яшәү мәгънәсен эзләү белән үз юлыңны табу, яшәешне танып белү идеясе өстенлек итә. «Мәгънә», «Кыйблага тугрылык», «Яшәү – көрәш», «Бар да кала» тезмәләрендә лирик герой адәм баласының җирдәге вазифасы, тормыш максаты турында уйлана һәм укучыга «Бармы яшәүдә бер тирән мәгънә?» дигән сорау белән мөрәҗәгать итә. Укучы күз алдында яшәешнең универсаль моделе тергезелә: һәркем бу дөньяга килә, хыяллана, хисләнә, яши, әмма бер көнне мәңгелеккә күчә. Шул рәвешле кеше гомеренең галәм масштабында бары бер мизгел генә булуы ассызыклана.

*Шулай хисләнеп гомер дә үтә –*
*Җан мәңгелеккә калдырып китә.*
*Күрми да кала адәм Галәмне,*
*Бирми дә кала Җиргә сәламне.*
«Мәгънә»

«Бар да кала» шигыре дә борчулы, кайгылы халәтне тергезә. Аның сәбәбе шулай ук фәлсәфи планда аңлатыла, вакыт категориясе аша кеше тормышының бары бер мизгел булуы ассызыклана. Әлеге шигырьдә вакыт берничә яссылыкта ачыла: җир йөзенә аваз салган адәм баласына бирелгән кыска вакыт аралыгы һәм җәрәхәтләрне юкка чыгарган, мәңгелек белән тәңгәлләштерелгән вакыт. «Вакыт җитеп, бар да бетә / Бу дөньяда. Бар да кала» дигән юллар беренче карашка гадәти нәтиҗәне чыгаруга этәрә: кеше никадәр генә дөнья куса да, вакыты җиткәч, бар әйберсен калдырып китәргә мәҗбүр була, мәгәр бу юлларны бер кеше язмышына гына кайтарып калдырмыйча, дөнья, кешелек тарихы, табигать күренешләре яссылыгында карасаң, нәтиҗә һәр кылган гамәлнең «мәңгелеккә эзе кала», бер генә әйбер дә, бер генә гамәл дә эзсез югалмый дигән фикер булып гомумиләшә. Шигырьләрдә фәлсәфи планда ачылган яшәү мәгънәсе проблемасы һәркемнең тормышында урын алырга мөмкин булган гади категорияләр аша чишелеш таба. «Яшәдем» дип әйтер өчен гаилә кору, атаң-анаң назын тою, авыр чакта туганнарыңа таяну, якын дусларың белән юану, яраткан эшең булып, ялкынланып янып яшәү дә җитә дигән нәтиҗә ясала.

*Тирә-юньгә нурлар сибеп,*
*Авырлыкка башны ими,*
*Чит-ятларга серне бирми,*
*Үтсә әгәр гомерләрем,*
*«Яшәдем!» дип әйтер идем.*
«Әйтер идем»

Иҗатының башлангыч чорында, нигездә, күңел лирикасына корылган шигъри шәкел традицияләрен үстерү, яңа мөмкинлекләрен ачу юнәлешендә эзләнүләр алып барган һәм уңышлы нәтиҗәләргә ирешкән шагыйрә соңрак халык җырына нигезләнгән поэтик формаларны, халык иҗатына хас традицион поэтик образларны, детальләрне үзләштерүгә игътибарын көчәйтә. «Җилгә», «Олы Солтаным, сиңа

җырларым», «Сиңа», «Сагышларым», «Җавапсыз мәхәббәт булмасын» шигырьләре халык җырларына хас структурага нигезләнсә, җырларның поэтик образлылыгын өлге итеп алса, «Баш иелгән», «Ятимлек», «Суга сал сагышыңны», «Кайту» әсәрләре афористик әйтелмәләргә корыла, халык мәкаленә салынган меңъеллык тәҗрибәнең көндәлек яшәештәге урынын билгели, мәңгелек кыйммәтләр турында уйларга мәҗбүр итә, «Юлларда», «Көрәш», «Зөһрә – ай», «Утка дан!» кебекләре исә халык авыз иҗатында символик мәгънәгә ия каен, юл, тәрәзә, ут, ай кебек ачкыч-сүзләргә мөрәҗәгать итә, аң төпкелендә яшеренеп яткан шигъри кодлар ярдәмендә шагыйрәнең фәлсәфи уйлануларын мәйданга чыгара. Сурәтләүдәге, образлы фикерләүдәге индивидуаль үзенчәлеген саклаган хәлдә, ул бу юнәлештә дә яңа иҗади уңышларга ирешә. Кичерешләре тагы да тирәнрәк һәм катлаулырак, фикерләре тагы да саллырак, колачлырак төс ала.

Фикердә кыскалыкка омтылу, халык афоризмнарына якын калыплар белән эш итү шагыйрә иҗатында табигатьнең, тормышның яки кешеләрнең нииндидер бер халәтен иң «кабарынкы» урыннан тотып алуда һәм тирән мәгънә бирә торган тапкыр сүзләр ярдәмендә ачыклауда да күренә.

*Намуссызлык кичерелми беркемгә дә.*
*Юл, сәяхәт саф уйлыларны ярата.*
*Сөенечле хәбәр алып килсә берәү,*
*Аны көтеп, сукмак түгел, киң юл ята.*

«Намуссызлык кичерелми беркемгә дә...»

Ф.Солтан әлеге дүрт юлны яза да дәвамын укучылары хөкеменә калдыра. Кайбер укучыларга «юл, сәяхәт саф уйлыларны ярата» дигән сүзләр – автор уйлап чыгарган поэтик образ гына булып күренеп, башкаларның интеллектына, тормыш тәҗрибәсенә карап, мәгънә төсмерләре үзгәрәк юнәлештә дә ачылырга мөмкин.

Ф.Солтан үзенең иҗатында татар поэзиясе өчен традицион гыйбарәләрне, образ-детальләрне иркен куллана, табигать образларын хис-кичерешләрне җиткерү юлында файдалана, аларны яңа мәгънә төсмерләре белән баетып, укучы белән җитди әңгәмә кора. Кыскалыкка, төгәллеккә омтылу шигырьләргә атама куюда да күзәтелә: атамалар, гадәттә, бик кыска булып, фикерне тәгаенләштереп кенә калмыйлар, ә шигырьнең эчтәлеген дә тулыландыралар.

Агымдагы елның сентябрь аенда гомер бәйрәмен билгеләүче Фәүзия Солтан-Галиуллина кеше күңеленең ихласлыгын, хисләрнең олылыгын, адәм баласының мәхәббәткә омтылуын, туган нигезгә тартылуын галәм, дөнья, гомумкешелек, милләт яссылыгында ачып, төрле мәгънәви катламнарда чишәргә омтыла. Аның күңел лирикасы кысаларында үсеш алган иҗаты яшәешне лирик «мин»нең күңел дөньясы контекстында бәяләү белән характерлана; кеше һәм милләт язмышы, туган як / туган җир / туган нигез турындагы фәлсәфи уйланулар белән баетыла, символлар, образ-детальләр ярдәмендә сагышлы өмет хисе белән сугарыла. Ф.Солтанның татар әдәбиятында һәм укучы күңелендә үз урыны, иҗат мәйданында әйтер сүзе бар, киләчәктә дә шагыйрә үзе сайлаган юлга тугры калып, яңадан-яңа үрләр яулар дип ышанабыз.

**Ләйлә ДӘҮЛӘТШИНА,**
*филология фәннәре докторы.*

## Аяз Гыйләҗев хатлары

*26 октябрь, 1979 ел.*
*Переделкино.*

Марсель!

Менә, парин, яңа гына табадан пешеп төшкән повесть.

Яза башлаганга ун елдан артык вакыт узып китте!

Менә ничек авыр языла хәзер!

Әле повесть белән мавыгып (ай узып бара!), Мәскәүгә барып, егетләрне күрә алган да юк. Үзләре дә килеп чыкмыйлар.

Син ни хәлләрдә? Ниләр кыдырасың?

Монда татар-башкорттан берәү дә юк, танышлардан шул калмык Алексей Балакаев. Шуның белән вакыт кыскартабыз. Эш белән көн үткәне сизелми...

Эдуард Касыймовның романын ни дип хәл иттегез?

Дусларга сәлам!

Эшеңдә уңышлар, ныклык һәм сәламәтлек телим.

Бирешмә һәм каушама!

Син үзең талант иясе, шулай булгач, нык тор!

*Сәлам белән, Аяз.*

***

*29 октябрь, 1980 ел.*
*Рига-Дубылты.*

Марсель дус!

Чуктин-чук сәламнәр! Менә срокның беренче биш көнлеген уздырып җибәрәбез. Кәеф начар түгел, эшләнә, борын гына бирешергә маташкан иде, кичә кич ике йөз грамм каты аракыны тондыргач, бер баш сарымсакны бөкли-бөкли, алты пирожки суккач, бүген, шөкер, борын да маймылның арт ягыннан адәм әгъзасына – борынга охшап тора. Егетләр дә ничего гына йөриләр сыман. Кәшфулыч *(Рәдиф Гаташ.–* **М.Г.***),* гадәтенчә, бераз мырлый инде ул, диңгез шавы да ошамый аңа, юлларда да машинаны да бетерер иде, нарат урманнары өстенә, томанны таратып, кояш та элеп куяр иде. Без ул яшьне узган, безгә ничек тә бара, кояш безнең күкрәкләрдә, утырдык исә, машинканы шакылдатабыз гына!.. Пьеса язып маташам бит. Академия театрына берәр нәрсә биреп булмасмы дигән идем. Репертуарлары юк, репертуарларында минем исем юк. Ике «юк» нәрсә дигән сүз ул? Начар дигән сүз. Менә шулай.

Инде сүзне бүгенге татар прозасына күчерик. Син бүгенге көндә иң җаваплы, иң олы тәхетләрнең берсендә – татар прозасының башында утырасың. Кем син? Язучы буларак, син – бик үзенчәлекле талант. Дөрес, әле син ачылып бетмәдең, бөтен барлыгыңны раслый торган әсәрләрең әле язылмаган, әмма, әгәр онытмаган булсаң, мин сине беренче адымнарыңнан ук, беренче проза әсәрләреңнән үк үз иттем, яраттым. Хәтта Туфан Миңнуллин «капустник» дигән пьесаңда да яхшы өмет яралгылары бар иде. «Чаян»да басылган юмор әсәрләрең синең ул якка да канат җәя алачагыңны күрсәтсә, «Соц. Татарстан»да басылган публицистик мәкаләң шул рубрикада, шул тема тирәсенә багышлап басыла торган бик күп материаллардан өстен, анда төп-төгәл, дөп-дөрес тормыш күзәтүе, бүгенгене үзеңчә аңлау һәм аңлатырга тырышу бар иде. Бәс, шулай икән, син дөньяны үзеңчә танып белүче кеше, үзеңчә ачарга тырышучы

сәяхсың. Бу, дустым – ифрат зур җаваплылык. Талант бар кешегә дә бирелми. Таланты бар кеше халкы алдында мең тапкыр җаваплы, талант бер синең байлыгың гына түгел, ул – уртак хәзинә. Без синнән күпне көтәбез, өметләнәбез һәм законлы рәвештә таләп итә алабыз. Килештекме? Әгәр монысы белән килешсәң, арытабан китәбез.

Бүгенге татар прозасының уртак кимчелеге нәрсәдә? Һәм ул кимчелек ни дәрәҗәдәге кимчелек?

Кимчелек – авторларның надан булуында. Безнең бик күп авторларыбыз дөнья агышын бәяли алмыйлар, тормышның бүгенге көнен хәрәкәттә билгели белмиләр, дөнья әдәбиятын, рус әдәбиятын укымыйлар. Бөтен илебезгә таралып утырган бик күп төрле тормыш формалары булган татарларны һаман бер үк сюжетлар, бер үк эчтәлекле гади ситуацияләр белән аңлатырга тырышалар. Әйтик, безнең әсәрләрне русчага яки башка телләргә тәрҗемә иткәч, алар татар әсәре булып яңгырау дәрәҗәсенә менә алмыйлар, русның яки башка милләтнең урта кул әсәрләре белән аваздашлык алалар да югалалар. Мисалга ерак барып йөрисе дә юк. Г.Әпсәләмов күпме әсәрләрен нинди тиражлар белән әдәбият мәйданына чыгарып карамады. «Роман-газета»да миллион тиражлар белән чыкты әсәрләре, хәзер дә китап кибетләренә керсәң, бары тик аның әсәрләре генә тезелеп торганын күрерсең. Ә берәр җирдә әдәби мәсьәләләрне чишкәндә, стиль, форма якларына игътибар юнәлткәндә, бүгенге совет әдәбиятына багышланган күпсанлы мәкаләләрнең берәрсендә аның әсәрләре нигез булып, бүгенге әдәби үсешне билгели торган әсәр булып телгә алындыларммы? <…>

«Лит. Газета»ның быелгы 22 октябрь санында Ч.Айтматовның «Буранлы Идегәй» исемле өзеге басылды. «Көн гасырдан да озын була» романыннан өзек. Мин романны бәяләргә керешмим, тулаем басылгач, укып чыккач, суы сеңгәч сөйләшербез, әмма авторның эш принциплары турындагы заявкасы ук кызык. Менә ни ди ул: «Узгандагы әсәрләремдәге кебек үк мин мифларга һәм легендаларга таянам, үткәннәр авазын тәҗрибә урынына кулланам, алар бездән алда булган буыннарның васыяте», дип яза.

Бармы безнең әдәбиятта «үткәннәр авазы»н актив рәвештә куллану? Без милләтебезне күрә торып ярлыландырдык. Бездә дә бар ул эзли башласаң, риваятьләр-легендалар! Мишәрләр – үзләре нинди кызыклы этник группа! Ә керәшеннәр? Алардагы җолалар, май чабулар, нардуганнар, кырау куулар, яфрак бәйрәмнәре, покраулар – һәммәсе әллә никадәрле мәгънәгә ия! Типтәрләр аерым, себер татарлары, нугайлар, Урал татарлары, Нократ татарлары... Фольклор экспедицияләре аларның байтагын җыеп туплап куйды. Тик без һаман аларны әдәби хәрәкәткә кертеп җибәрергә кыймыйбыз. Татар язучысы кайда гына туып үссә дә, һаман шул бер төбәкне – Казан арты татарларын гына яза яки кызык өчен (мәгънә өчен түгел!!!) бер мишәрне кертеп, кеше көлдерергә маташа. Ал син грузиннарны. Сваннар икән – алар үз тарихлары, үз тормышлары, үз төсләре, гореф-гадәтләре белән әдәбиятка килеп керәләр. Гуриецлар, имеретиннар, мегреллар һәммәсе Грузия чикләрен үтеп чыгып, дөньядагы мең халыкка таныш. Әдәби әсәрләр илчелек итеп таныштырганнар алар белән! Ә без чикылдап торган мишәрләр, мишәр авыллары, мишәр кызлары, мишәр мәхәббәте турында язарга кыймыйбыз. Кояшның «Тәңкәле тау» повестенда шуның бик матур ялгылары бар иде. Аңа шушы юнәлештә бик нык үсәргә һәм әдәбиятны үстерергә кирәк. Кара инде син Гәрәй керәшенне, чукына-чукына, татарлар турында язып азаплана бит. Күр инде мине, егерме яшенә кадәр керәшеннәр белән яшәгән килеш алар турында рәхәтләнеп укырлык этнографик әсәр язалганым юк. Этник группалар турында язу – тарих турында да язу ул. Нурихан шикелле тарихны әллә кай тамырларына төшкәнче, якынрак үткәннәребезне яза алсак та, ярар иде. Керәшеннәр турында яза башладыңмы, Иван Грозныйны телгә алмыйча булмый. Ә Иван Грозный шәхес буларак – татар тарихына нык кагылган кеше. Ни өчен тарихны бер яктан торып, руслар гына язарга тиеш?

Без үз тарихыбызны белмибез. Өйрәнмибез. Ялкаубыз. Татардан да ялкау халык юктыр дөньяда! Ялкау!

Шуннан менә Миргазиян Юныс килеп чыга.

Хәзер сүз аның соңгы әсәре турында барачак. Китәр алдыннан мин повестьны шактый нык печүләрен ишеттем. Бәлки шулай булыр да, печәрләр дә, ләкин мин бу очракта бик җентекләп, повестька синең шәхсән мөнәсәбәтеңне күреп тордым. Син алдан ук курка-калтырана башладың. «Цензура үткәрми инде аны! Толстой турындагы урыннарны сызып аталар... Ялчинскийның сәяхәте, гомумән, журналга кертерлек түгел!» Болар синең сүзләр... Марсель, шәкерт җиләненнән бет чүпләп азаплана дип, миңа үпкәләмә, бу хатым синең белән бергә утырып уйлануларым... Бер вакыйганы искә төшерик.

Минем академия театрында куелган «Китмәгез, тургайлар!» спектаклен карарга Вәлиев М.Ф. белән Мусин М.М. премьераның икенче көнендә килделәр. Ян бүлмәдә спектакльдән соң алар янына мин дә сугылдым. Мине котларга дип, Н.Фәттах белән Ш.Хөсәенов та килеп керде. Инде таралышкач, режиссёрым М.Сәлимҗанов болай ди: «Да-а, хуҗалар сине котларга кемнәр кергәнне күрделәр». Ишетәсеңме, нәкъ менә шулай диде һәм ап-ак агарынды. Ә мин аңа болай дидем: «Аларның күрүләре дә, шулай уйлаулары да гаеп түгел. Менә синең шуңа игътибар итүең һәм калтырап төшүең гаҗәп!»

Курка-курка, кемнеңдер Миргазиянны кисәргә тырышуы гаҗәп түгел, шул кисүләргә синең алдан ук әзерләнеп, кайчы үткенләшеп йөрүең искиткеч гаҗәп! Син кайчы үткенләшеп йөрүдән бигрәк әсәр өчен талашырга, әсәрнең яхшылыгын кемгәдер исбатларга һәм җиңәргә тиеш идең.

Менә узган кич һәм төнлә Н.Думбадзеның «Ак флаглар» исемле романын укып чыктым. Ни генә юк Надарның романында! Төп герое кеше үтерүдә гаепләнеп, төрмәгә кергән егет. Вакыйга гел төрмә камерасында бара. Монда сүз язгы ерганак шикелле бөтен якларга агып кереп китә. Исең китәр! Автор да курыкмаган, язган, ышандырырлык итеп яза алган. Бастырып чыгарганнар, тәрҗемә иткәннәр һәм укыла!

Укыла бит! Яңа итеп, кызыксынып укыйсың. Шушы төрмә камерасына автор грузиннарның күпме тарихын, гореф-гадәтләрен, әдәби әсәрләрен, җолаларын, тапкырлыкларын, тагын әлләниләр сыйдыра алган. Үз халкыңны яратсаң, караклар, кеше үтерүчеләр аша да туган иленә булган мәхәббәтне биреп була икән!

«Бездә мифлар, легендалар юк!» дип, кул кушырып утыру ансат ул. «Безнең тарих Октябрь революциясеннән соң гына башлана», – дип әйтү кемгәдер бик ошыйдыр да...

Неужели без бүген ирекле илдә, әдәбият үсәргә бөтен мөмкинлекләр барда, татар прозасына азмы-күпме борылыш кертә алмабыз инде? Кемдер безнең арадан чыгып, дөнья халыкларына татар халкының барлыгын исбатларга тиештер бит?! Алдан ук әйтеп куям, андый эшне Б.Камалов, Ш.Бикчурин, Г.Ахунов һ.б. кебекләр башкарып чыга алачак түгел. Өмет Н.Фәттахта, М.Мәһдидә, М.Юныста. Алар беренче булып, тарлык-татарлыктан чыга алалар. Чыгарга тиешләр. Һәм син, бүгенге көнге татар прозасының штаб начальнигы, алар иҗатына аеруча җете күзле була алсаң иде! Чөнки син үзең дә талантлы егет, әдәбиятның төрлелеген ярата торган егет, талантларны яклаучы егет...

Миргазиянның бу повесте уңае белән хата җибәрмәдекме?

Ашыгыч рәвештә авторны чакыртып алырга кирәк булмадымы?

Уйлашыйк әле.

Инде соң булмаса...

Татар акылы төштән соң.

Гел-гел алай булмасын инде!

Сиңа иң яхшы дуслык теләкләремне юллыйм. Минем повестьны укып чыга алдыңмы? Бер-ике авыз сүздән торган җавабыңны язсаң, ифрат сөендерер идең!

Дусларга сәлам!

*Аяз.*

***

*31 октябрь, 1980 ел.*
*Рига-Дубылты.*

Марселино, хәерле көн!

Хатыңны укыгач, мин бик сөендем. Көенүчеләр дә булды. Кларaның 500 тәңкәлек кулонын балкытып йөргүен ишеткәч, Роберт чишенмичә-нитмичә, күн тужуркасының төймәләрен дә ычкындырмыйча, караватка менеп ятты да, ярты сәгать дисәм – аз, бер сәгать үк дисәм – күбрәк булыр, беркемгә эндәшмәде. Түшәмнән ни эзләгәндер, белеп булмады. Шуннан кайгыдан берәр шешә польский сыра җибәрдек. Аның исәбеннән. *(Роберт Миңнуллинның җәмәгате Клара ханым «Татарстан коммунисты» журналында эшли, бер этажда, гел исәнләшеп йөри идек. Роберт иҗат йортына киткәч, Клара ханым киенеп-ясанып, кәс-кәс кенә басып йөри дигән кебегрәк итеп, мәңге көнләшмәс Роберт Миңнуллинны бер шаяртып алуым хәтердә. Аяз ага шуңа ишарә ясый. –* **М.Г.***)*

Рәхмәт. Үземчә, бу повестьта стиль, форма ягын да үзгәртергә тырышкан идем, гел-гел Мөхәммәт Мәһди шикелле бер иярләнгән атта гына чабып булмас. Озын юлга чыккан кыпчак-болгар бабаларыбыз иярләнгән ат янына тагын бер юртак тага торган булганнар. Мин китәр алдыннан, «әллә укып чыгасыңмы?» – дип, Фәрвазга мөрәҗәгать иткән идем. Ул «укырмын» дип вәгъдә биргән иде. Туфан укыганда да ярар иде, әйдә, Фәрвазны да бераз эшләтергә кирәк. Редколлегия бик сыегайды, киткәннәр урынына кемнәрне куялардыр, белгән юк.

Беренче хат синнән. Яртыны заслужил. Заказыңны үтәргә тырышырмын. «Ай ахыры» дип, егетләргә костюм сайладык. Костюм сайлаганда да, кешенең характеры йөз җитмеш градуска, ягъни процентка ачыла бит ул. Роберт бер кибеткә керде дә бик современный фасонда тегелгән бер костюмның җиңенә талпан кебек ябышты. Шуны алды да (кайткач, аны да юасы булыр). Ә Кәшфулычка икебез ике яктан костюм ташыйбыз да ташыйбыз. Күкрәк киң шул егетнең, тегермән ташы хәтле бар, бер генә костюм да ярата алмадык. Ул тора трикодан, без чабабыз размердан-размерга, юк кына бит таман костюм! Югыйсә «яртыны куям» дигән сүз дә ычкындырган иде. Кәшфулычтан андый өметле, җылы, нигезле һәм юмарт сүз сирәк чыкканга, тырышып та карадык инде, малай!..

Ә болай, егетләр эшли! Эш вакытында бер-беребезне күрмибез. Йөрергә чыкканда, рәхмәт инде, мине дә ияртәләр, карт-коры дип кимсетеп калдырмыйлар.

Сиңа кичә генә озын бер хат юллаган идем, алгансыңдыр.

Шуңа күрә бүген шуның белән сүзне тәмамлыйм. Кояшка, Ринатка *(Кояш Тимбикова, Ринат Мөхәммәдиев. –* **М.Г.***)* аерым дуслык сәламнәре тапшырырсың. Эшеңдә уңышлар телим. (Кларaның 500 тәңкәлек кулонына гел карап торма, көнләштерәсең Робертны, чын).

Хат яз.

*Сәлам белән, Аяз.*

*Нияз Даутовның тууына – 110 ел*

# УЛ ЗАМАНДА ОПЕРАЛАР МИЛЛИ ИДЕ

Җырчы, режиссёр, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нияз Даутовның (1913–1986) тууына 110 ел.

Нияз Даутов Казанда ат заводы һәм сафьян эшләнмәләр фабрикасы хуҗасы Курамша Даутов гаиләсендә дөньяга килә. Мәктәпне тәмамлауга авыл мәктәбендә укытучы булып эшли башлый. Тагын берничә елдан Мәскәүгә китеп, заводка гади эшче булып урнаша. Эш урыныннан Балык сәнәгате институтына юллама ала. Балачагыннан ук сәнгатькә гашыйк булып үскән егет студент елларында Мәскәү театрларыннан кайтып керми, шул замандагы иң абруйлы җырчыларның, актёрларның иҗаты белән таныша.

Тиздән кабатланмас матур тавышлы җырчы егет Мәскәү консерваториясе каршында ачылган Татар опера студиясенә кабул ителә. Анда уку чорында Фәрит Яруллин, Муса Җәлил, Нәҗип Җиһанов, Святослав Рихтер, Мстислав Ростропович кебек бөекләр белән аралашу аның өчен үзе бер зур мәктәп була.

1941 елдан Фронт опера театрында хезмәт итә. Нәкъ менә шул вакытта аның җырлавын В.Немирович-Данченко ишетеп ала һәм яшь җырчыны К.Станиславский исемендәге Мәскәү музыкаль театрына солист итеп чакыра.

1943 елда Н.Даутов партия карары белән Свердловск опера һәм балет театрына күчерелә. Биредә ул барлык спектакльләрдә диярлек баш партияләрне башкара. Шулай ук Свердловск киностудиясендә төшерелгән «Сильва» музыкаль фильмында баш рольне – Эдвинны уйный. Әйтүләренә караганда, фильм экраннарга чыгуга актёрга Советлар Союзының барлык кызлары гашыйк була.

Сугыштан соңгы елларда илнең иң мәшһүр театрларында гастрольләрдә була.

Казанда яңа театр бинасы ачылгач, Н.Даутов бирегә иҗат коллективы җитәкчесе итеп чакырыла. Биш елдан соң янә Свердловск, аннары Чиләбе театрларында эшләп ала. Ә инде 1975 елда ул туган шәһәренә бөтенләйгә кайта һәм аның шуннан соңгы гомере М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры белән бәйләнгән. Шул ук елда ул Рәшит Гобәйдуллинның «Җиһангир» операсын сәхнәгә куя һәм ул опера сәнгатенә чын мәгънәсендәге милли юнәлеш бирүче спектакль була.

Илле елга сузылган иҗат гомерендә Н.Даутов ике меңнән артык спектакльдә катнаша, илнең төрле сәхнәләрендә сиксәннән артык опера спектакле куя. Хәйдәр Бигичев, Зилә Сөнгатуллина, Рафаэль Сәхәбиев, Венера Ганиева, Мөнир Якупов, Руслан Дәминов, Клара Хәйретдинова, Сәет Рәинбәков, Айдар Фәйзрахманов кебек дистәләгән затлы шәкертләр тәрбияли.

Журнал укучылар игътибарына тәкъдим ителә торган язма «Казан утлары» сайты өчен махсус әзерләнде. Башта сез радиобыз фондыннан Нияз Даутов чыгышын ишетерсез. Биредә ул 1975 елда «Җиһангир» операсы куелу уңаеннан уй-хисләре белән уртаклашкан. Аннары җырчы башкаруында берничә җыр урын алган. Тапшыруны Гөлназ Ибраһимова алып бара.

*Әзһәр Мөхәммәдиевның тууына – 90 ел*

# АКЧАЛАРДАН ТАРИХ СӨЙЛӘТТЕ

Халкыбыз тарихын өйрәнүгә һәм аны халыкка җиткерүгә биниһая зур өлеш керткән күренекле галим Әзһәр Мөхәммәдиевның (1933–2018) тууына 90 ел тулды.

Булачак галим Башкортстанның Илеш районы Сеңрән авылында туып-үсә. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый.

Татарстан Фәннәр академиясенең рәсми сайтында урын алган мәгълүматларга караганда, Ә.Мөхәммәдиев – нумизматика өлкәсендә танылу алган белгеч. Ул 30 меңнән артык акча һәм борынгы акча төрләрен өйрәнә. VI–XV йөзләрдә Идел буенда һәм Урал алдында акча әйләнешенең чорларга бүленешен эшләп чыгара, дәүләт күләмендә үткәрелгән 10 төрле акча авырлыгы реформасын һәм билгесез тәңкәләрне ачыклый. Дөньякүләм әһәмияткә ия тарихи ачыш ясый. Аның тарафыннан Хәрәзем акчаларына таянып төзелгән Туран алфавиты Идел буенда һәм Урал алдында табылган б.э.к. II – б.э. VIII йөзе акчаларындагы, шулай ук кыйммәтле металлардан эшләнгән савытлардагы һәм бизәнү әйберләрендәге һун язуларын укырга мөмкинлек тудыра. Ә.Г. Мөхәммәдиев антик төрки язмаларны һәм соңрак рун алфавитының нигезе итеп алынган антик туран алфавитын тикшерә. Түбән Идел Сарай әл-Мәхрус, Сарай әл-Җәдид, Бәлҗәмән, шулай ук Иске Казан, Казан Кремле һ.б. шәһәрлек казылмаларында катнаша.

Актив рәвештә укытучылык хезмәтен алып бара. Ватан тарихы, Татарстан тарихы, археология һәм нумизматика буенча лекцияләр укый. Фәндә беренче тапкыр «Төрки-татар (Хәрәзем, Хәзәр, Болгар, Урда, Казан) нумизматикасы», «Алтын Урда шәһәрләре һәм шәһәр мәдәнияте», «Евразиянең борынгы һун-төрки дәүләтләре» дип исемләнгән махсус курслар хәзерли һәм аларны алып бара.

Әзһәр Мөхәммәдиев – Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, тарих фәннәре докторы, профессор. Татарстанның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Галим халкыбызның үткәненә кагылышлы гыйлемне халыкка җиткерү юнәлешендә дә актив эш алып барды. Аның матбугат битләрендә дөнья күргән фәнни-популяр язмалары укучыларыбызның хәтерендәдер әле. Ә инде Татарстан радиосы белән хезмәттәшлеге аерым бер сәхифә булып тора. Узган гасырның 80 нче еллары ахырында радио мөхәррире шагыйрь Әхмәт Рәшит татар халкы тарихына багышланган «Еракка китеп кара» дигән тапшырулар циклы алып барган иде. Аларны Әзһәр Мөхәммәдиев үткәргән тарих дәресләре дип әйтсәк тә ярыйдыр. Хәзер игътибарыгызга әнә шул циклга кергән тапшыруларның берсе тәкъдим ителә. Биредә галим Алтын Урда империясенең таркалу чорында татар халкы һәм аның дәүләтләре кичергән вакыйгаларны бәян итә.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире*
**Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### БӘЙРӘМ

Татарстан халкы, кунаклар Республика һәм Шәһәр көнен зурлап билгеләп үтте. Ватандашларыбызны ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов котлады. Ратушада узган тантаналы җыелышта башкалабызның Мактаулы гражданнарын тәбрикләделәр. Бәйрәм «Милли кием» халыклар костюмнары, «Казан сөлгесе» халык җыр-бию сәнгате, «Казан көзе» опера фестивале, эшче яшьләрнең «Безнең заман» гала-концерты, «Уйнагыз, гармуннар!» флешмобы, ипподромда ат чабышлары, «Казан» гаилә үзәге каршындагы мәйданда зур концерт, салют белән истә калды.

### МӘСКӘҮДӘ ТАТАРСТАН МӘДӘНИЯТЕ КӨННӘРЕ

Мәскәүдә Татарстан мәдәнияте көннәре Габдулла Тукай һәйкәленә чәчәкләр салудан башланды. Аннары Татарстан язучылары белән очрашу булды. Мәскәүдә Татарстан мәдәнияте көннәрен ачу тантанасында ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Мәскәү мэры Сергей Собянин, РФ вице-премьеры Марат Хөснуллин катнашты. Ул көннәрдә Мәскәү тамашачысы Татарстан режиссёры Байбулат Батулланың «Ядәч! Истә!» фильмын карады. Фильмның авторлары, анда уйнаган артистларның чыгышларын тыңлады. Мәскәүдә Татарстан мәдәнияте көннәре Муса Җәлил һәйкәленә чәчәкләр салу белән тәмамланды.

### БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ СЫЙФАТЫН КҮТӘРЕРГӘ

Казандагы Б.Рәмиев исемендәге IT-паркта мәгариф хезмәткәрләренең һәм фән эшлекләренең август киңәшмәсе булып узды. ТР мәгариф министры Илсур Һадиуллин чыгышында узган уку елына йомгак ясады, мәгариф системасында өстенлекле юнәлешләргә, яңа стандартларга тукталды, якын арада хәл итәсе проблемаларны билгеләде. Август киңәшмәсенең пленар утырышында Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты. Ул бер төркем мәгариф хезмәткәрләренә һәм фән эшлекләләренә дәүләт бүләкләрен тапшырды. ТР Рәисе карары белән укытучылар өчен 36 мең ноутбук сатып алынган. Утырышта ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев катнашты.

### ТАТАРЛАРНЫҢ КАҺАРМАНЛЫГЫН ИСКӘ АЛУ

Казандагы 1 Май мәйданында фашист төрмәсендә җәзалап үтерелгән Муса Җәлил һәм җәлилчеләрне искә алу мәрәсиме (сценарий авторы Фәрдия Сәфәргалиева) булды. Анда Казан шәһәре башкарма комитеты рәисе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова, Татарстан һәм Башкортстан Язучылар берлекләре рәисләре урынбасарлары Илсөяр Иксанова белән Тәнзилә Дәүләтбирдина, галим Искәндәр Гыйләҗев, Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, шагыйрә Дания Нәгыйм, М.Җәлилнең кызы Чулпан Җәлилова һ.б. чыгыш ясадылар. Искә алу мәрәсимендә Георгий Ибушев, Гөлнара Байназарова (җыр), Геннадий Максимов (баян), Камилә Сәйфуллиналарның (скрипка) җыр-моңнары яңгырады. Чараны Илдар Кыямов алып барды.

### РОБЕРТ МИҢНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА – 75 ЕЛ

Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, җәмәгать эшлеклесе Роберт Миңнуллинның тууына 75 ел тулу уңаеннан бер төркем каләм ияләре, галимнәр, киң җәмәгатьчелек вәкилләре, туганнары Казанның Тынычлык бистәсе зиратында әдипне искә алды, каберенә чәчәкләр салды. Аның рухына дога багышланды. Роберт Миңнуллин 2020 елның 27 мартында 71 яшендә вафат булды. Мәрхүмнең кабер ташына «Шигырьләремнән табарсыз, бик кирәк булсам» – дигән сүзләре язылган. Искә алу мәрәсимендә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе Зилә Вәлиева, ТР Рәисе каршындагы Мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды директоры Нурия Һашимова, ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, Роберт Миңнуллинның хатыны Клара ханым, кызы, Р.Миңнуллин исемендәге фонд директоры Таңсылу Сабирова һ.б. чыгыш ясады. Искә алу мәрәсимен Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, әдипнең бертуган энесе Ким Миңнуллин алып барды. Шагыйрьне искә алу Роберт Миңнуллин исемендәге Республика балалар китапханәсендә дәвам итте. Каләмдәшләре, дуслары, әдипнең

иҗатын яратучылар, туганнары Р.Миңнуллин турында якты хатирәләрен, матур истәлекләрен уртаклаштылар.

***

Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә Роберт Миңнуллинның тууына 75 ел тулу уңаеннан «Яшәргә икән, яшәргә» дип аталган зур концерт булды. Анда республикабызның җыр сәнгате осталары әдип сүзләренә язылган җырларны җырладылар.

* * *

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте бинасы каршында «Роберт Миңнуллинга багышланган Сабантуй» булды. Аны «Сабантуй» журналы редакциясе (заманында Р.Миңнуллин монда эшләде) оештырды. Мәйданда әдипнең шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады. Балалар өчен төрле ярышлар, уеннар үткәрелде.

## ӘДӘБИ САБАНТУЙ

Апаста «Әдәби Сабантуй» булып узды. Чара бүләк җыю күренеше белән башланды. Кунакларны Апас районы башлыгы урынбасары Данис Сәйфетдинов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Татнетны үстерү фонды җитәкчесе Раил Гатауллин, меценатлар бизнес берләшмәсе рәисе Ильяс Гыймадов һ.б. сәламләде. Бәйрәмдә быелгы әдәби марафонда җиңүчеләрне бүләкләделәр. Әдәби көрәшчеләрнең эшләрен Газинур Морат, Илсөяр Иксанова, Раил Гатауллин составындагы жюри бәяләде. Җиңүче – Санкт-Петербургтан биология һәм химия укытучысы Рәсимә Фатыйхова. Ул финалда Чаллыдан Энҗе Әхмәтҗанова һәм Мөслим районыннан Равилә Шәрифуллина белән көч сынашты. Әдәби Сабантуй концерт, милли уеннар белән үрелеп барды. Бәйрәмдә бер төркем язучылар катнашты.

## «ГАШЫЙКЛАР ТАВЫ» ФИЛЬМЫ ТӨШЕРЕЛӘ

«Татаркино» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевның «Гашыйклар тавы» әсәре буенча фильм төшерергә җыена. Бу уңайдан кастинг үткәрелде. Анда барлык катнашучыларның татар телендә камил сөйләшүе шарт итеп куелды. Илдар Юзеев «Гашыйклар тавы» әсәрен 1985-1986 елларда язды. Ул тамашачыларның яраткан спектакльләренең берсе иде. 2014 елда К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында кабат куелды. Кинофильм өчен сценарийны И.Юзеевның улы Салават Юзеев язды. Фильмны да ул төшерәчәк.

## БЕР ПЬЕСАДАН – ИКЕ СПЕКТАКЛЬ

Яңа сезонда Г.Камал һәм Әлмәт театрларында Ркаил Зәйдулланың «Хан һәм шагыйрь» пьесасы куелачак. Рамил Гәрәев сәхнәләштерәчәк «Игезәк» дип аталган спектакльне Г.Камал театры ноябрь аенда чыгарса, Әлмәт театры март-апрель айларына планлаштыра.

## АЛТАЙГА СӘФӘР

Язучылар Марсель Галиев белән Рафис Корбан Таулы Алтай Республикасында сәяхәттә йөреп кайттылар. Атна буена алар Алтайның гүзәл табигате, таулары, елга-күлләре, үсемлекләр дөньясы белән танышкан арада Республиканың Язучылар берлегендә, китап нәшриятында, узган ел чыга башлавына 100 ел тулган «Алтай чулпаны» газетасы редакциясендә каләм ияләре, наширләр белән очраштылар. Сәяхәтчеләрне Алтай халык шагыйре Кулер Тепуков озатып йөрде. Былтыр К.Тепуков Габдулла Тукай шигырьләрен алтай теленә тәрҗемә итеп, «Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен» дигән китап бастырып чыгарган иде. Казан кунаклары аңа бу изге эше өчен рәхмәт йөзеннән ТР Мәдәният министрлыгының «Мәдәнияттәге казанышлары өчен» күкрәк билгесен тапшырдылар.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Әдәбият галиме, филология фәннәре докторы, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының бүлек мөдире **Әлфәт Закирҗанов**ка «Татарстанның атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе **Фәйзуллин Равил Габдрахман улы** «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы» төзелүгә 100 ел» медале белән бүләкләнде.

2023 елның 18 августында 96 нчы яшендә ТР Фәннәр академиясе академигы, филология фәннәре докторы, профессор, Россия лингвистика фәннәре академиясе академигы, РФ һәм ТРның атказанган фән эшлеклесе, фән һәм техника өлкәсендә ТРның Дәүләт премиясе лауреаты **Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Казанда, Самосыроводагы Мөселман зиратында җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: рассказ Ш.ИДИАТУЛЛИНА «Тубагач»,
роман-эссе Р.КУРБАНА «Лишние люди», роман Г.ГИЛЬМАНОВА «Искушение дьявола»;
стихи Л.ЛЕРОНА, А.СИТДИКОВОЙ, Л.ВАЛИЕВОЙ.
«Литература народов мира»: стихи Р.ГАМЗАТОВА в переводе Р.КУРБАНА.
«Литературный конкурс «Учитель – прекрасный человек на земле!»:
рассказ К.КАРА «ЧТД».
«Новые имена»: рассказ Г.САФИУЛЛИНОЙ «Две крупинки».
Фотоархив, посвящённый 100-летию Л.Ихсановой, 90-летию В.Ихсановой.
«2023 год – год дастанов»: статья Л.МУХАМЕТЗЯНОВОЙ; вариант дастана
«Идегей», записанный А.Ходзько.
«Юбилеи»: статья А.ШАРИПОВА к 85-летию Р.Юсупова.
«Литературная критика»: статья Л.ДАВЛЕТШИНОЙ.
«Памятные письма»: письма А.Гилязова М.Галееву.
«Бесценные голоса»: статьи к 90-летию А.Мухамадеева и 110-летию Н.Даутова.
Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: улица Петербургская г. Казани. Фото И.АБРАМОВОЙ;
лингвист, лексикограф Р.Сафаров. Фото Ф.ЗАКИРЗЯНОВОЙ.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: story by Sh.IDIATULLIN «Tubagach»,
novel-essay by R.KURBAN «Superfluous people», novel by G.GILMANOV « The Devil's
Temptation»; poems by L.LERON, A.SITDIKOVA, L.VALIEVA.
«Literature of nations of the world»: poems by R.GAMZATOV translated by R. KURBAN.
Literary competition «Teacher is a wonderful person on earth!»: story by K.KARA.
«New Names»: story by G.SAFIULLINA «Two Grains».
Photo archive dedicated to the 100th anniversary of L.Ikhsanova,
90th anniversary since V.Ikhsanova birth.
«2023 is the year of dastans»: article by L.MUKHAMETZYANOVA;
version of the dastan «Idegey», written down by A.Khodzko.
«Anniversaries»: article by A.SHARIPOV on the 85th anniversary of R.Yusupov.
«Literary criticism»: article by L.DAVLETSCHINA.
«Memorial Letters»: letters by A.Gilyazov to M.Galeev.
«Priceless voices»: articles on the 90th anniversary of A.Mukhamadeev and
the 110th anniversary of N.Dautov. The rubric is led by N.AKMAL.
Diary of social and cultural life.
On our covers: Peterburgskaya street in Kazan. Photo by I.ABRAMOVA;
linguist, lexicographer R.Safarov. Photo by F.ZAKIRZYANOVA.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Казанның Петербург урамы. *И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* тел галиме, сүзлекче Ринат СӘФӘРОВ.
*Ф.ЗАКИРҖАНОВА фотосы.*